# КАЗАН УТЛАРЫ

3.2003





Әхмәт Фәйзи

1903—1958

# Казан утлары
# Qazan utları

2003

3

(965)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Салих Маннапов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Альбина Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.
Факс — 43-56-12., E-mail: kazanutlari@telebit.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Әхмәт ФӘЙЗИ. Тышта яз. *Шигырь* ... 5
Марат ӘМИРХАНОВ. Тояк эзе. *Роман* ... 6
Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Яңа шигырьләр ... 58
Рәшит ИБРАҺИМОВ. Очучы язмалары ... 64
Рашат НИЗАМИ. Вакыт агачы. *Шигырьләр* ... 87
НУРЗИЛӘ. *Хикәяләр* ... 92
Фирая ЗЫЯТДИНОВА. Тынма, җаным. *Шигырьләр* ... 102
Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА. Өр-яңа әкият. *Шигырьләр* ... 106
Ольга ЛЕВАДНАЯ. Юка бозда миннән эз дә калмас... Шигырьләр ... 109
Рәшит ГАРИФ. Ак манара. *Шигырьләр* ... 122

**ДӨНЬЯ ӘДӘБИЯТЫ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ**

Агата КРИСТИ. Гаепләүче шаһит. *Хикәя* ... 112

**ӘДӘБИ МИРАС**

Мәхмүт ХӘСӘНОВ. Бичура җинги. *Хикәя* ... 125

**«МӘГАРИФ» ЖУРНАЛЫНА 90 ЕЛ**

Фәрит ШӘРИФУЛЛИН. Үткән елларга бер күз салсак ... 143

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Хәзинәдә—алтын бөртекләре ... 149
Фәрит БӘШИР. Кеше күңеле—карурман ... 154

**СӘНГАТЬ**

Шамил МОНАСЫЙПОВ. Батырлыкка сусау ... 158

Корьән татар телендә ... 170

**ӘХМӘТ ФӘЙЗИНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ**

Әхмәт ФӘЙЗИ. Төрле еллардан шигырьләр ... 175

**ЮБИЛЕЙЛАР**

Лирон ХӘМИДУЛЛИН. Осталарның остазы ... 177
Илдар ЮЗЕЕВ. Язучы, тәрҗемәче С. Ибраһимовага 75 яшь ... 181
Рөстәм АКЪЕГЕТ. Көндезге йолдызлар ... 182
Үткәнне киләчәккә ялгаучы ... 184

«Казан утлары» архивыннан ... 186

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 190

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: М. АМИРХАНОВ. Роман «Следы копыт» *(окончание)*; «Записки летчика» Р. ИБРАГИМОВА; рассказы НУРЗИЛИ; стихи А. ФАЙЗИ, Р. ФАЙЗУЛЛИНА, Р. НИЗАМИ, Ф. ЗИЯТДИНОВОЙ, Ф. ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ, О. ЛЕВАДНОЙ, Р. ГАРИФА.
«Из классики мировой литературы»: рассказ А. КРИСТИ «Свидетель обвинения».
«Литературное наследие»: рассказ М. ХАСАНОВА.
«К 90-летию журнала «Магариф»»: статья Ф. ШАРИФУЛЛИНА «Взгляд на прошлое».
«Книжное обозрение»: Ф. ГАРИПОВА рецензирует новую книгу Р. Амирхана и Ф. БАШИР—поэтический сборник Ф. Гиззатуллиной.
«Искусство»: статья Ш. МОНАСЫПОВА посвящена творчеству композитора Р. Белялова.
Коран на татарском языке.
«Юбилеи»: в номере отмечаются 100-летие А. Файзи, 90-летие Ш. Зайни, 75-летия Р. Даутова, С. Ибрагимовой, 70-летие Т. Набиуллина, 60-летие Р. Юнуса.
Новые члены союза писателей Татарстана.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Средневековая Казань; поэтесса Х. Мударисова.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and poetry": M. AMIRHANOV´S novel «Hooves scents» *(ending)*; «Pilot´s notes» R. IBRAGIMOV, NURZILYA´S stores; verses of A. FAYZI, R. FAYZULLIN, R. NIZAMI, F. ZYATDINOVA, F. ZAMALETDINOVA, O. LEVADNAYA, R. GARIF.
"From classic of word literature": A. KRISTY´S story «Witness accusation».
"Literary legacy": M. HASANOV´S store.
"Commemorating the 90th anniversary of "Magarif" journal": F. SHARIFULLIN´S article «View on the past».
"The book´s review": F. GARIPOVA reviews the new book R. Amirkhan´s and F. BASHIR - the poetic collection of F. Gizzatullina.
"Art": Sh. MONASYPOV´S article devotes the works of composer R. Belyalov.
Koran in Tatar language.
"Jubilees": in this issue mentions 100th anniversary of A. Fayzi, 90th anniversary of Sh. Zayni, 75th anniversary of R. Dautov and S. Ibragimova, 70th annivarsary of T. Nabiullin, 60th anniversary of R. Yunus.
New members of Tatarstan´s writers union.
The diary of social and cultural life.
On our covers: Mid century Kazan; poet KH. Mudarisova.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмахананең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 18.02.2003 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8031. Заказ Я—76
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2003 ел.

## Әхмәт Фәйзи

*

Тышта яз... Мин боегып өйдә утыра идем,
Илһамымны көтеп, сагынып яшьлегемне,
Кинәт шунда тәрәзәләр тетрәп куйды:
Әллә кайсы какты минем ишегемне.

«Илһам!» дидем, сикереп тордым урынымнан,
Кабаланып, барып ачтым ишекне мин,
Берәү дә юк!.. Фәкать минем өй турыннан
Ераклашкан күкрәү тавышын ишеттем мин.

Һәм күрдем мин ерак яшен чаткыларын
Киң офыкның бер буеннан бер буена,
Алар мине яннарына чакыра иде:
—Чык бүлмәңнән, әйдә, безнең белән уйна!

Син җуймадың яшьлегеңне, ул—яныңда,
Ишетәсеңме, сине чакырып ишек кага?
Чык урамга, кырга, төзелеш мәйданына!
Чык яшьлегең дәшкән бөек тантанага!

*1947*

## Марат Әмирханов

# ТОЯК ЭЗЕ

РОМАН

* * *

Мәҗлес Сафия Имре йортында үтәргә тиеш икән. Исмәгыйль шулай диде. Аннан соң: «Сез бик шәрәфле галимебез ахры, Сафия ханым-әфәнде үз өендә кунаклар хөрмәтенә бик сирәк мәҗлес җыя»,—дип тә өстәде. Хәтта мөгамәләсе үзгәрде. Ул инде Кәшшафка хуҗасына караган хезмәтче малай кебек карый иде. Ә үзе чакырулы түгел.

—Сезне, әфәндем, Җансай Хаммат бәй үзе кереп алачак, әзерләнә торыгыз, мина башка эш куштылар,—диде Исмәгыйль Гаяз Исхакыйга зиярәт кылып кайткач.

Кәшшаф күңеле белән һаман каберлектә иде. Ул бу олпат татар зыялысының бөеклеген бөтен тулылыгы белән зиратта гына аңлады. Үз халкыннан кадер-хөрмәт күрмәгән бер бичара. Әмма соңгы сулышына кадәр халкым дип авыз суын корыткан милләтпәрвәр зат. Кызганыч, Кәшшаф аның иҗатын бик аз белә. Кәшшаф кынамы? Тулы бер буын мәхрүм калды. Инде капкалар ачылды. Яна буын кабул итәрме Исхакыйны? Ул үз чорында гына утырып калмасмы? Теләнче кызларның, сөннәтче бабайларның хаҗәте калырмы? Өзелгән чылбырны ялгау, ай-һай, бик авыр вазифа.

Төркиягә рәхмәт, күпме үксез татар зыялыларын сыендырган ул. Сыендыру гынамы, иҗат итәргә, тормыш дулкынының иң өстендә йөзәргә мөмкинлек биргән. Гаяз Исхакый, Садри Максуди, аларның күренекле кызлары филолог һәм тарихчы Сәгадәт Чагатай, мәшһүр дипломат һәм сенатор Әдилә Айдә, Йосыф Акчура, Рәшит Рәхмәти, Абдулла Баттал, Әкъдәс Курат, Хәмит Зөбәер, Әхмәт Тимер... Болар бит барысы да татарның асыл егет солтаннары.

Кәшшаф сәгатенә күз төшерде. Кичке бишләр якынлаша иде инде. Димәк, тиздән Хаммат килеп җитәчәк. Мәҗлесне алтыда диделәр. Кызык, ничек үтә икән монда мәҗлесләр?

Ул уйларын уйлап бетерергә өлгермәде, ишек шакыдылар. Йөгереп

---

Ахыры. Башы 1-2 саннарда.

барып ишекне ачты. Анда искиткеч ыспай гәүдәле Җансай Хаммат басып тора иде.

—Үзе чакыра, үзе кача булып чыкты әле бу, Кәшшаф әфәнде...

Җансай, һәрвакыттагыча, чәчләрен учы белән маңгай читенә сыпырып төшерде.

—Кочаклашыйк, әйдә, тәртибенә китерик,—диде. Алар ирләрчә бер-берсенең аркасына суккалый-суккалый кочаклашып алдылар.

—Төркия ничек, ияләшәсезме?—дип сорады Җансай.

—Минем чит илләргә чыкканым юк иде әле, бөтенләй үзгә дөнья икән.

—Калганын юлда сөйләшеп бетерербез, Кәшшаф әфәнде, кузгалыйк,—диде Хаммат,—София ханым төгәллекне ярата.

Кәшшафның үзенең дә машинасы бар, стажлы шофер. Ләкин мондагы урам хәлләре Казандагы белән чагыштыргысыз. Юл тасмасыннан бер якка гына берьюлы биш-алты рәт машина элдертә. Юллар көзге шикелле, шоп-шома. Аларның унайлыкларына машинада йөреп кенә бәя бирергә мөмкин. Күзенне йомсаң, машина бер урында туктап тора кебек тоела, ник бер селкенеп карасын. Күзенне ачсаң—мәхшәр! Алда да машина, артта да машина, уңда да, сулда да, выж да выж килеп торалар.

Җансай куркып-өркеп тормый, машиналар арасыннан еландай боргаланып кына үтеп китә. Куркыныч. Шуңа күрә Кәшшаф спидометр угына күз ташламаска тырышты. Дусты аның хәлен сизде ахры:

—Мин тизлек рәтеннән барам, йөздән киметергә ярамый,—дип аңлатма бирде.—Машиналарны узарга да рөхсәт ителә.

Ниһаять, шәһәр үзәге артта калды. Машина көтүе сирәгәйде. Бераздан магистральдән читкә борылдылар. Машина кылт та итмәде, шундый ук тигез юл. Ян-якта утарлар тезелешеп киткән. Җансай шуларның берсенә борын төртте. Тирә-ягы ал да гөл, хәтта агач-куакларга кадәр шау чәчәктә утыра.

Йорт яны бакчасын шушы дәрәҗәдә тәртиптә тотып буладыр дигән уй монарчы Кәшшафның башына кереп тә караганы юк иде. Болар аның әнисен дә уздырып җибәргәннәр. Башта юл шаккатырган иде, инде бакча. Театр сәхнәсендәге шикелле һәр нәрсә үз урынында, ник бер артык ботак тырпаеп торсын, ник берәр чүп үләне күренсен? Бу шомалыкны хәтта күнел кабул итеп тә бетерми. Табигать ниндидер бер кыргыйлыгы, тәртипле тәртипсезлеге белән аерылып торырга тиештер, мөгаен.

Машина янына: «Хуш килдегез, рәхим итегез»,—дип, озын буйлы бер яшь егет килеп басты.—Ачкычыгызны урынында калдырыгыз, Җансай бәй, машинагызны үзем урнаштырырмын.

Ак мәрмәр баскыч янында икенче хезмәтче басып тора иде. Өйгә ул алып керде. Бай икән Әхмәтвәли агайның кызы, дип уйлап куйды Кәшшаф. Ул инде «Әхмәтвәли Мәнгәр» ширкәтенең тарихы белән дә таныш иде. Әлеге ширкәт 1948 елда Төркия белән Алманиянең хезмәттәшлеге нәтиҗәсендә корылган «Мерседес-Бенц» һәм «Бош» дигән автобуслар, шулай ук йөк машиналары эшләп чыгара торган бөтен дөньяга таныш ширкәт санала. Анда эшләнгән машиналарны хәзер Казан урамнарында да күрергә була. Әхмәтвәли Мәнгәр егерме елдан артык, 1978 елга чаклы, ягъни үлгәнчегә кадәр ширкәт белән җитәкчелек итә. Садри Максуди Мәнгәр турында: «Сәүдә даһие булып саналырга лаек»,—дип язып калдырган. Аннан соң дилбегәне кызы София белән кияве Иззәт үз кулларына ала. Иззәт Имре дә вафат икән инде. Хәзер ширкәт уллары Эргин карамагында. София Имре исә вакыф эшләре белән генә мәшгуль диделәр.

Аларны бүлмә эчендә түгәрәк йөзле, кыска чәчле, җыйнак кына гәүдәле, искиткеч мөлаем ханым каршы алды. Чыраенда—тыйнак елмаю. Тешләре сөт кебек ап-ак.

Алтынны пычракка салсаң да алтын булып кала. Бу ханым да теләсә-нинди киемдә дә, теләсә-нинди шартларда да менә шушылай энҗе кебек ялтырар иде.

—Танышыйк, мин Сафия Имре булам,—дип хуҗа хатын иң беренче булып Кәшшафка үзенең кечкенә нәфис кулын сузды. Кәшшаф бер генә мизгелгә каушап калды: кулын үбәргәме бу ханымның, әллә күрешү белән генә чикләнергәме? Төркиянең мөслимәсе үбүне кабул итәрме? Үпмәсән, гаепкә санаулары ихтимал. Европа стилендә яшиләр ич. Һәм бу кулны болай озак итеп татып тору шулай ук килешә торган эш түгелдер, мөгаен. Ни булса, шул булыр дип, Кәшшаф иреннәрен әлеге ымсындыргыч ак кулга тигезде. Кул кайнар иде, кош баласы шикелле талпынып куйды.

—Кәшшаф әфәнде тарихчы галим, Казанның гуманитар институтында эшли,—дип Жансай Хаммат Кәшшафны рәсми рәвештә тәкъдим итте. Кунаклар белән Сафия Имре үзе таныштырды.

—Гөлчәчәк Зыялы ханым-әфәнде. Музыкант, җырчы.

—Сәлиха Гомәр ханым-әфәнде. Журналист, китап белгече.

—Гөлчи ханым-әфәнде. Минем кызым.

—Мәхмүт бәй Алукәй, ярдәмчем...

Хатын-кызлар барысы да озын итәкле, озын җиңле кичке күлмәктән иде. Гөлчәчәкнең генә аркасы биленә кадәр ачык. Тик ул әллә ни күзгә ташланмый, чөнки җилкәсенә җиңел шарф япкан.

Бүлмә иркен иде. Җиһазның кирәклесе генә. Берничә йомшак диван, берничә кәнәфи, тәбәнәк өстәл, аяклы яктырткыч. Нәкъ уртада—зур рояль.

Иң купшы урын монда аяк асты икән. Идән тулы калын, затлы келәм, басуга аяклар батып китә. Түр стенада—зур фото.

—Әтием Әхмәтвәли белән әнием Гәйшә,—диде Сафия ханым.

—Бик күркәм булганнар икән әти-әниегез,—дип мактау сүзләре әйтте Кәшшаф.

—Искиткеч нурлы иделәр.

Утырыштылар.

—Гөлчәчәк ханымның җырлавын тыңларга тәкъдим итәм,—диде Сафия ханымның кызы Гөлчи. Бу мәҗлеснең башлануы иде булса кирәк.

—Сорыйбыз, сорыйбыз,—дип, кулларын чәбәкләде кунаклар.

Гөлчәчәккә мандолина китереп тоттырдылар. Гәүдәсе калынрак булса да, Гөлчәчәк бик килешле ханым. Йөзе дә, буй-сыны да үзенә тартып тора.

Җилкәләренә кадәр салынып төшкән куе кара чәчләрен рәтләгәндәй итте дә Гөлчәчәк мандолина кылларына чиртеп алды. Бүлмә эче үзенә бер мавыктыргыч аһән белән тулды.

Күбәләк гөлләргә кунса,
Гөлләр тибрәнә микән?

Гөлчәчәк тамак төбе беләнрәк, карлыкканрак тавыш белән җырлый. Көйнең бормаларына озаклап тукталып тормый, шомартыбрак уза. Ә моны барыбер йөрәккә ята. Башкару манерасының шушы үзенчәлеге җырның асылын көнчыгышның сузынкы мелодиясенә охшатып җибәрә. Гадәти башкаруда әлеге җыр яктылыгы, җиңеллеге, җорлыгы белән аерылып тора. Гөлчәчәк исә аңа сагыш тамчыларын да тамызып-тамызып ала, гүя тыңлаучыларга адашкан күбәләк кыйссасын житкерә.

Имеш, җиһанның гүзәлләрдән-гүзәл бер төбәгендә күбәләкләр мәмләкәте яшәгән, ди. Табигате искиткеч матур икән. Болынлык. Болынлык уртасында—көмеш сулы түгәрәк күл. Тирә-якта аллы-гөлле чәчәкләр. Күбәләкләр шул чәчәкләр арасында гомер кичергәннәр.

Әлеге мәмләкәттән ерак та түгел, иләмсез биек таш-кыялы тау өстендә Зилзилә атлы җилбикә көн күргән. Ул күбәләкләрнең бәхетле тормышыннан бик көнләшкән, һәм, ачуына чыдый алмыйча, бер иртәдә күбәләкләр мәмләкәтенә һөҗүм итеп, аларны тар-мар итеп бетергән, үзләрен күз күрмәгән, колак ишетмәгән җиргә олактырган.

Күбәләкләр туган илләрен сагынып, саргаешып беткәннәр. Берничә

мәртәбә кайтырга да омтылып караганнар. Тик юлга чыгуга, миһербансыз Зилзилә килеп җитә икән дә, тагын башка урынга сөрә икән.

Күбәләкләр әле һаман да илдән-илгә күчеп, адашып йөриләр ди.

...Кәшшаф бүлмәдәгеләрне күзәтә. Җансай кәнәфиенә сеңеп беткән. Сафия ханым яшьләрен яшерми дә, корытмый да. Сәлиха Гомәр җырның берәр хәрефен төшереп калдырмасам ярар иде дигән шикелле муенын сузып, колакларын шәмдәй торгызып тынлый. Аның юка гәүдәсе әледән-әле дерелдәп куя.

«Күбәләгем» җыры бу бүлмәдә еш яңгырый, ахры. Һәрберсе аңа үз мәгънәсен салып тынлый.

Гөлчәчәк тагын берничә җыр җырлады. Ләкин берсе дә «Күбәләгем» биеклегенә күтәрелә алмады.

Кәшшаф Гөлчәчәк алдында да үзенең егетлеген күрсәтергә булды, алдына тезләнеп, кулын үпте. Бу барысына да ошады. Казан егетен мактап, гөрләшеп алдылар.

—Кызганыч, ходай миңа сәнгати сәләт бирмәгән, Казан егетләре минем алдыма да килеп тезләнерләр иде,—дип шаяртты Сафия ханым.—Безнең Сәлихабыз да музыка уйный бела.

Сәлиханың басынкы холыклы икәнлеге йөзенә чыккан, оялып кына башын иде. Монда һәрберсе үзе хакында сүз әйтүчегә рәхмәтен белдереп, ихтирам белән башын ия.

Фортепианода уйнаганда Сәлиха бөтенләй үзгәреп китте. Гәүдәсе турайды, кыюланды, күзләренә очкын кунды. Туры килсә дә килер икән, ул Салих Сәйдәшевнең Кәшшаф яраткан көйләрен башкарды. Иң элек «Әдрән диңгез» яңгырады, аннан соң «Көнчыгыш биюе» сюитасы. Бу көйләр фортепиано өчен махсус эшкәртелгән иде. Күңелгә хисләр өермәсе бәреп керде.

Кәшшафның күз алдыннан Батый ханнар, Идегәйләр, Айтулылар, Йолдызлар үтте.

—Афәрин, Сәлиха ханым!

—Бәрәкалла!

Бу юлы каршысына тезләнеп, башкаручының кулын Җансай үпте.

—Ашханәгә рәхим итегез,—диде Сафия ханым. Аның күзләрендә һаман яшь иде.

Кәшшаф мул табын көткән иде. Бу исә дипломатик кабул итүләрдәге кебек этикет өстәле булып чыкты. Кайнар аш юк, кабымлыклар гына. Ә ассортимент бай. Җиләк-җимеше дә, тәм-томы да, уылдыгы да—һәммәсе бар. Шунда ук савыт-саба, чәнечке, кашык, пычак. Нәрсә телисең, шуны салып аласың да, баскан килешме, йөренепме, утырыпмы ашыйсың.

Кәшшаф Казаннан алып килгән күчтәнәч чәкчәкне үзенә бер кечкенә түгәрәк өстәлгә куйганнар. Иң элек барысы да шуны авыз итеп карады.

—Гаяз абый сагына иде Казан чәкчәген,—дип искә алды Сафия ханым.—Әни дә пешерә иде. Тик болай ук тәмле булмый иде. Күрәсең, Төрек җирендә Татар чәкчәген җиренә җиткереп пешереп булмыйдыр. Ходайның хикмәте, мин булып мин дә шушы аерманы тоям бит. Югыйсә, Кытайда дөньяга килгәнмен, Япония, Америка, Польша, Алмания илләрендә яшәдем. Алман лицеенда укыдым, «Фридрих Шлегель иҗатында хатын-кыз проблемасы» дигән темага диссертация якладым. Инглиз, француз телләрен өйрәндем. Бер мәртәбә дә ата-бабаларыбыз җирендә булганым юк. Ә менә Казан чәкчәгенең тәмен башка бер тәм белән дә буташтырмыйм. Алай гынамы, мин үзем бервакытта да күрмәгән арыш басулары, бәрәңге бакчалары, кар көртләре төшемә керә...

Сафия томырылып Кәшшафка карап алды. Ханым аннан өлкәнрәк, оныклары да бар икән инде. Ә нинди мөлаем, үзе япь-яшь күренә. Теләсә кемне гашыйк итәрлек.

—Сафия ханым, сезнең ирегез бик бәхетле булгандыр,—диде Кәшшаф.

Сафия ханымның күнеленә әлеге комплимент бик хуш килде. Йөзе балкып китте. Күзләре генә түгел, сөрмә тарткан озын керфекләренә кадәр елмая иде аның.

—Рәхмәт, Кәшшаф әфәнде, жылы сүзегезгә...

Өзелгән әңгәмәне Сәлиха ханым ялгап жибәрде.

—Сәгадәт апа вафат булгач, Исхакыйларның тамыры корыды,—дип офтанды ул.—Соңгы көннәрендә авыр яшәде Гаяз абый. Үзе мичкә якты, үзе чәй әзерләде...

—Алай димә,—дип каршы төште аңа Сафия ханым,—Гаяз Исхакый бик бай мирас калдырды.—Бу тамырлар түгелмени?

—Мәрхәбә, мин икенчерәк мәгънәдә әйткән идем...

Жансай әңгәмәне тагын да конкретлаштырырга теләде булса кирәк: «Кәшшаф әфәнде, Казанда Гаяз Исхакыйның жәсәден туган иленә алып кайтып күмү турындагы сүзләр һаман дәвам итәме?»—дип сорады.

Игътибар Кәшшафка юнәлде. Аның, билгеле, бу сүзләрне ишеткәне бар, нигездә алар жете кызыл милләтчеләр авызыннан чыга. Ә аның үзенең бу хакта тәгаен генә фикере юк иде әле. Шуна күрә хужаларны рәнжетми торганрак жавап табарга тырышты.

—Бу бик катлаулы мәсьәлә,—диде,—моны аяк өстен генә хәл итәргә ярамый дип беләм.

—Фу, мәетләр турында сөйләшмик әле,—диде Гөлчәчәк,—жырлыйк без бүген, хәзер кунак бүлмәсеннән мандолинамны гына алып керәм дә...

Ул тырт-тырт басып ашханәдән чыгып та китте.

—Безнең Гөлчәчәк шундый инде ул, кош кебек очып кына йөрергә күнеккән,—диде Сәлиха,—житдилекне сөйми.

—Гаяз Исхакыйның туган иленә жәсәде кайтмаса, мирасы кайтачак,—дип сүзгә Мәхмүт Алукәй кушылды.—Шулай бит, Сафия ханым-әфәнде?

Ул Гаяз Исхакыйның гәүдәсе Төркиядә калырга тиеш дигән фикердә тора иде.

Сафия белән Алукәй бер-берсенә карашып алдылар, әйтерсең лә, ниндидер серләре бар иде. Сафия ханым чәшкесеннән бер йотым кофе эчеп куйды да инде баядан бирле әтәч булып кыткылдап чыгарга торган әлеге серен чиште.

—Ханым вә әфәнделәр,—диде ул зур мөнбәрдән чыгыш ясагандай рәсми күтәренкелек белән,—сез Мәңгәр вакыфының күренекле язучыбыз һәм жәмәгать эшлеклесе, татар халкының сөекле улы Гаяз Исхакыйның шәхси архивын үзенә алырга ният итеп йөргәнен беләидегез инде. Ниһаять, бу ният тормышка ашты! Мәхмүт бәй барлык рәсми кәгазьләрне дә әзерләде, кул куелды...

Сафия ханымны уратып алып, кул чабарга тотындылар.

—Мәрхәбә!

—Сөбханалла!

—Урының ожмахта булгыры...

—Сабыр, жәмәгать, сабыр,—дип Сафия нәфис ак кулын югары күтәрде.—Мин әле иң мөһимен әйтмәдем.

—Рәхим итегез, Сафия ханым-әфәнде,—диде Алукәй.

—Вакыф Гаяз Исхакыйның шәхси архивын Казанга кайтарырга карар кылды.

Янә кул чабулар, котлау, сәламләүләр ишетелде.

—Аллаһы насыйп итсә, әлеге кыйммәтле мирасны Татарстан Президентына үзем тапшырырмын дип торам, берочтан Казаныбызны да күрермен,—диде Сафия ханым.

Ул арада яна туган ай кебек балкып бүлмәгә Гөлчәчәк әйләнеп керде.

—Күбәләк, күбәләк,—диештеләр ханымнар.

Бүлмә янә күкрәк астыннан чыккан йөрәк өзгеч моң белән тулды.

Мандолина кыллары аңа ниндидер чарасызлык та өсти, гүя тәкъдиргә буйсынырга өнди иде.

Очып барып кайтыр идем,
Күбәләгем, түгәрәгем...

—Без адашкан күбәләкләр инде,—диде Сафия ханым. Кәшшаф сискәнеп китте. Күр, ничек фикерләре тәңгәл килә. Җырның беренче авазларын ишетүгә үк аның да күз алдына адашкан күбәләкләр турындагы риваять килеп баскан иде ич.

Зыялы катламга хас милли гореф-гадәтләр монда ата-бабаларыбыз чорындагыча, бозылмыйча сакланган. Бу бер-береңә булган мөнәсәбәттә генә түгел, тормышны көйләү, алып бару фәлсәфәсендә дә, югары катлам—түбән катлам иерархиясендә дә бик нык чагыла. Кәшшафка иң ошамаганы, хезмәтчеләрнең түбәнсенүле ялагай карашлары булды. Монда моңа гадәти хәл дип карыйлар, һәр кешенең җәмгыять баскычында үз урыны бар. Аның үз-үзен тотышы да шуннан чыгып тәгаенләнә, күрәсең.

Тагын бер гаҗәеп нәрсәгә тап булды Кәшшаф. Баксаң, үзара аралашуның эпистоляр жанры һаман яши икән әле биредә. Сафия ханым Кәшшафка оныкларына язылган хатларының күчерелмәләрен күрсәтте. Югыйсә, оныклары белән ул көн саен диярлек күрешеп-белешеп тора икән, әйтәсе сүзен күзгә карап та әйтә алыр иде.

Сафия ханым әлеге хатларында җәмгыять һәм кеше, тарих һәм милләт турындагы фәлсәфи, әхлакый уйлануларын тәкрарлый. Берсендә, мәсәлән, «Кеше үзенең нәсел-нәсәбен, тамырларын белү белән бергә, үз халкының тарихын да әйбәт белергә тиеш»,—дип яза, оныкларына татар халкының Болгар чорыннан алып бүгенгәчә гасырларны иңләгән катлаулы, газаплы, көрәш вә сабырлык белән тулган тарихы турында бай мәгълүмат бирә.

Сафияләр, Җансайлар, Гөлчәчәкләр, Сәлихалар исән-сау булганда, билгеле, Төркиядә татар рухы, татар исеме яшәячәк. Чөнки алар эстафетаны Исхакыйлар, Максудилар кулыннан алганнар. Болардан соң ни булыр?

Әлбәттә, бу бер Төркиягә генә карамый. Финляндиядә дә, Америкада да, Алманиядә дә шул ук хәл.

Хатлар белән танышкан арада Кәшшаф шулар турында да уйланып алды.

Ширбәттән соң Гаяз Исхакыйның 1954 елның 12—18 апрелендә Финляндиянең Тампере шәһәрендә яшәүче Зиннәтулла әфәнде белән Мөшфика ханымның дини тәрбия алган инсафлы кызлары Халидә туташка адресланган хаты турында сүз кузгалды.

—Бу хатны Әдипнең киләчәк буынга мөрәҗәгате итеп карарга кирәк,—диде Җансай Хаммат ниндидер үзенекенә охшамаган катгый тавыш чыгарып. Әйтерсең лә, кемдер аңа каршы төшәргә тели иде.

—Гаяз абый гомер кояшының батып баруын тәненең һәр күзәнәге белән тойган мескенем,—дип яшьләрен кулъяулыгы белән сөртеп алды Сәлиха Гомәр.

Бу кешеләрне язмыш уртаклыгы бербөтен итеп укмаштырган. Аларның көче нәкъ менә шунда. Мәңгәр вакыфының девизын да бик белеп сайлаганнар. "Берлектән куәт туар" дигән әйтем эш кәгазьләренең башында тора.

Гаяз Исхакыйның әлеге хаты Кәшшафка таныш иде. Танылган галим Хатыйп Миңнегулов аны Финляндиядән алып кайтып үз аңлатмасы белән «Казан утлары» журналында бастырып чыгарган иде. Тик ни өчендер ул киң җәмәгатьчелектә зур дулкынлану тудырмады, сизелмичә дә диярлек шома гына узып китте. Җансайның шуңа ишарә итүе иде булса кирәк. Кәшшаф шәхсән үзе әдипнең Идел-Урал халкына кагылышлы фикерләре белән килешеп үк бетми, гадиләштерелгән кебек тоела ул аңа. Ләкин бу һич кенә дә әлеге хатның сәяси-иҗтимагый әһәмиятен киметми. Дөнья

белән хушлашыр алдыннан язылган хат ич ул. Гаяз Исхакый «Ауропага дарулану өмиде берлә барырга план корып» йөргән чагында вафат була.

Сафия ханымның салоны Лев Толстойның «Сугыш һәм тынычлык» романында сурәтләнгән Анна Шерер салоныннан һич тә ким түгел иде. Дөрес, Анна Шерер салоны—сәяси салон, ә Сафия ханымны күбрәк мәдәни мәсьәләләр кызыксындыра. Казанда мондый зыялы салоннар юктыр әле, мөгаен. Казанда да мәҗлесләрне хуп күрәләр анысы. Ул мәҗлесләрдә, әлбәттә, сәясәт турында да, әдәбият турында да, мәдәният турында да сүз чыга, бәхәс тә ерак йөрми. Тик болар ашау-эчү арасында кысылып кала, хәмер пары белән шундук очып та бетә.

Ширбәт касәләрен җыеп алдылар. Мәҗлес тәмамланып килә иде инде. Кәшшафның күнелен кытыклап торган бер тема һаман калыкмый да калыкмый. Ахры үзе кузгатырга булды.

—Төрекләр сездән көнләшмиме, юлыгызга аркылы төшмиләрме?—дип сорады кыенсыныбрак кына.

Сорау, Кәшшаф уйлаганча, ризасызлык тудырмады, бер-берсенә карашып, елмаешып кына алдылар.

—Без үзебез дә төрек ич инде хәзер, үз-үзебездән көнләшикме?—дип Гөлчәчәк мәсьәләне уенга борып җибәрде.

—Әгәр хата җибәргән булсам, гафу итегез,—диде Кәшшаф.

Җансай ана ярдәмгә ашыкты.

—Юк, юк, бернинди хата да юк. Казаннан килгән һәр кешедән ишетәбез без бу сорауны, шуна күрә әллә сүз берләштеләрме икән болар дип елмаябыз.

—Кичерегез, зинһар... Элек бездә һәр әдәби әсәргә карата һәр тәнкыйтьче ин төп житешсезлек итеп коммунистлар партиясенең житәкчелек роле тулы күрсәтелмәвен билгеләп үтә иде. Шунын кебегрәк килеп чыкты инде...

—Зыян юк, Кәшшаф әфәнде,—дип энҗедәй нәфис ак тешләрен күрсәтеп елмайды Сафия ханым,—төрекләр бездән көнләшә алмый. Ник дисезме? Чөнки без аларнын мөгаллимнәре. Акчура, Садри Максуди, Гаяз Исхакыйларнын Төркиягә килеп сыенуы алар өчен бәхет кенә булды. Бүгенге төрек зыялылары шул мәктәпне үткән кешеләр... һәм Ататөрек... Цивилизациягә капканы ул ачты. Байлык—инвестиция байлыгы. Ә төрек һаман да шул төрек инде ул...

—Әле без аларга матур-матур бәбиләр дә алып кайтып бирәбез,—диде Гөлчәчәк уены-чыны белән,—ин чибәр, ин акыллы балалар безнекеләр.

—Шулай да сезне бер төрек ханымы белән очраштырырга ниятләп куйган идем,—дип дәвам итте сүзен Сафия ханым.—Талант иясе! Хәтта татарларның да борынына чиертте. «Казан Мәликәсе Сөембикә» диган драма әсәре язды. Кайсыдыр театрда куела да бугай. Фатма Музаффер Кайа. Каршы килмәссез ич?

—Бик шат булыр идем,—диде Кәшшаф.

Кунаклар урыннарыннан кузгала башладылар. Күрәсен, вакыт житкән иде. Һәрберсе хужа янына килеп баш иеп, рәхмәтен әйтә, саулык-сәламәтлек тели. Ишек катында аларны тар мыеклы мәһабәт гәүдәле хезмәтче егет озатып калды. Ана шулай ук өлеш чыгардылар, һәрберсе чәйлек биреп калдырды. Кәшшафнын да калышасы килмәде, кесәсен кырып-себереп дигәндәй тиеннәрен егеткә сузды.

—Бик кыерсытмыйлармы?—дип, Кәшшаф башы белән өскә ымлады. Бу анын хужаларга ишарә итүе иде.

—Мин контракт буенча эшлим,—диде хезмәтче.

—Башка эш табылмадымы?—Бу сораунын да үз мәгънәсе бар иде, әйтик, синен шикелле егеткә юньлерәк шөгыль дә чыккан булыр иде.

—Мина шушы эш җайлы,—диде хезмәтче,—мин бит институтта укыйм. Әти түләп укыта. Ә ашау-эчү, кием-салымга үзем эшләп табам.

—Гаиләгезнен икътисади хәле авыр алайса...

—Юк, әфәндем, без хәлле кешеләр. Әтием «Әхмәтвәли Мәнгәр»

ширкәтенең бер кампаньоны. Сафия ханым миңа җинги тиешле. Иззәт бәй әфәнде әтиемнең туганы...

—Кәшшаф әфәнде, сез кая югалдыгыз?—дип, Сафия ханым килеп җитте,—көтәбез, көтәбез... —Шунда ул хезмәтче егетне күреп алды. Бөтенләй башка тавыш белән:

—Йосыф бәй, бүгенге хезмәт хакыгызның яртысын тотып калам,—диде.

* * *

—Сезне бик ошатканнар,—диде юлда Җансай Хаммат.—Китабыгызның язмышы да унай хәл ителәчәк болай булгач.

—Рәхмәт яхшы сүзегезгә, Җансай әфәнде,—диде Кәшшаф,—тик мин үз-үземә ошамадым. Авызымны ачарга да кыенсынып утырдым...

—Шул сыйфатыгызны килештергәннәр дә инде, кешене бүлдермичә тыңлый белә, бик мәдәниятле галим икән, диделәр. Төрек ир-атлары күбрәк үзләре такылдарга яраталар, хатын-кызга түбәнсетебрәк карыйлар.

Миңа да дөнья бер елмаеп карар икән, дип уйлап куйды Кәшшаф. Иң зур шатлыгы, монографиясе, билгеле. Ул китап булып басылып чыкса, үзен иң бәхетле кешеләрдән санар иде. Җансай аркасында инде болар.

—Мин сезгә бик зур бурычлымын,—дип дустының җилкәсенә орынып алды.

Җансай кайтарып сүз әйтмәде, елмайды гына.

Машина килгәндәгечә, җилдәй элдертә. Тик Кәшшаф инде куркынып як-ягына каранмый, тыныч күңел белән тирә-якны күзәтеп бара. Шәһәр үзенең кичке рәвешен алган. Бөтен халык урамда. Шунда сату итәләр, шунда ашыйлар, шунда эчәләр. Тормыш урамга күчкән. Берсенең дә авызы буш түгел, һәммәсе нидер чәйни, нидер күши. Шуңа калын гәүдәле инде бу төрекләр.

Җансай машинасын кызганмый, куа гына. Юл полициясе бөтенләй күренми. Казанда сыбызгыларын сызгыртып хәзер килеп җитәрләр иде.

Бу ашыгуның җитди сәбәбе булган икән. Әнә, кунак йорты да күренде. Ул ыгы-зыгылы олы урамнан эчтәрәк урнашкан иде. Күрәсең, пыяла һәм бетон архитектурасына кадәр үк салынган булган. Стеналары калын, тәрәзәләре кечкенә. Таш койма белән әйләндереп алынган ишек алдында үзе кебек йөзъяшәр биек агачлар уртасында яшел күлмәген балкытып утыра. Машиналарны капкадан үткәрмиләр.

Кәшшаф сумкасын иненә салып алга узды. Җансай машинасы янында тоткарланып калды. Болдыр янына җитәрәк ул артына әйләнеп карыйсы итте. Дусты бер кыз белән сөйләшеп тора иде. Кызның дала кылганыдай аксыл чәче шәрә иннәренә таралып төшкән, гәүдәсе килешле, һич тә төрек кавеменә ошамаган.

Чит илдән килгән танышын очраткан ахры, дип уйлап куйды Кәшшаф. Ул арада Җансай кулларын изәп аны үзе янына чакырды.

—Таныш булыгыз, ватандашыгыз, Русия туташы Наташа,—диде Җансай,—ә миңа китәргә кирәк, бигайбә, намаз вакыты җитте.

—Әй, бәй әфәнде, бәй әфәнде, без бит әле аңлашып та бетмәдек,—дип, чибәр туташ Җансай артыннан ыргылды. Ләкин Җансай аңа таба борылып та карамады.

—Их, күңелем якын иткән бер төрек очраган иде, анысы да балык шикелле кулымнан шуып төште,—дип уфтанды кыз.

—Ул татар,—диде Кәшшаф эчке бер горурлык белән.

—От такого мужчины мозги выключаются.

Бу ир-егеткә хатын-кыз тарафыннан бирелгән иң зур бәя иде. Кәшшаф аз гына көнләшеп тә куйды. Җансай чыннан да көнләштерерлек кеше. Төскә-биткә чибәр, буй-сыны коеп куйган кебек. Кин җилкәле, нык бәдәнле, үзе төп-төз. Бөтен килеш-килбәтеннән бетмәс-төкәнмәс көч, ташкын бөркелеп тора. Хатын-кызларга шундыйлар ошый. Ул үзе

дә мондый игътибарга күнгән иде булса кирәк. Хәер, Казанда чагында чыгырыннан чыгып алды алуын. Тик бу инде анын язмышы, ә язмыштан узып булмый.

—Наташа, сез монда ял итәсезме?—дип сорады Кәшшаф.

Кызнын матур иреннәре кыйшаеп алды.

—Ял итү генәме...

Шунда гына Кәшшафнын анына бәрде. Рус кызлары Төркиядә тән сатып акча эшлиләр икән дип ишеткәне бар иде. Күрәсен, әлеге кыз шул Наташаларнын берсе иде.

* * *

Фатма Музаффер Кайа янына Кәшшафны Вакыф вәкиле Исмәгыйль бәй алып барды. Рәссам аларны шәһәр читендәге остаханәсендә кабул итте.

Остаханә тау куышында ясалган. Тирә-ягы таш кыя, аста—дингез. Дулкыннар гөрс-гөрс килеп ташларга китереп бәрәләр дә, кире чигенәләр. Бераз тын алып, көч җыйгач, башларына ак бүрек киеп, янә һөҗүмгә күчәләр.

Ачык карашлы, салмак хәрәкәтле бу урта буйлы ханымнын күнеле дә шушы дингез кебектер, мөгаен, һаман шаулап тора торгандыр ул. Югыйсә, ничек туар иде бу картиналар. Юк, аларда ярсу дингез манзаралары сурәтләнмәгән, киресенчә, күбесе гади көнкүреш хәлләренә багышланган. Әмма һәрберсендә ниндидер яшерен көч тоемлана. Менә хәзер ак күбекле дулкыннар рамнарны ватып, бәреп чыгарлар кебек. Осталыкмы, иҗади табышмы, стиль үзенчәлегеме—бәлкем барысы бергәдер? Ничек кенә булса да, бу инде талант! Ходай кайбер кешегә аны потлап бирә. Фатма ханым да әнә шундый бәхетле затларнын берсе иде.

—«Казан Мәликәсе Сөембикә» әсәрен язарга сезне нәрсә этәрде?—дип сорады Кәшшаф.

Фатма ханым касә читенә иреннәрен тигезеп алды да сөйләп китте:

—Сөембикә шикелле гүзәл хатын-кызлар төрки халыкларда бармак белән генә санарлык. Хикмәт төркилектә генә дә түгел. Мәсәлән, Бернард Шоунын «Әүлия Жанна» дигән әсәре бар. Мин аны бик еш кулыма алам. Инглиз язучысы француз кызы турында яза... Ни өчен? Монын сәбәбен аңлатып булмыйдыр, мөгаен. Шәхсән мин үзем, аңлата алмыйм...

—Исмәгыйль әфәнде, сорагыз әле, ни өчен Музаффер ханымәфәнде бу иҗат җимешен шушы вакытка кадәр Казаннан яшереп саклаган икән?—диде Кәшшаф.

Фатма ханымнын йөзе балкып китте. Гомумән, анын йөзеннән елмаю югалып тормады. Күренеп тора, Казаннын тарихчы галиме белән очрашу ана зур канәгатьлек бирә иде. Дөрес, татарлар арасында анын дуслары бар. Сафия Имре, Сәлиха Гомәр, профессор Надир Дәүләт. Болар җирле татарлар. Ә Кәшшаф Сөембикә каласыннан килгән олы кунак.

—Нинди бәхетле безләр—тарихыбызда Сөембикә кебек хатын-кыз шәхесләребез бар. Мин ана хезмәт итү мөмкинлегеннән чиксез горурлык хисләре кичерәм,—диде Фатма.

—Сорауны тагын кабатлагыз әле,—дип үтенде Кәшшаф Исмәгыйльдән. Ул, бу хәлнен төбендә бер-бер сер яшеренмәгәнме, дип уйлый иде.

—Үткән эшкә салават, Кәшшаф әфәнде,—диде Музаффер—Аллаһынын кушуы белән, ниһаять, хезмәтем шушы көннәрдә Казанга да барып ирешә.

—Ничек?—дип урыныннан сикереп торганын сизми дә калды Кәшшаф.

—Зинһар өчен тынычланыгыз, Кәшшаф әфәнде, барысы да үземнен ризалыгым белән,—диде Фатма. Кәшшаф исә драманын язмышын үз кулына алырга ниятләп тора иде.

—Хөрмәтле Надир бәйгә рәхмәт. Казан басмасы «Сөембикә» белән элемтәгә керде.

Соңыннан Чыңгыз хан турында, Алтын Урда турында гәп куертып алдылар. Фатма ханым чыңгызлыларны вәхшиләр дип саный икән.

—Алар Урта Азияне талап-җимереп бетергәннәр, дөньядагы иң бай Багдад китапханәсен яндырып көлгә әйләндергәннәр,—диде чын әрнү белән.

—Моның Алтын Урдага бер катнашы да юк, Алтын Урда бөтенләй башка дәүләт,—дип акланды Кәшшаф. Аның һич тә Алтын Урдага телтеш тигертәсе килми иде. Анысы да дөрес, Бату ханнар һич тә әүлия булмаганнар. Шулай ук кырганнар, шулай ук җимергәннәр. Бигрәк тә баштагы мәлдә. Тора-бара гына, бер күренекле тарихчының билгеләп үтүенчә, Алтын Урда «төрле халыкларның тыныч яшәүләре өчен идеаль шартлар тудырган дәүләт»кә әверелгән.

Фатма ханым үзе яшәгән шәһәрнең тарихы белән бик кызыксына икән. Остаханәсенең бер бүлмәсендә Истанбулның күренекле урыннары сурәтләнгән картиналар, репродукцияләр тупланган. Кәшшаф әле шәһәр белән бөтенләй диярлек таныш түгел. Гаяз Исхакый күмелгән зиратны күрде дә, Сафия Имре йортында булды.

—Мин үзем Анкарада туганмын, әмма Истанбулны күбрәк яратам,—диде рәссам.—Истанбул ачык һавадагы музей ул. Аның төрле чорда төзелгән бина-корылмалары, урам-мәйданнары гаҗәеп бер тарихи ансамбль тудыралар. Монда һәр буын үзенең ядкарен калдырган. Византия чорыннан калган кальгалар хәзерге кешеләрне дә сокландыра. Беренче урынны, әлбәттә, Әйа-Суфия корылмасы алып тора.

Фатма ханым кулындагы күрсәткеч таякчыгын үзенә бер осталык белән рамга тигезеп алды да сүзен дәвам итте:

—537 елның 27 декабрендә император Юстиниан тарафыннан гыйбадәтханә рәвешендә ачылган бу бина 1453 елда мәчеткә әверелә. Күрәсез, хәзер ул музей. Гомумән, мәчетләр төзүне Төркиядә элек-электән изге гамәл, Аллаһу гамәле дип караганнар. Мәсәлән, госманлылар дәверендә күтәрелгән менә бу мәчет, аны «Зәңгәр мәчет» дип йөртәләр, унике мең кешене сыйдыра. Калада инде XVI гасырда ук биш мең мәчет булуы мәгълүм. Ә госманлыларның соңгы сарае—Долмабакча! Ул Босфор бугазының Аурупа өлешендә төзелгән. Төркиянең иң зиннәтле музее. Барып карагыз, югыйсә, зур гөнаһлы булырсыз.

Кәшшаф Долмабакчаны барып күрде. Фатма ханым күрсәткән сурәттәгедән миллион мәртәбә гүзәлрәк иде. Чын мәгънәсендә оҗмах бакчасы. Тәхет залындагы дүрт тонна авырлыктагы хрусталь люстра аны аеруча хәйран калдырды.

Кайчандыр Карл Маркcның Истанбул турында: «...бу—гомерлек шәһәр, бу—көнчыгышның Риме» дигән сүзләрен укыганы бар иде Кәшшафның. Барысы да дөреслеккә туры килә иде.

Кәшшаф Төркиядә үзен бик бәхетле хис итте.

* * *

Кәшшафның Төркиядән кайтуын судка чакыру кәгазе көтеп тора иде. Әллә Аккош күлендә булган вакыйганы яңадан чокып чыгардылар микән? Башына бәргән беренче уй шул иде. Тик бу уеннан шундук кире кайтты, чөнки эшне күптәннән яптылар ич инде. Алайса ни-нәрсә соң бу? Әйбер урламады, кеше кыйнамады... Бәлкем кинәш-табыш итәргә чакыруларыдыр? Юк, судка кинәш-табыш итәргә чакырмыйлар. Суд суд инде ул, син йә гаепләнүче, йә шаһит...

Шунда ул чакыру кәгазендәге телефон номерын күреп алды. Җыйды. Трубкада тынкыш борынлы хатын-кыз тавышы ишетелде.

—Вахитов районы халык суды...

Кәшшаф хәлне төшендереп бирде. Ханымның кыштыр-кыштыр итеп ниндидер кәгазьләр актарганы телефоннан ишетелеп торды.

—Сез шәхесне мыскыл итү билгеләмәсе нигезендә судка куеласыз.

Дәгъвачы—Гуманитар институт директоры урынбасары Газизуллин Әлтаф Мәхмутович.

Кәшшафның гәүдәсе чайкалып китте. Әйтерсең лә, искәрмәстән тез астына китереп типтеләр. Соң алар хәмерләр эчеп, сугыша-сугыша гафу итешкәннәр иде ич инде. Димәк, кире уйлаган. Тискәре. Әллә котырттылар микән?

Юк, Әлтафны берәү дә котыртмады. Аның эш кузгатуы көнчелеккә бәйле иде. Иске дустының институтны узып, Төркиягә китүен күтәрә алмады. Моңа элекке үчләре дә килеп кушылды. Һәм ул Кәшшафның мәкаләсен тотып судка китте. Аңа гариза язарга куштылар. Җинел кулдан тиз генә гаризасын да сырлап бирде.

* * *

Әлтаф судка үзе килмәде, ышанычлы кешесен генә җибәргән иде. Ана кадәр Кәшшаф белән институт коридорында берничә тапкыр йөзгә-йөз очраштылар, әмма кул бирешмәделәр.

Суд узачак бүлмә зур гына иде. Җиһазлары гына ярлы. Урындыклар кыйшаеп беткән, утырырга куркыныч. Бер почмакта кемнәрдер быдыр-быдыр сөйләшә. Консультациягә килгәннәр, күрәсең. Судья ханым боларның берсенә дә игътибар итмичә, нәкъ күрсәтелгән вакытта, агач чүкечен жиз калканга бәрде. Йоласы шулайдыр инде. Югыйсә әлеге эш буенча судта ике генә кеше: Кәшшаф белән Әлтафның ышанычлысы гына катнаша иде.

—Судьяга дәгъваларыгыз юкмы?—дип сорады бүлмә хуҗасы. Ул зур калын күзлеге аша әле берсенә, әле икенчесенә текәлеп карап торды. Дәгъва белдерүче булмады.

—Башлыйбыз алайса.

Судья бу очракта әйтелә торган тагын нинди дер рәсми сүзләр сөйләде, ант иттерде.

—Фәкать дөресен генә сөйләргә, бернәрсәне дә яшереп калдырмаска ант итәм,—диде Кәшшаф. Бу сүзләрне әйткәндә аның тәннәре чемер-чемер итеп китте.

—"Телеграф" газетасындагы "Заместитель директора Гуманитарного института Газизуллин ратует за самостоятельную нацию сибирских татар" исемле мәкаләне сез яздыгызмы?—дип сорады судья.

—Мин яздым,—диде Кәшшаф.

—Гражданин Газизуллин мәкаләне үз шәхесен мыскыллау дип саный, экспертлар да моны раслый. Ул документ белән сезне таныштырган идек инде. Сез үз гаебегезне танырсызмы?

Кәшшафның секретарь кызга күзе төште. Тегесе ашыгып алдындагы кәгазьгә нидер язып куйды. Бу чикерткә минем җавабымны алдан ук белеп тора икән ләбаса, дип уйлады Кәшшаф. Ачуы чыкты.

—Әгәр мин юк дисәм?—дип, судьяга карады.

—Бу суд карарына бернинди дә йогынты ясамаячак...

—Алайса нигә сорыйсыз соң?

—Сез югары инстанцияләргә шикаять юлларга хаклы.

—Рәхмәт. Сез инде хөкем карарын чыгарып та куйгансыздыр. Мин алдан ук риза. Суд залында ук кулга аласызмы?

Судья аның төрттерүләренә игътибар итмәде, үзенекен төпченде. Ә ярты сәгатьтән соң тантаналы вәгъдә биргән пионер сыман олы күтәренкелек белән кычкырып хөкем карарын укыды. Хәтта почмакта гөрләшкән төркем дә тынып калды. Ул Әлтаф Газизуллиннан матбугат аша гафу үтенергә тиеш иде.

Дөнья куласа, бер әйләнә, бер баса. Әле генә Төркиядә һиммәтләнеп йөргән иде. Инде суд каршысында җавап тота. Үзе гаепле. Мәкаләнең корректурасын укып, имзасын төшерергә тиеш иде ул. Шуны редакциядән таләп итәргә тиеш иде. Ачык авызны шулай өйрәтәләр инде аны. Төп башына утырттылар менә.

Төркиядә күнел ачып йөрүләрнен шаукымы монын белән генә бетмәгән иде әле. Атна-ун көннән сон директор әмер чыгарды. Ул хезмәтне яңача оештыру турында иде. Шул сәбәпле ике эш урыны бетерелә. Үзеннән-үзе аңлашылганча, әлеге урынны биләгән кешеләр эшсез кала. Ул ике кешенең берсе Кәшшаф иде. Юридик яктан барысы да законга туры килә. Тел-теш тидерерлек нәрсә юк. Урыны кыскаргач, кешесе дә кыскара.

Институт белән исәп-хисапны өзеп, Кәшшаф болдырга чыгып басты. Кулында тулар-тулмас бер букча. Ун елдан артык эшләү дәверендә җыйган бөтен бирнәсе шуна сыеп бетте. Мактанырлык чамасы юк. Үзенә дә, җәмгыятькә дә әллә ни файда китерә алмады. Эштән куып дөрес эшләделәр. Үпкәләсә дә үзенә генә үпкәли ала. Шушында ничәмә-ничә чалбарнын гына төбен туздырды, кандидат та була алмады. Нульдән башлады, нульгә килеп терәлде.

Институтнын ишек уемына терәлеп диярлек кара "Волга" килеп туктады. Йөгереп чыгып, шофер арткы ишекне ачты. Галимовнын юан гәүдәсе шунда ук йомшак кәнәфи өстенә тәгәрәде. Кәшшафны ул күрмәмешкә салынды.

Кәшшаф акрын гына урыныннан кузгалды. Аяклары атлый, ә үзе кая барганын белми. Шуңа күрә аңа сәерсенеп карыйлар. Салмыш дип уйлыйлар, күрәсең. Берсе хәтта үз ишенә санап, жиненнән тартты.

—Братан, әйдә, өстибез, миндә рәт бар,—диде.

Кәшшафнын атлавы атлау, братаннын сүзләрен дә ишетмәде. Тегесе артыннан сүгенеп калды.

—Псих, тинтәк.

Кәшшаф берзаман ниндидер агач капкага килеп төртелде. Күтәрелеп караса, Дәригаларнын йорты икән. Ул ихата эченә узды. Әбисе Сәмига бакчада казынып йөри иде. Эшеннән туктады да, кулын маңгаена куйган хәлдә, озак кына керүчегә карап торды.

—Кем дип торам, кияү син икән,—диде ул элеккечә дустанә кыяфәттә.

—Әллә башка кешене көтә идегезме?—дип иреннәрен чалшайтты Кәшшаф.

—Ни иртә, ни кич дигәндәй, нишләп йөрү болай?

—Мине эштән чыгардылар,—диде Кәшшаф. Анын күнеле мөлдерәмә тулган иде, чак кына күзләре ерылып китмәде. Әбисенен күкрәгенә башын куеп үксеп җибәрүдән үзен көч-хәл белән генә тыеп калды.

Сәмига киявенен эчендә ут кайнаганын бер күз сирпеп карауда шәйләп алган иде. Шуңа күрә аңа жебеп төшәргә ирек бирмәде.

—Синен кебек әзмәверләргә кайда да эш бетмәс,—диде,—болай да алма кебек чакларын тиенсезгә үтте.

Бу йортта акча культы хөкем сөрә. Акчаны таба да беләләр, тота да беләләр. Дәрига да шул чыбыктан сөрелгән.

—Әйдә, өйгә уз, суыткычымда әзер котлетларым да бар, тиз генә кыздырып бирермен,—диде Сәмига.

Өйдә жиләс иде. Рәхәт. Әбисе ашарга әзерләгән арада Кәшшаф диванга утырып ял итте. Стенага Кәримнен зур фотосурәтен рамлап элеп куйганнар. Анын Дәрига белән төшкән фотосы да элекке урынында иде. Димәк, бу йортта әле ул артык кашык түгел икән.

Сәмига табынны залда хәзерләде. Өстәл өстенә бер шешә аракы да китереп куйды.

—Якынрак утыр, кияү,—диде.

Кәшшаф ин элек касәгә хәмер агызды. Ләкин эчмәде, кулына алгач, кире куйды.

—Нәрсә, кичәгедән сон үтмиме әллә?—дип төрттерде Сәмига.

—Көпә-көндез аракы эчереп, исертер иде бугай.

Башка бу хакта сүз чыкмады. Беравык бүлмә тынып калды.

—Төркиядән алып кайткан уенчыкларынны Кәрим бик ошатты,—дип өзелгән сүзне ялгап җибәрде Сәмига,—йоклаганда да үзеннән калдырмый.

—Бу якшәмбедә мин аны циркка алып барырмын дип торам,—диде Кәшшаф,—вакыт буа буарлык минем хәзер, әйтеп куегыз әле.

Сәмиганың кулындагы тәлинкәсе идәнгә төшеп челпәрәмә ватылды. Ләкин ул ана әһәмият бирмәде, кияве каршына килеп басты.

—Син әти кеше, әнәтрәк, үз сүзенне үзең житкер, жәме, бүрәнә аша бүре кума.

Кәшшаф йокысыннан куркып уянган кешедәй сискәнеп китте. Әбисенең ана болай каты бәрелгәне юк иде әле. Әмма туры сүзгә жавап юк.

—Әйтә башлагач, әйтеп бетерим инде, кияү, үпкәләмә,—дип тезеп китте Сәмига,—хатынына да баш булырга кирәктер ләбаса инде. Бераү булса, әллә кайчан жилтерәтеп өенә алып кайтып киткән булыр иде, әнәтрәк. Йомшак булма, йомшак агачны корт баса аны, вәйт!

И, әбекәем, беләсеңме икән, гаеп минем үземдә шул, дип сызланып алды Кәшшаф. Заһидә белән чуалуны күтәрә алмады Дәрига. Бала хакына гафу итәргә дә мөмкин иде анысы. Алай дисәң, ул вакытта Кәшшафның башы-күзе әйләнгән чак иде шул, үзенең ни-нәрсә теләвен дә анык кына белми иде. Кәрим турында да уйламады. Дәриганың китүенә куанды гына.

—Дәригага каты кул кирәк,—диде Сәмига. Ул кызы өчен бик борчыла иде. Чөнки Дәрига бик нык үзгәрде. Соң кайта, кунып калган чаклары да булгалый. Еш кына авызыннан хәмер исе килә. Әйтсәң, эт кебек ырылдый. Әтисе булса, сыртын каезлар иде дә, иртәрәк китеп барды шул. Бер сүзне ике әйтми иде мәгәр. Жир жимерелсә дә үз дигәнен эшләр иде. —Сәмига үз тәртәсен бөгә, форсаттан файдаланып калырга тели.—Ике дә уйлап торма, хатының белән малаеңны өенә алып кайтып кит. Дәригадан базарын да ташлат. Ирен тәрбияләсен, әнәтрәк, эштән кайтканын көтеп алсын.

—Минем эш юк бит, әби,—дип көлде Кәшшаф.

—Муены булса, камыты табылыр, бер дә генә хафаланма.

Сәмиганың кызын өйдә утырту турындагы сүзләре Кәшшафны гажәпләндерде. Ник дисәң, мона кадәр ул ана "акча эшлә" дип тукып тора иде. Шуна күрә:

—Дәрига белән берәр күңелсезлек булдымы әллә?—дип сорады.

Сәмига идәндәге тәлинкә ватыкларын жыярга кереште. Их, бу телкәйләрне, тозлап кына куясы нәмәрсә, дип офтанды. Дәриганың азып-тузып йөрүен сизенсә, әйләнеп тә карамый ич инде ул ана.

—Ни булсын ул ташбашка,—диде Сәмига эшеннән туктамыйча гына,—товар артыннан чаба. Әле Мәскәү, әле Төркия.

—Мин Дәриганы куып чыгармадым,—диде Кәшшаф,—фатир ачкычы кесәсендә, кайтсыннар, бер сүзем юк.

* * *

Дәригалар кичә парлашып мунчала булдылар. Ләбиб—Дәрига, Таһир һәм аның мәткәсе "Маша". Маша—озын буйлы, аксыл чәчле яшь-яшь рус егете.

Балдак мажарасына карамастан, Ләбиб Дәриганы читкә типмәде, куллан кулга да жибәрмәде. Чишендереп каеш белән әйбәтләп бер ярды да тынычланды. Дәрига бернинди тавыш чыгармады, тешен кысып булса да түзде. Аннан соң бик матур итеп жырлашып утырдылар. Белүенчә, Ләбиб аның өстеннән сөяркәләр дә тотмый. Ул аны ларектан да алды. Хәзер Дәрига үзе хужа кеше, ике сатучы яллады.

Кулына автостоянка эләккәч, Таһир да базарга сирәк йөри башлады, читтән торып кына "житәкчелек" итә. Ул элек тә "салым" жыеп йөрми иде, билгеле. Ләкин аның барлыгы өчен Дәрига Ходайга мең рәхмәтле. Чөнки, ул хәзер: "Абыстай, бер-бер йомышың юкмы?"—дип кенә тора. Бу Ләбиб аркасында, әлбәттә. Шәһәрнең нәкъ үзәгендә бер зур

автостоянканы кулына төшерергә булышты ул ана. Максатына иреште. Хатыны юк, гаиләсе юк, ул байлык ниемәдер инде? Акчасын "малай"ларга туздырып бетерә.

Мунчада төнгә кадәр юандылар. Маша гына нигәдер мышык-мышык килеп елап утырды, үпкәләшкәннәр иде булса кирәк.

Дәрига аларга игътибар итмәде, күзе гел Ләбибтә булды. Ул бик мөлаем иде бүген. Ак чәче, очлы ияге аны затлы шәхесләргә охшатып тора. Чынында да, зыялы нәселдән ул. Әбисе-бабасы, әтисе-әнисе мөгаллимнәр булган. Сеңлесе әле дә мәктәптә эшли. Үзе белгечлеге буенча мәдәният хезмәткәре. Югары белемле. Күпмедер вакыт зур гына Мәдәният сараеның директоры булып эшләгән. Шул чакта район Советына депутат итеп сайлаганнар. "Депутат" кушаматы шуннан килә.

Ләбиб инде күптәннән мәдәният кешесе түгел. Үз-үзен тотышы да, сөйләме дә. Тик барыбер күңелендә мафиоза корты кимереп бетерә алмаган ниндидер әдәплелек сакланып калган. Югыйсә, акча дигәндә әшнәләре кебек үк бер бәндә. Дәрига аның бар ягына да күнегеп бара инде, кул уйнатуын гына охшатып житкерми. Кеше дими, ашау-эчү вакыты дими, кулы әллә кайларга кереп китә. Әле дә:

—Әзерлән, абыстай, ялга Кипрга китәбез, во блин,—дип Дәриганың түшен ачып жибәрде.

—Ләбиб...

—Киләсе дүшәмбедә очабыз, биш йолдызлы кунакханә, дингез. Типтерик әле бер.

—"Алла бирсә, хатын ишекне ач" кебек булмасын,—дип шаяртты Дәрига.

—Без үзебез алла, блин.

Мунчадан төнге икеләрдә таралыштылар. Ә иртән иртүк Дәриганың телефоны челтерәде. Ул кесә телефонын йоклаганда да сүндерми, баш очына куеп ята.

—Абыстай, хәзер машина килеп житә, жыен!

—Нәрсә булды? Таһир... Таһир...

Таһир трубканы куйган иде инде. Дәрига тиз-тиз генә киенде дә урамга чыкты. Әнисе аны сүзсез генә башын чайкап озатып калды.

Дәриганың күңелен шом басты. Нидер булган, билгеле, болай иртүк кузгатмаслар иде. Ләкин шофердан сораштыруның мәгънәсе юк. Ул белсә дә әйтмәс иде. Аларның авызлары йозакта, колаклары томаланган.

Таһир аны ни өчендер Елга порты янындагы куаклар арасында көтеп тора иде.

—Нинди фокус бу, Таһир, шулай шаярырга ярамый ич инде,—дип Дәрига үпкәсен белдерергә ашыкты.

—Синдә Депутатның кәгазьләре сакланмыймы?—диде Таһир.

—Юк, ә нигә аның кәгазьләре миңа?

Таһирнын күз карашы усал һәм мәрхәмәтсез иде.

—Абыстай, бүгеннән башлап, Депутат турындагы бар нәрсәне дә онытасын. Аңладыңмы?

Дәриганың йөрәге өзелеп төшкәндәй булып борсаланды.

—Ә мин аңларга теләмәсәм?

—Депутат каюк,—дип Таһир бармагын муенына тигезеп алды.

—Ничек каюк?

—Мунчадан кайтканын сагалап торып, подъездда бугазын ярганнар.

Дәрига егылып китмәс өчен каршындагы каенга килеп сыланды. Ләкин буыннары тотмады, жиргә сыдырылып төште. Жиргә капланып үксергә кереште. Ләкин аңа иркенләп еларга ирек бирмәделәр, тиз генә машинаның арткы урындыгына кертеп салдылар. Ул шунда хәтсез вакыт тезләрен иягенә чәнчеп, тавышсыз гына елады.

—Жә, абыстай, житте, сак тот дип күпме әйттем мин ана, тыңламады бит. Үзе гаепле.

—Ләбиб кайда соң хәзер?—дип сорады Дәрига.

—Әлегә экспертизада. Күмү берсекөнгә. Сина зиратларга барып, күренеп йөрергә ярамас. Хушлашырга теләсәң, өйләренә килерсең. Тугыздан-унбергә кадәр. Безнең әле алда сүзләр булыр, мин сине үзем табармын. Ә хәзер эшенә бар. Безнең кичә бергә булганны берәү дә белергә тиеш түгел!

Ләбибне соңгы юлга танылган дәүләт эшлеклесен озаткандай зурлап озаттылар. Хәтта тәртип саклауны да милициягә ышанып тапшырмадылар, үзләре оештырдылар. Сәер хәл. Бер-берсен чүкешәләр дә, аннан соң корбаннарын барысы бергә җыелышып җирлиләр.

Дәрига кешеләр төркеменә ияреп, Ләбибнең өенә керде. Гап-гади өч бүлмәле фатир. Хатынныкы диделәр. Ул ире белән алтын унитазлы коттеджларда яшәмәгән. Ләбиб үзе дә шушы фатирны яраткан, фаҗига буласы төнне дә шушында кайткан, үлемен шушында тапкан.

Дәрига каш астыннан гына Ләбибнең хатынына карап торды. Яше бар икән инде. Үзе тыныч булырга тырышса да, кабарып чыккан күз кабаклары аның йокысыз төн үткәргәненә ишарә итә иде. Ике кызы әтисенең баш очында басып тора. Чибәрләр. Матурлыкларына кайгы да күләгә төшермәгән.

—Хуш, Ләбиб, урының җәннәттә булсын!

* * *

Университетның татар халкы тарихы кафедрасы мөдире профессор Мөхәррәм Каюмовны Кәшшаф хәтсездән белә. Акыллы, төпле, булдыклы галим. Студентларга кадәр аны үз итеп, яратып Әбүгалисина дип йөртәләр. Кәшшаф та аннан күп нәрсәгә өйрәнде. Әле Алтын Урда терминының колакка ятышсыз чакларында ул аңа Ашказарский шикелле үк: "Сез Алтын Урда урынына "Җучи олысы" тезмәсен кулланыгыз",—дигән киңәш биргән иде.

Университетта туры китерә алмагач, Кәшшаф, бөтен кыенсынуын җиңеп, профессорның фатирындагы телефон номерын җыйды. Каюмов аны тавышыннан ул танып алды.

—О, Кәшшаф Газизович, исәнмесез-саумысыз, үзем дә сезнең турыда уйлап йөри идем әле, бик әйбәт, бик хуш, шулай бер-беребезнең хәлен белешеп яшәргә язсын.

—Өегезгә шылтыратып борчыганым өчен гафу итегез, Мөхәррәм Мирсалихович, киңәшләшәсем бар иде.

—Зарар юк, җәйләрен безне университетта очрату авыррак шул инде ул. Ни йомыш соң?

—Миңа сезнең үзегезне күреп сөйләшергә кирәк иде.

—Мин барысын да беләм, ишеттем,—диде профессор,—әйдәгез, "Крематорий" мәйданында очрашыйк, мин үзем дә чыгып керергә дип җыенып тора идем.

"Крематорий" дигәне элекке Ленин мемориалы. Хәзер анда Милли мәдәни үзәк урнашкан. Халык бу тәрәзәсез сәер архитектура корылмасына әнә шундый ятышсыз исем бирде. Үзе бик матур җирдә, Казансу ярында салынган. Су буена йөз басмалы баскычтан төшәсе. Аргы якта ниндидер әкияти шәһәрчекне хәтерләтеп, Нәшрият бинасы, Яшьләре үзәге күренеп тора.

Кәшшаф килгәндә Каюмов анда иде инде. Елгага карап мөкиббән киткән. Һәйкәл сыман мәһабәт булып күренеп тора.

—Мин үзем Арча Кырында торам, ә һава суларга бирегә киләм,—диде Мөхәррәм кыл шикелле тырпайган мыегын шомарта-шомарта.

—Урыны матур,—дип хуплады Кәшшаф әңгәмәдәшен.

Берара вак-төяк хәлләр турында сөйләшеп тордылар. Бу дежур сүзләргә Мөхәррәм нокта куйды.

—Сезгә хәзер, Кәшшаф Газизович, диссертациягезне куаларга кирәк. Әзердер бит инде, шәт?

—Әйе, диссертациясе дә, монографиясе дә әзер. Монографияне Төркиядәге Мәңгәр фонды китап итеп чыгармакчы.

—Беләм,—дип бүлде аны Мөхәррәм,—Сафия ханым бу хакта минем белән дә киңәште, мин бит әлеге фондның консультанты булып та саналам.

—Рәхмәт...

—Кәшшаф Газизович, турысын гына әйтегез әле,—дип аның күзләренә текәлде Каюмов,—институтта ни өчен сезнең диссертациягезнең темасын расламадылар?

Бу туры һәм катгый сораудан Кәшшафның мангаена тир бәреп чыкты. Ник дисәң, хәтта якыннары да аның диссертация яклый алмавын фәкать үзенең кирелегенә генә сылтыйлар. Күрәсең, профессор да бу хакта хәбәрдар иде.

—Башта, инде яклау вакыты килеп җиткәч, диссертация өстеннән Мәскәүгә шикаять яздылар. Монда мөмкинлек тугач, раслау кирәкми дип сузып килделәр. Үзегез беләсез, дәүләт планына кермәгән темага бездә сан юк. Аннан соң үзем чыгымчыладым. Кырык яшьтә малай-шалай шикелле кандидатлык диссертациясе яклап йөрмәссең бит инде. Мин докторлык дим. Ләкин бу мәсьәләнең күзгә күренеп торган өлеше генә. Бөтен хикмәт шунда, минем тема институт директоры Галимовның фәнни юнәлешенә каршы килә. Аны да аңларга мөмкин, билгеле. Нәрсә генә әйтсәң дә, Галимов Болгар теориясенең хәзерге вакыттагы әйдәүчесе.

—Һәммәбез дә Шиһабетдин Мәрҗанига, Ризаэтдин Фәхретдинга таянабыз,—дип мыегын шомартып алды Мөхәррәм,—һәм барыбыз да алар хезмәтеннән азык табабыз. Чөнки ул бөекләр тарихны гадел ысул белән өйрәнгәннәр, төркемнәргә бүленмәгәннәр Тарих бик катлаулы фән. Кайчакта монысы Алтын Урда, монысы Болгар дип тәгаенләве дә бик авыр була. Ә без, җүләрләр, үз оябызны корабыз да, кеше-кара кәрә күрмәсен дип бикләнәбез. Менә шуннан китә тарткалашулар.

—Сез миңа нинди киңәш бирер идегез, Мөхәррәм Мирсалихович?—дип Кәшшаф та үзенең үтенечен житкерде.

—Диссертациягезнең темасын университет советында раслатып, планга кертергә кирәк,—диде Каюмов һәр сүзенә мөһер суккандай.—Бу—бер. Икенчедән, рәсми яклау вакытына китабыгыз да чыгып өлгерер дип ышаныйк. Оппонентларны Мәскәүдән дә, башка җирләрдән дә чакыру мәгъкуль булыр. Әйтик, төрекләрдә Җансай Хаммат бар. Сезнең аның белән борчагыгыз пешә дип ишеттем. Казакъларда да көчле белгечләр житәрлек. Әзербәйҗан. Кыскасы, Татарстан белән генә чикләнергә ярамый.

—Мине университетка кертерләрме икән соң?—дип шикләнүен белдерде Кәшшаф.

—Сез диссертациягезне хокукы рәсми рәвештә беркетелгән теләсә-кайсы югары уку йортында, теләсә-кайсы гыйльми институтта яклый аласыз. Шул исәптән Казан университетында да. Өстәвенә, сез безнең хезмәткәребез

—Ул ярты ставканың язмышы ничек бетәр бит әле.

Каюмов кулларын артка куеп, сүзсез генә Казансуны күзәтә башлады. Ә анда җилкәнле көймәләр пәйда булган иде. Җылы якларга юл тотучы торналар шикелле бер җепкә тезелешеп баралар.

—Мин тау-таш арасында үскән кеше,—диде Каюмов,—ә менә елгаларны, дингезләрне кечкенәдән яратам. Казансуны күрер өчен генә килəм мин монда.

Җилкәнле көймәләр Ял паркына таба узып киттеләр.

—Тәмле ризык күп булмый, миңа кайтырга вакыт,—диде Каюмов.—Яучылар көтәбез бит әле, кызны ярәшергә йөрибез. Бабай булырга хәзерләнәм.

—Гафу итегез, Мөхәррәм Мирсалихович, бик изге эшегездән бүлгәнмен икән, әйтергә иде аны, башка көн дә бар ич...

—Зыян юк,—дип мыегын җәеп елмайды Мөхәррәм,—хатын-кызлар, комачаулап йөрмә әле дип, үзләре чыгарып җибәрде. Мин бит гаилә,

хуҗалык мәсьәләләрендә наданның наданы. Ә кызымны бик яратам. Бәхете генә булсын иде. Кияве минем кебек булса, әнисе шикелле башы эштән чыкмаячак.

Ул еш-еш атлап китеп барды.

Бераз юл алгач, кисәк кенә борылды да кире килде.

—Ярты ставкагыз өчен кайгырмасагыз да була, ул сезнеке,—диде.

Кәшшаф "Сөембикә" журналы редакциясенә шылтыратып, Фатма Музаффар Кайаның әманәтен—"Казан мәликәсе Сөембикә" драмасының китап итеп басылган нөсхәсен тапшырырга ниятләвен әйтеп куйган иде. Эш сәгате беткәнче шунда барып җитәсе бар. Ара ерак булмаса да, автобуслар сирәк йөри.

Ул Ирек мәйданы аша узып, опера театры янына чыкты да, юл чатында машиналар хәрәкәтен көйләүче милиционер шикелле, ялт-йолт карангалап тора башлады. Ике куянның койрыгын тотмакчы: 56 автобус күренсә, авиация институты тукталышына йөгермәкче, 69 автобус сыртын күрсәтсә, билгеле, китап кибете каршысына элдертәчәк. Шулай да 56 автобус өлгеррәк икән. Этешә-төртешә торгач, борчак кузагы шикелле бүртенгән салонга гәүдәсен тәки сыйдыра алды. Кеше шул кадәр күп иде ки, аяклары идәнгә тимәде, гәүдәсе юл буе асылынып диярлек барды.

Аны редакциядә ачык чырай белән каршы алдылар. Баш мөхәррир бик мөлаем, бик чибәр ханым икән. Буй-сын коеп куйган шикелле. Теләсә-кайсы мәмләкәткә илче итеп җибәр, мәмләкәт абруена кызыллык китермәячәк. Ул кайсы ягы беләндер төрек дипломаты, милләттәшебез Әдилә Айдәне хәтерләтә иде.

—Сез безгә кыйммәтле бүләк алып кайткансыз икән, бик рәхмәтлебез,—дип ирен очлары белән елмайды баш мөхәррир. Аннан соң әлеге әсәрне танышлары аша Төркия кадәр Төркиядән эзләп табып, электрон почта аша үзенә алдырып, инде тәрҗемәсе белән шөгыльләнүче журналист ханым белән таныштырды.

—Драманы мин үзем барып алырга тиеш идем, сез мина аяк чалдыгыз,—дип шаяртып алды тегесе.

—Фатма ханымның тизрәк ирештерәсе килде бит,—дип акланды Кәшшаф.

Чәй эчкән арада Кайа турында сөйләштеләр. Кәшшаф дингез буендагы остаханәсендә үзенчәлекле картиналар иҗат итүче рәссам хатынның тарихи темага драма әсәре язуга алынуына гаҗәпләнүен белдерде.

—Фатма дулкыннар өстендә тибрәлүче аккош кебек ул,—диде журналист,—ана ходай өрфә җан бүләк иткән. Һәм шул өрфә җан Сөембикә ханбикә роленә керә белгән.

—Хатын-кызлар шулай инде алар, Кәшшаф әфәнде,—диде баш мөхәррир,—безне акыл белән анлау бик читен. Хатын-кыз хистән яралган. Кайа ханым-әфәндегә килгәндә, журнал иң мәшһүр мөселман ханымнарына гына бирелә торган бүләк булдырырга җыена, "Сөембикә" беләзеге дип аталачак ул. Ханбикә сурәте төшерелгән көмеш беләзек. Беренче лауреатыбыз Музаффер Кайа булыр дип торабыз.

* * *

Татар үзенең бөтен гамәлен атка мөнәсәбәтле рәвештә башкарган. Атны ул барысыннан да якынрак күргән, баласы кебек үк үз иткән.

Татарга тегенди-мондый гына ат кирәкми, ана затлы булсын. Ул үзе дә тирә-юньдә житезлеге, зирәклеге, көчлелеге һәм хәйләкәрлеге белән аерылып торган. Кошта—шонкарны, елкыда толпарны асыл иткән. Ә толпар меңнән берәү генә чыга.

...Үлән ярган бүредәй,
Адәм егып юл ярып,
Килә бирде Идегәй.

Салкын казан, суын су,—
Аны житеп аударып,
Чыңгыздан калган кара ту—
Аны житеп аударып,
Ат астында калдырып,
Тоякка салып сындырып,
Юлда борын таптатып,
Сөрә бирде Идегәй.

Тәфкилев теге вакытта Кәшшафны "Идегәй" дастаны буенча тарих яза", дип тәнкыйть итеп чыккан иде. Янәсе, әдәби әсәр тарихчы өчен таяныч була алмый. Ихтимал, "Идегәй" тарихны төгәл дә чагылдырмыйдыр. Чөнки ул әдәби әсәр. Әмма грекларның "Илиада"сы, кыргызларның "Манас" эпосы, һиндларның "Махабхарата"сы шикелле үк ул милләтне формалаштыручы әсәр. Андыйлар бармак белән генә санарлык. Баскынчылар шуңа күрә шүрлиләр дә алардан: тыялар, эзәрлеклиләр, яндыралар. "Идегәй" дастаны да ниләр генә күрмәде? Аны тыеп махсус карар да кабул иттеләр. Ул кешеләр инде юк, ә дастан яши. Һәм яшәячәк тә!

"Идегәй" кисәтә, бердәмлеккә өнди. Шул бердәмлек, татулык булмау сәбәпле таркалган да ич инде Алтын Урда. Менә хәзер татар янә баш калкытып килә. Татарстанның суверенлыгы турында Декларация кабул ителде. Бу декларацияне дә шундый ук язмыш көтмиме?

Кәшшаф стакандагы салкын чәйне йотып куйды да, өстәл өстендәге кәгазьләрне алдына ук сыдырып китерде. Аңа Туктамышлар, Идегәйләр турында түгел, диссертациясе хакында күбрәк уйланырга кирәк иде, югыйсә. Юк, салулаган чана шикелле һаман читкә каерыла.

Телефон шылтырады. Улы Кәрим икән.

—Әтием, минем үзебезнең фатирда, синең белән бергә яшисем килә,—диде. Үзе елый.

Каян шылтыратасың, нишләп үзең генә йөрисең дип белешү урынына Кәшшаф: "Әниең кыйнадымы әллә?" дигән мәгънәсез сорау бирде.

—Минем әниемне күргәнем юк,—диде Кәрим шундый ук калтыранган тавыш белән.

Әнисенең өйдә сирәк күренүе этәрде дә инде аны бу адымга. Әбисеннән качып чыгып, вокзалдагы телефоннан фатир номерын җыйды. Әгәр элеккечә бергә-бергә яшәсәләр, әнисе өйдә генә торыр иде, күңелле булыр иде, бергәләшеп зоопаркка барырлар иде. Кәрим кошларны, җәнлекләрне, хайваннарны бик ярата.

Кәшшаф улының борчуларын аңлый алмады. Чөнки үзенең дә тынгысыз чагы. Бәргәләнә, салулый аның күңеле, шуңа Туктамышлар, Батыйлар белән саташа. Иртәгә аның диссертациясен тикшерәчәкләр. Яклауга тәкъдим итәрләрме-юкмы?

Кәримнең тиеннәре бетте, күрәсең, телефон тынды.

* * *

Каюмов бик төгәл кеше. Кунакка чакырсалар да: "Сәгать ничәгә килергә",—дип кайтарып сорый. Әгәр шул чагында чакыручы кеше жиделәр тирәсенә дисә, Каюмовның бәйләнәсен көт тә тор! Тирәсендә дигән вакыт берәмлеге юк, дип, тетмәнне тетәр.

Әле дә сәгатенә карап алды да нәкъ дүрттә тамагын кырып, аваз салды.

—Җәмәгать, башладык. Гыйльми совет тулы составта катнаша. Чакырылган кешеләрнең дә күбесе монда. Кворум бар.

Каюмов (парламентарийларга хас төгәллек белән) җыелышның көн тәртибен житкерде. Аннан тыш та ул үзенә әлеге сөйләшүнең кысаларын чамалап куйган иде инде. Сөйләшү никадәр киңрәк, никадәр тирәнрәк булса, аның файдасы да шул бәрабәргә арта. Чөнки Хәмитов кандидатлык-

ны сикереп үтмәкче. Өстәвенә, низаглы, сакаллы диссертация. Аңа каршы чыгучылар да сүзләре үтә торган дәрәҗәле кешеләр. Әнә, Галимов, сузма инде, җәтрәк кылан дигәндәй түземсезләнеп итләч йодрыгын өстәл өстенә бәргәләп утыра. Янында мөритләре. Тәфкилев, гадәттәгечә, энәдән-җептән генә чыккан яңа костюм кигән, кара чәчләрен майлап тараган. Фырт күренә, әйтерсең лә, театрга килгән. Әлтаф Газизуллин, анысы тук бурсык кебек бүселгән. Көнләшүе, ахры.

Хәмитовныкылар да төкергәннәрен ялый торганнардан түгел, һәрберсенең эчендә иярле ат ята. Араларында иң абруйлысы, мөгаен, Рамил Сәмигуллиндыр. Элеп киптергәндәй юка гәүдәле үзе, ә тавышы гөбегә кычкыргандай көр чыга. Мәртәбәле галим. Сүзен әйтә икән, өздереп әйтә. Аның теленнән хәтта Галимов та шүрли. Мазһар Мөхәммәтҗанов шулай ук бик зыялы зат.

Башкалар шушы ике төркемнең берсенә кушылачак. Әлеге мәсьәләдә битараф булып булмый. Бу җыелыш диссертация яклау алдыннан үзенә күрә генераль репетиция. Рәсми оппонентлар гына житешми. Алары белән дә сөйләшү бара. Күбесе ризалык бирде инде. Бик мөһим диссертация. Әгәр дә ул уңышлы яклана калса, Алтын Урда тарафдарларының да ата казлары ду китереп бер биер иде.

Кәшшаф моңа кадәр һаман җиңелеп килде. Бу аның характерына да тәэсир итмичә калмады, билгеле. Кешеләргә ышанмый башлады, үзсүзлеләнде, кирелеге артты. Татар тарихында Алтын Урдага карата еллар буе тәгаенләнеп килгән негатив карашларны ул бер үзе җимереп ташламакчы булды. Көрәшеп карады. Ләкин үз дигәнен булдыра алмады.

Каюмов аңа тикшерү вакытында гына булса да, үпкәләрне онытып торырга киңәш итте. Кәшшаф бу киңәшне тотарга тырышты. Чыгышында берәүгә дә төрттермәде, үпкәсен белдермәде. Әмма каршы як килешүне кабул итмәде, шундук һөҗүмгә күчте. Беренче укны Тәфкилев атты.

—Кәшшаф Газизович,—диде ул төче телләнеп,—сезнең библиографиягез мәрхүм профессор Ашказарский библиографиясе белән тәңгәл килә. Әйтегез әле, зинһар өчен, моны ничек аңларга?

Тәфкилев кесәсеннән крахмал белән катырылган ап-ак кулъяулыгын тартып чыгарды да нәзакәтле генә итеп ирен кырыйларын корытып алды.

—Минем библиографиям Мәхмүт Имаметдиновичныкы белән тәңгәл килгән очракта да бернинди гаеп тапмас идем,—диде Кәшшаф.—Ул минем остазым. Ләкин мин үземне аның дәрәҗәсендәге галим дип санамыйм. Ул безнең барыбыздан да бер башка өстен. Мәсьәләне конкретлаштырганда исә, библиографиямдә яңа исемнәр дә бар. Әйтик, Галимов Сәүбән Сәүбәнович, археолог Сәмигуллин, филолог Мөхәммәтҗанов, башкорт галиме Гайсә Хөсәенов, комык галиме Марат Ажи, төрек галиме Җансай Хаммат, руслардан Вадим Трепавалов... Күп алар.

Тәфкилевнең угы иясенә барып җитмәде, бумеранг булып үзенә әйләнеп кайтты.

Галимов Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэтдин Фәхретдин мирасларь буенча үзен иң компетентлы белгеч дип саный, гәрчә институтта әле кайчан гына бу галимнәрнең исемнәрен дә әйтмиләр иде. Хәзер исә ул һәр гыйльми бәхәстә шушы шәхесләрне калкан итеп файдалана.

—Сезгә Ризаэтдин Фәхретдиннең "Безләр татармы-түгелме?" дигән мәкаләсе билгелеме?—дип сорады ул Кәшшафтан.

—Билгеле,—диде Кәшшаф,—мәкалә 1906 елның гыйнвар аенда Кырымда "Тәрҗеман" гәжитендә басылып чыккан.

—Хәтерегезгә төшерегез әле, татар этнонимын галим ничек аңлата?

Кәшшаф Каюмовка сораулы караш ташлады. Ник дисән, тегесе кирәк-кирәкмәгән бәхәстән качарга киңәш иткән иде. Каюмов җиңел генә башын кагып куйды. Бу фатыйха бирү иде.

—Ризаэтдин Фәхретдин татар этнонимын татар-монголлар белән килгән сүз дип аңлата, Сәүбән Сәүбәнович,—диде Кәшшаф тынычлыгын

җуймыйча,—хәтта татар кабиләләренең баштагы теле монголча булырга тиеш, дип тә саный. Аныңча, монгол яулары белән килгән шул татарлар электән хазар, соңрак болгар дип аталган кабиләләрне буйсындырганнар. Үзләре аз булу сәбәпле төркиләшкәннәр. Шулай да чит халыкларга исемнәрен такканнар. "Безләр татар түгел, чын төркләрбез",—ди галим.

—Нигә дип алайса тәртәгә тибеп маташасыз? Үзгәртегез диссертациягезне шушы юнәлештә.

Галимовның киң кәнәфиләргә җәелеп утырырга күнеккән арт санына бер урындык кына тар иде. Түземлеге беткәч, ике урындыкны бергә кушты.

—Үзегез үк, Сәүбән Сәүбәнович, әйтәсез ич, монгол яуларында катнашкан татарлар төрки кавеменә караганнар, дисез. Ризаэтдин Фәхретдин исә татарларның монголларга якынлыгын мөмкин дип саный. Димәк, безнең беребез дә пәйгамбәр түгел. Мин чын күнелемнән ышанам, кайчан да булса сез үзегез дә "халыклар күченеше" дигән хак теорияне хуплаячаксыз әле.

Галимов нидер әйтмәкче иде дә Кәшшаф аңа ирек бирмәде.

—Бер очтан әйтеп бетерим инде, Сәүбән Сәүбәнович, сез әле Шиһабетдин Мәрҗанине дә телгә алачаксыз. Мәшһүр галимебез бик дөрес билгеләп үткәнчә, "Кайбер сәбәпләр аркасында, бигрәк тә Аксак Тимер фетнәсе нәтиҗәсендә, Туктамыш ханның патшалык көннәре бетеп, Дәшти-Кыпчак, Җуҗи улусы һәм Бәрриятел Бәрәкәттәге кабиләләр арасында таркалу һәм илгә гомуми зәгыйфьлеге килеп, Олуг Мөхәммәт хан илнең башкаласы Сарайдан чыгарылганнан соң, Җуҗи хан нәселе шаһзадәләре арасында ызгыш тагын да куера. Нәтиҗәдә ил төрле кабилә биләмәләренә охшаган аерым, вак-вак дәүләтләргә бүленеп бетә". Мәрҗани бүленеп чыккан Казан, Әстерхан, Касыйм, Кырым, Себер ханлыкларын татар дәүләтләре, ә аларның халкын татарлар дип атый.

Галимов кешеләргә фикерен үзе көчләп тагарга күнеккән кеше. Ләкин Кәшшафның үз-үзен тыныч һәм ышанычлы тотуы аның кайнарлыгын басты. Югыйсә, барысы да менә хәзер Галимов атылып чыга инде дип көткәннәр иде.

Бер мәлгә тынлык урнашты. Шул вакыт ачык форточкадан бер корт очып керде. Бүлмә эче бызылдау тавышы белән тулды. Корт тәрәзә пыяласына орылып-бәрелеп йөрде дә чыгып китте. Унынчы катка кадәр ничек менеп җиткән ул? Әллә биектә үрчегән нәселме?

Галимнәр тарих сикәлтәләрен онытып, шул хакта баш ватып алдылар.

—Җәмәгать, сөйләшүне дәвам итәбез, кыскарак һәм конкретрак булырга өндим. Кем сөйләргә тели? Рамил әфәндеме? Рәхим итегез, Рамил Фәесханович, рәхим итегез!

Рамил егетләр җинеллеге белән урыннан торып басты.

—Мин Хәмитовның диссертация темасын расларга тәкъдим итәм,—дип үгезне мөгезеннән үк алды.—Әле татар милли тарихында Алтын Урда һәм татар халкының формалашуы темасы буенча диссертация яклаучы кеше, мөгаен, булмагандыр. Мәсьәлә бик актуаль. Моңа кадәр Татарстан тарихын гына өйрәнеп азапланган халык ич без. Аңысы да СССР тарихының бер нәни генә тармагы иде. Хәзер, азмы-күпме мөмкинлекләр ачылгач, һәр милләт тарихта үз урынын эзли. Буталышып та бетәбез бугай инде. Фоменко дигән бәндә, әйтик, Туктамыш хан ул Дмитрий Донской икән, ә Батый Александр Невский булган икән дигән уйдырма уйлап чыгарды. Башка версияләр дә бар. Батыйны хәтта Рим Папасына да әйләндереп куйдылар инде. Әгәр йоклап ятсак, Алтын Урданы безнең кулдан тартып алырга да күп сорамаслар. Һәркемгә мәгълүм, гыйльми бәхәсләрнең файдасы бик зур. Әмма бездә алар ни өчендер итәк астыннан ут уйнатуга кайтып кала. Үзебез буталабыз, җәмәгатьчелекне бутыйбыз. Кызганычка каршы, XV—XVI гасырларга караган материаллар күп түгел, булганнары да каршылыклы. Әмма шунысы ап-ачык, Алтын Урда бөек татар дәүләте. Моны аңлау өчен Эрмитаждагы хәзинәләренә генә күз

төшерү дә житә. Аны Казанга да алып киләсе иде, Сәүбән Сәүбәнович!

Галимовның урындыклары шыгырдап куйды. Ләкин жавап кайтармады.

Чират Әлтафка килеп житкән иде булса кирәк, ул кулын күтәрде.

—Татар-монгол явы белән болгар явын күз алдыгызга китерегез әле,—диде үзенә бер пафос белән,—диссертантның чыгышыннан күренгәнчә, аларның икесе дә без икән ләбаса. Минем башка сыймый бу, иптәшләр!

—Башың кечкенә, шуңа сыймый,—диде Рамил. Көлешеп алдылар.

—Иван Грозный Казанны алганда аның гаскәрләре арасында кырык мең татар була. Куликово сугышында руслар чын татар халкын яклап чыккан татарлар ягыннан торып сугышканнар,—диде Кәшшаф Әлтафка туры карамыйча гына,—беренче карашка, болар да башка сыймый кебек.

Кайберәүләр нигәдер уртаклыкны түгел, аерымлыкларны күпертеп күрсәтергә тырышалар. Болгарлар да, монгол-татар явының күпчелеге дә төркиләр. Безне шул берләштерә. Бабаларыбыз арасында болгарлар да, кыпчаклар да, нугайлар да булган. Бүгенге көндә татар милләтеннән болгарларны, мишәрләрне, керәшеннәрне, типтәрләрне, нугайбәкләрне, Себер һәм Әстерхан татарларын аерып чыгару өчен жан атып йөрүчеләр дә юк түгел.

Кәшшаф, ниһаять, Әлтафка текәлеп карады. Тегесе аның карашын күтәрә алмады, башын борды. Әле кайчан гына бер кашыктан ашап, Бату ханга мәдхия жырлап йөриләр иде. Инде болгар—татар баррикадасының икесе ике ягында.

Кәшшаф Әлтафның Себер татарлары турындагы язмасына да, суд хәлләренә дә тукталып тормады. Дөрес эшләде, үзенең өстенлеген дәлилләде. Ә Әлтаф шул мәрәкә калкып чыкмаса ярар иде дип куркып утырды.

—Әлтаф әфәнде, монда Хәмитовның диссертациясен хупларга диган тәкъдим әйтелде, сезнең фикерегез ничек?—дип кычкырды бунтарь йөрәкле Мазһар утырган урыныннан.

—Мин Гыйльми совет әгъзасы түгел,—диде Әлтаф. Һәм үз жавабыннан бик канәгать иде, бер генә мизгелгә чытык йөзе ялтырып китте.

—Иуда...

—Жәмәгать, утырышны митингка әвереллдермик,—дип Каюмов каләме белән сулы графинга суккалап алды.

—Рөхсәт итегез әле!

Бу университет доценты Жәмилов иде.

—Мин, иптәшләр, кайсыдыр ки, раслау өчен тавыш бирәчәкмен,—диде ул көр тавыш белән,—шул ук вакытта теманы артык дәрәжәдә гомуми дип саныйм. Бу тулы бер институт темасы.

Жәмилов аңлыйсызмы мине дигәндәй, каш астыннан гына бүлмәне күзәтеп алды. Риза калды кирәк, сүзен дәвам итте.

—Минем Сәүбән Сәүбәновичка да ихтирамым зур, иптәшләр, кайсыдыр ки. Алтын Урданы таныйбыз икән, болгарның югалып калуы ихтимал. Алайга китсә, безнең халыкның этник компонентлы болгарлар да, татарлар да түгел. Нindидер борынгы төрки этносы булырга тиеш. Ник дисәң, кайсыдыр ки, болгарларның да, татарларның да гамәл-хәрәкәтләре халык авыз ижатында һичнинди чагылыш тапмаган.

Жәмиловның сүзе озынга китте, шаулаша башладылар, шуңа күрә туктарга мәжбүр булды.

—Жәмәгать, мәсьәләне тавышка куяр алдыннан минем дә кыска гына үз фикерем белән уртаклашасым килә,—диде Каюмов.—Мин үзем татарны болгардан кинрәк, ләкин алтынурдалылардан таррак дип саныйм. Кәшшаф әфәнде исә барысын да бергә өяргә тели. Дөрес, татарлар бер халык буларак, Алтын Урда чорында тәгаенләнгән. Ул элекке мөселман болгарларны да, кыпчакларны да, фин-угырларны да үз эченә алган була. Ләкин бербөтен булып оешырга, укмашырга өлгерә алмый калалар, вакыт житми, Урда тарала.

Болгары да, Алтын Урдасы да үзебезнең тарих бит, җәмәгать. Нинәрсә бүлешәбез соң без?

—Ни әйтсәгез дә, безнең халыкның чын тамыры болгарга барып тоташа,—дип үз фикеренең үзгәрмәгәнлеген кисәтте Галимов.

Җыелыш ике тавышка өстенлек белән Кәшшафның диссертация темасын раслады.

* * *

Ниһаять, Кәшшаф бүген улын циркка алып барды. Урап-тулып, арып-алҗып шуннан кайтып килешләре. Күзләренә ак-кара күренми. Кәрим туп шикелле тәгәрәп килә дә әтисенең аягына урала, тәгәрәп килә дә әтисенең аягына урала. Кулларын бутый-бутый һаман нидер сөйли, нидер аңлата, авызы ябылып та тормый.

Бәхетле иде ул бүген.

—Әтием, зур үскәч мин дә дрессировщик булам,—диде ул бер уралуында,—минем филләрем тез чүгеп кенә калмас, мәтәлчек тә атырлар.

—Егылып корсаклары ярылмасмы соң?—дип шаяртты Кәшшаф.—Лилипутиядән җибәрелгән филләр булса гына инде.

Кәримнең тумпак борыны өреп кабартылгандай киерелеп китте.

—Син нәрсә, әгием, алар чын Африка филләре булачак. Мин аларны нәни вакыттан өйрәтәчәкмен!

—Монысы яхшы, улым, хуплыйм, тик кулың кәкре икән бит синең.

—Җә, әтием, житте инде, ярар мылтыкларының прицелы бозылганга мин гаеплеме әллә?

—Башка малайлар да шул мылтыктан аттылар ич.

—Әтием...

Кәримнең озын керфекләренә иртәнге чык кебек яшь бөртекләре кунды. Кәшшаф аны кочаклап алды. Малай сүзне шундук икенчегә борды.

—Әйдә, бәхәс, минем кесәдә ничә фанты бар?—дип сорады.

—Нәрсәдән бәхәсләшәбез соң?

—Мин синең маңгаена өч мәртәбә, юк, юк, биш мәртәбә чиертәм.

—Мин отсам дамы?—диде Кәшшаф.

—Син ота алмыйсың, әтием,—диде Кәрим хәйләкәр елмаю белән,—әйтимме ни өчен?

—Әйт.

—Минем кесәмдә бер фанты да юк. Һе-һе-һе...

Улының чын күнеленнән шатлануы Кәшшафка да бетмәс-төкәнмәс куаныч китерә иде.

Кәрим кулы белән әтисенең аркасына орынып алды да кешеләр арасыннан бар көченә чабып китте. Кәшшаф аның артыннан теркелдәде.

Шунда Заһидә белән чак кына йөзгә-йөз бәрелешмәделәр. Хатын әсәрләнеп туктап калды. Кәшшаф исә ана игътибар да итмәде, карашы салкын битарафлык белән чана табанындай шуып кына узды.

Заһидә Кәримне дә абайлап алды. Үзенә охшаган икән дип уйлап куйды. Әгәр тапкан булса, Заһидәнең дә улы булган булыр иде. Юк, кыз булыр иде, ул кызларны ярата. Ә Кәшшаф бу турыда белми дә калды. Заһидә үзе гаепле. Нарасыен уксус белән харап итте ич. Гөнаһысын ничек ярлыклар.

Әлеге коточкыч хәлләрдән соң бала хакында да, башкасы хакында да уйламаска, ул вакыйгаларны исенә төшермәскә тырышты Заһидә. Кәшшафка үч итеп кияүгә чыкты. Ире Мефодий белән дөнья мәшәкатьләреннән ваз кичеп, Остаз тәгълиматына бирелеп яшәделәр.

Бу сазлыктан аны бер очрак тартып чыгарды. Фәйләсуфләр очраклыкларны да зарурилык кануннарына буйсына диләр. Бу нәкъ менә шундый зарури очрак.

Мефодий йоклаганда да күлмәген салмый иде. Ул гомумән киемсалымына Заһидәне кагылдырмый, үзе юа, үзе рәтли. Мунчадан ук эшен бетереп кайта. Шулай беркөнне Мефодий, гадәттәгечә, кич-кырын урам

урап кайтты да диванга сузылып ятты. Арыган булган, күрәсең, оеп та китте. Заһидә рәхәтләнеп ял итсен инде бу дип, өстенә одеал китереп япты. Һәм күзләре чеviews чыкты. Чөнки Мефодийның ачык изүеннән тәре күренеп тора иде. Булавка башы кадәрле генә кечкенә алтын тәре. Бик нәзек жепкә тагылган. Чекерәеп карамасаң, күренми дә. Менә ни өчен күлмәген салмаска киреләнгән икән?

Заһидә ачуыннан бүртенеп чыкты. Нишләргә? Бу намуссыз бәндәнең сакалыннан урап алып, типкәләргәме, әллә шәрә мангаена кайнар үтүк белән басаргамы? Тик ни генә кылсаң да үчен кайтара алмаячак. Юк, Мефодийның гаебе аклана торган гаеп түгел. Ничек итеп шулай икейөзле булмак кирәк, ә?

Заһидә үз тормышында күп алданды, әмма монысы аеруча авыр тоелды, гүя бәгърен кыеп алдылар. Үзе өчен түгел, башкалар өчен дә йөрәге әрнеде. Бик күп мөселманны Иванов ягына аударды ич Мефодий. Һәм алар барысы да аның хәлендә, бу тәгълиматның христиан диненә кагылышы юк дип ышанып йөриләр. Ә үзләре сизмичә дә Мефодий корган капкын эченә кереп баралар. Миссионерлар көчләп чукындырган, ә бу, мәкерле жан, күнел аша эш итә.

Заһидә хәлсезләнеп ятакка ауды. Төшендә ул унжиде яшендә урманнан утын алып кайтканда чанасы салулап, йөге астында калган мәрхүмә Халисә апасын күрде. Боегып кына басып тора.

"Апа, ни булды, берәр жирең авыртамы әллә?"—дип сорады Заһидә.

Халисә жавап урынына кош канаты кебек кулларын гына жәйде. Шул ук мизгелдә баш очында ут кабынды. Ә ут эчендә тәре.

Заһидә куркуыннан кычкырып жибәрде. Уянды да кебек, күзләрен ачарга тели—ача алмый, әйтерсең лә, күз кабакларына гер тагып куйганнар.

Тарткалаша-тарткалаша торгач, янә онытылып китте. Бу юлы үзен ниндидер озын, караңгы, тар мәгарә эчендә күрде. Сукыр кеше шикелле капшанып кына атлый. Аяк астында бала башы кадәр зур-зур ташлар аунап ята. Әледән-әле шуларга килеп сөртелә. Бара торгач, бер ишеккә юлыкты. Ачаргамы-юкмы? Кемдер колагына: "Анда кермә!"—дип пышылдый. Алайса бу мәгарәдән ничек чыгарга соң?

Заһидә ишек астыннан чыккан ниндидер сәер яктылыкны шәйләп алды. Көмеш төсендәге тоныкяктылык, чит-читләрендә кан кызыллыгы. Ул үзе дә сизмәстән ишеккә килеп орынды.

Буш бүлмәнең нәкъ уртасында бер ап-ак сакаллы карт ята иде. Йөзендә жан әсәре юк. Түшәмдә кара кучкыллы болыт асылынып тора. Аннан тирә-якка әлеге канлы көмеш төсендәге жепләр сузылган.

Остаз! Аны коткарырга кирәк ләбаса! Ләкин Заһидә бернәрсә эшләргә дә өлгерә алмыйча калды, болыт болганып китте, шунда ук тоташ гүләү тавышы ишетелә башлады.

Остаз күзләрен ачты, урыныннан торып басты. Шуны гына көткәндәй болыт эченнән нурлар көлтәсе бәреп чыкты. Гүләү көчәйде. Бер мизгелдә тавыш кыл шикелле шартлап өзелде. Остаз басып торган урында тәре генә утырып калды.

Болыт жанлы зат шикелле жинел сулап куйды.

Заһидә күзләрен ачты. Иртә иде әле. Мефодий чалынып бетмәгән бәрән шикелле гырылдый. Ул башта аңышмыйча торды. Нишләп ул монда ята, аның урыны бу түгел ләбаса! Аяклары да оеп беткән. Шунда кылт итеп тәре вакыйгасы хәтерен уеп алды. Сикереп торды да бернинди тәкәллеф саклап тормыйча иренең изүен ачып жибәрде. Тәре төкләр арасыннан сүнгән учактагы куз шикелле ялтырап күренеп тора иде.

Димәк, бу төш түгел. Мефодий христиан динен тота икән ләбаса! Тик аны нигә яшерергә? Нигә алдашырга? Нигә икейөзләнергә? Ялган барыбер бер тотыла ич ул. Болай итеп Иванов тәгълиматының абруен гына төшерә ич. Остаз үзе үк: "Әгәр миннән дин ясыйлар икән, минем эшем оттырачак",—дип язып калдырган ләбаса.

Заһидә башын учларына салып, озак кына кымшанмыйча да уйланып утырды. Инде барысы да ачыкланды. Ул, әлбәттә, Мефодий белән яшәмәячәк. Әле ярый язылышмаганнар иде. Күрәсең, бу никах алдан ук таркалуга дучар ителгән булган.

Мефодий сөякләре шыгырдаганчы киерелеп алды. Җөнтәс каш-лары арасыннан төймә шикелле түм-түгәрәк күзләре шәйләнде.

—Коенырга вакыт җиткән ахры,—дип сәгатенә үрелде. Алар һәр көнне парлашып сәгать алтыда коенырга чыгалар иде.

—Бүген үзең генә коенырсың инде,—диде Заһидә тыныч булырга тырышып. Аның Мефодий белән тату гына аерылышасы килә иде. Булганы—булган, аны хәзер кире кайтара алмыйсың. Кәшшафны рәнҗеткәненә дә әле һаман борчылып йөри. Мәрхүмә Маһинур апа беләнниләр булып бетмәде. Һаман тавыш-гауга. Югыйсә, омтылышы гел игелектә үзенең, гамәле генә ничектер кыек килеп чыга.

Мефодийның колаклары шәлперәйде. Димәк, ниндидер гадәттән тыш хәл килеп туган. Иванов тәгълиматының һәр хәрефен җиренә жит-кереп үтәүче турылыклы шәкерт авызыннан мондый сүзнең чыгуы бик сәер иде.

—Әйт әле, Мефодий, синең минем алда намусың сафмы?—дип текәлде ана Заһидә.—Фәкать дөресен генә әйт, ялганламыйча гына!

Мефодийның куллары муенындагы тәрегә үрелде. Ул урынында иде.

—Син шушы хактамы?—диде һәм Заһидәнең җавабын да көтмичә үзе һөҗүмгә күчте.—Син инде мине фаш итәм дип уйлыйсың. Ялгышасың. Теләсәм үзеңне фаш итә алам. Мин сине җүләр дип игълан итсәм—миңа ышаначаклар!

—Хәзер үк күземнән югал, башка монда эзең булмасын,—диде Заһидә. Тагын нидер өстәмәкче иде дә, тотлыгып калды.

—Мин болай да Наталья янына күченә идем инде,—дип, иреннәрен очлайтты Мефодий,—ул синнән мең өлеш артыграк.

* * *

Заһидә Остаз белән араны өзде, мәчеткә йөри башлады. Әле дә мәчеттән кайтып килеше иде. Кәшшафның аны танымавы да гаҗәп түгел. Чөнки Заһидәнең килеш-килбәте бик нык үзгәрде. Башы бөркәүле, өстендә аяк йөзенә төшеп торырлык итеп тегелгән озын авыр күлмәк, җиңле камзул, аягында бизәкле читекләр.

Кәшшафлар инде күптәннән кешеләр арасында эреп юкка чыктылар. Ә Заһидә һаман шул якка карап басып тора. Күр, Кәшшафны ярата икән ич ул. Бу ачышы аны ни өчендер канатландырып җибәрде. Дөресе дә шулай ич! Башка берәүдән дә Кәшшаф күрсәткән кадер-хөрмәтне күрмәде ул. Сөйде дә, сөелде дә. Кәшшаф шикелле самими, хисле, яраткан кешесен әүлия дәрәҗәсенә күтәрүче хыялый затлар сирәк алар.

Заһидә күптән түгел генә бер журналда үзенең иң яраткан киноактрисасы Татьяна Самойлованың әңгәмәсен укыган иде.

—Сез ни өчен Лановой белән аерылыштыгыз, мәшһүр шәхес, бөек артист, бер-берегезгә бик туры килә идегез бит,—дип сорый корреспондент.

—Мәхәббәт сүрелде,—дип җавап бирә актриса.

—Мәхәббәт нәрсә соң ул?—дип сорый корреспондент.

—Дәрт. Женесләрнең тәңгәл килүе, ир-ат белән хатын-кыз затының берлеге. Мәхәббәт ул—хис. Ә хис үтәргә мөмкин, суынырга, бетәргә, янә кабынырга...

Заһидә әнә шул халәтне кичерә иде.

* * *

Көзен Казанда җәйгә алыштыргысыз ямьле көннәр була. Башлыча бу әбиләр чуагының соңгы көннәренә туры килә. Һава чистара, күк

биегәя, кояш тәүге мәртәбә күкрәгенә гыйшык күбәләге кунган яшь кыз шикелле нурга чума.

Менә шундый матур иртәләрнең берсе иде. Рамил күтәренке күңел белән йокысыннан уянды. Озак кына тәрәзә пәрдәләре арасыннан сузылган яктылык тасмасын күзәтеп ятты. Бүлмә эче жем-жем итеп тора. Тузаннар алтын бөртекләргә әверелгән, кояш яктысында уттай янып уйнашалар.

Рамил, гадәттә, озын-озак экспедицияләрдән кайтканнан соң тоя иде мондый күтәренке халәтне. Эш вакытында археолог кайда жае чыга, шунда ятып йоклый, еш кына цивилизация кагыйдәләрен дә бозарга туры килә. Шуңа күрә өйгә кайткач, беренче көннәрне ак япмалар бөркәнү ничектер сәеррәк тә тоела. Бүген исә—андый сәбәп тә юк кебек иде. Дөрес, ул кичә генә егетләре яныннан кайтты. Алабугада казыну эшләрен янадан башлап жибәргәннәр иде.

Алабуга—археологлар өчен бетмәс-төкәнмәс хәзинә оясы. Борынгы мәчет нигезенә тап булганнан соң аеруча очынып эшли башладылар. Гади генә мәчет түгел, алты манаралы ныгытма рәвешендәге мәчет ул. Гарәп дөньясында мондый мәчетләрне Ислам дине таралган чорда, VIII–XI гасырларда төзегәннәр. Гарәп эзе Алабуганың борынгылыгына ишарә итә. Су юллары буйлап гарәпләр Алабугага да килеп житкән булырга мөмкиннәр. Иделдә сәүдә юлын Казан саклап тора, Чулманда шул вазифаны Алабуга үтәгән дигән фикер инде баш күтәреп килә. Бу әлегә фараз гына. Ләкин нигезле фараз.

Бер-ике көн эшләүгә Рамил нигәдер тынгысызлана башлады. Юккабарга бәйләнә, гаеп таба, орыша. Акылы белән ул үзенең хаксыз икәнлеген аңлый да кебек, тик тыела алмый. Хезмәттәшләре дә аптырады. Әмма күрмәмешкә, белмәмешкә салындылар. Тормышта ни булмас, ихтимал, сырхауланып киткәндер, йә башка сәбәбе бардыр?

Рамил үз хәлен үзе белеп, Казанга кайтып китте, бер-ике көн жилләнеп килим әле дип уйлады. Шөкер, әлеге халәте үтте. Бүген, әнә, кәефе күз тимәсен, бөтенләй башка, өй һавасы килеште үзенә. Иркә хатын шикелле шактый ара ятагында назланып ятты ул. Әле тагын да яткан булыр иде, телефон шалтыравы комачаулады. Тора-торышка жилкәсенә халатын элде дә ишек катына чыкты. Кәшшаф икән. Алар кичә сөйләшкәннәр иде инде. Дусты аны Аккош күле буена ял итәргә чакырган иде. Рамил ризалыгын бирергә ашыкмады, төнне үткәрик әле, аннан соң күз күрер, диде.

—Профессор галиҗәнапләренең борынын черки тешләгән дигәннәр иде, жә, ничек, операция уңышлы үттеме?—дип жорланды Кәшшаф.

—Батый тешләренне коймасын, сак бул,—диде Рамил,—йөрерсең карт алаша сыман иреннәренне шәлперәйтеп.

—Аңлашылды,—диде Кәшшаф,—борынына зыян килмәгән икән, кайда очрашабыз?

—Тукай һәйкәле янында.

Рамил спорт костюмыннан иде. Күкрәк турысына симез хәрефләр белән "Adidas" дип язылган. Башында вертолет төшеп кунакларлык зур күрикле заманча кепка, аякларында шул ук фирмада эшләнгән кедалар. Аның гәүдәсе дә спортчыларныкы кебек жиңел. Шуңа күрә киемнәре сылап куйгандай бик иплe утыра.

—Бик ыспай күренәсең, бүген Аккош күле буендагы кызларның күзе синдә генә булыр инде,—диде Кәшшаф.

—Мин моңа һич тә каршы түгел,—дип елмайды Рамил.

—Каршы булмасаң бик хуп, инде кибеткә сугылып чыгыйк.

—Аккош күленең үзендә дә кибетләр күп, ресторан да бар.

—Профессор кеше бай була инде ул, минем үземнең кесәдә, әйтик, жилләр уйный.

—Алайса нигә ял, ял, дип, жаныма тидең соң?

—Мин ипикәйгә саф һава ягып, сыра чөмербез генә дип уйлаган идем...

—Ярар, җорланма, маршрутыңны әйт.

—Дүртенче троллейбус белән Физкультура институтына кадәр барабыз, аннан соң автобуска кереп утырып, туп-турыга Аккош күленә тү-түт...

Көн матур булса да, ял итүчеләр күп түгел иде. Күрәсең, җәй үткәч, кешеләрнең башка ихтыяҗлары барлыкка килгән. Дуслар моңа сөенделәр генә.

Аккош күленең күк гөмбәзен кытыкларлык булып үскән төз биек чыршылары хозурында дөнья бөтенләй башка. Монда археологиягә дә, Алтын Урдага да урын юк. Ашказанына затлы сый белән бер рюмка коньяк та кереп оялагач, дусларга тирә-юнь ал төскә манчылгандай булып тоела башлады. Ә йомгактай чуалган борма-борма сукмак аларны Зәңгәр күл янына алып килде. Күл, чыннан да, зәңгәр иде. Рамил кычкырып шигырь укырга тотынды.

Зәңгәр һава, зәңгәр һава,
Зәңгәрләтә диңгезне.
Зәңгәр диңгезләрдән эзлим,
Бик сагынсам мин сине...

Дуслар бу көнне Аккош күле урманын аркылыга-буйга инләделәр, болай ачылып, болай тәфсилләп сөйләшкәннәре юк иде әле аларның.

—Көн бик матур үтте,—диде Рамил,—рәхмәт сиңа, сагынып сөйләрлек булды бу.

—Башта шундый матур планнар бар, малай, кул кычыта, әллә нәрсәләр майтарып ташлыйсы килә. Мин хәзер татар милләтенең бөеклеген исбат итү өчен бөтен алшартлар бар дип исәплим. Җәмгыятьне дә үзебезнең якка каратасы иде. Ул вакытта аерым бер төркемнең генә сүзе сүз булмас. Шәхси мәнфәгатьләрне читкә куеп торасы иде. Каюмов әйтмешли, берләшәсе, дуслашасы иде.

Икенче зур хыялым—Алтын Урданың башкаласы Сарай-Бату хәрабәләрен өйрәнү, шунда айлар буе куна-төнә яту. Егерменче елларда Сарай-Бату һәм башка шәһәр урыннарында казу эшләре алып барган профессор Баллод сукмакларыннан үтәсем килә. Ул юкка гына Сарай-Батуны “Идел буе Помпее” дип атамаган. Аның бу китабы алтын бәһәсендә йөри, көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба торган түгел. “Ефәк юлы” да Алтын Урда чорына туры килә ич. Менә сиңа кыргый халык? “Чыңгыз ташы”н энәсеннән-җебенә кадәр өйрәнәсе иде. Урыслар аны кузгатып дөрес эшләмәгәннәр дип уйлыйм. Торсын иде үзенең куелган урынында, Байкал буенда. Шунда ачык музей оештырырга мөмкин булыр иде.

—Давыт бабаң колагыңны борыр.

—Алай димә, Кәшшаф, Алтын Урда мәктәбенә Герман Алексеевич Федоров-Давыдов нигез салды, аны ныклап өйрәнүне алтмышынчы елларда академик Тихомиров белән алар башлап җибәрде.

—Урдага ия күбәйде хәзер, үзбәкләр дә, казах, нугай, кумык, хәтта хохоллар да,—диде Кәшшаф.

—Шулай да Алтын Урда мирасының төп варисы без, татарлар!

—Шуңа күрә 1959 елга чаклы татарларның авызын да ачырмадылар.

—Ярар, гел кирегә сукалап утырма, әле,—дип, Рамил Кәшшафны ачуланып ташлады.—Алары үткән инде, хәзергесе хакында кайгыртырга кирәк. Үзеңнең диссертациянне тикшергән җыелышны исеңә төшер. Бик гыйбрәтле фикерләр янгырады.

—Беләм, мин болай гына,—диде Кәшшаф.

—Син минем янга Алабугага киләсеңдер ич,—диде Рамил автобустан төшкәч.

—Дүшәмбе белән пәнҗешәмбедә лекцияләрем бар, шуннан соң бушыйм. Бәлкем, Мазһарны да кодалармын әле, ул тәмле балыкларыңны безгә дә авыз иттерерсең, шәт.

—Син сыйланырга гына киләсең мени? Эшләргә киләсең дип уйлаган идем.

—Тәмлерәк ашатсаң, күбрәк эшлим мин.

Саубуллашып һәркайсы үз юлына китеп барды. Бу аларның соңгы күрешүе булган икән.

* * *

Лекциядән соң Каюмов Кәшшафны кабинетына чакыртып алды. Кәефе шәптән күренми иде профессорның. Мыегы күсе койрыгы шикелле асылынып төшкән. Күзләре кырыс.

—Утырыгыз,—дип, Кәшшафка урын тәкъдим итте, ә үзе тавык кетәге чаклы гына бүлмәсен адымлый. Стенадан аны Лев Гумилев портреты күзәтеп тора.

Профессор чираттагы уравында өстәл өстендәге бер кәгазьне сузылып алды да, Кәшшафның күзләре алдында селкеп торды.

—Галимов галиҗәнапләренең мөхтәрәм президентыбызга Гыйльми совет өстеннән язган шикаяте. Кайсыдыр ки, без Гуманитар институттан куылган Кәшшаф Газиз улы Хәмитов дигән булдыксыз һәм җәнҗалчы галимнең диссертациясен яклатуны үз өстебезгә алганбыз. Аңа һәртөрле булышлык күрсәтәбез.

—Мөхәррәм Мирсалихович, сезгә авырлык китерә торган булса, диссертациянне кире кайтарыгыз, әле соң түгел.

Каюмов аны күз карашы белән өттереп алды.

—Акыллы башыгыз белән ничек шундый акылсыз киңәш бирергә җөрьәт итәсездер, белмим. Мин сезне бөтенләй аның өчен чакырмадым. Командировка алып, иртәгәдән Мәскәүгә чыгып китегез, институтка керЕп барын да белешегез, Югары аттестация комиссиясенә сугылып чыгыгыз, гыйльми оппонентларыгыз белән сөйләшегез. Эшне сузарга ярамый. Сез урап кайткач, конкрет датаны тәгаенләрбез. Галимовка рәхмәт, ул безне итәк-чабуларыбызны җыеп йөрергә, җебеп төшмәскә өйрәтә.

Бу хәбәрдән соң Кәшшафның башына килгән беренче уй: "Рамил үпкәләр инде",—дигәне булды. Йөрәге нигәдер сызылып китте.

Инде билет хәстәрен күрергә кирәк иде. Ашыкканда лифтына кадәр аяк чала бит аның. Тоташтан өчесе тулып килде, аннан соң тоткарланып торды. Лифтның үзен күтәреп чабарлык хәлгә җитте Кәшшаф.

Лобачевский урамыннан төшеп барганда ул кемнеңдер карашын тойды. Таныш, йомшак караш. Кем булыр бу? Тик хәзер аның берәү белән дә тел кашып тора торган вакыты түгел. Ә караш ярамыйга карамый, баш чүмечен җылы нуры белән иркәләвен дәвам итә. Бу, һичшиксез, хатын-кыз булырга тиеш.

Кәшшаф артка борылып, як-якка күз салды. Һәм төрек хатын-кызларына охшатып киенгән бер мөслимәне шәйләп алды. Таныш та кебек үзе, аяк атлауларына кадәр якын.

—Исәнме, Кәшшаф, җитешеп тә булмый, очасың гына,—дип аваз салды, ниһаять, җылы караш иясе.

—Заһидә, синмени бу?

Кәшшафның тавышы Заһидәнең күңеленә нәфис моң булып яттьы. Сагышының тирәнлеген, хаталарының рәхимсезлеген тагын бер кат тоемлап алды. Ничек ярата икән ул Кәшшафны! Теге чакта мәхәббәтенең янаруын Заһидә Аллаһы Тәгаләнең фарыз гамәле дип кабул итте. Ә бу дөньяда бар нәрсә дә Аллаһының кушуы буенча гына башкарыла. Бар горурлыгын тыеп, Кәшшафны сагалап йөрүенең дә сәбәбе шул иде.

—Танымый да торам, син бик үзгәргәнсең,—диде Кәшшаф. Үзе тутырып Заһидәгә карап алды. Элекке хисләренең әсәре дә калмаган бугай. Заһидәнең матурлыгы ана сабын тышындагы җансыз рәсемне генә хәтерләтә иде. Ул аны хәзер очындырмый да, җилкендерми дә.

—Мин Аллаһ юлына бастым,—диде Заһидә.

—Ә Мефодий?—дигән сорау Кәшшафның авызыннан үзеннән-үзе ычкынды?

—Без инде бергә яшәмибез,—диде Заһидә үртәлмичә генә.

—Мине ашыгыч рәвештә Мәскәүгә җибәрәләр, билетка барышым иде, гафу.

—Улың үзенә охшаган икән,—диде Заһидә.

—Заһидә, мин бик ашыгам, әле күрешербез.

Кәшшаф йөгерә-атлый китеп барды.

Заһидәнең күзләреннән ике бөртек яшь сытылып чыкты да түшенә тамды. Сүзләре бик күп иде аның Кәшшафка. Төшкән баласы турында да әйтмәкче иде, башкасы турында да. "Мин синсез яши алмыйм, никах укытыйк",—димәкче иде. Насыйп булмады. Хәер, Аллаһының рәхмәте киң, әйтер әле.

* * *

Волчек бүлмәсендә башка мөдир утыра иде инде. Балык күзле, кыска муенлы Кәшшаф яшьләрендәге бер кеше. Үз-үзеннән бик канәгать булырга охшый. Кычкырып сөйләшә, юкка-барга да авызын тутырып шаркылдап көлә. Волчекка охшап та карамаган. Волчек мыжык булса да беренче чиратта фән кешесе иде. Капризлары да фәнгә бәйле иде.

Яна мөдир яна Россиянең Ельцин куйган кадрларыннан булса кирәк. Волчек, Ашказарский кебекләрне идея дигән канатлы ат ашкындырып тора иде. Югары идеяләр белән яшәү коммунизм калдыгы дип игълан ителгәч, су өстенә калкавыч шикелле былт итеп меркантель хаҗәтләр калкып чыкты. Һәм аны хәзер яшереп торуны да кирәк санамыйлар. Мәрхүм Дмитрий Олегович теге вакытта Кәшшаф алып килгән бүләк бүрекне кунакханәгә үк китертеп бирдергән иде. Хәзер бүрек ише вак-төяк, утка чыдам чәй савытлары белән генә Мәскәү түрәләренең күңелен кузгатырмын димә. Сәркәтип кыз, әнә, конфет тартмасыннан да йөз чөерде һәм ачыктан-ачык әйтеп салды:

—Без конвертлар гына алабыз, Петр Петровичка дигән конвертыгызны менә бу тартмага салыгыз.

Кәшшаф башта моны шаярту дип аңлады. Шуңа күрә конфет тартмасын көчли-көчли кызга тоттырды. Аның бәхетенә, нәкъ шушы вакытта ишектә Петр Петрович Петров үзе күренде.

—Һо, әфәндем, Мәскәү чибәрләрен хәзер конфет белән генә үзенә каратып булмый,—дип елмайды мөдир.

—Мин Казаннан, Хәмитов булам,—дип үзе белән таныштырырга ашыкты Кәшшаф.—Герман Алексеевич кушуы буенча.

Мөдир ияген чөеп, бермәл түшәмгә текәлеп карап торды. Бөтен дөньяга билгеле галимнең исеме дә ана тәэсир итмәде. Һәрхәлдә, ул аны күрсәтергә ашыкмады.

—Татар тарих дәгъвалыймы?—диде Петров бүлмәсенә кереп, гәүдәсен йомшак кәнәфигә чумдыргач. Бу аның мыскыл итүе идеме, шаяртуымы, анысын Кәшшаф аңламады.—Ярый, без Алтын Урданы бирергә риза,—дип дәвам итте ул,—ләкин сез рәсми рәвештә татар-монгол изүенең җаваплылыгын да үз өстегезгә алырга тиешсез.

—Рус дәүләтенең Алтын Урда канаты астында ныгуын да онытмагыз, Петр Петрович,—диде Кәшшаф.—Лев Николаевич Гумилев язганча, "урыс олысы" Алтын Урданың бер төбәге генә булган. Хәтта бәйсез Смоленск та, Литва явыннан яклау табу өчен, үзен Җуҗи олысына алуны үтенгән.

—Болар бернинди тарихи чыганаклар белән дә исбатланмаган буш фаразлар гына,—дип үзе башлаган сүзгә үзе нокта куйды Петров.

"Иван Грозныйның вәхшилеге өчен руслар татар халкы алдында гафу үтенделәрме соң?"—дип мөдирнең авызын капламакчы иде дә Кәшшаф, түзде, әйтмәде, мондый җаваплы чорда мөнәсәбәтләрне кискенләштерергә ярамый.

—Минем үтенечне беләсездер инде,—диде Кәшшаф,—докторлык диссертациясен төгәлләдем, монографиям дә чыгып килә.

—Оппонент мәсьәләсен һәр галим үзе хәл итә. Моны сез беләсездер, әлбәттә. Тик шунысын да өстик, хәзер элекке шикелле бушка йөрүләр бетте. Мәскәү галимнәренең сүзе бик бәһале. Спонсорыгыз бардыр бит? Тагын бер яналык, без доллар системасына күчтек. Баш фәнни учреждение буларак, институтның диссертациягезгә кагылышлы нәтиҗәсен тиздән алырсыз.

Кәшшафның эчендә нидер өзелеп төште сыман.

—Спонсорлар гына табарбыз,—дип, мөдирне тынычландырырга ашыкты.

Бу очракта Кәшшаф сабакташы Зиннурны күз уңында тотты. Бергә үстеләр. Бик булдыклы малай иде. Оста кул. Ниләр генә уйлап чыгармый, ниләр генә ясамый иде. Агачтан пулемет дисеңме, сырлап-бизәкләп эшләнгән бала арбалары дисеңме, бөтен тирә-якта дан тота иде. Соңыннан велосипед шикелле аяк белән әйләндереп йөри торган дүрт тәгәрмәчле ябык машина әмәлләде. Инженер булыр бу дип юрадылар аның киләчәген. Үзе дә шуңа хәзерләнде. Мәскәү нефть институтын кызыл диплом белән тәмамлады. Тора-бара оештыру сәләте дә ачылды. Хәзер зур бер нефть берләшмәсендә баш инженер булып эшли. Бик абруйлы белгеч.

Зиннур очрашкан саен, бер-бер ярдәмем кирәкмиме дип сорый. Авылга мәчет салдырып куйды. Башта: "Үзем акчасын бирәм, аен син ясат",—дип ялынган иде. Ялган була бит бу, дип, Кәшшаф ризалашмады. Чыннан да, Аллаһ йортында да гаделлек булмаса, кайда булыр соң инде ул?

Константинов дигән профессор рәсми оппонент булырга ризалашты. Дөресрәге, элек биргән ризалыгын яңартты. Дөрес, алар арасында фикер каршылыклары да бар. Әйтик, Константинов Алтын Урдага татарлар белән бергә бер үк дәрәҗәдә казахлар да, башкортлар, үзбәкләр, аварлар, балкарлар да дәгъва белдерә алалар дип саный. Алтын Урдага, дәүләт буларак, Каспий буенда, Кавказ итәгендә, Урта Азия куенында нигез салына башлаган, дип исәпли. Идел буена алар сугыш белән килгәннәр. Ә Идел буеның төп халкы болгарлар булган. Татар—болгарның дошманы. Аларны Ислам дине генә татулаштырган. Исламны да беренче булып 737 елда хазарлар кабул иткән. Тәүге азан Хазар каганатының башкаласы Итил каласында яңгыраган.

Мәскәүдә яшәүче татар тарихчысы Борһан Акъегет тә Казанга гыйльми советка киләчәген раслады. Акъегет үтә җете карашлы галим, "болгарчы"ларның кан дошманы. Чөнки ул болгарларны чувашларның ата-бабалары дип саный. Болгарларның бер өлеше ислам динен кабул итеп, "татар"га кушылган, икенче өлеше чуваш милләте булып оешкан, дип расларга ярата.

—"Болгар"чылар үзләрен шул халыкның калдыгы дип исәплиләр икән, мәрхәбә, чуваш милләтенә кушылсыннар,—ди ул үзенә бер катгыйлык белән,—ә татарны бүлгәләргә ирек бирергә ярамый. Безнең төп максат—татар милләтен оештырып бетерү процессын төгәлләүгә шартлар тудыру.

Борһан Акъегет гомум татар халкы оешуны аерым чорларга бүлеп карый. Алтын Урда чоры; күчеш чоры (XVI—XVII гасыр); оешу-берләшү чоры (XVII гасыр). Кәшшаф исә мондый бүленешләрне кабул итми. Халык оешу даими процесс, ул бүген дә дәвам итә. Иртәгәгә дә, берсекөнгә дә туктамаячак. Алтын Урданың төп роле шунда, әлеге дәүләт төрки телле халыкларны, аерым алганда, татарларны, кыпчакларны, нугайларны укмаштырып (мона элекке хазарлар да керә), бинһаят зур казанда кайнаткан. Шул рәвешле татар халкы "пешеп" чыккан, кайсыларындыр үзенә йоткан, бәгъзеләрен читкә этәргән.

Инде Зиннурдан долларлар гына теләнәсе калды.

Кәшшаф арып-алҗып караватына кайтып ауды. Төнен Рамил белән саташып чыкты. Имеш, ниндидер бакча эчендә йөриләр. Янында гына бик зур кара миләш агачы үсеп утыра. Ябалдашлары җиргә салынып төшкән. Кый җимеш. Мәмрәп пешкәннәр. Авыздан сулар килә. Рамил дә сусаган ахры, шул миләшләргә мөлдерәп карап тора. Ләкин үзе

нигәдер җимешләргә үрелми. Кәшшаф учына берничә миләш алып, дустына сузды. Рамилнең йөзе кара янып чыкты.

—Татып кара инде, телеңне йотарлык,—дип кыстады Кәшшаф. Рамил сүзсез генә миләшне авызына капты. Һәм шул ук мизгелдә дөбер-шатыр килеп җир убылып төште. Рамил күздән югалды.

Кәшшаф тирләп-пешеп уянып китте. Күп йөрелде, арылган, дип уйлап куйды. Әллә нинди тузга язмаган төшләр керә башлады. Хәер, төш түгел инде бу, саташу.

Саташу түгел—төш, һәм мәгънәле төш икәнен Казанга кайткач кына төшенде Кәшшаф. "Татарстан" поездына билет булмады, шуңа күрә Мәскәүдән кич-кырын гына кайтып төште.

Юлдан соң юынып-ясанып йөргәндә ишек шакыдылар. Кәшшаф сөлгесен муенына элеп, ишек катына юнәлде. Күрше әби икән. Почта тартмасыннан ул аның гәҗит-журналларын алып тора, шуларны кертkән.

—Хәдичә әби, әйдә, узыгыз, Мәскәүдән күчтәнәчләр алып кайттым,—дип, Кәшшаф аны фатирына кыстады.

—Китчәле, апаем, юкны сүләмә, болай да гелән тәм-том белән сыйлап кына торасың, әнәтрәк,—дип карчык олавы белән Актаныш сөйләмен аударды.

Кәшшафка бу диалект ошый, кайчак Хәдичә карчыкны кызык өчен генә дә сөйләндереп тора. Җырга тартым көйле сөйләм. Сүзләре дә озынча, авыз тутырып әйтмәле: бармаем, кайтмаем.

Кәшшаф күчтәнәчен карчыкның кулына тоттырды.

—Бәрәч, бик рәхмәт балам, Ходай үденне дә сөендерсен,—дип, карчык теләкләрен теләде.

Ашап-эчкәч, Кәшшаф канәфигә кырын ятып, үзе Мәскәүдә вакытта чыккан татар гәҗитләрен караштырырга тотынды. Ләкин игътибарны җәлеп итәрдәй кызыклы мәгълүматка тап булмады, барысы да гадәти иде. Баш түрәләр кая барганнар, кем белән очрашканнар, кемне кабул иткәннәр—барысын да бәйнә-бәйнә теркәп баралар. Эшләр болайга китсә, озакламый бәдрәфкә йөрүләрен дә яза башлардыр, мөгаен. Татар матбугаты яраклашырга күнеккән. Берәр вакыт ул бу чиреннән арына алырмы, юкмы, моны Ходай үзе генә белә.

Кәшшаф кулына соңгы санны алды. Беренче битләрдә күзләре тоткарланмады. Ачуы чыгып, гәҗитне идәнгә тондырам дигәндә генә бик якын таныш йөзне күреп алды. Ул кара рамкага алынган иде. Рамил ләбаса бу! Кәшшаф берничә минут иләс-миләс булып аңышмыйча торды. Аннан соң чалгы йөзенә баскандай урыныннан сикереп торды. Бу мөмкин түгел! Юк! Сон әле алар узган атнада гына Аккош күлендә кәеф-сафа корып йөргәннәр иде ләбаса! Киләчәккә матур-матур планнар корганнар иде...

Кәшшаф тагын бер мәртәбә мәрсиягә күз йөртеп чыкты. "Фаҗигале үлем" дигәннәр. Нинди фаҗига икән ул? Их, Рамил, Рамил, җан дустым! Мин бит Алабугага синең янга барырга тиеш идем. Без бит әле Кама буенда балык шулпалары пешереп ашарга килешкән идек. Мин казу эшләрендә катнашырга тиеш идем.

Әгәр Кәшшаф Алабугага барган булса, фаҗига булмый калган булыр иде ләбаса! Дустының үлемендә ул да гаепле.

Кәшшаф күз яшенә төелеп йөзтүбән диванга ауды. Ирексездән бөтен күзәнәкләренә кадәр яшь тулышты. Еласа җиңелрәк булыр иде дә соң, юк, күңеле тораташ булып каткан. Шулай нәүмизләнеп ята торгач, башына Мәскәү кунакханәсендә күргән төш килеп ябышты. Шунда гына бу төшнең мәгънәсенә төшенде.

Кәшшаф, ниһаять, Мазһарны күреп сөйләшергә кирәк, ул барысын да белә булыр дигән карарга килде.

Мазһар, әйтерсең лә, аны көтеп кенә торган. Кыңгырау шалтырауга ишекне ачты. Кәшшаф дустын кочаклап алды. Шактый вакыт ишек катында шулай басып тордылар.

—Кайчан?—дип сорады Кәшшаф яше кибеп бетмәгән тавыш белән.
—Сишәмбе көнне
—Машина таптаганмы?
—Юк, Камада көймәсе капланган Матәм жомга көнне булды.
—Нигә мина хәбәр итмәдегез?—диде Кәшшаф үпкәсен белдереп.
—Сине Мәскәүдән ничек табасың ди, эскерттән энә эзләү белән бер ич бу.

* * *

Рамилнең фажигасен Кәшшаф бик авыр кичерде. Эштән гаме китте, хәтта кулына китап та алмый башлады, ә ул китап корты иде. Ябыкты, суырылды. Һаман үзен гаепләде, әгәр мин Алабугага барган булсам, бу хәвеф булмый иде, дип өзгәләнде.

—Авылга әниең янына кайтып килер идең, Кәшшаф,—диде ана бер көнне Мазһар,—сиңа бераз жилләнеп алырга кирәк. Чынлап әйтәм, бик жаваплы чорың бит, диссертацияң ярты юлда калмаса ярар иде дип куркам.

Кәшшаф башта йөзен чыткан иде дә, соңыннан күнде тагын, тиз-тиз генә жыенды да юлга чыгып китте. Моннан алда гына туңдырган иде. Лычтыр-лаштыр килеп торган авыл урамнары шакылдап туңды. Сулы жирләр көзгегә әверелде. Бала-чага шунда чыр-чу килә. Аяк асты корыды, ләпек ерып йөрүләр бетте.

Кәшшафның иң сөймәгәне—авылның баткаклы урамы. Янгыр яудымы, жәй көннәрендә дә урамнан машина белән үтәрмен димә. Кайтасың да, урам пычрагына кереп тә чумасың. Бу кайтуында исә, кара көз булуга карамастан, Кәшшаф бернинди тоткарлыксыз капка төбенә кадәр үк килеп туктады.

Ишек алды, гадәттәгечә, чиста иде. Кәшшаф күзләре белән әнисен эзләде. Күренмәде. Өйдәдер, мөгаен, сюрприз ясыйм әле үзенә, дип елмаеп куйды. Иплэп кенә капканы ачып, иплэп кенә машинасын ишек алдына кертте дә ауга чыккан жанвар шикелле йомшак кына атлап ишек катына килде. Ә анда ат башы чаклы йозак эленеп тора иде. Менә хикмәт нәрсәдә икән? Өйдә булса, әллә кайчан атылып чыккан булыр иде, билгеле. Күршеләрдәдер. Алай дисәң, ишеккә йозак салган. Әйдә, кайтыр әле, авылдан чыгып китмәгәндер.

Кәшшаф абзар-кураларны караштырып йөрде. Туза башлаганнар икән инде. Бигрәк тә бакча белән ишек алды арасындагы койма бетерешкән, баганалары төртсәң аварга тора. Иртәгә беренче эш итеп шуларга тотынырга кирәк булыр дип күнеленә салып куйды. Хәмит тә булышыр. Бәлкем әле баганалыклары да бардыр. Өч-дүрт жепсә дә кирәк булачак икән. Кар базының өскормасы турында элек тә сөйләнә иде әнисе, янгыр үтә дип зарлана иде. Яптырган икән инде, аны күтәп тормаган. Бик чырыш инде анын әнисе. Ватык-жимерекне һич яратмый. Өс-баш та пөхтә булсын, йорт-жир дә.

Шылтырап капка келәсе ачылды. Шунда ук әнисе дә күренде. Ул башта күзләрен челт-челт йомгалап, аптырабрак басып торды. Улын күргәч кенә ачылып, балкып китте. Кәшшаф йөгереп барып аны кочаклап алды.

—И-и, кара инде, гомер эчендә бер тапкыр биләмгә чыккан ием, анда да тотылдым,—дип сөйләнде Мәмдүдә.

—Әни, төплекәй пешерерсен әле, жәме!—дип пышылдады Кәшшаф анын колагына, әйтерсен лә, нинди дер яшерен сер житкерә иде.

—Пешерермен, пешермичә теге, төплекәен дә пешерермен, бәлешен дә салырмын... Хәзер, әйдә, улым, өйгә керик, чәй куеп жибәрәм, хәл алырсын. Анын: "Нигә үзен генә кайттын, килен белән Кәримне ник алып кайтмадың?"—дип тә сорыйсы килә. Тик бу аяк өсте генә сөйләшә торган сүз түгел. Ачуланышуларына да байтак бит инде, һаман татулашмаганнар икән әле, баланы ятим итмәсәләр ярар иде, Ходаем.

Чәй янында Кәшшаф кайгысын сөйләп алды. Әнисе аны чын

йөрәгеннән әрнеп кабул итте, хәтта килене белән оныгы турында сораштыруны да кичектереп торырга булды.

—Гаиләсе ятим калган икән.

—Әнисе белән генә яши иде.

—Ходай түземлекләр, сабырлыклар бирсен.

Өстәлнең бер кырыенда самовар җырлап утыра, кызыл ашъяулык өстендә кабарып пешкән түгәрәк ипи. Шунда ук атланмай җамаягы. Ап-ак итеп акшарланган мичтән җылы бөркелә. Барысы да нәкъ балачагындагыча, өем-өем өелгән ястык-мендәрләр дә, олы бизәкле чаршаулар да... Әнисе генә олыгая төшкән. Тик барыбер көмештәй ак чәчләре, аркасына җәеп салган зур кәшимир яулыгы, маңгаена сызылган сырлары ничектер үзенә килешеп тора. Күзләре элеккечә үк шәфкатьле, куллары элеккечә үк йомшак.

Кәшшафка әнисе янында бик рәхәт иде.

—Улым, бераз таянып тор,—дип, әнисе ул утырган сандык өстенә мендәр салды, аяк очына урындык китереп куйды. Ул сандыктан озынрак шул инде. Ләкин Кәшшафка назланып ятарга туры килмәде, ишектән аю кебек дөп-дөп басып Хәмит килеп керде.

—Бик вакытлы кайткансың, яшьти, балыкка барырга җыенган идем, кулдаш булырсың, әйдә, җыен,—дип чабатадай олы кулын Кәшшафка сузды.—Исән-сау гынамы, бу араларда бер дә күзгә-башка чалынмадың.

—Исәнме, Хәмит, үзең ни эшләр майтарып йөрисең?

—Балыгыннан булырмы, бакасыннан булырмы, дип әйләнгәлибез инде шунда. Авыл җиренең шул инде аның.

Мич янында камыр басып кайнашкан Мәмдүдә башын күтәрде.

—Җитешмәгән җире юк ул безнең Хәмитнең, гел игелек юлында, рәхмәт төшкере, мине дә ярдәменнән калдырмый.

Мәмдүдә камыр белән эшен бетереп, самоварга тотынды, ләкин Хәмит каршы төште.

—Юк, Мәмдүдә апай, мәшәкатьләнмә, без яшьти белән чәйне су буенда эчәрбез. Кузгалырга вакыт, юкса балыклар үпкәләр.

—Салкын түгелме соң?—дип шикләнүен белдерде Кәшшаф.

—Балык салкынга карамый ул, аның үз дөньясы. Ә сина җылырак, авылчарак киенергә кирәк булыр.

Юлда бүксә-бүксә кәс йомарламнары тырпаеп ята. Хәмит аларга игътибар да итми, элдертә генә, Кәшшаф аның артыннан көчкә житешеп бара. Шулай аллы-артлы күл буена килеп җиттеләр. Халык аны Каз күле дип йөртә. Элек бу тирәләрдә зур әрәмәлек булган дип сөйлиләр. Киекжанварның исәбе-саны юк икән. Бигрәк тә кыр казлары үз иткән бу якларны. Көзен жылы якларга китәр алдыннан күлдә туктап, ял итеп ала торган булганнар. Күлнең исеме дә шуннан килә, имеш.

Хәзер әрәмәлекләр юк инде, сөреп бетерделәр, иген уңышын күтәрәләр, янәсе. Сазда икмәк уңамы соң? Купъеллык үлән дә чәчеп карадылар. Анысы да тернәкләнмәде. Инде ташландык җир булып ята, ярасы һаман төзәлми.

Каз күленә күптәннән казлар төшми. Ә балыгы, тота белсәң, азмыкүпме әләгә икән әле.

Күлнең тагын бер аерымлыгы бар, ул кырлач салкыннарына кадәр тунмый. Шуна күрә Хәмит шикелле балык җене кагылган кешеләр монда эзне суытмый.

—Минем күптән кармак таягы тотканым юк,—диде Кәшшаф,—сан өчен генә утырсам инде.

—Нәрсәгә юрасаң, шул була, ди торган иде бабай. Һәм рас. Күңелне яхшы кылга көйләү кулай. Була дисәң, була, юк дисең икән—юк. Аның арифметикасы бик гади.

Хәмит көймәсен рәтләгән арада Кәшшаф тирә-якны күзәтеп алды. Күл яп-якты булып җәйрәп ята, гүя төнге айны җиргә төшереп куйганнар.

Читендәге күрәннәре зәгыйфьләнсә дә камышларның күкрәкләре әле һаман киеренке, бирешергә теләмиләр.

—Корабка рәхим итегез, иптәш профессор,—дип кычкырды Хәмит.

Кәшшаф зур итекләрен өстерәп, су читенә таба атлады.

—Көймәне чайкалдырмый гына керергә тырыш, капланып китмәсен, юк ише түгел, ярап тора безгә.

Кәшшаф көймәнең койрыгына чүгәләде. Хәмит уртага басып, озын колга белән этә-этә, көймәне күл эченә юнәлтте. Кәшшаф калтыранып китте. Чөнки бу «ялгаш»ның әйләнеп китүе бик ихтимал иде.

—Балыкчының арты юеш була инде аның, яшьти, бер чирканчык алудан баш бетмәгән,—дип, көймә хуҗасы аны ирештереп алды.

Ниһаять, җайлашып утырыштылар. Калкулыктан караганда алар бүрәнә башына кунаклаган ике карганы хәтерләтә иде. Кукраешканнар, кыймшанмыйлар да. Кәшшафның бөтен игътибары хәзер шадра дулкыннар өстендә чайкалган калкавычта. Вакыт-вакыт ул батып киткән сыман да була. Шуңа тәңгәл рәвештә Кәшшафның да гәүдәсе йомгактай бөтәшә, колаклары шәңкәя, йөрәге ашкыныбрак тибәргә тотына.

Балык!

Ләкин бу әле алдавыч хәбәр генә, җилбикәнең шаяртуы гына.

Кәшшаф өчен дөнья хәзер шул каз каурыеннан ясаган бармак буе калкавычка сыйган. Рамил фаҗигасе дә, диссертация мәшәкатьләре дә томан эченә чигенде, хәтта көймәнең кечкенәлеге дә онытылды. Ул да, калкавыч, калкавыч та, ул. Бәхет өчен кешегә, бер карасаң, күп тә кирәкми икән үзе.

Калкавыч селкенгәндәй итте. Беравык хәтта югалып та торды. Тик шундук былт итеп кире өскә чыкты. Их, булмады, дип офтанып өлгермәде, калкавыч элеккесеннән дә ныграк тизлек белән күздән югалды.

Кәшшаф үзен-үзе белешмичә кармак сабына ябышты. Хәмит тә аны күзәтә икән. "Күтәрмә, җебеңне савып ал, ычкына күрмәсен",—дип өйрәтеп торды.

Кәшшафның кулы җинел булды. Үз кешебез диптер инде, балыклар күбрәк Хәмитнең кармагы янында чуалыштылар. Тик бу озакка бармады, 30-40 минуттан чиертү тынды.

—Шуның белән шул, яшьти, балыклар төпкә төште,—диде Хәмит,—инде кармакларны җыйсаң да була.

Хәмитнең күл буенда яшереп куйган утын пүләннәре дә бар икән.

Учак яккач, тагын да күңеллерәк булып китте, тәнгә май кебек булып җылы керде. Балачак хатирәләре яңарды. Элек кичләрен учак ягып сыер саклау гадәте бар иде. Үзе бер сабан туе. Төрле уеннар уйныйлар иде. Беренче мәртәбә ана гыйшкын белдерүче кыз да кичке уен белән бәйле. Халидә исемле кыз иде ул. Җиденче класста укый. Кәшшаф—дүртенчедә. Әле борынына кызлар исе кермәгән вакыт.

Халидә йомры сөякле бик житез кыз. Йөзенә сирәк-мирәк кенә ясмык сибелгән, тик ул шадралар аны ямьсезләми, киресенчә, ниндидер мутлык, шаянлык өсти иде. Сүзгә кесәгә кермәс, бөтерчек шикелле һәр уенның үзәгендә кайнар.

Бер кичне йөзек салыш уйнадылар. Кәшшаф отылды. Шуңа күрә ана җәза тиешле иде.

—Сөйгәнеңнең исемен әйтсәң,—дип чәчрәп чыкты уртага Халидә.

Кәшшаф оялуыннан җир ярыгына керердәй булды, йөзе-бите чөгендер шикелле кызарып чыкты. Ә Халидә кысыпмы-кыса, әйт булгач, әйт, өзми дә куймый да. Башка кызлар да аны куәтләде, "әйт, әйт", диләр. Аптырагач, бу ябышкак черкидән котылу өчен "син",—дип әйтергә мәҗбүр булды.

Халидә сүзне чынга алган булып чыкты. Икенче көнне уеннар бетеп, сыерларны алып кайтканда Кәшшафның кулына ниндидер төргәк тоттырды, кешегә күрсәтмә, үзең генә ач, дип кисәтте.

Кәшшаф учына утлы күмер салгандай тетрәнеп китте. Нидер сизенгәндәй төргәкне кире кызга бирмәкче итте. Ләкин ут булды да, су

булды Халидә. Әле ярый, кеше-кара күрмәде, дип шатланды соңыннан Кәшшаф. Малайлар күрсә, авыз да ачтырмаслар иде. Шул ук вакытта күнеленә кызыксыну корты да кереп оялады: нәрсә бар икән ул төргәк эчендә?

Калган ашны аяк өсте генә чөмереп, юрган астына кереп чумгач кына Кәшшаф әлеге серле төргәкне ачып карады. Анда кулъяулык белән чәчәкләп-чуклап язылган хат иде. Башта ул аларның мәгънәсен аңламыйчарак торды. Башына алгач, икесен дә читкә бәрде. Нәрсә, ул шадра тилергәнме әллә? Сыерларын басуга куып кертергә дә күп сорамас, тотсын аннан соң каравылчы алдында җавап.

Күрәсең, ул вакытта каравылчыдан да усалрак затны белмәгәндер Кәшшаф. Ләкин кызыксынуы да көчле булгандыр, ахры, иртәгәсен хатны учакка ыргытканчы барыбер күз йөртеп чыкты. Ул озын түгел иде, күптин-күп сәламнәрдән соң, "яратуыңны бөтен кеше алдында ачып салма, хат аша гына белгерт", дигән.

Кәшшаф Халидәгә суганлап-борычлап җавап хаты язды, тик бирергә кыймады. Хәзерге акыл белән үлчәгәндә бик дөрес эшләнгән. Югыйсә, ул гөнаһсыз кыз баланы бик нык рәнҗеткән булыр иде.

Кулъяулыгы бик матур иде. Әле дә күз алдында: чит-читләрендә берсеннән-берсе купшырак чәчәкләр чигелгән. Уртада ике күгәрчен. Челтәр белән әйләндереп алынган. Өзгәләргә кулы бармады. Әле тәрәзә кашагасына яшереп, әле күзгә артына куеп, шактый әвәләп йөртте.

Черт-черт янган учак шушы хатирәләрне яңартты.

—Халидәнең хәлләре ничек?—дип сорады ул Хәмиттән.

—Тегүче Шәмсетдин кызын әйтәсеңме?

—Шул инде.

Халидәнең әтисе бик оста тегүче иде. Бөтен тирә-якны толып, тун ише кием белән ул киендерде. Кышларын капка төпләрендә һаман җигүле ат торыр. Үзенең «кырык алдар» дигән даны чыккан. Тәрәзәдән кем килгәнен күреп алса, шул кешенең киемен тегәргә тотына икән.

—Алар соң Чаллыга күчеп киттеләр бит. Халидә нәчәльник хатыны ул хәзер. Нәрсә, бер-бер сүз ишеттеңме әллә?

—Болай гына, элек күршеләр идек ич.

Хәмит төпченеп тормады, вакыты ул түгел иде. Балыклар, әнә, пешеп чыкты, күзләре ап-ак булып агарды. Ул аларны ватмыйча-җимермичә берәм-берәм алдан хәзерләп куелган шомырт яфраклары өстенә тезде. Шомырт балыкка үзенә бер кабатланмас тәм өсти. Яфраклар инде корыган-коруын, барыбер шартын китермичә ярамый.

—Өйрәнеп беткәнсең син, күрше,—диде Кәшшаф.

Ана яшьлек дусты янында бик рәхәт иде.

* * *

Кәшшафның күңеле, тәнендәге бөтен күзәнәкләре моң белән тулды. Армиягә китүче егетләрнең авыл белән хушлашулары хәтеренә төште. Кыңгыраулар тагып, җигүле атларда урам әйләнерләр иде. Җырлары күзгә күн шикелле моңсу була иде. Ә Кәшшафка күз дә, моңсулык та ошый иде.

Ул селкенергә дә кыймыйча ятты, әйтерсең лә, күзләрен ачса, әлеге моң да югалачак иде. Аны уянса да, тәне уянмаган иде әле. Моң, чыннан да, бишектә тибрәткәндәй янә оетып җибәрде.

Чәй янында ул аны төш итеп әнисенә сөйләде. Әнисе яулык очы белән генә авызын каплап елмаеп алды да әйтте:

—Төш түгел ул, улым, йокы аралаш азан тавышы ишеткәнсең син. Баштарак барыбыз да шулай әлле-мәлле йөрдек. Бигрәкләр дә ямьле инде, авылга җан кергәндәй булды. Муллалыкны Инсаф алгач, дөньялар үзгәреп китте әнәтрәк. Мәчет авылны бербөтен итеп үз канаты астына туплады да куйды.

—Инсаф муллалыкка укыганмыни?

—Саба районында эшли иде ул, улым, мал брачы булып. Казанда укыды. Мәдрәсәгә дә йөргән икән. Хәзер дә ике эшне алып бара.

—Әллә азанны да үзе әйтәме?

—Үзе булмыйча, үзе.

Кәшшаф әнисенә ышанып житмәде, буташтырадыр дип уйлады. Чөнки Казан мәчетләрендә дә азан магнитофон язмасында әйтелә. Шуна күрә кичен үзе барып карарга булды.

Кәшшаф мәчет янына килеп житкәндә авыл өстенә азан авазы таралды.

—Ал-ла-һу, әкбәр, Ал-ла-а-һу әкбәр.

Ул башын чөеп манарага бакты. Анда дөрестән дә азан әйтүче күренә иде. Тавышы көр, аһәнле. Кәшшаф мәчет эченә кермәде, мулланың эшен бетереп чыгуын капка янында гына көтеп торды.

—Әссәламегаләйкүм, хәзрәт,—дип сәламләде ул аны.

—Вәгаләйкемәссәлам,—диде мулла тотлыгыбрак,—сезне кем дип белик?

—Мин шушы авылда туып-үскән кеше буламын, исемем...

—Ә-ә, Сез Кәшшаф абый, шулаймы?

—Нәкъ үзе,—диде Кәшшаф.

—Кайтканыгызны ишеткән идем, балыкка да баргансыз икән.

—Анысы да билгелемени инде?

—Авылда чыбыксыз телефон бик яхшы эшли ул, Кәшшаф абый.

—Ә мин азан әйтүеннен чынмы-түгелме икәнлеген тикшерергә килгән идем.

Инсафнын ике бит очындагы чокырлары тагын да тирәнәебрәк китте, ирен очларына беленер-беленмәс кенә елмаю кунды. Чибәр иде авыл мулласы. Төз, ыспай гәүдәсе, сөрмә тарткандай балкып торган конгырт күзләре, йомры ияге аны сәхнә кешесенә охшатып жибәрә иде.

—Тавышын монлы, ачык,—дип мактады аны Кәшшаф,—тик көн саен азан әйтү авырга туры килмиме?

—Әлегә ике генә тапкыр әйтәм. Аннан сон, барысы да табигый булсын дип тырышу инде. Күреп торсыннар дим. Халык болай да дингә авыр тартыла. Жомга намазын кайвакыт берүзем укыйм. Совет вакытында халыкны диннән тәмам биздереп бетергәннәр иде ич. Халыкны агартырга да агартырга әле. Менә бүген күрше Кече Елга авылына чакырганнар иде. Өч көн элек кенә уналты яшьлек бер кызнын женазасын куеп кайткан идем. Инде әнисе: "Мин кызым янында булырга тиеш",—дип үзенә-үзе кул сала башлаган. Ярый, күршеләре абайлап өлгергән. Гомерне Аллаһы Тәгалә бирә, Аллаһы Тәгалә ала. Киткән кеше артыннан китеп булмый. Калган адәмнәрнен бурычы—догада булу. Догага гына мохтаж жәсаденнән аерылган жан.

Шуларны анлатып, азмы-күпме тынычландырып кайттым әлеге апаны. Дин бит ул, Кәшшаф абый, жан терәге, күнел тотрыклылыгы. Аллага шөкер, халык минем үземә дә еш мөрәжәгать итә, зарлана алмыйм. Ләкин диннен чын мәгънәсендә тернәкләнеп китүе өчен вакыт зарур. Ана минем гомер генә дә житмәскә охшый.

Кәшшаф дин тотмаса да аны ихтирам итә, тәкъвә кешеләргә мөнәсәбәте дә әйбәт. Тик ни сәбәпледер дин анын йөрәгенә билә ала алмады, ышанычына, иманына әверелмәде.

Бигрәк тә балалар кызганыч иде ана. Дингә кергән балаларнын йөзендә һәрвакыт чарасызлык, мескенлек, курку булыр. Сабый чактан ук ахирәт, гөнаһ турында уйлау—кайгысыз балачакка кул сузу түгелме? Андый балалар рәхәтләнеп көлә дә, шаяра да белмиләр. Шуна күрә улы Кәримне дә мәчет янына якын жибәртмәде.

Ә бүген япь-яшь кенә авыл мулласынын гап-гади сүзләре Кәшшафны әллә ничек жилкендереп жибәрде. Хәер, башта ул аны азаны белән әсир итте. Инде акыллы вә үтемле сүзләре белән күнеленә шифа өрде.

—Шушы араларда гына минем Рамил исемле якын дустым вафат булды,—диде Кәшшаф,—аңа атап дога кыла алмассызмы икән?

—Иншалла, дустыгызның урыны оҗмахта булыр, Кәшшаф абый. Мөэмин кеше башкаларга өлфәт кылыр вә башкаларның өлфәтен кабул итәр. Моның бердән-бер шарты—сәдака. Сәдака сират күперенә юл ачар ди.

* * *

Туган-үскән якның һавасы да дәва дип бик дөрес әйтәләр икән. Шушы бер-ике көн эчендә Кәшшаф та аруланып, тернәкләнеп китте ләбаса. Мәчеттән кайтуга, әнә, китапка ябышты. Үзе дә сөенеп куйды, шөкер, егәре бетмәгән икән әле. Ул үзе белән Мәрҗанинен «Мөстәфадел»ен алган иде. Бу китап—белем коесы. Төбенә генә төшеп җитеп булмый. Әйтик, Алтын Урданың дошманнары Болгар ханлыгын басып алу белән ул яшәүдән туктый дигән теорияне алга сөрәләр, татарларны вәхшиләр итеп күрсәтергә тырышалар. Ә Мәрҗани акка кара белән болай дип терки: "633 (1235) елда, Бату хан гасырында, татарларның Сүбәдәй дигән гаскәр башлыгы белән зур көчләре Болгарга килә. Болгарлар аларга түбәнчелек һәм итәгать күрсәтеп, татар мәмләкәтенең бер өлеше булырга һәм аңа салым түләп торырга риза булалар. Шулай итеп, татарлар аларны бөтенләй үз кулларына алалар, әмма дәүләтләрен бетермиләр".

Кәшшаф еш кына Алтын Урданың соңгы көннәре турында уйлана. Бу мәгърур дәүләт бик аз гомерле булган. Өч йөз ел тарих күзлегеннән караганда, төкерек кенә ул. Ләкин шул кыска гына вакыт эчендә дә тарих мөнбәрендә үз эзен калдыра алган, дөнья цивилизациясенә бөек шәхесләр бирергә өлгергән. Шуларның иң мәшһүре—Бату хан.

Бату яшьтән үк бөек эшләр майтару турында хыяллана. Гарәп галиме Хаҗи Рәхимгә шәкертлеккә биргәндә әтисе Җуҗи хан улыннан болай дип сорый.

—Минем атам, бердәнбер һәм бөек Чыңгызхан, җиһанның яртысын яулап алды, ә икенче яртысын Искәндәр Икемөгез үзенә буйсындырды. Сиңа нәрсә кала соң, Бату хан?

Малай утлы күмер шикелле ялтырап торган күзләрен уйнатып ала да әйтә:

—Мин Искәндәрдән җиһанның яртысын тартып алачакмын,—ди.

Хаҗи Рәхим Батуга берничә ел дәвамында аң-белем бирә, укыргаязарга өйрәтә. Әтисе Җуҗины үтергәннән соң гына уку өзелә. Батуны Сүбәдәй баһадур үз тәрбиясенә ала.

—Сине монда әтиең язмышы көтә, шуңа күрә үзем белән Кытайга алып китәм, җиһангир ясыйм,—ди.

Сынар күзле, чулак баһадур сүзендә тора.

Ә Бәрәкәт хан Чыңгызлар нәселендәге ханнар арасында беренче булып Ислам диненә күчә. Үзбәк хан исә Исламны дәүләт дине дип игълан итә.

Рус тарихчылары Алтын Урданың таркалуын 1380 елда булган Куликово орышы белән бәйлиләр, шунда аның соңгы сәгате сукты диләр. Алтын Урда исә бу чорда әлеге вакыйгадан битәр, үз эчендәге ызгышталаштан җәфа чигә. Ул "Амайдагы, Мамайдагы эшләр" дигән әйтем белән фольклорга да кереп калган. Елъязмалар шуны ассызыклый, 1370—1380 еллар арасында үзара тәхет сугышлары китә. Шул ун ел эчендә ундүрт хан Сарайдан куыла. Әлеге дау-низаглар уртасында нугайларның хәрби башлыгы Мамай мирза да кайный. Куликовода нәкъ менә ул җинелә дигән фараз бар. Русларга килгәндә, алар чын ханны яклап чыккан татарлар ягыннан торып сугышканнар дип раслый кайберәүләр.

Мамай татар тарихына кереп калган олы шәхес. Әле аны өйрәнәсе бар.

Куликово орышыннан соң ике җәй дә үтми, Туктамыш хан

Мәскәүгә һөҗүм ясый. Мәскәү кенәзе Дмитрий Донской башкаладан качарга мәҗбүр була. Русь ясак түләвен дәвам итә.

* * *

Әхмәт хан йомшак күңелле, артык дәрәҗәдә итагатьле кеше иде. Аның килеш-килбәте дә патшадан бигрәк, чәчәнне хәтерләтә иде. Ходай аны, мөгаен, шагыйрь итеп яраткан булгандыр. Ул хикмәтле сүзе белән, моңы, җыруы белән бәндәләрне Аллаһ юлына күндерүче, гаделлеккә, мәрхәмәтлелеккә өндәүче акыл иясе булырга тиеш булгандыр. Тик Әхмәт–хан нәселеннән, аксөякләр затыннан. Ә аксөякләр дәрвишлекне кабул итә алмыйлар. Аларның урыны—тәхет. Ызгыш-талаш, орыш-үтереш, шуның аркасында килеп чыга. Чөнки тәхет бирәү генә!

Әхмәт ханны хакимияткә көчләп китерделәр, аның өчен Сәетәхмәтне тәхеттән кудылар. Аның үзенең дә вафатын көтеп торучы туганнары хәтсез. Гайбәтне шулар тарата. Имеш, ул чирләшкә, шуңа күрә ил белән идарә итә алмый. Хан корыч куллы, каты бәгырьле булырга тиеш!

Әхмәт хан моны үзе дә аңлый иде. Хакимият дилбегәсе аның кулыннан менә ычкынам, менә ычкынам дип кенә тора. Дәүләт бик нык какшады. Ул хәзер терәүләре черегән иске абзарга охшап калды. Кайчандыр бөтен дөньяны дер селкетеп торган Урда ләбаса бу! Нидер эшләргә, ниндидер чарасын күрергә кирәк иде. Тик ни эшләргә, нинди чара күрергә? Шушы хакта тагын бер мәртәбә киңәш-табыш итү өчен Әхмәт хан баш вәзирен чакырып кертте.

—Болай кул кушырып утырсак, дәүләтебездән колак кагачакбыз, вәзир, нишлибез, фикерегезне әйтегез,—диде.

Вәзирнең күз кабакларына чаклы салынып төшкән озын төкле кашлары җыерылып маңгаена менде. Туры сүз—куркыныч сүз. Бигрәк тә олы түрә алдында теленне тыю хәерлерәк. Шуңа күрә ул ишарәне ханның үзеннән көтте. Менә шунда җилнең кая таба искәнен абайлап алачак ул.

Вәзиренең икеләнебрәк торуын әмир үзенчәрәк аңлады булса кирәк, кулларын өскә күтәреп, учларын чәбәкләп алды. Шуны гына көтеп торгандай савыт-саба асып хезмәтчеләр килеп керде. Кыска аяклы озын өстәл җиләк-җимеш, кавын-карбыз белән тулды.

—Мин ашыктырмыйм, ашап-эчеп, тук корсакка уйлашыйк,—диде Әхмәт хан,—күңел ачып алганда да зыян итмәс. Ул янә кулларын чәбәкләде. Бу юлы ярымшәрә кызлар пәйда булды. Барабан кагырга тотындылар. Шул көйгә бинибая олы келәм өстендә берсеннән-берсе чибәррәк зифа буйлы җарияләр һөнәрләрен күрсәтә башлады. Гәүдәләре гүя камырдан ясалган, нинди генә хәрәкәтләр ясамыйлар, исең китәрлек. Ләкин ханның башында бөтенләй башка уйлар бөтерелә иде. Игътибарсызрак булды. Башка вакытта үзенә охшаган кызны янына алып, алдына утырта, иркәли-сыйпый иде. Бүген исә бию бетәр-бетмәс үк кул чапты. Бу тамаша беткәнне аңлата иде.

—Ил язгы Идел шикелле болгана, вәзир, безнең сүзне колакларына да элмәүче ханнар, түрәләр барлыкка килде, һәрберсе үз ягына каера. Кырым бөтенләй азды. Иван ясак түләүдән баш тарта. Шушы тузган көтүне җыю өчен бер-бер гамәл зарур.

Хан вәзиргә текәлеп карап торды. Бу караштa үтенеч тә, төшенкелек тә, ышаныч та бар иде. Вәзирнең икеләнүләре бетте.

—Галиҗәнап, Алтын Урданы сугыш тудырды, сугыш яшәтте,—диде ул ханнан күзләрен алмыйча,—аны сугыш кына саклап кала алачак. Зур сугыш!

—Мин дә шулай уйлыйм,—дип җанланып китте хан.—Мәскәүгә яу чабарга кирәк.

—Бу яуның башында, Галиҗәнап, Сез үзегез торырга тиешсез.

Вәзир артыгын җибәрмәдемме дигәндәй ханга күз төшереп алды. Юк, хан аңа рәнҗемәде. Чөнки ул үзенең күренекле гаскәрбашы түгеллеген белә иде. Шуның белән бергә, яуны үзе җитәкләргә тиеш икәнен дә аңлый. Дәүләтне таркалудан коткарырга кирәк. Бу барысыннан да өстенрәк.

* * *

1480 елның бер җәйге көнендә Угыр елгасы буена атлы чирү килеп туктады. Үзләре күп түгел, санасаң барысы утызлап җайдак булыр.

Күз күременДә елга тасма шикелле бормаланып-бормаланып ала. Бу аңа ниндидер көязлек, купшылык өсти иде. Елга туп-тулы. Күрәсең, яңгырлар еш ява. Әледән-әле су өстендә көмештәй ялтырап вак-вак шадралар йөгерешеп уйный. Чәчәктән-чәчәккә куныл бал кортлары бызылдаша.

Атлыларның күзләре исә бүтәндә: кичү кайда икән, яр буенда хәрби ныгытмалар юкмы?

Арьякта күзәтү манаралары күренә иде. Димәк, Иван йоклап ятмаган, әзерлек чаралары күргән.

Әхмәт хан бик сак кыланды. Башта ул Литва кенәзе Казимирны көтте, аннан соң су катканны. Ләкин үзе тотты да елгалар туңганчы кузгалды. Беренче һәм соңгы орыш шәгъбан аеның икенче көнендә булды. Тоташтан дүрт көн чәкештеләр. Шулай да Угырны кичә алмадылар. Елганың бер ягында татарлар, икенчесендә—руслар.

Елга боз белән капланугa, ул гаскәрен бөтенләй кирегә борды. Һөҗүмгә күчәргә кирәк иде, югыйсә.

Тарихчылар әле булса баш вата, ни өчен Әхмәт хан бу уңайлы форсатны кулдан ычкындырды икән?

Руслар үзләренчә тукый. Елъязмага таяналар. "Наги и босы, страхом гонимы",—дип яза елъязмачы Алтын Урда гаскәрләре турында. Рус тарихчысы Соловьев Әхмәт ханның кире борылуын салкын кышка сылтый. Казимирның килмәвен дә, Кырым ханы Миңлегәрәйнең Мәскәү ягына авышуын да сәбәп итеп куя.

Кәшшаф Ризаэтдин Фәхретдин версиясенә ышанарак төшә. "Шура" журналында галим болай яза: Әхмәт хан "Кырым һәм Касыйм татарларының барысының да Иван тарафында булып, Нур Дәүләт командасындагы татар гаскәренең Сарайга һөҗүм итәчәкләреннән хәбәр алып, сугышмый кайтып киткән булыр".

Китүен китә хан, тик тагын табышмак. Әхмәт хан кышны Донец елгасы буенда кичерергә карар итә.

Шәүвәлнең егерме икесендә җепшек кар явып үтте. Иште генә, җәя арасы җирдә кеше күренерлек түгел иде. Атлар, җайдаклар күшегеп бетте, учаклар да җылытмады. Кичке якта гына туктады кар. Офык сызыгында кояшның ватык чүлмәк читенә охшаган бер кисәге күренеп алды. Ул кан шикелле алсу иде.

Әхмәт ханның баш өянәге кузгалды. Ачуыннан хезмәтчеләренә камчысын да уйнатып алды, тик башы барыбер авыртудан туктамады. Бераздан им-томчыны чакыртты. Тегесе үткен пычак очы белән аның кул тамырын тиште. Ыргылып кан бәрде.

—Сезне сихерләгәннәр, Галиҗәнап, каныгыз каралган,—диде ул,—борчылмагыз, мин сезне аякка бастыракчакмын.

Әхмәт хан, дөрестән дә җиңеләеп китте, башы да ачылды. Кымыз китерделәр. Ул эчәргәме-юкмы дигәндәй кырын күзе белән генә им-томчыга карап алды. Алай да бер тустаганнан артык эчмәде.

—Сезгә, Галиҗәнап, иртәнгә кадәр ятып, тыныч кына ял итәргә кирәк, җарияләр дә чакыртмагыз,—дип тезеп китте им-томчы,—мин сезгә бик яхшы төнәтмә эчерәм, ятуга йоклап китәрсез.

Хан төнәтмәне эчүгә ятакка башын төртте. Шуны гына көтеп

торгандай чатырга ниндидер ят кешеләр бәреп керде. Сакчыларны ә дигәнче идәнгә ектылар.

—Галиҗәнап, рәхим итегез, мин аны йоклаттым,—дип кычкырды им-томчы.

Чатыр уемында көянтәдәй кәкре аяклы, җәлпәк борынлы, затлы киемле бер хәрби кеше күренде.

Бу Иуак хан иде, Миңлегәрәй ханның әшнәсе.

—Ул хәзер бервакытта да күзләрен ачмаячак,—дип тешләрен ыржайтты хан. Аннан соң кәкре кылычы белән Әхмәт ханның башын чабып өзде.

Куликово кырындагы сугышка нәкъ йөз ел үткән иде.

"Иуак исә, дошманыңны үтердем, дип Мәскәүгә, Иван хозурына сөенеч илчесе күндерде, ягъни җибәрде",—дип яза Ризаетдин Фәхретдин.

Бату хан корган бөек дәүләт шул ук Бату хан балалары тарафыннан харап та ителә.

* * *

Академия утырышыннан Галимов бик боегып, шөбһәләнеп кайтты. Төне боргаланып-сыргаланып үтте, күзенә йокы кермәде. Даруларның да ярдәме тимәде. Башы тубал кебек булды. Нишләргә? Ул игътибарга, зурлауга, мактауга күнеккән кеше. Мона кадәр уч төбендә генә йөрттеләр. Ә бүген аны күрмәмешкә салындылар. Шуңа күрә адәм рәтле сөйли дә алмады. Алтынурдалыларга кирәгеннән артык якты чырай күрсәтелде. Алай гынамы, Президентның яна киңәшчесе Хәлилов болгарлар белән татарларны бер этник төркемгә кушып әвәләде. Бу аның карашларына бөтенләй капма-каршы килә. Ул, мәсәлән, татар-болгарның ата-бабалары әле безнең эрага кадәр үк Кара диңгез буенда көн күргән скифлар булган дигән теорияне алга сөрә. Аны Мәскәү галимнәре арасында да яклаучылар бар. Скифлар һуннарга караганда күпкә борынгырак. Татарның абруен күтәрү өчен бу күпкә мөһимрәк ләбаса!

Президент аппаратына Хәлилов килгәч, дөньялар шулай үзгәрде дә китте. Инде, әнә, фәнгә дә борын төртеп маташа. Академия җитәкчелеге дә—ләббәйкә. Ник бер каршы сүз әйтсеннәр.

Бүгенге хәленә ирешү өчен күпме көрәшергә, күпме кан коярга туры килде ана?! Үзе генә белә. Һәм менә хәзер, фән кыясының ин очына менеп житкәч кенә, йөз түбән тәгәрәсенме?

Эш тирәнгә кергәнче ниндидер чарасын күрергә кирәк. Ирененнән селәгәе дә кибеп җитмәгән шул малай алдында баш имәс бит инде. Ин элек Сабиров белән киңәшү мәгъкуль булыр, мөгаен. Мона кадәр ул аны яклап, ярдәм итеп килде. Хәзер дә кире чигенмәс. Сабакташлар ич. Университетта укыганда бер бүлмәдә тордылар, бер табактан ашап-эчеп яшәделәр.

Галәттәгечә, иртән ишек төбендә машинасы көтеп тора иде инде. Шофер, хуҗасы күренүгә, урыныннан купты. Директор арткы утыргычта йөрергә күнеккән. Ләкин Галимов бүген алгы ишек янына килеп басты. Шофер ярдәмгә ашыкты. Артык тырышып ташлады, ахры, аягы таеп китте дә бөтен гәүдәсе белән җиргә ауды. Галимовны да үзе белән өстерәде.

—Ахмак, шушы гына житмәгән иде,—дип ырылдады Галимов урыныннан торганда. Ә шоферы бүрәнә шикелле ята.

—Башым, башым...

Галимов тиз генә машинадагы телефоннан "Ашыгыч ярдәм"гә шылтыратты. Озак көттермәделәр. Шоферны үзләре белән алып киттеләр.

Галимов үз кул астындагы турылыклы хезмәткәрләренә хак бәһасен бирә белә торган кеше. Ул аларны бервакытта да читкә типми, абынган чакларында да ярдәм кулын суза. Әле дә рульгә үзе утырып, сырхауханәгә барды. Рентген нәтиҗәләрен белмичә китмәде.

Шоферның мие селкенгән икән. Алай да борчылырлык урын юк, диделәр, тыныч кына ятса, берәр атнадан аякка басар, диделәр. Тегесе

каршы килеп караган иде дә, Галимов авызын да ачтырмады. Ике генә сүз әйтте:

—Каласың! Дәваланасың!

Галимов институтта эшкә иң беренчеләрдән булып килеп утыра. Йомышы чыгып, сонарасы булса, алдан кисәтеп куя иде. Бүген әлеге кагыйдә бозылды. Сәркәтип кыз аны борчулы йөз белән каршы алды.

—Бер-бер хәл булмагандыр бит, Сәүбән Сәүбәнович,—дип сорады.

—Хәйдәр инде, ахмак.

Сәркәтип кыз бернәрсә дә аңламады, ә кайтарып сорарга кыймады.

—Министр сезнең турыда белешкән иде,—диде.

Галимов җанланып китте.

—Ашыгыч түгелдер бит?—дип сорады.

—Юк, аны-моны әйтмәде, минем белән хәбәрләшсен генә диде.

—Яхшы. Хәзер үк тоташтыр.

—Хәерле көн, Сәүбән Сәүбәнович,—дип сәламләде министр директорны,—сез бүген Төрек-татар гимназиясе ачылу тантанасына барасыздыр бит?

—Әйе, чакыру җибәргәннәр иде.

—Шунда күрешербез, киңәшләшәсе бар иде, хәзергә хушыгыз.

Тантанада, чыннан да, гәпләшү җае чыкты. Концерттан соң табынга утырышкалаганчы бер буш ара булып алды. Сабиров аннан Академиядә үткән кичәге киңәшмәдә алган тәэсирләре турында сораштырды.

—Бик файдалы, тәнкыйди юнәлештәге сөйләшү булды,—диде Галимов,—безнең киләчәк планнарда ул идеяләр, һичшиксез, чагылыш табар дип уйлыйм.

—Әлбәттә, әлбәттә.

Галимов әңгәмәдәшенә сынабрак карап торды да:

—Сезнең чыгышны да тынлыйсы килгән иде, Ильяс Хәбирович,—диде.

—Вакыт ягы кысанрак иде, үзегез күреп тордыгыз.

—Козгыннар комачаулады дип турысын әйтсәгез дә була, безне тыңлап торучы юк,—диде Галимов.

—Нинди козгыннар,—дип белмәмешкә салынды Сабиров. Үзе сагайды, башын бормыйча гына тирә-якка күз салып алды.

—Шикләнмәгез, козгыннар «Галиябану» пьесасындагы канатлы сүзләр генә. Ләкин безгә ачыктан-ачык сөйләшергә кирәк дип саныйм, Ильяс әфәнде.

—Шуның өчен очраштык та инде.

—Сиздегезме, киңәшмәдә Хәлилов пышылдаганны гына кабатладылар. Болайга китсә, ул Президентны да үз ягына аударачак,—диде Галимов.

Сабиров ике бармагын тырпайтып, юка иреннәренә тигезде, сак бул, янәсе.

Җир йөзендә хакимият яралганнан бирле идарә даирәсенә караган әһелләр дәүләт башлыгын—Президентларны, патшаларны, ханнарны, корольләрне үз ягына аударырга омтылып яшәгәннәр. Һәрберсе кәкреләр мәмләкәтендә бөкре булырга тырышкан. Кайсы төркемнең йогынтысы зуррак, дәүләттә шул төркемнең сүзе үткән.

Татар йомышчылары да әлеге чирдән азат булмаган, хуҗаларының ышанычын аклау өчен бер-берсенең бугазына ябышкан. Хәзер дә шул ук хәл. Үзгәреш фәкать ана ирешү алымнарына гына кагыла.

Илбашының игътибары—ул хакимият мөнбәрендә үз оянны кору дигән сүз. Бүгенге мал бүлешү чорында бу исә калҗаның зуррагын эләктерергә мөмкинлек бирә. Дөрес, баш кешене «үз кубызына биетү» Дөлдөл күкәе эзләү белән бер. Тик ул да кеше, аның да йомшак яклары бар. Даирә моннан хәбәрдар. Һәммәсе шул төймәгә үреләә. Кайсы өскә үрмәли, кайсы мәтәлеп аска тәгәри.

—Сәүбән Сәүбәнович, сез инде бигрәк, ул кадәр арттырмагыз,—дип каршы төшкән булды министр.

—Җә, кайсыбере арттыру да булсын ди. Ә татар тарихчыларына ышанмауны ничек аңларга? Янәсе, алар мүкләнеп беткән, янәсе, заманча фикерли белмиләр. Ни ди бит, әнә, Хәлилов, татар тарихчылары милли тарихның дүрттән берсе чамасын гына тарта алачаклар ди. Бу сон чын мәгънәсендә томаналык ләбаса! Беренче чиратта безнең институтка яла ягу.

Аннан соң, үзегез дә шаһит, уратыбрак булса да ул мина төрттереп тә маташты бит әле. Янәсе, мин директор буларак, үземә ошамаган галимнәрне эзәрлеклим, янәсе, мин кара эчле. Мин аның кемне күз алдында тотуын бик яхшы беләм. Фән мөнбәренә Кәшшаф Хәмитовны менгезмәкче. Ике чабата бер кием. Хәмитовка ирек куйсаң, бөтен татар тарихын ботарлап ташлаячак ул. Хәер, анысының башы тиз генә судтан чыкмаячак әле...

—Сезгә әле җил-янгыр тигәне юк, Сәүбән Сәүбәнович,—дип, Сабиров директорны тынычландырырга ашыкты,—быел гына академик исеме алдыгыз.

Галимов сөт өсте белән сыйланган мәче баласы шикелле ләззәтләнеп иреннәрен ялмап алды. Сабировның бу сүзләре аның йөрәгенә сары май булып ятты.

—Мин дә шуны тукыйм ич инде, Ильяс Хәбирович. Президентка әле күп яхшылыклар эшли алыр идек дим. Без аның ныклы терәкләре ич.

—Безнең вазифа—киләчәктә дә ныклы терәк булып калу, Сәүбән Сәүбәнович,—диде Сабиров ярым пышылдау белән,—безгә ничек тә Президент алдында Хәлиловларның абруен төшерергә кирәк, сүзләрен аста калдырырга. Тиздән Президент тарихчы галимнәр белән очрашачак. Әлеге кинәшмә шуңа хәзерлек кысаларында гына узды. Бу форсатны һич тә кулдан ычкындырырга ярамый. Тик искиткеч саклык һәм акыл белән эш итү зарур. Шунысын да белеп торыгыз, Хәлилов минем урынга дәгъва итә.

—Молокосос!

Әшнәләр әле тагын нәрсәләр турындадыр чыш-пыш килделәр.

* * *

Дәриганың кесә телефоны капкынга эләккән әрлән тавышлары чыгарып чәрелдәргә керешә. Ул рульне бер кулы белән генә тотып, телефонның уң колагына терәде. Мондый хәлләргә Дәрига күнегеп бетте инде, машинасының тизлеген дә киметмичә телефоннан иркенләп гәпләшә ала. Кайчак милиционерлар бармак та янап кала үзенә.

—Абыстай, син кайда?—дип сорады шалтыратучы. Дәрига аны шундук танып алды.

—Сәлам, Таһир,—диде дустанә тавыш белән,—нинди хаҗәтем чыкты?

—Сүз бар.

—Әйт соң, авызыңны бәйләп куймаганнардыр ич.

—Колагына гына әйтә торган сүз ул.

—О-лә-лә, алайса рәхим ит, мин хәзерге вакытта Татарстан урамы буйлап барам, алда Камал театры.

—Театр янында тормозларына бас, мин хәзер килеп җитәм.

Озак та үтми аның янына «Волга» машинасы килеп туктады.

—Син нәрсә, баржага буксир булып ялландыңмы әллә?—дип мыскыллап каршы алды аны Дәрига.

Иномарка ияләре «Волга» машинасын үзара «баржа» дип йөртәләр. Килбәтсез, янәсе, тимер-томыр өеме.

—«Мерсик»ны ялга куйдым әле, ату чат саен туктатып җанны тинтерәтәләр. Моның белән дөнья рәхәте, күрүче дә юк.

—Җә,—диде Дәрига,—колагыма гына нәрсә әйтмәкче идең?

Таһир үзе дә бакылдык, телнең маен тамызып сөйли белә. Ләкин бүген ул үзенә охшамаган иде, дәшми утыра.

—Бик пошаманга төшкәнсең, Маша белән тагын үпкәләштегезме әллә,—диде Дәрига.

—Син Тэтчер белән эш йөртә идеңме?—дип сорады Таһир аның төрттерүенә игътибар итмичә.

—Безнең танышлык ул дәрәҗәгә үк килеп җитмәде бит әле, Таһир. Бүген күрешергә сүз дә куешкан идек, анысы хак.

Таһирның иреннәре сорау билгесе рәвешенә керде.

—Күрешүләр кичектерелә, абыстай, Тэтчерны алганнар,—диде ул.

Дәрига бермәл машинасына сөялеп катып торды. Шуннан соң гына:

—Кайчан?—дип сорады.

—Иртән. Җә, ярый, абыстай, ашыгыч эшләрем бар, итәк-җиңнәреңне җыйгала дип кенә кисәтүем.

—Рәхмәт, Таһир.

Дәрига дусты китеп баргач та әле озак кына урыныннан кузгала алмыйча торды. Бу хәбәр аның тәмам аңын чуалткан иде. Таһирга: «Бер гөнаһым да юк»,—дисә дә, әлеге ханым белән эшлекле сөйләшүләр алып бара башлаган иде инде. Соңгы ноктаны куярга гына нидер комачаулады. Димәк, бер-бер изге зат саклый булса кирәк аны. Бу, бәлки, Кәшшафтыр, бәлки, Кәримдер, әнисе. Кем генә булмасын, әлегә бәла-казалардан котылып тора. Ләкин бу гомергә дәвам итмәячәк. Фәрештә бер куяр канатын, ике. Ә өченчесендә? Шул кирәк синең ише гөнаһ капчыгына дип арты белән борылыр.

Дәрига машинасына утыргач та ерак китә алмады, Болак борылышында аны кара мыеклы өлкәнрәк яшьтәге бер милиционер туктатты. Дөресрәге, ул аның таяк болгавын да күрмәде, сыбызгы тавышын да ишетмәде. Көзгедә милиционерның чалшайган йөзен генә шәйләп алды. Артына чигенеп, нәкъ гаишникның борын төбенә килеп туктады.

—Капитан Хафизов!—дип, иң элек үзе белән таныштырды милиционер.

Капитаннарны да урам сакларга чыгаралар икән, дип уйлап куйды Дәрига.

—Документыгыз!

Дәрига ачык тәрәзә аша хокукнамәсен сузды. Тегесе аны әйләндерә-тулгандыра җентекләп тикшерде. Аннан соң: «Бик игътибарсыз йөрисез, мин сезнең хәмер куллану-кулланмавыгызны билгеләргә мәҗбүрмен, рәхим итеп, менә шушы көпшәгә өрегез әле»,—диде.

Дәрига өрде. Тыны чиста иде.

—Берәр борчуыгыз юктыр бит?—дип төпченде капитан.

—Зинһар өчен, күңелемдә казынмагыз, китәргә буладыр бит?

Капитан дорфалыкка дорфалык белән җавап кайтармады, киресенчә, ничектер үз итеп, якын итеп күз сирпеп карап алды да киңәшен җиткерде:

—Дәрига Хәсәновна, мин сезгә бүген җәмәгать транспортында гына йөрергә киңәш итәр идем.

—Нинди транспортта йөрү мәсьәләсен үз иркемдә калдырсагыз иде, иптәш капитан.

Милиционер җитез хәрәкәт белән уң кулын чигәсенә тигезеп алды. Бу китәргә ярый дигән сүз иде.

Каян белә икән бу мокыт минем исем-фамилиямне, дип башын ватып барды Дәрига, күргән-ниткән кешесе түгел. Әллә берәр мәҗлестә очрашканнар иде микән?

Цирк янындагы юл чатында бер шофер тәрәзәсен ачып, аңа йодрыгын төйнәп китте. Күрәсең, Дәрига кагыйдәне бозган иде. Кара мыеклы капитан янә күз алдына килеп басты. Вәйт, ахмак, ул соң аңа хокукнамәсен үз куллары белән тоттырды ләбаса. Шуннан укып белгән ич ул аның исем-фамилиясен. Капитан дөрес кисәтә, дөрестән дә, бүген руль артына утырырга тиеш түгел ул. Аллам сакласын, машинаң-ниең белән мәтәлеп китүеңне сизми дә калырсың.

Болай да пычак йөзендә йөри ич инде. Зөләйха кошчыкны, әнә, читлеккә ябып куйганнар. Әшнәләрем күп, дип мактана иде. Ул әшнәләр

хәзер ярдәм кулын сузарлармы, әллә бөтенләй белмәмешкә салынырлармы? Чын дуслык авыр вакытта сынала бит ул.

Зөләйха бөтерчектәй бөтерелеп кенә йөри торган бик унган хатын иде. Кирәкмәгән матурдыр. Аны үзенә каратырга теләүчеләр бихисап. Бу яктан ул искиткеч талымлы иде. Ялгызы гына кызын тәрбияли. Мәгәр ут борчасы инде. Шуңа да «Тэтчер» кушаматы такканнар.

Алар ниндидер бер жыенда таныштылар. Эшмәкәрләр арасында хатын-кызлар юк дәрәжәсендә, булганнары да сирәкләр, жарияләр генә. Шуңа күрә бик тиз якынлашып киттеләр. Соңгы очрашуда наркотиклар турында сүз кузгатты Зөләйха, кылын тартып карамакчы булды ахры. Дәрига ачылып ук бетмәде. Алар Ләбиб белән ирен асларына "яшәрткеч" үлән яфрагы салгалыйлар иде. Гайрәтлесенә үк жөрьәт итмәсә дә, аннан соң да кәефен күтәргәләде, хәзер дә.

Зөләйханы да ул «дару» тәкъдим итә икән дип уйлады. Шуңа күрә:

—Мин андый нәрсә белән шөгыльләнмим,—дип кырт кисте.

—Бик дөрес эшлисен,—дип хуплады аны Зөләйха,—куллану бер, бизнес башка. Кереме базар белән чагыштыргысыз. Уйлап кара.

Дәрига нидер әйтмәкче иде дә, Зөләйха аны култыклап алып, колагына: «Мин бик бәхетле»,—дип пышылдады.

—Әллә гашыйк булдыңмы?

—Миңа гашыйк булдылар,—диде Зөләйха. Бу сүзләрне әйткәндә аның эче-тышы нур белән тулды.

—Сиңа соң көн саен гашыйк булып торалар ич,—дип, Дәрига кулын селтәде.

—Ул чын ир-егет. Башкалар аның кисеп ташлаган тырнагына да тормый,—диде Зөләйха.—Әйтсәм әйтим, ул бер белмәгән килеш бөтен кеше алдында миңа сары розалар бүләк итте. Мондый нәрсә француз киноларында гына була.

—Сары розалар ятратканыңны сорашып өлгергәндер.

—Без бит чиратта торган арада гына таныштык. Бер үк мизгелдә икебезнең дә күзләрдән яшен ташыдай очкыннар сибелде. Бу күктән ингән мәхәббәт.

Дәрига дустына көнләшеп карап торды.

—Ул бәхет иясен кем дип беләбез инде?

—Очрашуга килә алмады, кичектергесез сәбәбе чыккандыр дип уйлыйм, андый хәлләр дә була. Ләкин ул мине барыбер эзләп табачак, күрерсең менә.

Дәриганың ярсый башлаган йөрәге тигез ритмга керде. Аның баш очында куерган кара болыт жилсез-гарасатсыз үтеп китте. Тәкәббер, һавалы, иркә Зөләйханы үзенә караткан әлеге гали затның ире Кәшшаф икәнен белсә, алдагы тормышы кайсы юлдан китәр иде, әйтүе кыен, әмма бу юлы Ходай аны аралап калды, фәрештә тагын канатын жәйде.

Хәл болай булды. Кәшшафның саклауда бераз акчасы бар иде. Хажәте чыгып, шуны алырга дип кассага барды.

Кассада жыен карт-коры иде. Пенсия бирәләр икән, шаулаша-шаулаша чират торалар.

Ул сәләмә киемле шактый олы яшьтәге бер карчык артына барып басты. Авыру, ахры, гыж-гыж килеп сулый.

—Сез күпме пенсия аласыз, күгәрченкәем?—дип сорады ул Кәшшафтан. Тирә-яндагылар тынычсызланып алдылар. Күрәсең, аларга да шушы ук сорау юлланылган иде.

—Мин әле пенсиягә чыкмадым,—диде итагатьле генә итеп Кәшшаф.

—Күзең чыкканмыни!—дип ысылдады ана кәкшәеп беткән тагын бер әби.

Карчыкның Кәшшаф биргән жавапка да, күршесенең кыланышына да исе китмәде. Ул бу сораулары белән эчен генә бушата иде булса кирәк. «Ашарга тотсаң, фатирга калмый, фатирга тотсаң, ашарга юк»,—дип сукранып алды.

Чираты житкәч тә мажаралары бетмәде карчыкның. Яна кагыйдә кергән икән. Элек оператор биргән исәп-хисап кәгазенә кул гына куймалы иде, хәзер алачак сумманы бер урында сан белән, икенче урында сүз белән язарга кушалар. Карчыкның имән ботагы шикелле кәкрәеп беткән бармаклары һич тә аңа буйсынырга теләмиләр. Арттан: "Тизрәк",—дип ашыктыралар.

—Ярдәм итегез әле, зинһар,—дип мөрәҗәгать итте Кәшшафка касса хезмәткәре.

Кәшшаф бланкны тотырып, әбидән кул куйдырды да бүрек авызы чаклы гына түгәрәк тәрәзә уемы аша эчкә бакты. Бакты да өнсез калды. Элек Кәшшаф Заһидәдән дә чибәррәк хатын-кыз юктыр дип йөри иде. Бар икән ләбаса! Аксыл чәчләре тәлгәш-тәлгәш булып чигәләренә асылынып төшкән. Очлары бөдрәләнеп тора. Шул тәлгәшләр арасыннан курчакныкы сыман нәфис колаклары шәйләнә. Ни сәбәпледер, Кәшшафның күзләре иң элек әнә шул колакларга төште. Сыйпап аласы, мәче баласын сыпырган кебек сыпырып-сыпырып торасы килде. Озын ак муен, карлыгач канатлары шикелле җәелгән кашлар. Күзләре зәңгәр, зур.

—Үзегезнең ни йомыш?—дип, сөттәй ак тешләрен күрсәтеп елмайды ханым. Күрәсең, ул бу ыспай ир-атның үзенә күзе төшүен сизеп алган иде инде.

Кәшшаф эшен бетергәч, Фәннәр академиясе тыкрыгыннан Черек күл бакчасына таба юнәлде. Исәбе шунда бераз һава алмаштырып, ял итеп алу иде. Ә үзе юл чатындагы "Чәчәкләр" кибетенең ишеген ачты. Бәйрәм вакытларында монда баш тыккысыз була. Бүген кеше күп түгел иде. Кәшшаф бер букет чәчәк сатып алды да килгән юлыннан кире менеп китте.

Кассада халык кимемәгән иде. Чыр-чу. Әби-бабайлар кулына чәчәк бәйләме тоткан килеш-килбәтле ир-егетне күреп, бер-берсенең каралыгына гаҗәпләнгән каргалар кебек бермәлгә авызларын ачып тынып калдылар.

Кәшшаф туп-туры тәрәзә янына килеп басты да үрелеп, әлеге чибәр ханымга чәчәк бәйләмен сузды.

—Бу сезгә,—диде дә үзе кырт борылып китеп барды.

Чибәркәй аны тышкы ишек бусагасында куып житте.

—Гафу итегез,—диде Кәшшаф,—минем сезгә чәчәк бүләк итәсем килде...

—Рәхмәт. Минем сары розалар яратканымны каян белдегез?

—Йөзегез шуны әйтеп тора. Сез, мөгаен, кояш кызыдыр.

—Сез әүлияме әллә, барысын да белеп торасыз?

Эчтә шаулашкан тавышлар ишетелә башлады.

—Пенсия көнне әнә шундый мәхшәр инде бездә,—диде ханым гафу үтенгәндәй. Аннан соң озын керфекләрен җилпеп алды да мәгънәле генә итеп өстәде: "Мин кичке җиедә бушыйм. Исемем Зөләйха".

—Ә мин Кәшшаф булам, ашыгыгыз, әбиләрегез бунт күтәрә анда.

Гарәпләр әйтә ди бит, йа рабби Ходаем, үзен китер унаен, ат бир, бия бир, өсте өстенә өя бир. Шуның шикелле Ходай ана өсте өстенә өеп бирде бүген. Юлына, әнә, Зөләйханы да чыгарып куйды.

Кәшшаф фатирына кайткач, тиз генә буйдаклар ризыгы—күкәй тәбәсе пешереп алды, чәй куйды. Аларны залдагы кечкенә өстәлгә тезеп, үзе диванга сузылып ятты. Уйлары аны хатын-кызлар дәрьясына өстерәп алып керде.

Дәрига да булдыклы, әйбәт хатын. Чибәрлек ягыннан да ким-хур түгел. Ләкин гаилә таркалу алдында тора. Диссертациясе бер якка хәл ителгәч, аның белән бик әйбәтләп анлашырга туры киләчәк. Җә яшәп китәргә, җә хушлашырга.

Бәлки, Заһидә белән мөнәсәбәтләрне яңартыргадыр? Иреннән аерылган, кем әйтмешли, дүрт ягы кыйбла. Тик Кәшшафның төн йокыларын качырган Заһидә түгел шул инде ул хәзер. Остабикәгә әйләнгән. Намазга бастым, ди, "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә укыйм, ди.

Хәер, элегрәк булса, Кәшшаф намаз дип, мәчет дип тормас иде, ике дә уйлап тормыйча әлеге адымга барган булыр иде. Хәзер сон инде. Мәхәббәте янып көлгә әверелде. Бер киселгән икмәкне кире ябышмый диләр. Хәлбуки, ул Заһидәнең мөселман асылына кайтуына сөенә генә.

Ә менә Зөләйха белән нишләргә? Очрашуга бармасаң, рәнҗер, мөгаен, буш бәндә икән дияр. Кәшшаф аның ничек үпкәләвен күз алдына китереп карарга тырышты. Тулы иреннәре, әнә, балаларныкы шикелле бүлтәеп чыкты, озын керфекләре күбәләк канатлары шикелле җилпенеп-җилпенеп ала. Авызы турсайган, ияк очлары мелт-мелт килә.

Кәшшаф шушы уйлар эчендә изерәп йоклап киткәнен сизми дә калды. Төшендә дә асыл затлар аны үз яннарыннан җибәрмәделәр. Башта ниндидер күл буенда Заһидә белән житәкләшеп йөрде. Кич иде, энгер-менгер вакыт. Камышлар арасында үрдәкләр куаныша, бәбкәләре чыккан күрәсең. Күл өстендә вак балыклар сикерешә. Ходайның илаһи бер матур киче. Нигәдер Заһидә генә боек. Кулындагы лилия чәчәкләренең озын сабаклары эт әчәгесе шикелле артыннан сөйрәлеп бара.

—Җайсыз бит, кая рәтләп бирим,—диде Кәшшаф.

—Мин хәзер карчыгадан калган тавык хәлендә инде.

—Чәчәк кебек әле син.

Хатынның күләгәле йөзе барыбер ачылмады.

—Нигә кирәк иде сина ул Мефодий?—дип, Кәшшаф үзенен үпкәсен белдерде.

—Син бернәрсә дә белмисең шул әле, Мефодий минем төп гөнаһым янында чүп кенә.

—Нинди гөнаһ ул?

Заһидә монсу гына карап куйды да, кичке томан эчендә эреп юкка чыкты. Ә Кәшшаф таш-кыялы бер тау итәгендә басып тора иде инде. Биек. Күтәрелеп карасаң, түбәтәең төшәрлек. Шунда гына затлы чатырлар тезелешеп киткән. Алар янында атлар уртлап йөри. Аякларына тышау, кулларына богау салынган кырык әсир ялга утырган. Алда-артта, унда-сулда—сөнгеле сакчылар. Таулар арасыннан тамырланып юл тасмасы сузылган...

Бик таныш күренеш, кайда күрдем соң әле мин бу утыз башлы ак утауны дип, баш ватты Кәшшаф. Тукта-тукта, бу соң баһадирлар батыры Кара Тиен Алыпның тирмәне ләбаса! Идегәй кая, аның унжиде орышчы ир солтаны кая?

Кәшшаф чуаркаеннан төшеп, атының башын тирәккә күтәртеп бәйләде дә, ак утауның ачык ишегеннән эчкә узды. Анда бүксәсе ярдай бүселгән, бик яман килбәтле Кара Тиен Алып гырылдап йоклап ята иде. "Әҗәлем шушы икән",—дип тирә-ягына куркынып каранды Кәшшаф. Ә алдындагы тамашаны күргәч, бөтенләй катып калды.

Янә торып бер бакса,
Ак чыбылдык оясында,
Күк чыбылдык авызында,
Ак утауның түрендә...
...Хур кызыдай утырган
Сылуны күрде.

—Акбеләк!—диде Кәшшаф үзен-үзе белешмичә.

—Атам булды Шаһ Тимер. Үзем булдым Акбеләк...

—Мин сине бу Алыптан коткарам,—диде Кәшшаф.

—Мине исән коткарып, Шиһ Тимергә житкерсән, ...Ни сорасаң—ул бирер!

Кәшшаф ризалыгын белдереп, кызның кулларыннан алды, күзләренә бакты. Һәм янә могжиза! Аның каршында Дәрига ләбаса!

—Мин дә сине яратам,—диде ул Кәшшафның колагына. Әйтерсең лә, Акбеләкнең сүзләрен тынлап торган.

—Алайса нигә ташлап киттең соң?—диде Кәшшаф.

—Син үзең сүзеңдә тормадың, мине бик нык рәнҗеттең.

Кәшшаф авызын ачарга да өлгермәде, кинәт таш-кыяларны ярып, бер кәтү ишәк акырган тавыш ишетелде. Куркуыннан җиргә сеңә язды. Шунда ниндидер көчле кул аны изүеннән эләктереп алды, чукмардай зур-зур йодрыклары.

Кара Тиен Алыпны шул алагаем зур чукмар йодрыкларыннан танып алды Кәшшаф. "Җибәр, Кара Тиен Алып, минем бер гаебем дә юк",— дип әйтергә теләи, әмма авызы кипкән, теле әйләнми.

Кәшшаф уянып китте. Кара Тиен Алып та, Акбеләк, Зәһидә, Дәрига да төш пәрдәсе артында калды. Әмма башын һаман нәрсәдер бораулый иде әле. Тәмам йокысыннан арынгач кына моның телефон чыңлавы икәнен төшенеп алды ул.

—Мин сезгә тоташтан биш минут шылтыратам инде,—дип ризасызлык белдерде телефончы кыз.

—Халыкара элемтәме әллә?

—Әйе, сезгә Төркиядән шылтыраталар. Тоташтырам.

—Хәерле кичләр булсын, Кәшшаф бәй, Аллаһу үзегезне рәхмәтеннән ташламас, иншаллаһ.

Бу профессор Җансай Хаммат иде. Тавышы шундый якын, хәтта тын алуы да аермачык ишетелеп тора.

—Үзегезгә дә иң изге теләкләремне җиткерәм,—диде Кәшшаф. Төркиядәге гадәт буенча төп сүзгә күчкәнче шактый ара хәл-әхвәл сорашып, таныш-белешләренә сәламнәр җиткерделәр. Соңыннан шул беленде, Җансайның китап белән котлап шылтыратуы икән. Шатлыгы эченә сыймый, гүя үзенең хезмәтен бастырып чыгарганнар.

* * *

Дәрига үзләренең капка төбенә килеп туктагач та машинасыннан чыгарга ашыкмады, уйланып утырды. Аның үзен дә Зөләйха язмышы сагалап тора ләбаса! Ул әвәләнә торган даирәне чылбырыннан ычкынган усал эт белән генә чагыштырырга мөмкин. Мәрхәмәтсез, комсыз, фетнәле даирә. Йә сине үз тирәндәгеләр үк батыра, әнә, Ләбибне дә ахирәт дип йөргән дуслары теге дөньяга җибәрде. Йә—төрмә. Чөнки акча алдан йөргән җирдә җинаять котылгысыз. Ә кырын гамәл иртәме-соңмы барыбер җәзасын ала.

Мал бәя түгел, баш бәя, дия торган иде аның әтисе. Тик балгамайга күнгән авыз һаман азык төрләнә, берсеннән-берсе тәмлерәкне сорый бит ул, каһәр. Нәфесне арканлау һәркемнең дә кулыннан килми. Нәфес житә адәм баласының башына. Кайда сый, шунда кәеф-сафа. Анысы сазлыктан да хәтәррәк, баш-аягың белән суырып алырга гына тора. Дәрига соңгы вакытта кәеф күтәрүләргә бирелә башлады, күнеле әледән-әле "ләззәт"ле үләнгә тартыла. Дөрес, ул әле үзен кулда тота ала. Ә тоталмый башласа? Сер түгел, әлеге көчкә каршы торучы көч тагын да көчлерәк. Юк, башка болай дәвам итә алмый. Бу бәладән аны фәкать Кәшшаф кына коткарып кала ала, аңа гына сыенырга була. Аның бит әле улы бар, Кәрим! Беренче чиратта ул улының хакын хакларга бурычлы.

* * *

Түгәрәк өстәл тирәсендә урын бүлешү ыгы-зыгысы булып алды. Галимов кешеләрне ера-ера Президентка елышты, аның янәшәсенә кунаклады. Хәлилов аптырабрак калды, ул хуҗаның бер ягына үзе, икенче ягына университет профессоры Каюмовны утыртмакчы иде. Галимов белән Сабиров өлгеррәк булып чыктылар.

Президентның кәефе әйбәт, йокысыннан ук пәйгамбәр төше күргән кешедәй сүз белән аңлатып булмый торган ниндидер якты омтылыш белән уянды ул бүген. Җилле-яңгырлы көннәрдә бераз башы бимазалап алган

иде. Үзе ныклап авыртмый да, бармак очына кадалган шырпы кебек тик борчып тора. Моны ул табибларга белгертеп тормады, үтәр әле дип, үзен тынычландырды. Чебен тигәнгә дә чер итәргә, авыл баласы ла ул! Дөрестән дә, көннәр утыруга башы да җибәрде. Шөкер, әлегә зарланырлыгы юк. Үзе ният иткән эшләрен дә акрын-акрын, җайлап-майлап кына кысасына кертә бара. Татар элек-электән дәүләтле булган. Бу традицияләр халыкның канында. Президент буларак, аның максаты да, бүгенге вәзгыятьтән чыгып, шул традицияләрне торгызу, аларга җан өрү, милләтне саклап калу. Әлеге олуг максат хакына чигенешләр дә ясарга туры килә, билгеле. Милләтчеләрдән моның өчен шактый гына эләгә дә үзенә, аны кайберәүләр хәтта татар халкына хыянәт итүдә дә гаеплиләр. Икенче яктан шовинистлар сагалап тора. Еш кына сандалдагы ике чүкеч арасында кала. Әнә, Россия Федерациясе белән Татарстан арасында төзелгән Шартнамә нинди зур бәхәс тудырды.

Татар халкының тарихы иске комган шикелле ямьшәеп беткән, аны ничек теләгәннәр, шулай боргалаганнар, бозганнар, яраклаштырып бетергәннәр. Хәзер татар тарихын өр-яңадан язарга кирәк. Монысы аның йөрәк түрендә утыра. Тиздән махсус тарих институты оештыру турындагы указга кул куелачак.

Кайчакта күңелне күтәреп җибәрү өчен кечкенә генә бер кыйпылчык та җитә. Бүген көне шундый иде булса кирәк. Эскорт Борисково бистәсен үтеп, Чистай магистраленә килеп кергәндә таудан төшүче машиналар да, Кабан күле ягыннан килүчеләре дә туктап торалар иде инде. Юл чатында озын буйлы яшь кенә милиционер үрә катып, үзенә бер дәрт һәм канәгатьләнү белән уң кулын чигәсенә тигезде. Йөзе балкыпмы-балкый, әйтерсең лә, күктән бәхет ишелеп төшкән.

Нигәдер балачактагы шикелле рәхәт булып китте, яңа күлмәк тегеп кигезделәр диярсең. Алар үскәндә авыл баласының шатлык-куанычы күлмәкыштан, япьле пәке шикелле вак-төякләрдән генә тора иде.

Әле дә хәтерендә, башлангыч класста укыганда әнисе чалбар тегеп бирде. "Карагыз әле, Минтимер нинди матур чалбар кигән",—дип, Хәдичә апасы бу яңалыкны бөтен балалар белән уртаклашты. Шунда сеңлесе Мәдәния укытучы янына килде дә: "Апа, ул ике төрле ситсадан тегелгән, аны әнкәй буяуга гына манды",—диде. Ләкин бу әләк кенә яңа чалбар кию шатлыгын киметмәде.

Кичә Әнәктән Олы апасы Дөргалия шылтыраткан иде. Балачакларын искә алдылар, әтисен, әнисен хәтергә төшерделәр. Әтисе озак еллар колхоз рәисе булып эшләде. Бик кырыс, шул ук вакытта бик гадел кеше иде. Беркемгә дә ташлама ясамады. Әнисе дә "Мин персидәтел хатыны" дип аркалануны белмәде, башкалар белән бертигез колхоз эшенә йөрде.

—Минтимеркәем, син үдең дә яшьтән үк үд сүдле булып, үҗәт булып үстең,—диде апасы,—елмаеп-көлеп кенә, тавыш күтәрмәй генә барыбер үденнекен итә идең.

Дөргалиянең бу сүзләре ошады аңа, кеткелдәп көлеп алды.

Шулай, сәясәтче йомры телен ястык итеп җәя белергә дә тиеш ул. Аның турында язганда, әйтик, зирәк, төпле эпитетларын еш кулланалар. Тик ул үзе, дәүләт эшлеклесенә иң кирәкле сыйфат нинди сыйфат, дип сорасалар, сабырлык, дип җавап бирер иде.

И, карендәш, син кирәксә суга бат йә сөткә бат,
Ит сабыр, күрсәт чыдамлык һәм дә ит гайрәт, сәбат!—

дигән бит Тукай да.

Ул кечкенәдән балта белән юнышырга һәвәс иде. Бу гамәл шулай ук сабырлык, түземлек сорый. Әтисе вафат булгач ядкяр итеп аның балтасын алып китте. Әле дә саклый.

—Олы апа, туган көнем җитә, хәзерләнә башла,—диде ул,—яраткан ризыкларымны берүк онытып калдыра күрмә.

—И, Минтимеркәем, онытаммы соң, булмаганны, кыдыл эремчегем әдер инде, катыкны иртәгә китәм дигән көнне оетырмын. Тәбикмәкне

быел әллә үдегедгә килгәчтен генә пешерерменме дип торам. Сина табадан гына алып кайнар көе ашатасым килә.

—Олы апа, син гел әнкәй инде.

Аның уйлары өзелде. Кешеләрнең утырышып бетүен генә көтеп торган шикелле почмактагы аяклы сәгатьнең герләре хәрәкәткә килде. Бүлмәгә жиз телле вараксин гармуны аһәненә охшаш тавыш таралды. «Дың-дың-дың».

Күзләр ирексездән шул якка төбәлде.

—Бар да сәгатькә карый, сәгать кенә берәүгә дә карамый,—дип көлемсерәде Президент.

—Әйе, еллар үтә, гомер сүтә, ертык кинәя,—диде Каюмов.

—Шул ертыкларны ямарга вакыт житте бит, жәмәгать,—диде Президент киная белән,—искесе юкның, янасы булмас ди.

Президент тапкыр сүзле кеше. Аның шаяртуы да ниндидер мәгънәгә ия. Әле хәзер дә халык мәкале аша бу очрашуның әһәмиятен ачыклады, юнәлешен билгеләде. Сүзне бөтенләй көтмәгәнчә башлап жибәрде.

—Борынгы Казанның тасвирламасын беләсем килә минем, аны сез, галимнәр, ничек күз алдына китерәсез?—дип сорады.

—Казан Рәис Саматовичның төшеннән дә чыкмыйдыр, мөгаен. Борынгы калабызны аннан да яхшы белүче юктыр,—дип Хәлилов кем сөйләргә тиешлегенә ачыклык кертте.

Рәис Шакиров күптән түгел генә оештырылган "Казан Кремле" археология экспедициясенең житәкчесе. Жинел сөякле кеше. Исемен ишетүгә ялт итеп торып та басты.

—Мин бу хакта күп уйланам,—дип сөйләп китте ул.—Рәссам булсам, кулыма кылкаләм алыр идем, язучы булсам, тарихи әсәргә тотынган булыр идем, ләкин миндә бу сәләтләрнең берсе дә юк. Шуңа күрә минем чыгышым мәгълүмат бирүгә генә кайтып калырдыр, ахрысы. X гасырның икенче яртысында безнең бабаларыбыз Кремль тавы тирәсенә килеп чыгалар һәм шаккаталар. Чөнки мондый гүзәл жирне күргәннәре булмый әле аларның. Аста тал-тирәкле яшел үзәнлек, шунда ук көмеш сулы елга жәйрәп ята. Мул сулы Идел дә ерак түгел. Ожмах! Әлеге тау башында Шәһре Болгар бистәсе урнашкан икән. Анда хәрбиләр, һөнәрчеләр яши...

Корылмалары башта ук таштан күтәрелгән. Агач ныгытмалар версиясе дөреслеккә туры килми хәзер. Һөнәрчеләр дигәннән, без казу барышында тимер койган урынга да тап булдык. Бер үк вакытта сәүдә дә алга киткән. Моны Гарәп дирһәме, Венгриядән китерелгән бизәнү әйберләре, Балтыйк буеннан гәрәбә, урыслардан—орчык башлары, Иран савыт-сабалары тулысы белән раслыйлар.

—Сез Казанга нигез салынуны X гасыр дип саныйсызмы?

—Мин моны туксан тугыз процент гарантия белән раслыйм, Минтимер Шәрипович.

Кәшшаф Рәиснең кыюлыгына көнләшеп утырды. Рамил менә диган шәкерт тәрбияләгән. Ә үзе болай кистереп әйтергә кыймас иде. Гомумән, эшләгән эшен күрсәтә белмәде мәрхүм. Кылган гамәленнән нәтиҗәсен дәлилли белү үзе бер осталык бит ул.

—Бер процентны гына түгел, чирек процентны да гафу итмәячәкләр,—диде Президент кырысрак тавыш белән.—Безгә мең процентлы ышаныч кирәк.

—Бик дөрес әйтәсез, Минтимер Шәрипович,—дип хупларга ашыкты Президентны Галимов,—хәзер фараз белән эш итүче галимнәр ишәйде.

Монысы безнең тарафка ыргытылган таш инде, дип нәтиҗә ясады Кәшшаф. Аның гажәпләнүенә каршы, Президент институт директорының сүзләрен колак очларыннан гына очыртып жибәрде.

—Хәзер менә шул житмәгән процентларны тутыру өстендә эшлибез, Минтимер Шәрипович,—дип дәвам итте Шакиров.

—Безнең институт бу вазифаны үз өстенә алырга риза,—диде Галимов.—Тәжрибәбез бар, кадрларыбыз ышанычлы.

—Аннан соң, Казан тү-тут, Болгарның башкаласына әверелер дә куяр...

Мазһар Мөхәммәтжановның төрттерүе урынлы иде. Чөнки Галимов болгар теориясенә шулай фанатикларча бирелгән ки, теләсә-нинди гыйльми концепцияне болгар белән изә, болгар белән әвәли. Фәнни бәхәс дигәнне ул үзен кимсетү, мыскыл итү дип кабул итә. Монысы, мөгаен, түрәлеге тудырган мин-минлектер. Югыйсә, булдыклы, төпле галим үзе. Әлегрәк аның сүзе сүз иде, ул нәрсә әйтә, шул була иде. Хәзер дөньялар үзгәрде шул инде. Галимовның авызыннан чыккан һәр җөмләне хуплап тормыйлар. Каршы да чыгалар, тәнкыйтьлиләр дә. Бу, әлбәттә, аңа ошамый.

—Мөһим сөйләшүне уенга бормыйк әле,—дип, ул Президентка карады, аннан яклау көтте. Ә Президентның мәсләге бөтенләй башка иде, тикшерелә торган мәсьәләнең төбенә төшенәсе, аңлыйсы, ачыклыйсы килә иде аның.

—Казан Болгар чорында да, Алтын Урда вакытында да административ берәмлек булгандыр ич,—диде дә укытучы шикелле каршында утыручыларны дикъкать белән берәм-берәм күзеннән кичерде. Әлеге кечкенә генә паузадан Хәлилов файдаланып, сүзгә кушылды.

—Шундый фараз бар, Минтимер Шәрипович,—диде ул борын эченнән чыккан тоныграк тавышы белән,—Туктамыш ханны тар-мар иткәннән соң 1391 елда Аксак Тимер болгар патшасы Абдулланы үтерә. Патшаның хатыны, Алтынбәк һәм Алибәк исемле уллары качып котыла. 1402 елда болгарлар Алибәкне Казанга хан итеп чакыралар. Күрәсең, бу вакытта Болгарның башкаласы Казан каласына күчкән була инде. Димәк, Казанда Алибәккә кадәр кемнәрдер хакимлек иткән. Бу бәйләнеш Кол Шәриф сүзләреннән дә күренә. Үз илен ул әле Болгар, әле Казан вилаяте дип атаган. Вилаять дигәндә ул, мөгаен, Казанны Алтын Урда дәүләтенең бер өлеше булуын күз алдында тоткандыр. Олуг Мөхәммәт улы Мәхмүт белән Казанны алганнан соң ул инде мөстәкыйль дәүләт буларак формалаша. Шуның белән Олуг Мөхәммәт Алтын Урданың башкаласын Сарайдан Казанга күчерә.

—Казан ханлыгын Алтын Урданың дәвамы димәкче буласызмы әллә?—дип Галимов янә башын күтәрде,—бу су язып май чыгару ләбаса, чын мәгънәсендә фальшивка.

—Нигә аны йөрәгегезгә бик авыр аласыз, Сәүбән Сәүбәнович, күптәннән мәгълүм хакыйкать ич бу. Профессор Фирсовның, мәсәлән, түбәндәге сүзләре бар: "Казан патшалыгының барлыкка килүен Алтын Урданың торгызылуы дип карарга мөмкин",—дигән ул. Беренче чиратта профессор моны Алтын Урда хакиме улының Казан тәхетенә утыруы белән дәлилли. Аннан соң, шунысын да онытмаска кирәк, Олуг Мөхәммәт Алтын Урда алып барган сәясәткә турылыклы кала. 1439 елның язында Түбән Новгородны басып ала, Мәскәүгә кадәр барып житә. Бигрәк тә 1444—1445 елларда унышлы походлар ясый. Хәтта Бөек кенәз Василийны әсирлеккә төшерә. Шуннан соң Казан түрәләре рус шәһәрләрендә салым җыя башлый.

Кәшшаф элек Президент тирәсендә йөрүчеләрне өнәп бетерми иде, эшләп түгел, кешнәп яраучы ялагайлар, интриганнар, юмагай тел белән куштанлык аркасында югарыга үрмәләгән буш куыклар дип саный иде. Баксаң, Президент үз даирәсенә тирән фикерле, кыю һәм тәвәккәл кешеләрне җыйган икән. Хәлилов, әнә, ошармы-юкмы, дип тормады, фикерен ярып салды. Ә фикере һич тә тапталганнардан түгел. Президент аппаратында шундый галимнең эшләве фән өчен зур отыш кына лабаса! Үзенең монда чакырылуы да шуның бер дәлиледер әле, мөгаен. Әлегәчә сәлам бирүче дә булмады ич. Хәзер менә санаулы гына галимнәр белән бергә илбашы Сараенда утыра.

—Инде татар-болгар мәсьәләсен ачыклап китүне кирәк дип саныйм,—диде Президент.—Мин, мәсәлән, Сәүбән Сәүбәновичның болгар теориясе белән азмы-күпме таныш. Үзгәрәк фикердә торучыларны да тыңлап үтик әле. Белүемчә шул "үзгә"ләр арасында мөхтәрәм галимебез Кәшшаф әфәнде Хәмитов та бар.

Президент күзләре белән Кәшшафны эзләп тапты да аңа атап сөйли башлады.

—Ишетүемчә, Төркиядә монографиягез басылып чыккан икән,

Кәшшаф Газизович. Котлыйм! Диссертациягезгә дә унай бәяләр алынган дип әйттеләр. Соң булса да уң булсын. Руслар әйтмешли "За одного битого двух небитых дают".

Президент авызыннан үзенә карата шушындый җылы сүзләр ишетү Кәшшафның күнелен утка тигән балавыз шикелле җебетте. Беренче тапкыр гына күргәндәй бөтенесе аңа карап тора. Бик авыр икән ул игътибар үзәгендә калу. Шушы бер минут эчендә чәч аралары тирләп чыкты. Хәзер аңа ничек тә сүз башларга кирәк, бу кыен хәлдән ул фәкать шулай гына котыла ала.

—Хронологик эзлеклелектә караганда, оешкан татар тарихы халыкның күпчелеген борынгы татарлар тәшкил иткән Бөек Төрки каханлыгы барлыкка килгән чордан башлана,—дип сөйләп китте Кәшшаф, ниһаять, хәтта Президентка рәхмәт әйтергә дә онытты. Ярый әле онытканын үзе сизмәде, югыйсә тагын да ныграк кыенсынган булыр иде.—Каханлык җимерелгәннән соң әлеге кабиләләрнең шактые көнбатышка китә, дип исәпләнә. Алар Көнбатыш Себернең, Урта Азиянең, Көнчыгыш Европаның аерым дәүләтләрен, Кимәк каханлыгын, өлешчә Идел Болгары мәмләкәтләрен төзүдә һәм үстерүдә катнашалар. Борынгы татарларның Урта Евразиягә күченүләренең куәтле дулкыны XIII гасырның 20–40 елларында Чыңгыз хан һәм Батый хан гаскәрләре составында була. Татарлар Алтын Урда дәүләтен төзүдә катнашалар, шулай ук аларга кардәш булган кыпчаклар белән берлектә XIV гасырда бөтен татар халкы формалашуның берләштерелгән нигезе булып саналган татар-кыпчак суперэтносын төзиләр. Ә татар халкының тәгаен сәяси-дәүләти төзелеше һәм этник тарихы X гасырда Көнчыгыш Европаның беренче феодаль дәүләтеннән—күп динле Хазар каханлыгыннан юл ала дип уйлыйм. Соңгы башкаласы Журҗан, ягъни Каспий диңгезе янындагы Итил шәһәре. Тагын бер искәрмә: Идел буе дәүләтчелеге тарихы биш чорга бүленеп карала: һуннар чоры (имәнкискәлеләр культурасы), Хазар каганаты чоры, Болгар дәүләте чоры, Алтын Урда чоры, Казан ханлыгы чоры. Һәр чор дәүләтенең башкаласы Идел буенда урнашкан. Шуңа күрә татар халкының килеп чыгышын әллә кайлардан эзләп йөрисе юк.

Кәшшаф, аңлыйсызмы мине дигәндәй, бераз тын алып, Президентка карады. Йөзе бик җитди иде аның. Калын кара кашлары күз кабаклары өстенә җыерылып төшкән, иреннәре кысылган.

Кәшшаф нотыгын дәвам итте:

—Мин Болгар тарихы буенча белгеч түгел, бу Сәүбән Сәүбәнович темасы, шуны гына әйтә алам, Казан татарларының этносәяси тарихында, Татарстанның урта гасыр тарихында һәм тулаем Урта Идел тарихында Идел буе Болгар дәүләте мөһим роль уйнаган. Шуның белән бергә, мин моны элек тә әйтә килдем, хәзер дә кабатлыйм, Болгар чоры гомум татар тарихының иң яхшы өйрәнелгән чоры. Шуңа карап, кайберәүләр бүгенге татарларның Алтын Урдага катнашы юк дигән теорияне алга сөрәләр.

Татар исемен кабул итмәүчеләр бер болгарчылар гына да түгел, әлбәттә. Хәзерге нугайлар да бу исемне үзләрен мыскыл итү дип саный. Уйлап карасаң, бу—Сөембикәне, Нурсолтанны биргән халык!

—Болгарны тулысы белән татар тарихына буйсындырырга ярамый,—дип реплика ташлады Тәфкилев.

—Мин үзем дә буйсындыру ягында түгел. Тик шунысы хак, XIV гасыр азагына—XV гасыр башына болгарларның татарлар тарафыннан ассимиляцияләнүе тәмамлана. Болгар тарихына шуның белән нокта куела. Гомумән, «болгар», шулай ук «хазар» дигән исем йөрткән халыклар булмаган, бу кабилә исемнәре генә. Әлеге кабиләләр, ырулар бетү белән юкка да чыкканнар. Чөнки барлык кабиләләр өчен уртак булган төрки этнонимын алыштыра алмаганнар.

—Димәк, татарларның да, болгар, кыпчакларның да уртак бабалары һуннар булган. Бу тезис күп каршылыкларны алып ташлыйдыр кебек. Әллә ялгышаммы?—дип сүзгә кушылды Президент.

—Ялгышмыйсыз, Минтимер Шәрипович, кайбер тарихчыларга нәкъ менә шундый масштаблы караш җитми дә инде. Хазарлар да, болгарлар да һәм аларның кабиләдәшләре дә үз вакытында һуннар урдасыннан чыкканнар. Әйтик, Мәрҗани үзенең "Мөстәфадел—әхбар" хезмәтендә болгарларның "һун", "утугыр", "кутугыр" дип йөртелүләре хакында яза. Бу юкка гына түгел.

—Мин дә бер ачыклык кертим әле,—дип Каюмов урыныннан торды.

—Утырып кына сөйләгез,—диде Президент.

—Гафу, лекция укып күнегелгән, утырган килеш башка фикер килми.

—Ихтыярыгыз.

—Мәгълүм булганча, Ризаэтдин Фәхретдин мөхәррирлек иткән "Шура" журналы битләрендә 1911—1912 елларда "Без татармы, төрекме?" дигән темага бәхәс куба. "Төрек улы", "Татар улы" псевдоминнарын кулланып, ике автор бил алыша. "Татар улы" Галимҗан Ибраһимов татарлык теориясен яклый. Һәм бу бәхәстә бер мәртәбә дә "болгар" сүзе кулланылмый.

Һуннарга килгәндә, мин сезнең фикер белән килешәм, Минтимер Шәрипович. Әйтик, мәгълүм "Җәгъфәр тарихы"нда шундый эпизод тасвирлана. Бөек хан Болгар тәхетенә дәгъва кылучы белән сөйләшә. Һәм шунда икесенең дә чыгышлары белән Һун каханнарыннан булуы ачыклана. Әгәр чингизидлар һун нәселеннән булса, электән үк һун каганатына буйсынып килгән җирле халык Чыңгыз токымына буйсынырга тиеш иде. "Җәгъфәр тарихы"ндагы хан тамгасын гына алыйк. Автор андагы ике япьле сәнәк тамгасының хазар, болгар чингизидлары тамгасына охшаш булуына игътибар итә. Нәтиҗә ясап әйткәндә, чингизидларның шушы халыклар белән идарә итүгә нәселдән-нәселгә күчеп килгән табигый хокуклары булган. Ягъни, алар басып алучы да, килмешәк тә түгел.

—Ә татар тарихын ничек язабыз?—дип, Президент залга сораулы караш ташлады.

Галимовны бу юлы хәтта Сабиров та тыя алмады.

—Безнең институт бу җаваплы бурычны үз өстенә алырга әзер, Минтимер Шәрипович. Чынында ул тарих бар инде. Басылып чыккан публикацияләрне җыеп туплаганда гына да күп томлы фәнни хезмәт хасил булыр иде.

—Болгар тарихы түгел, татар тарихы хакында сүз бара монда,—дип Мазһар Мөхәммәтҗанов янә Галимовка төрттереп алды.

—Әйе, сүз тулы канлы татар тарихы турында бара,—дип җөпләде аны Президент.

—Без, монда утыручылар, барыбыз да совет тәрбиясе алган, коммунистик идеология белән агуланган кешеләр,—диде Каюмов,—мин үзебезне объектив, хак тарих язарга сәләтле, дип санамыйм.

—Алайса нишлибез соң инде, җәмәгать?

Тынып калдылар. Бүлмә янә сәгать текелдәве белән тулды.

—Ринат Хафизович, хәзер менә синең чаң сукты,—дип Президент үзенең ярдәмчесенә карады.

Сүзгә керешкәнче Хәлилов болай да ыспай утырган соры төстәге пинҗәген сыпыргалаштырып алды, аны барлык төймәләренә дә каптырып куйды. Учы белән авызын каплап йөткереп алды.

—Мин үзем Мөхәррәм Мирсалихович белән килешәм,—диде ул,—безнең тарихчы галимнәребезнең чама белән дүрттән бере генә тарих язарга сәләтле дип уйлыйм.

—Гафу, гафу,—дип кулларын буташтырды Галимов.

Башкалар да әлеге фикерне өнәп бетермәделәр, күрәсең, каз көтүе шикелле гагылдашып тордылар. Шулай булмыйча, бу соң бөтен бер буын галимнәрне чүпкә чыгару ләбаса! Президент сабыр гына утырып кешеләргә хисләрен бушатырга ирек бирде. Тавышлар тынгач кына Хәлиловка ым какты. Һәм тегесе берни булмагандай, сүзен дәвам итте.

—Татар тарихын язуга бөтен дөнья галимнәрен катнаштырырга кирәк дип саныйм. Чөнки татар халкының тарихы Болгар белән генә дә, бүгенге Татарстан белән генә дә чикләнми. Ул үз эченә хәтта рус дәүләтен дә ала.

Мәсәлән, үз биләмәләрендә хакимлек итү өчен кенәзләр Алтын Урда ханнарыннан ярлык алганнар. Алай гынамы, мәшһүр тарихчыбыз Гумилевның язуынча, чынлыкта "Урыс олысы" Алтын Урданың күпләгән төбәкләреннән берсе генә була. Һәм ул Сарайга лояль олыс саналган. XIII гасыр азагында бәйсезлек алырга җай чыккач та әле форсаттан файдаланып калырга ашыкмый. Ә бәйсез Смоленск, Литва явыннан яклау табу өчен, үзен Җүжи олысына алуны үтенә. Күрәсез, татар тарихы бик күп халыклар тарихы белән бик тыгыз бәйләнгән. Әлбәттә, тарих объектив булырга тиеш. Моның өчен халыкара редколлегия төзергә дигән тәкъдим бар. Мин әйткәннәр, билгеле, әлегә проект кына. Әмма аның реаль җирлеге бар, дип исәплим. Калганы үзебездән тора.

Үзебездән тора дигәннән. Аксак Тимер, Идел буйларына һөҗүм итеп, Болгар шәһәрен алганда, бик күп алтын-көмеш хәзинәләр һәм әсирләр кулга төшергән, имеш. Ул бик канәгать калган. "Тоткыннар арасында хикмәт иясе бәндәләр бармы?"—дип сораган. Аңа шәһәрдә бер сукыр шагыйрь барлыгын әйткәннәр. Аксак Тимер аны үз каршысына китергән. Сукыр шагыйрь, думбрасын салып, аңа Болгарның данлы батырлары, байлыклары хакындагы хәлләрне хикәя кылып җыру җырлаган. Аксак Тимер гаҗәпләнеп тынлап торганнан соң, исемен сораган.

—Минем исемем Дәүләт,—дигән шагыйрь.

Аксак Тимер әче телле кеше булган, көлеп җибәргән дә:

—Шулай итеп, Дәүләт сукыр булдымыни инде,—дигән.

Хикмәт иясе шагыйрь болай дип җавап кайтарган:

—Әгәр дәүләт сукыр булмаса, аксак кулына төшәр идемени,—дигән.

Ходай барыбызны да сукырлыктан сакласын.

* * *

Кәшшаф Кремль диварлары янында бер ялгызы басып калды. Кинәшмәдә катнашучыларның, Мазһар белән аннан калганнары, барысы да "көпчәк" өстендәге кешеләр иде. Мазһар экспедиция җитәкчесе Шакиров янына керә калды, йомышы бар икән. Тәфкилев тә тоткарланган булган, күрәсең, каяндыр килеп чыгып, Кәшшафны култыклап алды.

—Котлыйм, дускай, Президент сиңа зур игътибар күрсәтте. Китабың да табадан төшкән икән, бүләк итәрсең бит?

Ул төймәдәй түгәрәк кара күзләре белән Кәшшафка текәлде. Әллә сихерләде инде, ун-унбиш ел буе үзенә каршы төрле аяк чалулар оештырган шушы кешегә: "Әлбәттә, бүләк итәрмен",—дип елмаерга мәҗбүр булды.

—Әйдә, машинага утыр, озатып куям,—диде Тәфкилев үзенә генә хас ясалма кылануы белән. Ә эчендә аның еланнар ысылдый иде: моңа кадәр изеп киллек, моннан соң да рәхим-шәфкать көтмә, безнең кул озын, безгә әле баш-аяк бәлеше пешерергә иртәрәк... Батыр илнең җәнҗалы бетмәс. Әнә, бүген Галимовның бер тәкъдиме дә үтмәде. Яңа институт ачылса, аның йогынтысы бермә-бер кимиячәк. Гуманитар фәннәрнең патшасы иде бит...

Мизгел эчендә Тәфкилевнең башыннан шушы уйлар йөгерешеп узды.

—Юк, минем өйгә кайтасым бар,—Кәшшаф бу юлы хатасын төзәтте.

Тәфкилевкә бу ошамады, йөзен чытып китеп барды. Ә Кәшшаф трамвай тукталышына таба атлады. Тик ул өендә хатыны белән улы һәм дә чираттагы суд утырышына чакыру көтеп торганын белми иде әле.

*1998—2001 еллар.*

***Редакциядән:*** *Шушы көннәрдә язучы Марат Әмирхановка 70 яшь тула. Аны ихлас күңелдән юбилее белән тәбрик итәбез, иҗат уңышлары, сәламәтлек телибез.*



## Равил Фәйзуллин

### ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

### Хәлең ничек, авыл?

*Әй, авыл, син мең шәһәрдән
мең кабат ямьле вә хуш.*

С. Рәмиев

**Хәлең ничек, авыл?**

**Хәлне әйтә табын!
Савым,
артым,
җыем...
Җыем, артым, савым...
Мал-каралтың—илең,
тирес түгәр җирең,
маңгаеңда—тирең...**

**Төшкән тешләр кебек
йортлар кимеп бара.
Беренче сыйныфта
быел ике бала...**

**Хәлең ничек, авыл?**

**Ару гына болай...**

---

Равил ФӘЙЗУЛЛИН *(1943)—Татарстанның халык шагыйре. Биш томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә басылган күп санлы китаплар авторы. Казанда яши.*

Өйләрдә газ яна.
Абзар тулы маллар.
Телевизор ачсаң—
яңа сериаллар.
Онытылды күптән
китап укыганнар...

Өйләнмәгән буйдак
ир-ат урам тулы.
Кызларның уенда
шәһәр-кала юлы.

Хәлең ничек, авыл?

Түгел зарланырлык,
өс—бөтен, тамак—тук.
Дөрес, акча бик юк...
Бетмәс, ахры, бездә
крепостнойлык...
Түләү—натурлата.
Ярый, кыр-басудан
иген, печән кайта.
Кем ничек булдыра—
шулай алып кайта...

...Тыкрык чатында
әйтте сәрхүш түтәй:
«Авыл—кабыгы сау,
эче—аккан күкәй...»

Хәлең ничек, авыл?

Әлхәмдүлиллаһ, шөкер.
Аулак өйләр җыры,
тальяннар моңы,
онытылды дисәм,
бәгыреңә тисәм—
кичер мине, дустым!—
авыл болай исән!
Сулар һава һәйбәт,
Сабантуйлар исән.

—

Буласылар булган,
кибәселәр кипкән...
Туган нигезләрдә
көлләр эреп беткән...
Безнең күбебезне
авыл кеше иткән!
...Буш мәчетләр өсләп
азан ишетелә.

## Юк белән Бар

*юк-бар түгел—*
*яңа мәсәл!*

Барны
барлап
барганда
очрады Юк.
Әйтерләр:
ничек очрасын Юк?—
Юк бит ул юк!

(Пародокс!—ә факт!
Була кайвакыт:
күңелсез—күңелле,
патшалар шыр тиле...)

Бар булмакчы икән Юк!
Кайчак кар булмакчы,
кайчак шар булмакчы,
кайчак яр булмакчы,
Барга пар булмакчы!..

...Ә соң Бар бармы?
Әлбәттә, бар!
Әмма Барны юкка чыгарырлык
бик күп җыен юк-бар.
Шулай да,
уйланырлык бит:
әгәр Җиһанда
Юк—
Бар булмакчы икән,
димәк, юк дигәндә дә
нидер бар!

—

Бу юллардан азык табып,
сөенсеннәр пародистлар!
Ә моралистлар?

Дөньяга кикрик булмасын
юк кешеләр—
чүп ишеләр!

Барлар бар булсын!
Данга пар булсын!

## Бәйлелек

Якты йөзе...
Мәгънәле сүзе...
Талант—үзе!

...Илһамлы каләме өстеннән
гомере буе
карап торды ипи күзе.

## Абсурдизм

*халык санын алу*

**Атаңны син жизни димә!—**
**атаңны атам диген!**
**Татарны тат йә ар димә!—**
**татарны татар диген!**
**...Болыттан күләгә төшкән—**
**шул минем Ватан диген!**

*Акча кирәк! Акча кирәк!*
*Казинога! Зинага!*

**Бу бит хикмәт бай эшмәкәр!**
**Фамилиясе татар!**
**Ата-бабасы татар!**
**Бәлки, милли мәнфәгатькә**
**бераз тәңкәләр атар?**

**Әй, Наивҗан, Наифҗан!**
**Башың бар, дәүләтең юк.**
**Акча уйнашчы хатын күк,**
**акчаның милләте юк.**

## Кисәтү

**Гарәп?**
**Латин?**
**Язсыннар кириллицада**
**беткәнче каралары!**
**Чиркәү динен өйрәнсеннәр**
**мөселман балалары!**
**Эшлә, татар! Тирдә парлан...**
**Азма син үз башыңа!**
**Теләсәк хач беркетербез**
**Сабантуй колгасына...**

## Ишек

*операция*

**Хирургның маңгаенда бөртек тирләр...**

**Күкрәген ярдылар хастаның.**
**Җан чыгарлык ишек ачылды.**
**(Куллар уйный, скальпельләр бии,**
**канлы мамыклар оча, салават күпере ясап...)**
**Финал кайда?**
**Катафалк сыртындамы?**
**Савыгуны көткәннәрнең**
**өмет-шатлык яшендәме?**

...Янә булдым җеназада.
(Хәзер ешайды...)
Таза бәдәнле яшь ирләр—
куллары да кирәк кадәр!—
актарганнар җир куенын.
Кабер әзер. Мәңгелеккә ишек ачык.
Җәннәткәме?
Җәһәннәмгәме?

❦

Ирлек чыкты бәреп тирләрдә!
Гөлләр шытты баскан җирләрдә!
Син, Мәхәббәт, мине нишләттең?!

Җиһан кичкән сабыр Ирне дә
Тал чыбыгы кебек идердең...
Син, Мәхәббәт, мине нишләттең?

Хатирәләр—ялкын, без—күмер...
Яшәр өчен аз шул бер гомер!..
Син, Мәхәббәт, мине нишләттең...

## Чибәрләр ярышында

Мисс!
Алиһә!
Браво!
Афәрин!...

Яралганнармыни чәчәктән!
Нинди грация! Нинди тән!
Оешып беткәннәр бит ундүрттә!
Пешеп җиткәннәр бит унбиштә!..

(Селәгәйләреңне эчкә йот!
Бөкрелегеңне туры тот!..
Алтын кашыгың юк йотарлык!
Дәрманың юк дәртең тотарлык...)

Яшьлек! Яшьлек!
Гомер язы—бәрхет яшеллек!

Шоуга гына түгел, сугышка да
бик тә хаҗәт икән яшь җаннар
(Ядрә бигрәк сизгер яшь канга!)...
Табутларга тамган яшь кайнар...

...Кем сискәнеп тора «Подъем!»га.
Кем таҗ кия Тәхет-подиумда.

# Дүртьюллыклардан

## Спонсор эзләү

*Н. авызыннан*

Ах, читен җиде ятлардан
буй сонып теләнүе!..
Җиңелрәк—карт, бөкре
карчыкка өйләнүең.

Вакыт—талкый... Уй-гамь, исәп баса...
Тәңресе шулай яраткан.
Ата ялкау, пошмас наданның да
башын олпат итеп чал яткан.

Ләйсән яңгырда, күзләрне йомып,
учларымны суздым, тамсын! дип.
...Кемдер учыма тиеннәр салган.
Дөньяда тагын бер ятсындым.

## Тәгәрәштек Думада

Без гел үстек! Һәм үсәбез!—
Юл юк безгә башкача!—
Дәрдмәнд, Максудилардан—
Ахмакыйханнаргача...

## Дәрья

Давылланып, ярсып ташып,
Җиһанны куркыта ала!
...Йомычканы батыра алмый,
корабларны йота ала.

Бу дөньяның аръягында
өч гөнаһка бер савап!
Яшәү дигән табышмакка
табалмадым мин җавап.

Юньсез илнең синдә эше юк.
Умартасы булса, күче юк.
...Тиләләр йортына чират зур.
Акыл базарында кеше юк.

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр

## ҺАВАЛАРДА ОЧКАН КОШЛАР КЕБЕК...

*Язучы Рәшит Габдерахман улы Ибраһимов 1927 елның 28 июлендә Ульяновск өлкәсенең хәзерге Чынлы районы Кәшә авылында колхозчы гаиләсендә дөньяга килә. Бөек Ватан сугышы башлангач та, яшүсмер Рәшит, укуын калдырып, колхозда эшли. 1946 елда Ульяновск шәһәрендә тимер юл училищесын тәмамлый. Куйбышев, Казан шәһәрләрендә урнашкан авиация заводларында эшли. Казан аэроклубы каршындагы радистлар курсына йөри. Кичке мәктәптә 10 классны тәмамлагач, Багырыслан шәһәрендә очучылар мәктәбенә имтихан тота.*



*Очучылык таныклыгы алгач, 1953 елдан, 1979 ел ахырына кадәр Казан аэропортында очучы булып хезмәт итә. По-2, Ан-2, Ил-14, ниһаять, 1966 елдан алып, пенсиягә чыкканчыга кадәр ТУ-124 реактив пассажир самолетында экипаж командиры буларак, зәңгәр һаваны колачлый. Беренче класслы очучы. Аэропорт отличнигы. Чирек гасырдан да артып киткән очу дәверендә кай тарафларда гына булырга туры килми аңа. Туган илендә генә түгел, бөтен җиһанны да аркылысын буйга салып, гаять күп чит мәмләкәтләрне якыннан күреп белергә насыйп була очучыга. Европа җирләреннән тыш, хәтта ерак көньяк-көнчыгышның Һиндстан, Бирма, Вьетнам, Япония, Кытай кебек илләрен гизеп, ниһаять, Җир шарының көнбатыш ягында урнашкан Канада, Флорида, Куба белән дә якыннан торып танышырга мөмкинлек туа аңа. (Болары инде турист-сәяхәтче буларак.) Сүз уңаенда шуны да өстисе кала. 1999 елның язында Сөгуд Гарәбстанында урнашкан Мәккәи Мөкәррәмәдә Олы Хаҗда булып, исламның барлык гыйбадәтләрен кылгач та, Хаҗи исеменә лаек булып кайта ул.*

*Рәшит Ибраһимов үзенең иҗади хезмәтен 1960 елларда «Яшь Ленинчы», «Татарстан яшьләре» газетасы, «Ялкын» журналында басылудан башлап җибәрә. «Көмеш канатлар» дигән махсус рубрика алып бара. Аның «Очучы булам дисәң», «Канатлыга зәңгәр биеклек», «Күктә ниләр булмас», «Көмеш канатлар, зәңгәр хыяллар» дип исемләнгән күләмле мәкаләләрен укыган малайларның кайберләре инде күптән үзләре штурвал тотып, зур-зур һава кораблары белән зәңгәр күктә идарә итәләр.*

*Рәшит Ибраһимов әдәбият өлкәсендәге казанышлары өчен Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исемгә лаек була.*

*1992 елдан Язучылар берлеге әгъзасы.*

Рәшит Ибраһимов

# ОЧУЧЫ ЯЗМАЛАРЫ

## Җир белән күк арасы, ничек үтеп барасы

Бөекбританиядә бер төркем авторлар тарафыннан 1994 елда шактый зур күләмле «Soviet Transports» дигән журнал дөнья күрде. Анда сүз СССР гражданнар авиациясендә иминлек торышы турында бара. Бу журнал сугыштан соң чыгарылган барлык пассажир самолетларының сурәтләрен төшереп кенә калмый, һәр очкычның кайда һәм кайчан ясалганыннан алып, аның нинди ситуациядә авариягә яисә катастрофага дучар булуы турында тәфсилләп бәян итә. Уку барышында журналдагы мәгълүматларның чынлыгына шик калмый, чөнки һавада булган фаҗиганең кайтавазы бик еракларга тарала, димәк, халык ул турыда үзе дә әледән-әле ишетеп-белеп тора. Тик торгынлык елларында бу турыда матбугат битләрендә язып бару түгел, хәтта үзара аралашканда сөйләү дә катгый рәвештә тыела иде. Әмма андагы мәгълүматларны укып чыккач та, кабат уйга каласың: чыннан да, совет халкының тормышы сукыр бер тиенгә дә тиңләнмәде микәнни?

Менә, мәсәлән, Казан аэропортында 1965 елдан алып, 1979 елга кадәр пассажирлар ташыган реактив ТУ-124не алыйк. Бу очкыч турында анда менә нинди мәгълүматлар бирелгән. Укып баксаң, колакларың үрә торырлык.

1964—1965 елларда Харьков шәһәре авиазаводында чыгарылган 112 данә ТУ-124 самолетының 13 е төрле елларда һәм төрле сәбәпләр вә төрле ситуацияләрдә һәлакәткә дучар була. Димәк, бу инде әлеге тип самолетларның һәр унысының берсе пассажирлары-ниләре белән челпәрәмә килгән дигән сүз.

Ә мина калса, очучы буларак, әлеге самолетта аның Казан аэропортына килеп төшкәннән беренче көненнән алып, ниһаять, аларны гамәлдән чыгарылганның соңгы сәгатенә кадәр очарга туры килде. Күрәсең, фәрештәләр (тән сакчыларым дисәм дә ярый) шәхсән мина карата мәрхәмәтле булганнар икән. Ниһаять, язмышым белән мин бәхетлемен. Әмма шулай да һәр очышым да шома гына үтте дигән сүз түгел бу, чөнки һавада ниләр генә булмый, очсыз-кырыйсыз күк бит ул...

## Мөстәкыйль очыш

«Чегән мина башын иде,
Очучы булырсын»,—диде.
Әйткәне юш килде—канатлы итте,
Ярты гомерем һавада үтте.

Оча башлаганнан гына түгел, инде чирек гасыр һавада хезмәт итеп тә, бу гаять җаваплы эштән киткәнемә генә дә шактый гомер узды. Шулай да тәүге мәртәбә үзем генә күккә күтәрелүемне беркайчан да онытасым юк. Һәм бу мөмкин дә түгелдер. Ул чагында иң әүвәле мин җирдәге җиләс һаваның югары биеклектә дуамал җилгә әверелүен тойгандай булдым. Очкычымның ачык кабинасыннан кулымны сузуга, учка ифрат тыгыз һава килеп бәрелде. Ә мин моңа чаклы һавада гел бушлык кына, дип уйлый идем. Тиешле биеклеккә менеп житкәч, тирә-якка күз төшереп алдым. Казан аэропортының ул чагында әле баракта урнашкан аэровокзалы, югарыдан караганда, шырпы тартмасыдай кечтек кенә булып күренә, ә офыкта бөтен бер җиһан, баш очымда исә—иксез-чиксез күк. Әле моннан берничә минут кына элек аэродромнан

күзәткәндә, күк гөмбәзе аксыл-зәңгәр кебек иде, хәзер ул, әнә, карасу-зәңгәр төскә кергән. Рульне үземә таба тартам. Итәкләрен еракларга җәйгән күк гөмбәзе тибрәнеп-чайкалып куйды. Аска юнәлдердем—минем өскә офык авып төште сыман...

Очучылар мәктәбен тәмамлап, хезмәт юлына озатканда очучы-инструкторыбыз: «Һәр очучының үз канат колачы, үз биеклеге, үз офыгы була»,—дигән иде. Минем дә менә фанер очкычта колач җәеп һавага тәүге тапкыр мөстәкыйль талпыныш ясарга маташуым. Бу минем тарафтан Татарстан күгендә салынган һава юлларының беренче чакрымнары гына иде әле. Ә аның дәвамы ничек булыр, кайларга алып барыр ул юллар, мина әле бөтенләй билгесез.

Мөстәкыйль очыш! Яңа канат чыгарган яшь очучы өчен моннан да истәлеклерәк, моннан да куанычлырак вакыйганың булуы мөмкинме икән? Әйе, һәр очучының үз биеклеге, үз офыгы, үз колачы. Шулай да беләсе иде, нинди ерак булыр икән алар минем өчен? Нинди генә булмасын, очучылык кебек зур хезмәткә алынгансың икән, димәк, барыннан да элек үзеңдә сабырлык, түземлелек, тәвәккәллек сыйфатларын булдыру зарури. Мөстәкыйль очыш алдыннан остазымның: «Ярый, канатлыга—зәңгәр биеклек!»—дип кулымны кыскач та, фатихасын алып, мин менә шундый зур һәм җаваплы юлга тәвәккәлләгән идем. Ә тәвәккәл таш ярган, ди. Озынмы ул, кыскамы? Әмма юлның иң ерагы да беренче адымнан башлана бит. Әнә шундый уйлар ул чагында минем башка еш кына килә иде.

Очышны дәвам итәм. Көн аяз, килә яз дигәндәй: күктә бер болыт әсәре дә юк. Югарыда ялгыз бөркеттәй калу, җанга зур рәхәтлек өсти. Очучылар мәктәбендәге кебек арттагы кабинадан торып сиңа беркем дә күрсәтмәләр дә бирми, кисәтүләр ясап та сине бимазаламый. Очкычың-ны теләсәң кайсы якка бор, теләсәң нинди биеклеккә менгер, барысы да синең ихтыярда, үзенә-үзең хуҗа.

Шушы урында үземнең яраткан шагыйрем Шәехзадә Бабичның «Бәхетем» дип исемләнгән гаҗәеп хисле шигыреннән түбәндәге юлларын ирексездән искә төшерәм:

> Зәңгәр күк тажым, чуар җир тәхетем,
> Үзем азат хан, ак кояш—бәхетем...
> ... Гөлләр елмайган, кырлар нурланган,
> Бөтен җир күге нурга чорналган...
> Шашам, ашкынам! Шатланам чиксез,
> Азат мин, азат! Бәхтем офыксыз...

Шул көенчә хисләнеп оча-оча, Кама елгасына җитәрәк, күрәм—маршрутымда бер болыт пәйда булды. Мамык мендәр кебек күпереп тора. Үзе әллә ни зур да кебек түгел иде. Безне инде инструкторыбыз, По-2 самолетының ачык кабинасы өстенә торыпша ябып, приборларга карап кына «сукыр очышка» өйрәткән иде. Ә менә табигый рәвештә чын болытка күмелеп очканым юк әле... Ничегрәк була икән ул? Инструкция буенча бу тыелса да, беркем дә күрми ич! Арт кабинадан йөз килограмм почтадан гайре берни дә юк. Күп тә уйлап тормыйча, тоттым да очкычымны шул болытка юнәлттем. Болыт эченә килеп керү белән башта самолетымны нык кына тотып селкетеп алды. Ярый әле, әйбәт итеп бәйләнеп утырган идем, юкса, кабинадан очып төшкән булыр идем. Шул арада караңгы болыт эчендә калгач та мин калкандагы җиһазларны инде шәйли алмый аптырап калдым. Очкычымның җиргә карата торышын, кая ничек баруымны һич чамалый алмыйм. Ярый әле очу биеклеге шактый югары иде. Шулай алпан-тилпән болытларга күмелеп очкач, ниһаять, караңгылыктан котылып, шактый янтаеп өлгергән очкычым белән болыт арасыннан яктыга килеп чыгам. Приборлар калканына беркетелгән җиһазларның төрле якка таралган укларын урыннарына «җыеп», тиешле юнәлеш алам һәм җинел сулап куям. Чистай

аэродромына төшеп утырганчыга кадәр бу гамәлемнән тәүбә кыла-кыла, бүтән алай эшләмәскә үземә-үзем сүз бирәм.

Әмма еллар үтү белән, очкычлар да камилләшә барды, без инде Ли-2, Ил-14 самолетларында сәгатьләр буена болытларга күмелеп очуларны гамәли күренеш дип йөртә башладык. Тәүге очышта алган күнегүләрем дә ярап куйды бугай. Шушы очкычларның тәҗрибәле очучысы һәм командиры буларак, минем үземә маршрутта гына түгел, ә исә приборларга гына карап томан белән капланган аэродромны эзләп табып исән-имин төшеп утырулар да әллә ни мактауга лаек дип саналмый иде инде. Алай гына булса икән әле.

## Боз каткан самолетта

Ил-14 самолетында очышта булган бер хәрефле вакыйга һаман да истән чыкмый әле. Казаннан Свердловск шәһәренә курс тотабыз. Әле визуаль, әле болытларга күмелеп, җилгә каршы инде ике сәгать буена очуыбызны дәвам итәбез. Вакыт исәбе белән без нәкъ Урал тавы сыртлары өстендә булырга тиешбез. Кабинаның алгы тәрәзәсенә ара-тирә генә ябышкалаган ак бәс шунда ук күзгә күренеп үсә башлады һәм, озак та үтми, анда ялтырап яткан боз чәмәкләре барлыкка килде. Кинәт кенә моторларның җегәрлекләре кимеде, мин моны пропеллерларның әйләнешен күрсәтеп баручы тахометрга карап беләм. Карбюраторлар бозланды дисән? Мин шуңа төшенү өчен моторга газны әле өстәп, әле киметеп, пропеллерларны зырылдатып алам. Бу ысул пропеллерга боз ката-нитә калса да зарури. Самолет эчендә йокымсырап барган пассажирлар ни уйлый торганнардыр, анысы безгә мәгълүм түгел. Хәер, алар инде пропеллердан ычкынып очкан боз кисәкләренең фюзелажга шап-шоп итеп килеп бәрелгәннәрен бераз шәйлиләр булса кирәк. Әмма безнең хәл катлаулана бара. Боз катламнары тәрәзәләрдә шактый калынайды. Сизелеп тора, очкычыбыз авырайды, димәк канатлар да бозландылар. Мин бу турыда янымда утыручы бортмеханикка «ым» кагам. Пассажирлар кабинасына чыгып, иллюминатор аша кул фонаре белән яктыртып караганнан соң ул да моны раслый.



*Рәшит Ибраһимов—«Ан-2» очкычы «командиры».*

Свердловск аэропорты диспетчеры белән элемтәгә кереп мин хәлебезне анлатам һәм өскәрәк күтәрелергә сорыйм.

—Әлегә андый мөмкинлек юк, каршыгызга самолет килә,—дип кырт кисте ул. Түбәнәергә ярамый, алда Урал таулары, без болай да иң аскы эшелонда барабыз.

Ниһаять, диспетчер безгә өске эшелонга күтәрелергә рөхсәт бирә. Әмма соң инде. Очкычыбыз шул кадәр авырайды ки, моторларның егәрлеге бер метрга күтәрелергә дә җитәрлек түгел. Боз каткан очкычыбыз иң акрын тизлектә очып, һавада көчкә тотылып тора. Менә ул инде калтыранып та куйды: ул ирексездән штопорга чумар алдыннан гына шулай итә. Шул көенчә сират күперен гизгәндәй, менә ычкынабыз, менә киттек бугай, дип тагын азмы-күпме очкач, безгә түбәнәергә мөмкинлек туа. Иң башта моторларның куәтен дә киметеп тормыйча, очкычыбызны түбәнәю юнәлешенә куябыз. Ниһаять, очу

тизлегебез инде тиешле дәрәҗәдә һәм самолет һавада тотрыклы булып кала. Аэродромга якынайгач та, бортмеханикка шассиларны чыгарырга кушам. Көпчәкләрнең дөбердәп ояларыннан килеп чыкканын инде ишетеп-сизеп торабыз, әмма ни хәл? Шассилар чыгып, йозакка бикләнсә, яшел ут кабынырга тиеш. Ләкин әле һаман кызылы яна. Көпчәкләрне янадан ояларына җыябыз һәм тагын чыгарабыз. Ләкин тиешле нәтиҗәгә ирешә алмыйбыз. Аэродром өстендә тагын бер мәртәбә әйләнәбез. Инде ягулык та чамалы, без бит каршы искән җилдә очкан идек. Мин, экипаж командиры буларак, бөтен җаваплылыкны үз өстемә алып, утырырга карар кылам, чөнки башка берничиди дә мөмкинлек юк. Югыйсә, безнең хәл тагын да катлауланачак. Безгә беркем дә ярдәм итә алмый, шулай да мин бу турыда диспетчерга белгертергә тиешмен. Алай-болай була калса, янгын сүндерүче машиналар хет якындарак торсыннар иде. Һәм диспетчердан янгын сүндерүче машиналарын стартка чакыруын таләп итәм.

Аэродромга утыру схемасының туры юлына чыгабыз. Биеклек—80 метр. Диспетчер кисәтүе буенча, без инде 100 метр биеклектә үк болытлардан ычкынырга тиеш идек, әмма җир һаман күренми әле.

—Полосаны күрәсезме?—ди диспетчер. Мин самолет белән идарә иткән килеш анар шунда ук җавап бирә алмадым. Беркадәр паузадан соң, минем ярдәмчем—икенче пилот:

—Күрәбез, күрәбез,—дип җавап бирде. Ә мина исә утыру полосасы күренми. Өстәге кабызгыч төймәгә күз төшереп алам. Тәрәзәгә җылыткыч тоташтырылган. Димәк, ул сафтан чыкты булса кирәк.

Ниһаять, ничек кирәк алай ярдәмчем белән икәүләшеп очкычны полосага китереп утыртабыз. Хәзер инде бар кайгы—шассиларда: йозакка нык итеп бикләнгәннәрме алар, юкмы? Тормозларга басарга да куркам, әгәренки шассилар чыгып урынына утырмаган булсалар, ул безнең хәлне тагын да катлауландырачак. Гадәттә, дүрт-биш йөз метр йөгереп баргач та тукталып кала торган очкычыбыз бетон полоса буйлап элдертәме-элдертә. Тормозларга аяк терәп бар көчкә баскан булсак та барыбер файдасы булмаячак икән, чөнки бетон полоса да бозланып каткан булып чыкты. Ярый әле, бирелә утыру полосасы гаять озын иде, югыйсә, хәлебез мөшкел булачак икән. Ә шассиларга килгәндә, алар йозакка нык бикләнгән булып чыкты, тик сигнал лампочкасының тоташтыргычы гына бозланып кату сәбәпле электр контакты булмаган.

Перронга туктап, самолеттан төшкәч кенә, барысы да аңлашыла. Кырпак кына итеп салкын янгыр сибәли, шул сәбәпле салкын бетонга төшү белән ул бозлавыкка әйләнә. Ә бу турыда безгә вакытында тиешле мәгълүматларны җиткермәгәннәр булып чыкты.

Безне каршы алган техниклар белән бергәләшеп самолет тирәсендә әйләнәбез. Кая гына боз катмаган! Канатларда, койрыкта дисенме, бар җирдә дә диярлек боз катламы ябышып тора. Хәтта әле бая гына аэродром өстендә чыгарылган шассиларга да боз ябышкан. Свердловск аэропортының перроны—төнлә булса да яп-якты. Пассажирлар төшеп беткәч, боз тун кигән самолетны тамаша кылырга аэродром хезмәткәрләре җыела башлады.

## Котып аэродромында

Инде бер сөйләгәндә әйтеп калыйм, шушындыйрак хәл Төньякның ин чигендә урнашкан Норильск шәһәрендә булган иде. Анысы да гаять гыйбрәтле.

Без Казан очучылары ул чагында инде ил күләмендә танылып өлгергән идек. Әле Кырымга барып кайтабыз, әле Урта Азия якларына китеп барабыз. Йә булмаса, Мәскәүдән ашыгыч йөк төяп, Хабаровскига юл тотабыз. Шулай итеп, илебезнең һава юллары безгә инде һәр тарафта да таныш иде.

Бәлки шуларын да истә тотып булса кирәк, без инде шактый тәҗрибә туплаган экипажга хөкүмәт заданиесе тапшырылды. Һәрхәлдә өлкән командирыбыз безне ерак сәфәргә озатканда әнә шулай дигән иде. Бу 60 елларның башы гына иде әле. Төньяк котыпның биләмәсенә җәелеп утырган Норильск шәһәренең зур аэродромы сафтан чыгып, анда ремонт эшләре башланган. Шул сәбәпле күп урынлы самолетлар анда төшә алмый тора. Ә җәйге сезонда исә, әнә шул салкын шәһәрдән җылы якларга омтылучы гаиләләрнең исәбе-хисабы юк. Бердәнбер мөмкинлек—авиация.

Менә без инде Красноярск шәһәренә килеп төшәбез һәм иртәгәдән тотынып эшне башлап та җибәрәбез. Безнең экипажга бирелгән йөкләмә әнә шул халыкны «олы юл»га ташып кую, аннан соң алар ул чордагы ин популяр булган күп урынлы Ил-18 һәм Ан-10 һава лайнерларында комфорт белән үзләре теләгән якларга очачаклар.

Әйтергә кирәк, таулы-ташлы урыннарда урнашкан аэродромнарда очулар бик үк җиңел булмады. Югыйсә, Красноярск аэропортының үзенең дә Ил-14 самолетлары бар икән бит, нишләптер ярдәмгә янадан безне чакырып алдылар. Бирeдәге аэродромнар әле берсе дә таныш түгел, без аларны махсус бюрога кереп, сер итеп сакланган схемалары белән генә азмы-күпме таныша алган идек. Баксан, Енисей аэродромы ифрат тар булып чыкты, ул да булса дүрт яктан да очларын күк гөмбәзенә кадәр сузылган карт нарат урманы уртасында урнашкан; Туруханск аэродромы ачык, әмма ул вак ташлардан гыйбарәт—пропеллерларыңны эштән чыгару өчен менә дигән шартлар, Тунгуска аэропорты исә биек ярга урнашкан. Әле өскә, әле аска исеп торган шактый көчле турбулент җил очкычыңны менә-менә ярга китереп сыларга гына тора. Инде соңгы утырыш—Норильскиның шәһәргә елышып торган элеккеге аэродромы. Без өч мең метрлы болыт катламын тишеп чыкканда очкычыбыз шактый гына бозланып та өлгергән иде. Менә безне аэродром диспетчеры да кисәтә:

—Сак булыгыз, исегезгә төшерәм, безнен утыру полосасы кыска, шуның өстенә урыны-урыны белән бозлы да. Бу инде әлеге дә баягы чөй өстенә тукмак иде. Шулай да безгә инде бүтән чара юк. Бөтен игътибарны туплап утырышка киләбез. Гадәттә без һәр кош-кортка хас булган алым белән—фәкать җилгә каршы гына утырырга тиешбез. Ә бирeдә андый мөмкинлек юк. Ян-якка этәреп куйган, күзне чагылдыргыч кар стеналар арасында бары тик бер юнәлештәге полоса. Ә яннан искән көчле җил безнең инде ягулыктан тәмам җиңeләеп бушап калган очкычыбызны әнә шул стенага этәрепме-этәрә. Шуның өстенә полоса да тотрыклы түгел. Инде әйткәнемчә, бозлы. Кыскасы, ничек кирәк шулай, көч-хәлгә килеп утыргач та, без самолетыбызны коймадан да биек кар өемнәре уртасында калган ындыр табагы кадәр генә перронга китереп туктатабыз. Анда инде без килгәнне атналар буена түземсезлек белән көтеп утырган пассажирлар, бала-чагалары белән бергәләшеп, кул чабып, елмаеп каршы алдылар. Ләкин кинәт башланган буран безнең очышны тагын шактый вакытка тоткарлады. Әнә шул көенчә без Казан очучылары өчен бу гаять җәфалы командировка булса да, аның каравы пассажирларны шатландыра-шатландыра өч ай буена үтә тырышлык куеп хезмәт итә-итә, Красноярск гражданнар авиациясе идарәсенә зур булышлык күрсәттек.

Шунысы да хәтергә сеңеп калган. Кайбер пассажирлар Норильскидан якалы пальто киеп очсалар, Красноярскига килеп төшкәч, утыз градус эсселектә алар инде нишләргә белми аптырап калалар. Ә без боларның барысын да кабина тәрәзәсеннән күзәтеп утырабыз һәм безгә ул бераз көлке кебегрәк тә тоела торган иде.

Упкынга убырылып...

Күкедән гомер юраттым,
Бик күп санады.
Кош әүлия дөрес әйтте:
Кабат үлсәм дә, әҗәл алмады.

Июнь аеның 24 нче көне. Күмәк ял вакыты. Самолетыбызга шыгрым тулы пассажирлар утыртып, чираттагы рейс белән Казаннан Кара диңгезгә таба юл тотабыз. Әмма Харьков аэропортында тукталыш ясыйсыбыз бар әле. Җәйге навигация расписаниесендә шулай каралган. Канатларга өчәр тонна ягулык салгач, янадан һавага күтәреләбез. Болытларга күмелеп очкан самолетыбызга кинәт туп ядрәсе килеп бәрелгәндәй булды. Чү! Нәрсә бу?

Очкычыбыз бизгәк тоткандай калтыранып куйды. Аннан соң, зур дулкын сыртына тап булган диңгез корабыдай, борынын өскә чөеп, янтая башлады. Самолетны минем ярдәмчем—икенче пилот алып бара иде. Көтмәгәндә мондый хәлдән сискәнеп китеп, үзем дә сизмәстән ике куллап рульгә ябыштым. Хәзер инде без самолет белән ике штурвалда дүрт куллап идарә итәбез, «чыгымлаган» очкычыбызны нормаль очышка кайтарырга тырышабыз. Бар көчкә тартышабыз, ләкин самолет безне тыңларга теләми. Дулап, тезгеннән ычкынган айгыр сыман, кире якка өстери. Кинәт «бәрелүдән» тибрәнеп калган күпсанлы приборларның күрсәткечләре дә гадәттән тыш танырлык түгел. «Сукыр» очышта самолетның җиргә карата торышын күрсәтүче төп җиһаз—авиагоризонтның торышы да аңлаешсыз. Әгәр ул дөрес күрсәтә икән, димәк, безнең очкычыбыз менә-менә штопорга егылачак. Югыйсә, болай да хәлебез мөшкел. Сизеп торам—тизлек тиешеннән артык кимеде. Ә бит самолетның һавада тотрыклылыгы тизлеккә бәйле. Бу инде безне тагын да кыенрак хәлгә куя. Менә очкычны кабат югарыга чөйде. Мин бөтен гәүдәм белән утыргычыма сыландым. Ул да булмады, ниндидер сихри көч самолетны выжылдатып түбәнгә таба этәрде. Очу тизлегенең кирәгеннән артык булуын күрсәткеч кызыл сигнал кабынды. Бу да куркыныч. Самолетның конструкциясе түзмәскә мөмкин. Бу юлы инде утырган җиремнән аерылып, түшәмгә бәрелдем. Ярый әле каеш белән бәйләнеп утырган идем, юкса... Хәер, болай да җитә калды—күземнән аллы-гөлле утлар чәчелеп китте. Кабинада гүр караңгылыгы урнашты. Ул арада инде безнең очкычыбызны боз ядрәләре тукмаклый башлады. Калай түбәгә эре яңгыр тамчылары төшкәндә дә нык сизелеп тора, ә биредә исә ул дөбердәтәме-дөбердәтә. Тирә-як караңгылыгын ярып якында гына бер-бер артлы яшен яшьнәргә тотынды. Тизлекне тагын да зурайтмас өчен штурвалны гадәттәгечә үземә таба тартмакчы булам, әмма ул бөтенләй бушап калган... «Атың дуласа, дилбегәнне бераз бушайтып ал, югыйсә, чыгымчы ат тезгенен өзүе мөмкин»,—ди торган иде безнең әти. Ике штурвал белән, тарта торгач, идарә органнарын тоташтыручы корыч тросны өзмәдек микән, дигән, шикле уй башка килеп китте. Шулай да өметне бөтенләйгә җуймыйм әле...

Димәк, без көтмәгәндә яшенле болытка тап булганбыз. Харьков аэропорты синоптигы:

—Маршрутыгызда яшен-фәлән булмаска тиеш, әле аңар иртәрәк,—дигән иде бит. Үзебезнең штурман да: «Алда алай-болай күренми» дип ышандырган иде, ичмасам. Әмма бу турыда безнең белән махсус комиссия соныннан төпченәчәк. Әлегә безнең бурыч инде кирәгеннән артык дулаган табигать афәтеннән котылу. Чөнки барысы өчен дә җаваплылык очучылар өстенә йөкләнгән.

Сихри көч йомычкадай итеп безнең утыз сигез тонналы очкычыбызны көтмәгәндә үз кочагына алып, азмы-күпме «шаярткан» соң, шул көенчә үк искәрмәстән чыгарып та атты. Кабина яктырып китте.

Карангылык әсиреннән котылгач та мин визуаль очышка күчәм. Янтаеп егылып төшеп баручы самолетыбызны офыкка карап турайтып горизонталь очышка җайлап куям. Двигательләрнең эшчәнлеген кабат-кабат тикшереп карыйм. Ни әйтсәң дә, иминлек дигәнең, беренче чиратта, шуларга бәйле бит. Шөкер, аларга зыян-зарә булмаган. Самолетның торышы белән мавыгып, биеклекне күрсәтүче җиһазга күз атарга да вакыт тимәгән икән. Баксам, үз күзләремә үзем ышанмый торам. Без бит биш мең сигез йөз метр биеклеккә күтәрелгән идек инде. Приборда исә хәзер бары тик ике мең сигез йөз метрны гына күрсәтә. Бу ничек булды соң әле? Санаулы секундларда шулкадәр тирәнлеккә убылдык микәнни? Әллә инде минем алдагы прибор дөрес күрсәтмиме? Әмма, чагыштырып карасак, икенче очучының да, самолет борынында утырып баручы штурманның да күрсәткечләре шуна тәнгәл килә.

Әле кайчан гына без экипаж әгъзалары белән бергә резервта утырганда «Огонек» журналыннан америкалы «Боинг» самолетының шушындый хәлдә калып, челпәрәмә килүе турында укыган идек. Катастрофа булган урынны югарыдан торып фотога төшереп алганнар. Аның калдыклары шактый кин мәйданда җәелеп ята иде...

Мин моны ихтыярсыз исемә төшерәм. Безнең дә бит әле аэродромга исән-имин килеш төшеп утырасыбыз бар. Ни әйтсәң дә, утлы давылда нык йолыккаланган очкычыбызның идарә органнарына зыян килүе ихтимал. Шуны күздә тотып, самолет белән мөмкин кадәр йомшаграк идарә итәргә тырышам.

Инде хәзер безнең очышка контроль ясап утыручы Харьков аэропорт диспетчеры аша элемтәгә кереп, безнең очкыч белән һавада булган хәл турында мәгълүмат бирергә кирәк. Ишетәм, ул үзе дә безне чакыра:

—45038! Нигә җавап бирмисез? Мин сезне баядан бирле чакырам. Йә, сезгә бирелгән эшелон 7200 метрга менеп җиттегезме инде?

—Харьков! Безне...

Диспетчер минем әйтеп бетергәнне дә көтеп тормыйча, бүлдереп:

—Нишләп алай? Нигә инструкцияне бозасыз... Фәлән-төгән дип, безне шелтәләргә үк тотынды. Күрәсең, безнең белән булган хәлне төшенми тора әле ул. Шул чакны элемтәне очулар белән житәкчелек итүче өлкән диспетчер үзе алды булса кирәк, ниһаять, ул безне аңлады һәм барысын да ачыклагач та безгә янадан үз эшелоныбызга күтәрелергә рөхсәт итте. Шулай да, бәлки Днепропетровск аэропортына төшеп утырырсыз, дип киңәшен дә өстәп куйды. Әмма, мин экипаж командиры буларак, бөтен җаваплылыкны үз өстемә алып, очышны дәвам иттерүне кулай күрдем!

Санаулы минутларда без шул ук тоташ болытларны янадан үтәли тишеп, өскә килеп чыгабыз. Карангы бүлмәдә кинәт ут кабызган кебек булып китә, кояш нурлары күзләрне чагылдыра башлый. Күңелне чиксез шатлык били—якты кояшны кабат күрергә насыйп булды бит, әй! Үземне дөньяга янадан килгәндәй хис итә башладым.

Жиде мен ике йөз метр биеклеккә күтәрелгәч, самолетны горизонталь очышка жайлыйм. Эшелонда барганда, гадәттә, без очкычыбызны автопилотка ышанып тапшырабыз. Ләкин аны ялгарга ашыкмыйм. Нормаль очышка турыдан-туры әһәмияте булган идарә органнарының төзек булуына инангач та, штурвалны ярдәмчем кулына тапшырам. Иллюминатор аша каерылып-каерылып койрыкка карыйм. Яшенле болытлар инде артта калган. Бераз сулыш алгач та, экипаж әгъзаларына күз йөртеп чыгам. Күрәм: алар да ярыйсы ук шүрләгәннәр, әмма эшкә барчасы да сәләтлеләр. Карашым үз кырымда басып торучы озын буйлы бортмеханикның йөзендә тукталып кала. Аның чәчсез пеләш түбәсеннән ак күлмәгенә пылт-пылт итеп кан саркып тора. Ә йөзенә хәтта карарга да куркыныч. Күрәсең, ул шул канны (соныннан үзе әйтүе буенча), тир дип белеп жине белән бөтен йөзенә сылаган... Шөкер, хәвефле минутлар инде артта калды дип, үткән кичерешләрдән бераз бушап калган күңелгә Володяның мондый кыяфәте янадан шом салды. Мин бит ана, салонга чыгып, пассажирларның

хәлен белеп керергә кушмакчы идем. Ул әле үзенең кыяфәтен күрми. Саркып торган кан юлларын янадан жиңе белән сыпырып алды да чыгарга жыенды. Стоп, Володя! Әнә, тәрәзәне кояштан каплый торган пыялага карап ал әле син, үзеңне-үзең танырсыңмы икән?

Пассажирлар янына үзем юнәләм. Алгы якка чыгып басу белән хәйранга калам. Биредәге бар әйберләрнең дә асты өскә килгән. Стюардессабыз Неля пассажирларга өләшергә дип әзерләп куйган конфитләр, татлы су шешәләре—барчасы да идәндә тәгәрәшеп яталар. Әмма, электр белгече дә буларак, минем чәчләремне үрә торырга мәжбүр иткәне алары түгел әле. Стюардесса утыргычы кырында—идән астында—генераторлар, ягъни икенче төрле әйткәндә, самолет электростанциясе урнашкан. Әнә шуның ике катлы идән капкачы икесе ике якка атылганнар. Бар куәтенә эшләп тора торган генераторлар шәрә килеш калганнар. Ә шуларга тоташтырылган ифрат зур ток үткәргеч ике бармак киңлек жиз шиннарның урта берсендә әнә шул «шифалы су» шешәсенең калай пробкасы ята. Тәнемнән салкын кырмыскалар йөгерешеп уздылар. Моның ни белән бетәчәген әйтеп торасы да юк. Очкычыбыз кабат янтая-нитә калса, ул фазаларны тоташтырачак. Ә кыска ялганышның бер көлтә ут чәчеген көт тә тор. Ягулык баклары исә янәшәдә генә беркетелгәннәр...

Кул яулыгымны дүрткә бөкләп, мин иң башта әнә шул пробканы алып ташлыйм. Аннан соң идән капкачларын эзләп табып, «баз»ны томалап куям. Шешә ватыкларын аягым белән бер якка этәреп пассажирлар ягына юнәләм. Шул секундта стюардесса үзе дә килеп чыга. Ишек чаршавын япкач та, уң як жанбызын тотып үз урынына лапылдап утыра. Каядыр бәрелеп, ялангач беләге, сыйраклары ике-өч жирдән сыдырылганнар. Уч табаны пыяла кыйпылчыгы белән жәрәхәтләнгән булса кирәк, шулай ук кызыл тапларга буялган. Аягында бары тик бер тапочкасы гына, әмма ул аны эзләп тә маташырга жыенмый. Неляның үз хәле хәл. Күрәм, шулай да ул самолет хужабикәсе буларак, шул хәлендә булса да пассажирларга ашыгыч ярдәм күрсәтеп керергә дә өлгергән. Инде хәзер кызыбыз күзен дә ача алмый утыра...

Пассажирлар салонына үтәм. Яңа гына кичергән фажигадән соң әле арынып та өлгермәгән барлык пассажирларның сораулы карашлары туп-туры миңа текәләләр. Кыска гына аңлатма бирәм.

—Кинәт кенә яшенле болытка эләктек. Тагын ярты сәгатьтән соң Симферопольдә булачакбыз... Мондыйрак игъланнан соң, пассажирларның йөзендә гадәттәгечә елмаюлар балкымаса да, күренә ки, күпләре тынычлангандай булып калдылар.

Салондагы күренеш чынлап та елмаерлык түгел иде шул. Бу рейста бала-чагалар ифрат та күп икән. Алар әниләре итәгенә әле һаман да чатырдашып ябышып утыралар. Хатын-кызларның күбесе куркышып агарынганнар. Гаилә башлыклары исә үзләренең жәмәгатьләрен бу фажигадән тынычландырырга, «айнытырга» тырышалар. Ара-тирә ыңгырашып аучылар да юк түгел. Күренеп тора, бил поясларын буш кына бәйләп утырганнарын шактый нык ук селкетеп алса да урыннарында утырып калганнар, ә исә бөтенләй бәйләнмәгәннәре түшәмгә очканнар. Нәтижәдә, кайсының кулы каймыккан, кайсысы башын тотып утыра, кайсы...

Салон буйлап жәеп куелган яшел палас өстендә бихисап пыяла ватыклары. Болары кайдан тагын? Күтәрелеп карасам, йа Хода! Түшәмдәге яктырткыч плафоннарның ник берсе исән калсын! Барысы да ярылып-ватылып, чәлпәрәмә килеп беткәннәр. Икенче салонга үтәм, анда да шундый ук күренеш.

Пассажирларның хәл-әхвәле белән өстән-өстән генә танышкач та, мин тизрәк эш урыныма кайтам. Чөнки соңгы утырыш—Симферополь аэропорты белән элемтәгә керергә вакыт житеп барадыр, мөгаен. Чыннан да без инде Сиваш култыгына якынлашып киләбез, ә калган юл реактив очкыч өчен кул сузымында гына. Тик шулай да ул араны гадәттәгедән беразга озаграк узарга туры киләчәк, чөнки мин двигательләрнең куәтен

беркаләр киметкән идем. Үзлексез контроль ясап приборларны күзлим, двигательләрнең эшләвенә колак салам. Әлегә барысы да ярыйсы диярлек. Шулай да һәлакәткә дучар булган очкычыбызга бик ышанып та житеп булмый әле.

Иркенләп бер сулыш алгач та, мин үзебез белән әле генә булган хәлне янадан күз алдыма китерәм. Илаһи көчкә ия булган дуамал табигать тырнагыннан көч-хәл белән генә котыла алсак та, минә әле. экипаж командиры буларак, югарыдарак торган түрәләрем алдында җавап тотарга туры киләчәк. Хәер, анысы инде соңыннанрак. Һавада төрле шартларда инде ничә мең сәгать очып та болай ук булганы юк иде әле. Без гаепле булмаган очракта да әле экипажның очышка әзерләнүен энәсеннән алып җебенә кадәр тикшерәчәкләр. Һавага күтәрелер алдыннан җирдә без уннарча имза калдырабыз. Старт докторы, рекламбюро, дежур штурман, авиадиспетчер, авиатехниклар, синоптикалар һәркайсы да безнең имзага мохтаҗлар. Димәк, алар шул көенчә бар җаваплылыкны безнең өскә аударалар. Менә бүген дә, әлеге очыш алдыннан гына соңгы имзамны мин синоптикта калдырган идем. Барачак маршрутыбыздагы һава торышы белән таныштырып, ул болай дигән иде:

—Сез очасы һава трассасы аша төнлә белән җылы фронт узды. Днепропетровск, Павлоград, Краснодар шәһәрләре метеобелешмә мәгълүматларына караганда, анда яңгырлар бик каты яуды...

Синоптикның «фронт» дигәне, ничектер минем өчен кечкенәдән үк яман төшенчә булып, гүя ул гел канлы вакыйга белән бәйле сыман. Бу атама мәгънәсеннән ерак торса да хәзер дә ул мине сагайта, гомумән, очучылар өчен гүя беркайчан да белеп бетермәслек сәер күренеш ул синоптикның фронт дигәне. Кышын ул нормаль очышка комачаулый торган кар-бураннар, бозлавыклар алып килсә, җәен исә яшенле яңгырлар, көчле җил-давыллар белән бәйле. Кайчакларда тропосферадан да өскәрәк калыккан яшенле болытлар, күтәрелгәндә яки түбәнәйгәндә генә түгел, хәтта реактив самолетларга эшелонда очканда да комачаулыйлар, ә кай очракларда үтә алмаслык киртә булып торалар.

—Фронт Ростов ягына күчте. Хәзерге сәгатьләрдә менә бу төбәктә,— дип, синоптик безнең игътибарыбызны картага юнәлтә. Мин махсус картага кызыл карандаш белән сызылган калын сызыкка күз төшерәм. Әлеге көянтә сызык әнә шул җылы фронт дигәннәре инде.

—Сезнең маршрутта һава торышы инде начар булмаска тиеш. Тик шулай да сак-уяу булыгыз, һавада ниләр булмас,—дип өстәп куйган иде синоптик, гүя җаваплылыкны үз өстеннән төшергәндәй сыман. Без бит сезгә бары тик прогноз буенча көтелгән һава турында гына мәгълүматлар бирдек,—дип тәмамлый ул гадәттәгечә үзенең сүзен.

Әлбәттә, синоптиклар биргән мәгълүматлар һәрчакны да чынбарлыкка туры килеп бетми. Кай очракларда, күрәзәчелек хәлендә генә дә калырга туры килә аларга.

Гадәттә, шушы фронт нигезендә хасил булган яшенле болытларның ин куәтле чагы төн уртасына туры килгәнен без инде үзебез дә беләбез. Мондый фронт сызыгы күп очракта бигрәк тә Сиваш сазлыклары өстендә үтә дә еш кабатлана торган иде. Югарыдан торып, ерактанрак күзәткәндә, гаять күркәм күренеш. Ләкин күрергә күркәм, тотарга куркам. Мин әле генә безнең тирәбездә ялт-йолт итеп торган яшенле болытның табигатен яңадан күз алдыма китерәм. Хәзер инде бу турыда уйланырга да мөмкин. Һәр елны диярлек җәйге навигация башланыр алдыннан синоптиклар без очучыларга лекция укыйлар. Менә шунда алар яшенле болытның илаһи көчкә ия булуы турында кабат-кабат безнең исебезгә төшерәләр:

—Бары тик бер яшен чыбыгының электр энергиясе меңләгән вольт белән исәпләнә, ә аның температурасы исә ун мең градуска кадәр күтәрелә. Мондый температура хәтта домна миченда дә булмый. Бөтен бер болытның потенциал энергиясен бергә тупласаң, атом бомбасына тәңгәл килер иде, дигәне бигрәк тә хәтергә сеңеп калган.

Безнең очракта исә, мин шуны искә төшерәм. Тоташ болытларга күмелеп очкан самолетыбызны баштарак кинәт боз кисәкләре дөмбәсләргә тотынды. Шалт-шолт, гүя туптан аталар. Инде әйтеп үткәнемчә бозлавык авиация өчен, гомумән куркыныч. Кайбер очракларда мондый боз кисәкләренең авырлыгы зенит снарядларына тәңгәл килерлек. Моннан бер-ике ел Воронежда яуган бозлар арасында дүртәр йөз граммлысын табып алалар. Аэропорт перронында торган бар самолетларны да яньчеп-тишеп бетерә ул. Ә шул авырлыктагы бозны һавада уйнатып йөри алырлык жил-давылның куәте нинди булырга тиеш диген син. Күрәсең, без әнә шунысына юлыкканбыз да инде. (Бусы—соңыннан ачыкланачак).

Ниһаять, Симферополь аэропортына исән-имин төшеп утырабыз. Безгә, гадәттәгечә, аэровокзал каршындагы перронга түгел, ә исә ремонт мастерскойлары ягында торган самолетлар рәтенә барып тукталырга ишарә ясыйлар. Пассажирлар төшеп беткәч тә, самолет бортына аэропорт администрация вәкилләре белән бергә, иминлек инспекциясе дә күтәрелә. Алар бездән һавада ниләр булганын төпченә башлыйлар. Ул арада ашыгыч ярдәм докторы кәнәфидә утырып калган пассажирны тикшергәч тә, болай ди:

—Хәзер инде аңар бернинди ярдәм дә кирәк түгел. Күрәсең, ул һавада ук жанын тәслим кылган... Бу әле минем өчен дә яңалык иде.

Иминлек инспекторы анын кесәсеннән таныклык катыргысын тартып чыгара һәм кычкырып укый:

—Харьков шәһәре прокуратурасының өлкән кинәшчесе...

—Әйе,—ди аэропорт начальнигы мина таба борылып,—сезгә жаваплылык тагын да өстәлде бугай. Инде болай да сизәм, бу минем өчен чәй өстенә тукмак булачак.

Самолет салонына юл хәрәкәте диспетчеры килеп керде:

—5515 рейсның экипаж командиры Мәскәү телефонга чакыра. Ашыгыч рәвештә!—дип өстәп куйды ул һәм шунда ук мине машинага утыртып туп-туры авиация диспетчерлыгына алып китте һәм:

—Аппаратта—Гражданнар авиация министрынын беренче урынбасары, сезнен вакыйга белән кызыксына,—диде ул, кирә-керүгә үк мина телефон трубкасын сузып.

Трубканы колагыма куйгач та әле мин дәшмичә торам. Нәрсәдән башларга. Ичмасам, бу бүлмәдә халык азрак булсын иде. Барысының да карашы мина текәлгән.

Трубкада, бераз шытыр-шытыр итеп алганнан соң, көр тавыш ишетелде.

—Симферополь, Симферополь, тынлыйм сезне.

Башта югалыбрак калсам да, урынбасарнын ягымлы итеп, игътибар белән әйтелгән беренче сүзләре мине бераз кыюландырып жибәрде булса кирәк. Һавада чакта ук уйлап куйган жавабымны искә төшереп, вакыйганы кыскача гына сөйләп анлатырга тырыштым. Әмма ул кайбер жирләрен яңадан кабатлатты.

—Әйе, әйе, иптәш министр урынбасары, өч мен дә сигез йөз метрга чумдык.

Ул, монар да әле ышанып житмәгәндәй, бераз эндәшми торды да, очышыбызнын шул моментына кагылган кайбер детальләре белән кызыксынып, янәдән берничә сорау бирде. Аннан сон: «Ярый, бүген-иртәгә министрлыктан махсус комиссия килеп житәр. Барысын да ачыкларлар»,—диде ул, кырт кисеп һәм трубканы аэропорт начальнигына бирергә боерды.

—Тынлыйм сезне иптәш генерал, элемтәдә аэропорт начальнигы Фед...—дип, күрәсен, ул үзенен фамилиясен атамакчы булгандыр, мөгаен, әмма тотлыгып калды. Урынбасарнын вакыты тар булды булса кирәк, ул бу якны тынлап та бетермичә, ана сораулар яудыра башлады. Аэропорт начальнигы исә ана бары тик: «Әле белмәдем, иптәш генерал, әле ачыкламадым, иптәш генерал...—дип кыска жаваплар гына бирә алды.— Пассажирлар турында кайгыртабыз, әлбәттә кайгыртабыз, иптәш генерал...»

Аннан соң ул җавапларын «әйе», «ярар», «эшләрбез» кебек сүзләр белән генә кайтарды.

Телефон трубкасын куйгач та ул, миңа таба борылып, ачулырак караш белән:

—Экипажыгызны җыегыз да, һавада булган хәл турында аңлатмалар язып тапшырыгыз,—диде.—Хәзер үк,—дип өстәп тә куйды.

Аңлатмаларны без—экипаж әгъзаларын—аерым бүлмәләргә утыртып яздырдылар. Нинди хәлдә калуыбыз, нинди халәт кичергәнебез турында һәммәбез дә фәкать үз фикерен кәгазьгә беркетергә тиеш. Андый аңлатмаларны бездән икенче көнне кабат яздырдылар. Янәсе, аңлатмалар арасында каршылыклар юкмы, дөрес сөйлибезме...



*«Ту-124» очкычы янында.*

Ниһаять, өченче көн дигәндә, комиссия үзенең эшен башлап җибәрде. Барлыгы утыздан артык кеше. Арада гражданнар, авиация министрлыгының җаваплы хезмәткәрләре, иминлек инспекциясе вәкилләре, тикшерүчеләр һәм авиациянең төрле тармакларыннан күренекле белгечләр. Хәтта без очучыларның өстәл китабы—«ТУ-124 самолетының аэродинамикасы» авторы да килгән иде. Күрәсең, һәр белгеч тә үз фәне буенча яңа мәгълүматлар алмакчы булгандыр. Ни әйтсәң дә, фаҗига кеше тормышы белән бәйле бит. Ә самолет бортында исән-имин калганнары да теге дөньяга бары тик ике мең метр чамасы гына барып җитми калдылар...

Әмма, экипаж командиры буларак, шәхсән мине гаепләргә тырышкан Одесса шәһәреннән кинәт килеп төшкән галиҗәнап полковник дәрәҗәле хәрби прокурор иде. Ул бик янады: «Хәлеңнән килмәгәч нигә штурвал артына утырдың»,—дип, төкрекләрен чәчрәтеп, уйнатып сөйләде. Баксаң, ул әлеге фаҗигада вафат булган әрвахның улы булып чыкты.

Безнең «эш» бер атнага диярлек сузылды. Башта экипаж әгъзаларының һәркайсын аерым-аерым чакырып энәсеннән алып җебенә кадәр төпченделәр. Аннан соң, аерым секцияләргә бүленеп, кайбер белгечләр үзенә караган сораулар биреп кызыксынды, шул уңайда экипаж әгъзаларының профессионал әзерлеген тикшерделәр. Аэрофлотның баш метеорологы исә, минем алга төрле төстәге сызымнар, тамгалар белән чуалып беткән синоптик картасы җәеп куеп, башта шартлы билгеләрне укытты, аннан соң яшенле болытларның күктә ничек һәм нинди шартларда яралганын тәфсилләп сорашты, аннан ничек итеп саклана белү кагыйдәләре турында сөйләтте. Мин ак кәгазьгә зәңгәр карандаш белән өер болытлар рәсемен төшереп, аның уртасында кызыл сызыкларны чәбәләндереп яшен укларын уйнаттым. Бу яшенле болытның кайсы өлешендә вертикаль һава агымы барлыкка килгәнен, ә кайсы төбәктә андый дуамал агымның түбәнгә юнәлгәнен белгәнемчә сөйләп бирдем. Иминлек инспекторы хәтта шундый сорау да бирде:

—Нигә һәлакәт сигналы «О»ны тоташтырмадың?—диде ул,—ә бит бөтенләй һәлакәткә дучар булуыгыз ихтимал иде.

—Вакыт секундлар белән исәпләнгәндә, без моңа барыбер өлгерә алмаган булыр идек,—дидем мин. Шуның өстенә һава корабында мәтәлгән

мизгелләр эчендә безгә кем һәм ничек ярдәм итә алган булыр иде икән?

Комиссия утырышының соңгы көннәре иде. Миңа аэропорт табибы шалтыратты.

—Санчастька килегез әле,—диде ул. Килеп керүгә үк, табиб мине өлкән яшьтәге бер ханым белән таныштырды.

—Сезнең рейста һавада вафат булган кешенең хәләл җефете...

Ул инде картын җирләгәч тә улы янына бару унаенда безнең тарафларга сугылып чыгасы булган. Вакыйганың ничек булганын шаһитларның үз авызларыннан ишетәсе килгән булса кирәк. Менә шунда ул яшь катыш, хатыннарда гына булган самимилек белән әйтеп тә куйды:

—Мин үзем табиб кеше. Ирем тирән инфаркт кичерде. Больницадан чыгып, азмы-күпме үткәч тә, улыбыз янына барырга ният кылды. Мин каршы килдем. Ләкин ул мине тыңламады. Җитмәсә, билетны да үҗәтләнеп самолетка алды. Янәсе поездда ярты тәүлек селкенеп барганчы, бер сәгать дигәндә анда булачак...

Комиссия җитәкчесе, әлбәттә, моны исәпкә алды. Димәк, бу очракта инде кеше язмышы өчен җаваплылыкны «Аэрофлот» үз өстеннән төшерә дигән сүз. Шулай булганда, авиапассажир үзе өчен үзе җаваплы булып кала.

Ниһаять, комиссия үз эшен тәмамлап, экипажны бүтән тоткарламавы турында белдерде. Безне вакытлыча эшебездән азат иттеләр. Комиссия рәисе мина болай диде:

—Экипажга ике көн ял бирелә. Ялтага барып диңгездә су коеныгыз. Комиссия нәтиҗәсе соныннан булыр. Ә сезнең киләчәк карьерагызны, иптәш командир, министрлыкта хәл итәчәкләр.

Без инде диңгез күрмәгән кешеләр түгел идек, әлбәттә, шулай булгач экипаж әгъзаларының кайберләре Казан рейсы белән шул ук көнне өйгә кайтып киттеләр. Мин бортмеханик белән үзебезнең самолетка юнәлдем. Анда авиатехниклар, Мәскәүдән—Туполев конструкторлык бюросыннан килгән инженерлар самолетыбызны яртылаш сүтеп ташлаганнар һәм аны җентекләп тикшерергә дә керешкәннәр. Детальнең сынган-ярылган җирләрен эзлиләр. Янәсе, бу самолет яңадан һавага күтәрелә аламы-юкмы? Шуңар җавап табарга тырышалар. Самолетыбыз өчен авиамастерской начальнигыннан кул куйдырып, икенче көнне без дә Казанга кайтып киттек.

Өйгә кайтып, ике-өч көн ял иткәч тә, безне, ягъни штурман белән мине, Мәскәүгә чакырттылар. Берничә сәгатьтән соң без билгеләнгән вакытта министрлыкның тугызынчы катында урнашкан иминлек инспекциясе кабул итү бүлмәсендә утыра идек инде. Сәркатип кыз янына кереп килеп җитүебез турында хәбәр иткәч тә, ул безгә ерак китеп йөрмәскә киңәш итте. «Сәгать унберДә коллегия утырышы башлана. Анда министрның беренче урынбасары да катнашачак,—диде улы.—Әнә коридор башында әсбаплар белән җиһазландырылган зур бүлмә бар, шунда кереп бераз әзерләнә торсагыз да ярый. Министр урынбасары профессиягезгә карата сораулар бирергә ярата».

Әйе, безне гел сыныйлар, тикшерәләр. Болай да елына ике тапкыр—җәйге һәм кышкы навигацияләргә әзерләнгәндә дистәгә якын әле зачет, әле экзамен тотабыз. Шулай да, яшенле кара болытлар эченә килеп эләккәч тә, аэродинамика законнары искә дә керми каядыр югалалар, ә штурвал артында утыручылар әнә шул чыгырыннан чыгып дулаган табигать көче белән бергә-бер кала бирәләр.

Коллегия утырышы инде башланды, әмма безне чакырырга уйламыйлар да. Коридорда эссе. Бүген иртән үк температура 25 градус иде. Төш вакыты узып бара. Хәзер инде, шөт, утыздан да югарырактыр. Ачык тәрәзә янына килеп баскач та күкрәккә йомшак кына җиләс һава килеп бәрелгәндәй була. Минем алда Мәскәүнең Үзәк аэровокзал бинасы. Аның теге ягында урнашкан Мәскәүнең беренче аэродромыннан—кайчандыр «Ходынка кыры» дип аталган җирдән аллы-артлы вертолетлар һавага күтәрелеп торалар. Алар Үзәк аэровокзалдан Домодедово, Шере-

метьево аэропортларына пассажирлар ташыйлар. Шушы «Ходынка кыры»ннан 1923 елның 15 июлендә Нижний Новгородка беренче пассажир самолеты күтәрелгән. Хәзерге көндә Мәскәү тирәсендә генә дә житмешкә якын аэродром бар. Әлбәттә, аларның туксан проценты хәрби аэродромнар. Җиде миллион халкы булган Мәскәүгә (хәзер ун миллионнан артык) бары тик өч-дүрт аэропорт хезмәт күрсәтә. Шулай да башкалада гражданнар авиациясе ерак юлларга йөрүдә төп транспорт чарасы булып исәпләнә.

Шул көенчә авиация тарихын искә төшереп, Үзәк аэровокзал белән горурланып, Мәскәү понорамасы белән хозурланып, бераз онытылып торганда, күрәм: Шереметьево аэропорты ягында инде күк гөмбәзенә кадәр сузылып барган кара болыт пәйда булды. Гаять зур болыт гөмбәзе берничә минут эчендә тагын да кабарынып, күперенеп Мәскәү астына авышты. Без аны штурман белән бергә, хәзер инде якыннан торып, күзәтәбез. Пәһлеван болыт тирәсендә ишелеп-ишелеп торган тагын да бихисап болытчыклар хасил булды. Аларның кояш ягындагыларының гөмбәзләре ак калфаклы, кире яктагылары исә кара бүрекләр. Кояшны каплар өчен бер болыт та житә, диләр. Нәкъ шулай булды да. Тирә-як кинәт караңгыланып калды. Шул минутларда безне дә чакырып алдылар. Күрәсең, коллегия әгъзалары утырышларын инде тәмамларга җыенганнар. Сизелә ки, алар әбәдкә ашыгалар. Керә-керүгә үк безгә сораулар яудыра башладылар. Фаҗиганең ничегрәк булганын миннән кабат-кабат сөйләттеләр. Ә флаг-штурман дип аталган гаять зур житәкче минем штурманга:

—Нигә соң алдыгызга куелган локаторыгыздан тирә-яктагы яшенле болытны яхшырак күзәтмәдегез,—диде.

—Мин ул вакытта сафтан чыккан локаторыбызның предохранителен алмаштырып маташа идем,—диде Геннадий.

Аэрофлотның баш метеорологы:

—Метеорология фәнен сез һавада хезмәт итүчеләр биш бармагыгыз кебек белергә тиешсез,—дип кисәтеп куйды.

Шулчак Мәскәү өстендә ифрат зур давыл купты, кемдер форточканы барып япты. Эре яңгыр тамчылары тәрәзә пыялаларын шакый башлады, кара болыт эчендә калган тугыз катлы бина тирәсендә аллыартлы яшен ялтырап куйды, бинаны дер селкетеп күк күкрәде.

Табигатьнең әлеге күренеше ифрат кыска арада шул дәрәҗәдә үзгәреп, дуамалланып, афәт белән янавына төшенеп булса кирәк, синоптикларның баш белгече бер мәлгә тынып тәрәзәгә карап торды. Аннары нидер исенә төшергәндәй, кинәт сикереп торды һәм чыгып та китте.

Безнең белән булган әңгәмәне бик кыска тоттылар.

Безне азат итәр алдыннан рәислекне алып торучы министр урынбасары безгә текәлеп карап торгач, бары тик бер генә сорау бирде:

—Үзегез белән булган фаҗигадән чыгып, Аэрофлот идарәсенә нинди тәкъдимнәр кертә аласыз?—диде ул ихлас күңелдән.

—Мөмкин булса, бары тик бер тәкъдим,—дидем мин.—Андый очракларда без җирдәге диспетчерлар ярдәменә мохтаҗбыз. Ә алар исә нәкъ шул вакытта күрмәмешкә салыналар. Җаваплылыкны үз өсләренә аласылары килми. Ә аларның локаторлары безнекенә караганда гаять камилләштерелгән һәм берсе сафтан чыкса кайнар режимда эшләп торучы икенчесе бар. Безнең бердәнбер локаторыбыз болытлар арасында сафтан чыккан очракта, сукыр песи баласыдай битараф булып калабыз. Ә якында яшен яшьнәгәндә, электрон аппаратының төгәл эшләвенә берминди гарантия юк. Яшендәге электр көче йогынтысында еш кына сафтан чыга торган «гадәте» бар аның,—дидем мин.—Әнә, үзегез күреп торасыз, яшенле болытларның нинди хәрәкәтчән булуларын. Ул болытлар бер урында гына торсалар икән...

Аэрофлот коллегиясендә шундый карар чыгардылар. Без фаҗигагә эләккән экипаж әгъзаларының язмышын безнең авиаотряд командирыбыз үзе хәл итәргә тиеш. Әмма Владимир Павлович Жулква кешелек сыйфатларына гаять бай һәм мәрхәмәтле житәкче иде. Ул безнең хәлгә

керә белде. Мәскәүдән кайткач та өч көн ял бирде һәм без янадан шул ук экипаж составында бергәләшеп яраткан хезмәтебезне һавада дәвам иттек. Безгә иң беренче бирелгән задание—Симферополь аэропортында калдырып кайткан самолетыбызны Минск аэропортында урнашкан рембазага илтеп тапшырырга. Ә бит ул деформация кичергән 45038 номерлы самолетны гамәлдән чыгарырга, дигән әмер килгән иде бит. Инде алгарак китеп әйтәм, ремонт ясагач та аны Казанга янә без алып кайттык.

Үзебезнең самолотыбызны Минскига илтеп кайткач та безнең экипажны кабат Симферопольгә җибәрделәр. Иртә унмаса кич унмый, кич унмаса һич унмый, диләр. Инде Симферополь һава капкасы булган Емельяновка дигән җирне үткәч тә безгә түбәнәергә рөхсәт иттеләр. Без инде хәзер өер болытларга бер күмелә бер чыга очабыз. Нәкъ шул чакны безнең сул канат астыннан тияр-тимәс диярлек бер истребитель очып узмасынмы! Мин бу турыда тиз генә Симферопольгә хәбәр итәм. Ул да булмый, безнең арттан биш-алты минутка сонрак килүче Ил-18 самолетының командиры шул ук каналда гауга күтәрә:

—Симферополь, безгә нидер килеп бәрелде. Болытларга күмелеп очабыз, нәрсә икәнен абайламый калдык...

Без самолетыбызны перронга илтеп туктаткач та, тиз генә урыннарыбыздан төшеп, Ил-18 самолетын каршыларга йөгерәбез. Ниһаять, ул да исән-имин җиргә төшеп утыра. Әмма аны перронга түгел, ә исә сафтан чыккан очкычлар рәтенә китереп туктаталар. Якынрак барып тамаша кылсак, ике күзебез дүрт булды: Ил-18 самолетының сул канат очы ярты метр чамасы әйтерсең лә балта белән чабып алынган...

—Ярый әле ягулык салган өлешенә туры килмәгән диештеләр техниклар, югыйсә, һавада янгын чыгасы көн кебек ачык. Авиадиспетчер янына кергәч тә барысы да аңлашыла. Тихорецк шәһәре янында урнашкан хәрби аэродромнан әлеге МИГ-17 истребительләрендә курсантлар очарга өйрәнәләр икән...

Безнең рейсны тоткарлап, экипажны, янәсе, аэропорт инспекциясенә чакыралар. Бу юлы инде фәкать шаһит буларак кына.

Җәйге навигациянең иң кызу чагы. Аэровокзаллар пассажирлар белән шыгрым тулы. Иншалла, хәвеф-хәтәрсез без инде ай буена очабыз. Нәкъ бер ай дигәндә, без оча торган самолет белән янәсе бер гадәттән тыш очрак. Чираттагы рейс белән Волгоградка очарга җыенабыз. Мин, тормозларга басып, бар куәтенә газ өстим. Двигательләрнең эшләү сыйфатына колак салгач та, очкычны үз ихтыярына куям. Ул шунда ук ыргылып алга чаба башлый. Бу курс белән очып киткәндә полоса тауга түбәнрәк, шул сәбәпле самолетның тизлеге дә сизелерлек арта. Инде менә-менә җирдән аерылып китәбез дигәндә генә кабинага стюардесса йөгереп керә:

—Командир! Пассажирлар салонында янгын,—дип сөрән сала ул. Әлбәттә, тикшереп торырга вакыт юк. Полоса инде бетеп бара, әмма күрә торып самолетка янгын капкан килеш очып китәргә дә ярамый. Һавадагы янгын—иң куркыныч фаҗига. Әнә шундый уй-фикер минем башка яшен тизлегендә килеп керә. Мин, озак та уйлап тормыйча, двигательләргә өстәлгән газны тулысынча алам да, авария тормозларына ике аякны да терәп басам. Самолетның сигез көпчәге дә чыелдап ала һәм бар көпчәкләрдән берьюлы төтен чыга башлый. Полоса беткәч тә без әле тагын ике йөз метр чамасы кара җирдән шуышып барабыз. Ниһаять, ничәмә тонналы бетон плитәләрдән[1] өелгән корылмадан ун-унбиш метр барып житмичә туктап калабыз. Мин салонга йөгереп чыгам. Ул чыннан да әче төтен белән тулган. Тышкы ишекне ачып җибәрү белән салоннан кышын мунчадан чыккан пар кебек югарыга төтен күтәрелә

[1]Азмы-күпме вакыттан соң нәкъ шул бетон корылмага бер ТУ-124 самолеты һәм бер ЯК-40 реактив самолеты килеп бәрелде.

башлады. Озакламый бу тамашаны күреп, старттагы янгын сүндерү машиналары да килеп житте. Ярый ла барысы да хәвеф-хәтәрсез тәмамланды. Тик көпчәкләрне генә алыштырырга туры килде.

## Ут капкан очкычта

Янгын дигәннән, безнең ТУ-24 самолетында булган тагын бер вакыйга турында искә төшерми булмый. Монысы инде һавада чакта булган хәл. Самолетыбызга капкан ут экипаж әгъзаларының гына түгел, ә исә барлык пассажирларның да котын алды һәм һәркайсыбызның язмышы ул санаулы минутларда Ходай Тәгалә кулында иде.

Ленинградтан Казанга кайтып барабыз. Вакыт төнге унберләр чамасы. Безнең самолет өчен бирелгән эшелонга—10 мең метр биеклеккә менеп житәргә әле шактый ара бар. Берничә сәгатькә тоткарланган рейс пассажирлары жирдәге мәшәкатьләреннән соң бераз ял итсеннәр дип, мин бортмеханикны салондагы кайбер утларны сүндереп кирәргә кинәш иткән идем. Ул чыгып китеп, бары тик бер-ике минут вакыт үткәндер, мөгаен, кинәт сул яктагы двигательдә нидер шартлагандай булды. Шул ук мизгелдә әлеге двигательгә контроль ясап торучы приборлар да берсе артыннан берсе нормаль күрсәтмәләреннән читләшеп, реактив двигательнең сафтан чыгуын расладылар. Андый вакытта инде инструкция буенча бары тик бер чара—газны кысып, ягулык керүне туктатырга гына кала һәм мин шулай эшләдем дә. Ул да булмады кабинага бортмеханик йөгереп керде:

—Командир, сул двигательдән койрыкка кадәр ялкын сузылып бара,—ди.

—Ә ни эшләп алай булгач, янгын сүндерү системасының сигнал лампочкасы кабынмады икән соң? Мин «О» сигналын тиз генә ялгап, шул ук вакытта жир белән элемтәгә керәм һәм хәлне аңлатам. Командир буларак миңа бирелгән хокуктан чыгып үземнең ниятем—Ленинградка курс алганыбыз турында да әйтәм.

Ул арада бортмеханик янгын сүндерү системасының беренче чиратын инде кулланып та өлгергән. Ләкин аның файдасы ташка үлчим генә булып чыкты. Янгын бераз сүнеп торды да, төнге караңгылыкны ярып, кабат пассажир тәрәзәләренә үрелә башлады. Икенче чиратны кулланырга туры килде. Ләкин анысы да тиешле нәтиҗәне бирмәде. Бәхеткә каршы ул чагында без инде утыру полосасына якынлашып килә идек. Диспетчер рөхсәте белән аэродром өстеннән әйләнеп тормыйча турыдан гына (гадәттән тыш шартларда) жил уңаенда бер двигательдә төшеп утырабыз. Янгын сүндерүчеләр инде машиналары янында көпшәләрен тоткан килеш безне көтеп торалар. Бу рейста Татарстан обком секретаренең хәләл жефете дә кайта иде. Мин кабинадан килеп чыгуга, аның беренче соравы шул булды: «Шулай ук без һәлакәткә дучар идекмени? Шундый зур самолетны ничек бер двигательдә генә утырта алдыгыз»,—диде ул калтыранган тавышы белән.

—Бу безнең беренче утыруыбыз гына түгел, чөнки бит Татарстан авиаторлары иске самолетларда очалар,—дидем мин.

Без бортмеханик белән шунда ук самолеттан сикереп төшеп, реактив соплога күз төшердек. Күренеп тора: эчтәрәк урнашкан реактив турбина күчәреннән ычкынып китеп, башкаларын да сафтан чыгарган. Акрын жил искәндә дә зырылдап әйләнеп тора торган «калаклы» компрессорны ике куллап та әйләндереп булмый.

Казаннан төзек двигатель китереп житкергәнче бу вакыйга безгә ул көннәрне падишаһ галиҗәнапләренең Кышкы сарае белән якыннан танышып экскурсиядә йөрергә мөмкинлек бирде.

## Күгәрченнән күргән зыян

Безнен «корыч» очкычларыбыз, хәтта йодрык каләрле кошлардан да шактый зур зыян күрәләр иде.

Мәскәүнен Шереметьево аэропортына төшеп житәргә бары тик санаулы метрлар гына калды. Шул мизгелдә полосага житәрәк, жирдә жим чүпләп йөргән күгәрченнәр төркеме дәррәү күтәрелеп китмәсенме! Безгә исә монарчы күзгә чалынмаган һәм көтелмәгәндә кинәт кенә каршыга очып килеп чыккан кошчыклардан читкә тайпылу мөмкин түгел. Чөнки авырлыгы утыз тоннадан да артык булган һава лайнерын жәһәт кенә борып алганда да, ул барыбер инерция буенча күпмедер араны элеккеге юнәлешендә барачак. Төшү тизлегебез бары тик 280 км. гына булса да, кабина тәрәзәсенә берничә күгәрченнең канлы таплары сыланып калды. Әмма шул ук вакытта двигательнен эшләвендә ниндидер ят тавыш пәйда булды. Мин моны самолет белән идарә итү белән мавыгып баштарак ишетми калганмын. Шулай да бортмеханик кинәшен колакка салып, двигательне сүндерергә мәжбүр булдым. Бер двигательдә самолетны аэровокзалнын перронына китереп туктаткач та, безне каршы алган авиатехник канатларнын берничә жирдән яньчелгәнен күреп, башын чайкап куйды—ни булганын ул болай да чамалап алган иде инде. Сул як двигательнен һава туплагыч каналын кесә фонаре белән яктыртуга, анда күгәрчен кереп кысылганын абайлап алабыз.

—Ярый әле двигательне вакытында сүндереп өлгергәнсез,—диде ул,—югыйсә, сигез мен әйләнештә эшләүче реактив компрессор калаклары челпәрәмә килгән булырлар иде. Шулай да бу двигательнен язмышын, яхшылап тикшергәннән сон, махсус комиссия генә хәл итәчәк әле. Шулай булгач, экипажга кунак йортында торып көтәргә туры килер,—диде ул.

## Рейсны киек казлар тоткарлады

Бусы инде киек казлар белән булган хәл. Без Кишинев шәһәреннән кайту унаенда Запорожье аэропортына туктальш ясарга тиешбез. Энгер-менгер вакыт. Ерак офыкта тан инде сызылып кына атып килсә дә, аста жир өсте әле карангылык кочагында. Днепр елгасы сазлыклары өстендә без сонгы борылыш ясыйбыз. Турыга чыккач та полосага төшеп утырырга гына кала. Шассиларны чыгарырга команда бирәм. Нәкъ шул чакны безнен очкычка таба киек казлар якынайганы күземә чалына. Биеклек тә шактый бит әле. Бу югарылыкта ниләре калган аларнын. Самолетны аска ыргылдырам һәм аллы-артлы тезелеп очкан казлар безнен баш түбәбездән үтеп китәләр. Ул да булмый, шап-та шоп безгә нәрсәләрдер килеп бәреләләр. Сизелә ки, болары да шул казлар булырга тиеш. Инде жиргә төшеп утыргач та күренә, бу чыннан да шулай булып чыкты. Шул казларнын берсе шасси рамына кысылып калган. Ул да безгә шактый мәшәкать тудырды. Рейсны ярты тәүлеккә диярлек тоткарлап, самолетны махсус кузлаларга «элеп», шассиларны бер жыеп, бер чыгарып, шактый азапландык. Запорожье авиатехниклары белән бергәләп.

## Бөркет һөжүме

Ә менә бу вакыйга Төньяк Кавказнын «Минеральные воды» аэропортында булган иде. Полосадан күтәрелеп барганда, безнен очкычыбыз кинәт бөркет һөжүменә дучар булды. Ай-һай гайрәтле кош икән ул Кавказ бөркете! Күрәсен, ул нәкъ шул турыда очыш курсынын ун ягында «Кинжал» дип исемләнгән гаять очлы тау кыясыннан күтәрелде булса кирәк. Йә күкәй салып утырганда, ә бәлки нәниләрен бимазалаганнары өчен самолетларга ачуы чыгып, үч алырга теләгәндер.

Ярый да, без әле күтәрелеп кенә бара идек. Шул сәбәпле тизлек зур түгел иде. Юкса, самолетны тишеп кергән булыр иде. Шулай да каты бәрелде. Әлбәттә, инде кыю бөркет бәләкәчләре хакына үзе һәлак булды, әмма безне дә аэродромга кире кайтып утырырга мәҗбүр итте ул. Чөнки без кинәт җир белән элемтәне югалттык. Инде җирдә ачыкланганча, ул безнең антеннабызга килеп бәрелгән икән. Шулай итеп, әлеге мәгърур кош авиаторларга шактый мәшәкать тудырды.

## Тычкан—навигатор

Ярый ла, кош—кош инде ул. Ни әйтсәң дә, һавага алар хуҗа. Ниндидер ясалма кош—самолет, әлбәттә, аларның көндәше булса кирәк. Ә менә һавада безгә чүт кенә авария ясамый калган, экипажны кыен хәлдә калдырган тычканның авиациягә нинди кагылышы бар соң?

Ун мең метр биеклектә Мәскәүгә якынлашып киләбез. Төнге очыш, җитмәсә ул болытлар катламында бара. Ара-тирә нык кына селкетеп тә ала. Димәк, кайдадыр якында гына яшенле болыт булуы да ихтимал. Әнә шундый шактый катлаулы һава шартларында барганда, кинәт кенә безнең компас системасы сафтан чыкмасынмы! Ә бит компас җирне күрми очканда төп прибор. Штурман алай да тикшереп карый, болай да—әмма нәтиҗәсез. Бу турыда Мәскәү авиадиспетчерына хәбәр итәм һәм янәсе «О» сигналын ялгыйм. Болай иткәндә «һәлакаткә дучар» булган самолетны өзлексез контрольдә тотачаклар. Ул алай-болай һава трассасыннан тайпыла башласа, авиадиспетчер экипажга булышырга тиеш. Запас аэродромнар Домодедово белән Горькийда. Ләкин аларның берсе дә компассыз барган самолетны үзләренә кабул итәселәре килми, чөнки аларның да аэродромнарында күз күреме чикләнгән. Мин экипаж әгъзалары белән киңәшеп, ягулык запасын тагын бер кат барлагач, Казанга таба юнәлеш тотарга дигән карарга киләм. Очуыбыз җил унаенда бит, ягулык җитәргә тиеш. Ул арада инде яктыра да башлады. Бортка алынган мәгълүматларга караганда, ярый әле һава торышы Казанда башка аэропортларныкыннан яхшырак булып чыкты. Үзебезнең аэропортка төшеп утырганда, компас турында без бөтенләй истән чыгарган идек инде... чөнки көндезге яктыда һәр нәрсә таныш булган үз аэродромына компассыз төшеп утыру әллә ни куркыныч янамый.

Казан аэропорты авиатехниклары әлеге самолетның идән астында көне буе маташкач та, ниһаять, компасның сафтан чыгу сәбәбен ачыклыйлар. Бер-ике көн элек бүтән экипаж шушы самолетта Ленинградтан фәнни-тикшеренү институты өчен ак тычканнар алып кайткан булган икән. Менә шул чагында берничә качкын тычкан самолетта посып кала. Күрәсең, аларның бик ашыйсылары килгән булса кирәк, югыйсә компасның ток үткәргеч чыбыгын кимерергә тотынырлар иде микән?

## Иминлек сагында торучылар гаебе белән

Әмма андый югарыда бәян ителгән хәвефле хәлләр авиациядә сирәк була. Күп очракларда кешеләр үзләре гаеплеләр. Әйтик, җирдә утыручы авиадиспетчерлар. Алар һавадагы самолетларның хәрәкәтен локатордан күреп, һава пассажирлары иминлеген тәэмин итәргә тиешләр. Әмма бу очракта киресенчә килеп чыкты.

1973 елның җәендә Сочидан кайтып киләбез. Безнең самолетка бирелгән ун мең метр биеклектә Куйбышевтан ерак түгел «Жигули» тауларына якынлаштык. Анда радиостанция куелган, без төгәл шуның аша үтәргә тиешбез. Кайчан һәм нинди биеклектә үтәчәгебез турында инде без югары биеклекне контрольдә тотучы диспетчер белән элемтәгә кереп, ана хәбәр иткән идек. Озак та үтми минем алдагы радиокомпасның угы инде уйный да башлады. Димәк, радиостанция безнең алдыбызда

гына диярлек. Бу төбәктә һава болытлы, әмма бертоташтан түгел. Шул чакны сул яктан, безгә чапырыш килеш, икенче бер самолет килеп чыкмасынмы! Мөгаен, ул әле безне күрми калды. Югыйсә, аның командиры: «Борт такой-то (номеры истә калмаган) проходим Жигули, высота 10 тысяч»,—дип гадәттәгечә генә искәртер иде микән диспетчерга... Шулай итеп, ТУ-134 самолеты безнең борын төбебездән выжылдатып узды да китте. Ул шулкадәр якын иде ки, безнең очкычыбыз исә, аның реактив двигательләреннән ыргылып чыккан дуамал һава дулкынында берничә мәртәбә тирбәлеп тә алды. Безне кара-каршы килеп бәрелү һәлакәтеннән бары тик секундлар аралады. Мин Куйбышев диспетчерын йолып калыр өчен тавыш күтәрмәдем, радиостанцияне үтеп китү вакытын бераз соңрак бирдем. Куйбышев диспетчеры безгә түбәнәергә рөхсәт итте һәм шул унайда хатасына үзе дә төшенеп, гафу үтенде. Әмма бу тавыш инде элеккегесенә охшамаган иде. Күрәсең, өйрәнчек (икенче) яшь диспетчер безне шул хәлдә калдырган иде булса кирәк.

Нәкъ шушыңарга охшашлы вакыйга моннан бер ел элек Днепропетровск аэропортында булган иде инде. Ташкенттан Мәскәүгә «Пахтакор» футбол командасын утыртып барган ТУ-134 самолеты шул ук биеклектә каршыга килгән икенче һава лайнеры белән маңгайга маңгай бәрелешәләр. Нәтиҗәдә, ике самолет ватыклары белән бергә, Днепр пляжларында кызынып ятучы кешеләр өстенә бихисап мәет әгъзалары да коела. Без ул фаҗигале көннең икенче яртысында Днепропетровск аша Киевка очкан идек. Шуннан кайту юлында кабат шул ук аэропортка төшкәч, мондый хәбәрне дә ишеттек. Бу фаҗига өчен җавап бирергә тиешле булган диспетчер, инде үз гомерен үзе чикләгән. Аны сак астына алгач та, ябып куйган бүлмәсендә муенына элмәк салган. Шулай итеп, һавада башланган һәлакәт шул көенчә җирдә дә фаҗига белән тәмамлана. Һава хәрәкәте иминлегендә торган әлеге диспетчерның үз мәете, аның аркасында һәлакәткә дучар булган әрвахларның йөз илле беренчесе була. Бу очракта да төп гаеп өйрәнчек өстендә була, әмма закон буенча аның остазы җавап бирергә тиеш...

## Кайчакларда шулай да була иде

Инде һавада булган хәлләрне сөйләгәндә шуны да әйтеп китми булмый. Кайчагында безгә—гади очучыларга авиация кануннары белән санашмаска үзебезнең җитәкчеләребез дә булыша торганнар иде. Шундый вакыйга әле дә истә. Безнең экипажга 265 рейс белән Мәскәүгә барып кайтырга йөкләнелгән иде. Аэропортта мине үзебезнең авиаотрядның иң өлкән командиры кул биреп каршы алды.

—Кара аны уяу бул. Очышыгыз махсус контроль астында торачак. Сезнең рейс белән обком хуҗасы очарга тиеш,—диде Өлфәт Мостафин, югарыга таба карашын чөеп.

Дежур синоптик ярдәмендә без экипаж белән башта, барачак Шереметьево аэропортының һава торышы белән җентекләп танышабыз. Аннан соң Мәскәү төбәгендәге бүтән аэропортларның да хәлен беләбез, әмма берсе дә бик ышанычлы түгел. Инде минем һәрчак көр күңелле штурманым такмаклап та куйды: «Иртә томан, кич тә томан, бу Мәскәүгә ни булган?»

Чыннан да, шул томан аркасында алдагы көнне дә кичке рейсны үти алмый калганнар икән бит. Мин дә задание биргән җитәкчегә расписание буенча барып җитә алуыбызга шик куйдым. Чөнки миңа командир буларак, очышны үз өстемә алу өчен инструкциядә күрсәтелгән гарантия юк.

Әмма мондый икеләнүем, күрәсең командирыма ошап җитмәде.

—Алай-болай Мәскәү ябылса, запас аэропорт Горькийда утырырсыз. Һава ярыйсы бит, шунда кәтәрсез,—диде ул.—Әгәр үзенә ышанып җитмисең икән, башка экипаж чакырам,—дип тә өстәп куйды остазым, миңа кырын карап.

Ул арада Шереметьево аэропорты синоптигы аэродромдагы томан-

нын күз күремен тагын ике йөз метрга арттырып куя. Әмма бу вакытлы күренеш кенә, һавада эшләвемнең күп еллык тәҗрибәсе шуны сиздерә. Ләкин шулай да пассажирлар төялгән очкычта һавага күтәрелергә бу миңа «рөхсәт» бирә.

Пассажирларны утыртып бетергәч, самолетка Обкомнын Беренчесе күтәрелде. (Ул чагында әле Татарстанның ин олы житәкчеләренен дә, партиянең күренекле әһелләре булуларына да карамастан, хәзергечә «үз» самолетлары юк иде. Алар «гади халык» белән бергә утырып очтылар.) Нәкъ шул чакны хужаны озатырга килгән иптәш, муенына кул аркасы белән сызып:

—Урынына илтеп житкерергә тырышыгыз, командир, югыйсә...

Түрә самолетка кереп киткәч тә әлеге ярдәмче тагын шул ук хәрәкәтләрен кабатлады. Аннары, сәгатенә күз төшереп алды да, минем колаккарак елышып: «Тагын дүрт сәгатьтән соң ул Брежнев янында булырга тиеш»,—дип кисәтте.

Менә без инде һавада. Бераздан Горькийны узып китәчәкбез. Кыска дулкынлы радиостанция ярдәмендә һава хәрәкәте диспетчеры белән элемтәгә кереп, һава торышының соңгы мәгълүматлары белән танышам. Запас аэродром буларак, әлегә ярыйсы кебек. «Ләкин безнең аэропорт ябык,—ди диспетчер.—Сәбәбе—самолетлар урнаштырырга урын юк!» «Менә сиңа көлҗемә,—дип, үчекләп куя аны минем штурман.—Аэродромда урын юк, имеш». Безгә һавада чакта диспетчерлар белән гапләшергә катгый рәвештә тыела. Без аның белән элемтәне өзеп, Мәскәүгә күчәбез. Элемтәгә Шереметьево аэропортын чакырабыз. «Ярый, әлегә безгә таба курс тотыгыз»,—ди өске һава зонасы диспетчеры. Әмма без Мәскәү һава зонасында түбәнәеп, утырырга килгәндә, аэродромда күз күреме кинәт начарланып китә. Инде безгә ни эшләргә кала. Запас аэродром безне кабул итүдән баш тартты, ә Мәскәүнекеләр барысы да томан эчендә калган. Хәзер инде пассажирлар иминлеге өчен экипаж командирыннан гайре беркем дә җаваплы түгел. Ә безнең самолет салонында бит әле дистәләгән пассажир белән бергә Беренче үзе дә утыра. Аның өчен икеләтә җавап тотарга туры киләчәк...

Мин, һич тә икеләнеп калмыйча, Шереметьево аэропорты диспетчерына:

—Сезнең аэродромга утырабыз,—дим һәм утырышка ярдәм итәрлек барча радио җиһазларны да эшкә җигүне таләп итәм.

Мин ышанам, биредәге полосаның озынлыгы Казанныкына караганда өч мәртәбә озынрак, ә киңлеге исә ике мәртәбә киңрәк. Радио җиһазлар да һәрчак яхшы эшли иде бирегә. Бу инде самолетны «сукыр» килеш утырту өчен гарантия дигән сүз.

Иминлектә контрольдә торган соңгы звонок шалтырады. «Полосага житәргә бер чакрым калды»,—ди штурман. Аны мин үзем дә беләм. Звонок нәкъ шуны аңлата да инде. Әмма полоса күренми...

Ниһаять, җирне бөтенләй күрмичә, бары тик приборлар ярдәмендә генә бетон полосага төшеп кунаклыйбыз. Инде очкычыбызның полосада йөгереп барганын сизәм, шулай да тормозларга басарга ашыкмыйм... Әгәр дә полосаның бер кырыена эләккән булсак, тигезсез тормозлау нәтиҗәсендә самолетны бетоннан чыгарып атуы мөмкин. Әйдә, йөгерә бирсен! Әйткәнемчә, полоса биредә чамасыз озын бит. Менә без бөтенләй туктальп калабыз. Әмма кайсы якка тартылып 180 градуска борылыш ясарга? Арбада утырган килеш ат дугасы күренмәстәй томан. Сиксән метр киңлектәге полосаның бер ягы да күзгә чалынмый. Шулай да мин уң якка ярым борылыш ясап, очкычны акрын гына кырыйга табарак юнәлдерәм. Бераз баргач минем ярдәмчем—икенче пилот, тәрәзә форточкасына башын тыккан килеш:

—Сигнал утларын күрәм, командир, сулга борыла башла,—ди.

Җәяүледән дә акрынрак барып, ниһаять, перронга килеп туктыйбыз.

Безгә ярдәм иткән диспетчерга рәхмәтләр яудыргач та соңгы үтенечемне әйтәм:

—Зинһар өчен пассажирларны төшерергә безгә трап бирсеннәр әле,

шул турыда перрон хезмәткәрләренә житкерегез,—дим.

Очыш тәмам. Без—барча экипаж әгъзалары—катлаулы очышның унышлы төгәлләнүенә куанып хушка килеп утыргач, мин Беренчене иска төшереп, тизрәк аның янына йөгереп чыгам. Ул инде пәһлевандай гәүдәсе белән коридорны каплап кабина янында басып тора. Безне күргәч та дәшми-тынмый гына башын чайкап куйды. Ни и ну, янәсе.

Перронда безне каршы алучы ник бер адәм заты пәйда булсын. Менә сиңа махсус контроль. Трапның безнең тарафларга әле тиз генә килеп житмәячәгенә тәмам ышангач, без Беренчене ничек жиргә төшереп бастырырга дигән ният белән баш вата башлыйбыз. Безнең бортта алюмин баскыч бар-барын, әмма ул шалтай-балтай гына. Аның буенча исән-имин төшеп житәргә бернинди гарантия дә юк. Ә жирдән самолет бусагасына кадәр шактый биек. Ул арада Беренчебез сәгатенә күз сала-сала арлыбирле йөрергә тотынды. Күрәсең, ул үзе дә борчыла булса кирәк. Шулай да бердәнбер чара буларак, мин бөтен жаваплылыкны үз өстемә алып, аның ризалыгы белән шалтырап торган баскычтан төшерәбез. Без—экипаж әгъзалары өчәүләп, астан баскычны терәп тотып торабыз, беребез ана өстән булыша. Шула да баскычыбыз бөгелде-сыгылды, әмма сынмый калды. Ниһаять, Беренчебез каты жирдә нык басып тора, инде мина, Ходай ярдәме белән, аның иминлеге өчен жавап бирергә туры килмәде бугай.

Ул арада мина өстән бортмеханик аваз сала:

—Командир, ә калган пассажирларны ни эшләтәбез? Күпме ягулык салырга?—кебек сораулар яудырып, күпмегәдер минем игътибарымны үзенә жәлеп итеп торды. Инде әйләнеп баксам, безнең Беренчебездән жилләр искән.

—Кая таба китте соң ул,—дип сорыйм, янымда басып торган штурманнан.

—Мин күрми калдым,—ди ул. Икенче пилотның жавабы да шул ук.

—Менә сиңа пәрәмәч! Каян эзләргә инде аны хәзер? Ә ул арада томан шул дәрәжәдә куерды ки, кая ана аэровокзалны күреп танырга, яныбыздагы очкыч канатының яртысы гына күзгә чалына.

Тотындык кычкырырга. Өчәүләшеп төрле тарафларга борыла-борыла беравыздан сөрән салабыз:

—Иптәш т..., Фикрать Әхмәтж...

Әмма жавап юк. Тагын кабатлыйбыз. Ниһаять, ул томан эченнән дәшми-нитми үзе килеп чыкты. Инде бүтән югалтмас өчен мин Беренченең жиненнән эләктереп алам һәм үзебез генә белгән ориентирлар ярдәмендә аэровокзалны эзләп китәбез. Кабаланып диярлек эзли торгач, ниһаять, без аэропортның соры бина стенасына чүт кенә мангаебыз белән килеп төртелми калабыз.

Беренчебезне депутат бүлмәсендә черем итеп утырган кызның кулына тапшыргач та, жинел сулап куям.

Диспетчер бүлмәсенә юл тотканда, штурман:

—Әгәренки ул үзе табылмаган булса, Мәскәү аэродромы буйлап Татарстанның Беренче секретарен эзләп йөрүче махсус группаны күз алдына китерә аласыңмы?—диде миңа текәлеп.

Инде шунысын да өстәми булмый. Үз урыннарында калып, шактый вакыт трап көтеп тилмереп утырсалар да, бер пассажир безнең борт кенәгәсендә шундый язма калдыра: «Казан аэропорты очучыларының осталыгына сокланып туя алмыйбыз. Күзгә төртсән күренмәслек томанда да аэродромга төшеп утыра алдылар алар...»

Бу юлларны укыгач та минем ярдәмчем болай ди:

—Әгәр бу рәхмәтне Казанга кайткач иминлек инспекторы укый-нитә калса, ну эләгә безгә командир...

Безгә чынлап та, шактый ук эләкте, тик соңыннанрак. Отряд командиры исеменә Мәскәүдән килгән хат авторының фикере башка төрлерәк иде. Аны шул чагында безнең белән очкан хәрби очучы язган. Ул экипаж командирын, ягъни мине һава торышына карата булган инструкцияне

бозуда гаепли һәм андый очышның ничек тәмамлану ихтималын сурәтли.

Әмма безнең командирыбыз ул эшне зурга җибәрмәде. Күрәсең, Татарстанның Беренче заты белән бәйләнешле булуын да истә тоткандыр, бәлки. Барысын да яңадан тикшереп-нитеп тә тормыйча, үткән эшкә салават, дип кулын гына селтәде. Ә без шул ук экипаж составында очуыбызны дәвам иттек һәм яңадан-яңа могҗизаларга тап була тордык...

Чөнки без иске самолетларда очтык.

Шулай да һавада гел кабатланып торган хәвефле хәлләрнең байтак өлеше самолетларга куелган җиһазларның сафтан чыгуы белән бәйле була торган иде, чөнки без бит нигездә иске самолетларда очтык.

Дистә еллар буена һавада эшләп тә Казан аэропортына яңа самолет кайтартканнарын хәтерләмим. Ул заманда (хәзер дә, мөгаен, шулай) өр-яңа очу аппаратларын мәскәүлеләр алалар иде, аннан соң шактый гына очкач та аларны Куйбышев шәһәрендә урнашкан Идел буе гражданнар авиациясе идарәсе карамагына тапшыралар. Куйбышев аэропортында аларны тагын күпмедер талкыгач, инде кыршылып-таушалып беткән самолетларны Казанга шудыра торганнар иде. Яңадан-яңа конструкцияле самолет дөньяга пәйда булуга да карамастан, мондый гаделсезлек елдан-ел кабатлана килде. Ә бит аларның кайберләре Казан заводларында төзелә торган иде.

Казан очучыларына куркынычсызлыкны тәэмин итү таләпләре шул ук дәрәҗәдә куела иде. Без исә казанлыларны кырык ямаулы самолетларда очыртабыз. Югыйсә, бит аларның да Мәскәү яки Самара кешеләреннән ким җире юк.

Әлбәттә, төрле хәвефле хәлләр бездә шактый ешрак була иде. Һавада двигатель туктап калу дисеңме, янгын чыгу дисеңме—барысы да булды. Шул ук вакытта безнең Казан аэропорты бөтен Идел буе идарәсе китергән каләр акча китерә иде. Әмма без эшләп алган акчалар Куйбышев белән Мәскәүгә китеп бара. Аннан исә иске самолет булып кайта.

Ул чакта ук инде шәбрәк, унайлырак пассажир лайнерлары алып булыр иде. Үзебезнең Казанда ясалып чыгалар бит әле! Һаман да шул—полосагыз ярамый, диләр. Шул ук «Ту-124» белән дә ике-өч тапкыр килеп карагач, мәскәүлеләр, тбилисилылар, куйбышевлылар үзләре дә безгә очудан баш тарттылар. Чөнки алар килгән саен диярлек берәр ЧП була иде.

—Ничек шушында җай табып очалар алар?—башка шәһәрдән килгән коллегаларыбыз шулай дип безгә шаккаталар иде. Без исә шул иске аэродромнан ТУ-124 тә 15 ел очтык. Житмәсә, ел әйләнәсендә. Күптән инде проектлаштырылган яңа аэропортны төзергә Мәскәү һаман акча таба алмады. Ә бит озак еллар буена пассажирларга гына түгел, шәһәр кешеләренә дә куркыныч янап торды. Берьюлы ике үзәккә бәйле булу менә нәрсәгә китерде.

Финанс ягыннан гына түгел, кадрлар ягыннан да рәнҗерлегебез бар иде. Экипажга командир сайлауны Куйбышев кына хәл итә, анысы да әле Мәскәү ризалыгы белән. Гражданлык авиациясенең бөтен эшләү дәверендә (20 нче еллардан кала) аэропорт начальнигы, шул исәптән авиаотряд командиры булып Мәскәүдән яки башка җирдән китергән кешеләр генә эшләде. Казанлыларга ышаныч юк иде. Ә читтән килгән җитәкчеләрнең нинди икәнен үзегез беләсездер. Алар бик озак яшәми иде. Киләләр, шәп квартира алалар, аннары аны бүтән шәһәргә алышалар. Гел шулай булып торды.

Ә бит Казан аэропорты Идел буенда ин өлкәннәрдән исәпләнә. Аэропорт музеендагы документлар Татарстан гражданлык авиациясенең тарихын күз алдына ачык бастыра. ТССР Халык Комиссарлары Советы тарафыннан (аның рәисе Мохтаров инициативасы белән) 1918 елның көзендә үк халык хуҗалыгы ихтыяҗлары өчен беренче авиабаза оештырыла. Тагын да ераграк карасак, 1917 елның 13 февралендә язылган шундый документ бар:

*«Его превосходительству Господину Главноначальствующему Казанской губернии*

*Покорнейше прошу Ваше Превосходительство принять: 500 рублей на*

*имеющуюся быть открытой в гор. Казани Авиационную школу и 500 рублей на подарки воинам к Пасхе.*

*Вашего Превосходительства покорнейший слуга А. Афанасьев».*

Ул елларда бөтен илдә Казан белән Тифлис аэродромнары гына I нче класслылар исәбенә кертелгән. Казанда бөтен СССР һава флоты өчен кадрлар әзерләгәннәр.

Шуна да карамастан, Казанда очучылар коллективы белән күпме еллар читтән килгән кешеләр житәкчелек итте. Башта булган мөстәкыйльлекне дәүләт структуралары әнә шулай бетерде.

Сизәм, мин инде төп фикеремнән бераз читкәрәк тайпылдым бугай. Әйтергә теләгәнем бары тик әнә шул дәвердә үзем очкан самолетларда булган хәлләр турында гына иде. Аларның да, минем уемча, иң гыйбрәтле очраклары турында гына сүз барды. Ә өч дистәгә якын һавада эшләү елларында андый вакыйгалар (кечесе дә, олысы да) ай-һай, күп тапкырлар кабатландылар алар. Ни әйтсәң дә, әгәренки шул һавада хезмәт иткән сәгатьләрне бергә кушып санасаң, күктән бер дә төшмичә ике ел ярым вакытка тәңгәл булыр иде.

Инде иң соңыннан шуны да әйтеп китәргә телим. Без теге вакытта упкынга чумган 45038 номерлы ТУ-124 самолетының язмышы тагын да фажигалерәк рәвештә тәгәлләнде. Аның белән әнә шул соңгы очышта минем сабакташым, беренче класслы очучы Геннадий Воробьев идарә иткән иде. Иң аянычлысы шул, әлеге рейска Геннадий үз теләге белән очкан иде. Айлык график буенча бу рейс белән аның экипажы очмаса да аңа ул бик кирәк иде. Хәләл жефетен Киевтан алып кайтасы бар. Ә жәйге айларда билет юнәтүләр жиңел түгел. Әнә шуннан кайтканда ун мең метр биеклектә, сәгать төнге бердә Пенза шәһәренә житкәнче, самолет һавада таркала. Катастрофа булган урында Геннадийның олы улы атасын бармагындагы (дөресрәге сөягендәге) киң алтын балдагыннан танып ала. Ә анасын исә, гаять чибәр украиналы ханымны күпереп торган кап-кара толымнарыннан барлый.

Әлеге инглиз журналында бу фажига 1979 елның 30 августы белән билгеләнә. Катастрофаның сәбәбе «усталость материальной части», дип язылган иде. Ул көн минем хәтергә дә аеруча сеңеп калган. Чөнки әлеге график буенча ул рейс белән нәкъ шул көнне безнең экипаж очарга тиеш иде, ә безне Воробьев урынына Ленинградка жибәрделәр.

... Менә без инде ул рейсны үтәп әйләнеп тә кайттык. Төнге сәгать унберләр чамасы. Казан аэровокзалы перронында безне нәни флаглар белән һәрчактагы кебек каршы алучылардан берәү дә күренми. Мин диспетчер белән янадан элемтәгә керәм: «Самолетны кайда туктатабыз?» Ул дәшми. Перронда да, гадәттәгечә самолетларны калдыра торган урыннар да ТУ-124 очкыч белән шыгрым тулы. Диспетчерга кабат мөрәжәгать итәм.

—Аптырагансыз икән, соң калдырыгыз шунда берәр жирдә,—ди ул йокы аралаш тавышы белән. Ниһаять, диспетчер янына кергәч, безгә шундый мәгълүмат бирәләр. Геннадий Воробьев идарә иткән 45038 номерлы самолет катастрофага эләккән. Иртәгәдән алып бер генә ТУ-124 очкычы да һавага инде бүтән күтәрелмәячәк. Шулай итеп, гражданнар авиациясе министры имзасы белән, бер селтәнүдә, Казан аэропортындагы 28 реактив очкыч һәммәсе дә гамәлдән чыгарылды һәм икенче көнне аэродромның иң аргы чатында өелеп яткан тимер-томырлар рәтенә төрттереп куелды. Аннан соң берничә көн үткәч тә, хәрби училище шәкертләре үзләренең танкларында аэродромга «һөжүм» итеп, әлеге бичара очкычларны изеп-ватып, пыран-заран итеп киттеләр. Шулай итеп, Татарстан күгендә унбиш ел буена бер тоташтан хезмәт күрсәткән кыйгач канатлы очкычларның язмышы әнә шулай кайгылы тәгәлләнде.



## Рашат Низами

### ВАКЫТ АГАЧЫ

### Илбашына безнең теләкләр

*Әле сине өстән әркетәләр,*
*Тарткалыйлар сине әле астан.*
*Татар халкы дигән җисемеңне*
*Саклап кала килдең, Татарстан!*

**Бездән соң да бик күп язлар килер,**
**Тарих кайнап торыр, әлбәттә.**
**Әмма ләкин бүген СИН кирәкле**
**Татарстан дигән дәүләткә.**

**Мәскәүлеләр әнә яңабаштан**
**Эләктермәк була якадан.**
**Дәүләтчелек дигән хәзинәбез**
**Кайтыр кебек әле яңадан.**

**Исемеңдә тимер чыңлап тора,**
**Җисемеңдә—мәрмәр ныклыгы.**
**Туган телдә сөйли белгән өчен**
**Тыңлау рәхәт сине йотлыгып.**

**Милләтебез, дәүләтебез өчен**
**Син—җаваплы. Без дә җаваплы!**
**Шушы юлда фидаилар булсак,**
**Кызганмастыр Ходай савапны.**

---

Рашат НИЗАМИ *(1950)—шагыйрь, прозаик; «Йолдыз яңгыры», «Кызыл җәй» һ. б. шигырь китаплары, «Ут һәм җыр» исемле роман-хроника авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

Балкып торган, үзенә тартып торган
Татарстан дигән «бу алмаз»—
Хәтәр елларда да югалмады,
Президентлы чакта югалмас,
Югалмас!

## Язгы тайгак

*Очты, очты, каргалар очты.*

Халык җырыннан.

Иртәләрен чытыр салкын була,
Ә көндезен кояш кыздыра.
Казан урамнары, ай-һай, хәтәр—
Аяк асты тоташ боз гына!

Кыз-җилкенчәк хәтта таеп китә,
Таеп-таеп китә инвалид.
Һәм сукрана: «Ниләр диеп кенә
Чыктым икән бүген юлга?»—дип.

Мәскәүдә дә эшләр хөрти бүген:
Бераүне дә тормый кызганып,—
Түрәләрнең шанлы урамына
Һөҗүм итә әнә бозлавык.

Хакимият коридорларында
Юллар тайгак, юллар бормалы:
Кемнең ничек итеп очканнарын
Безгә бары карап тормалы...

Очты, очты, министрлар очты—
Черномырдин очты берочтан.
Рәсәй мәңге чыга алмас, ахры,
«Скандаллар» белән бурычтан.

Тайгак өсләренә ком сибәләр—
Җәяүлеләр егылмас өчен.
Сәясәттә исә
Күзгә ком сибәләр
Ил эшенә тыгылмас өчен!

## Яңгырларың—яшел дастан

Туган якта әллә кар яктысы,
Әллә инде каен яктысы?
Урманнарда кар бөртеге саен
Чәчрәп яна кояш чаткысы.

«Сайрый» кырда чана табаннары,
Сәфәр чыккан, димәк, юлаучы.
...Көртлекләргә кулы күтәрелми—
Телсез калган яшь бер сунарчы.

Кар өстендә чыңлый салкын әрем,
Зеңләп тора җилдә куаклар.
Бабайларның җаны, рухы белән
Өретелгән, ахры, бу яклар.

Битләремә килеп тия төсле
Салкын карлар, бозлар аркылы,—
Көрт астында гына йоклап яткан
Яшел язның тере ялкыны.

Әй, туган як!
Җырымнан мин һәйкәл куяр идем
Йолдызларга, төнге аеңа...
Яңгырларың—яшел дастан синең,
Бураннарың—ап-ак поэма!

## Җир кызы бул!

*Кызым Айсылуга*

Караңгы төн буразнасын ерып,
Бар Җиһанга нурын өләшеп,
Галәм кочагында Ай тирбәлә—
Гашыйкларның якты сердәше.

Бәхет мизгелләрен күзли бугай:
Нинди халәт җанда, ни вакыт?
Шуңа да бит йә тулышкан була,
Китек чагы була кайвакыт.

Татар халык экиятләрендә
Зөһрә кызга урын тапканнар,—
Чиләк-көянтәсе белән Ай түренә
Элеп куйганнар да,
Сагышланып, аңа бакканнар.

Син дә Айга бик еш карыйсыңдыр,
Тоеп кичнең җылы рәхәтен.
Күкләр биек, күктә—билгесезлек...
Җирдән эзлә Яшәү бәхетен.

Романтика, яшьлек уты белән
Мөлдерәмә тулы йөрәгең.
Исемең Ай белән башланса да,
Җир кызы бул!—шулдыр теләгем.

## Инештә—каурый каләм

Тамчы-тамчы яңгыр яуган чакта
Су өстендә калка бөтеркә.
Әйтерсең лә шаян күбәләкләр
Шаярышып канат җилпетә.

Күпер бүрәнәсе өсләренә
Җигүле ат керә дөбердәп.
Кәгазь көймә сыман йөзеп йөри
Инеш өсләрендә каз-үрдәк.

Ә түрдәрәк—буа бусагасы,
Хәтәррәк монда бөтеркә.
Суларыңны, көннәр-айларыңны
Йотып кына тора кич-иртә.

Бездән өзеп, көннәр-яфракларны
Җилгә сибә вакыт агачы.
Казлардан да каурый тузгып кала—
Кирәк бары канат кагасы.

Инештәге суның бөтеркәсе
Нәрсә уйлый икән бу хакта:
Ап-ак казның ап-ак каурыйлары
Агып китте әнә улакта.

Каурый каләм, сүзен язалмыйча,
Мәңгелеккә китте микәнни?
Шуның эзләреннән барыр өчен
Мин күтәрәм бүген җилкәнне!

## Кар астында чишмә

Кар астында калды безнең чишмә,
Кар астында калды көзләребез.
Хыялларда гына бер-беренә
Орынышып тора тезләребез.

«Сөям сине...» диеп пышылдаулар
Булды микән әллә сүздә генә?

Шыбыр... шыбыр...
Каен очларыннан
Яфрак тамды чишмә күзләренә.

Ә чишмәгә нәрсә—тып-тын гына
Китеп барды инеш-диңгезләргә.
Син дә киттең...
Ерак офыклардан
Тиеш булдым сине мин эзләргә.

Кешни-кешни еллар каршысына
Актарылып чапты акбүз атым.
Күзләрдә дә, кышларда да һаман
Төсен югалтмады ак сурәтең.

Кар өстендә синең исем яна—
Үзем генә белгән серле тамга.
Кар астында калган чишмә кебек
Тып-тын гына челтерисең җанда...

## Сине эзләгәндә

Калдым ике утлар арасында,
Йөрәккәем тибә тып та тып:
Китәм икән—нәфрәтләнеп китәм,
Кайтыр булсам—кайтам яратып.

Мин шәһәрдә сукбай булып йөрим,
Светофорда сары ут яна.
Янәшәмнән әллә кемнәр уза—
Кайсы көләч, кайсы дивана.

Салкын рельсларны сискәндереп,
Үтеп китә төнге трамвай.
Кем өчендер, бәлки, мин үзем дә
Диванадай басып торам, вай...

Уты сүнгән тәрәзәләреңнән
Карап тора кебек күзләрең.
Үткәннәрдән мин ярлыкау сорыйм
Сары яфракларга тезләнеп.

Сукбай сыман тагын китеп барам,
Дөньясына җаным үртәлә.
Сине эзләп мин ялгышмыйм микән,
Ниләр көтә безне иртәгә?

Калдым ике утлар арасында,
Гүя «сугыш» бара күңелдә:
Китәм икән—мин мәңгегә китәм,
Кайтыр булсам—кайтам мәңгегә!

## Хакыйкать эзләгәндә

Нинди көчләр куәт бирә безгә—
Яшәп туеп булмый дөньялыкта!
Әй, син, тәкъдир, гозерләнеп сорыйм,
Калдырмачы соры урталыкта.

Бөтен курыкканым—пыскып яшәү,
Яшим икән, яшьнәр җаем булсын.
Юлга чыксам—кабарыма икмәк,
Учак ягар өчен утын булсын.

Хакыйкатьнең хакыйкатен эзлим:
Уч төбенә сыяр әнҗе микән?
Әллә инде, кешеләрдән качып,
Күкләр катламына мендә микән?

Туу белән үлем якалаша—
Ишетәмен оран тавышларын...
Зәңгәр чәчәк, кояш!..
Мин бит сезгә
Күпме җырларымны багышладым!

Түм-түгәрәк сезнең дөньягызны
Мәңгелеккә инде калдырыйммы,
Бөтен тәнем гүләп торган чакта
Соңгы күлмәгемне салдырыйммы?

Ни аяныч—йөрер туфрагыңны
Каплап китсә әгәр ачы әрем...
Куркытамы? Әйе, нык куркыта
Үтәлмичә калган вәгъдәләрем.

Егылса да кеше, торып басып,
Максатына таба барачактыр.
Бер кешесен генә югалтса да,
Ярты дөнья ятим калачактыр...

Төш һәм үлем патшалыкларын да
Ерып чыга торган татармын мин!
Җиргә иңсәм, кабрем өстендәге
Каен шавын тыңлап ятармын мин.

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр



## Нурзилә

### ХИКӘЯЛӘР

### Кош баласы

Язып утыра торган кәгазьләренең жилфердәп куюына сискәнеп, дежур хирург башын күтәрде—ишек ачылып киткән икән. Эш белән мавыгып, шакуны тагын ишетми калгандыр инде.

—Керегез!

Ишектә мамык шәлгә төренгән хатын-кыз күренде.

Табиб алдындагы журналын ябып куйды. Керүче—киләсе атнага операция билгеләнгән авыру иде.

—Узыгыз, утырыгыз,—диде табиб,—йә, ничек хәл иттегез соң?

Кыз, иң элек, зур зәңгәр күзләрен мөлдерәтеп, табибка карады, бераздан башын түбән иде. Дәшмәде. Табиб та көтте. Операция ясарга тиешле табиб янына авыру кеше соң сәгатьтә юкка гына килеп кермәс. Һәм мондый сәер диагнозлы авырулар—бигрәк тә.

—Берничек тә...—дип, тонык тавыш белән сүз башлады кызый,—берничек тә хәл итә алмадым...

—Юкны сөйләмәгез инде!—диде табиб, урындык артына таба ава төшеп. Моның ишеләрне генә күп күргәнлектән, юктан артык мәшәкать тудыра дип, аның кызыйга ачуы чыга башлаган иде.—Хатын-кызны белмәсәм иде мин, кырык була аларның...—дип кызмакчы иде дә, авыруның озын керфекләре очына эленгән яшь тамчысын күреп, тыелып калды.

Торып, өстәл тирәли әйләнеп килде, тамагын кыргалап, шкафтан авыру тарихын алды, баскан жирдән генә актара башлады. Менә бит, акка кара белән язылган: әгәр бу хәлендә, ягъни гыйффәтле килеш, авыруга операция ясасаң, аның гомерлеккә бала таба алмый торган булып калуы бар. Табиб, папканы кире урынына куеп, авыруга тагын күтәрелеп карады. Тал чыбыгы кебек нәзек кенә бу кыз бала кызганыч иде аңа.

—Шушындый кыен вакытларда ярдәм итәрлек бер генә якын кешең дә юкмыни соң?

---

НУРЗИЛӘ (Нурзилә Нотфуллина)—*яшь язучы, «Кашлы балдак» исемле китап авторы. Казанда яши.*

—Мине анларлыгы юк...—Кызның тавышы зәгыйфь кенә, ишетелер-ишетелмәс кенә чыкты.—Мина шушы килеш кенә операция ясагыз, зинһар...

—Юкны сөйләмә инде, сенлем! Артыннан йөрүчесе, ярдәм итүчесе юк дигәч тә син... Без, врачлар, меннән бер бөртек кенә өметне дә яшәтергә тырышабыз бит!

Табиб, моны юатырлык тагын нәрсә әйтим икән, дигән сыман авыруга карап алды. Кызыйда өмет дигән нәрсәнең тамчысы да сизелми, алай гына да түгел—бусы табиблар арасында яхшы фал саналмый—ул бөтенләй битараф иде кебек. Шушы сүзләрне әйткән минутта аның күзләре буп-буш иде. Кешене өмет яшәтә. Операциясенең катлаулылыгы өстенә, савыгырга бөтенләй ышаныч булмау хәлне кыенлаштыра гына бит, дип уйлап алды табиб.

—Әгәр мин булсам?—Хирург бу сорауны кычкырып әйтүен сизми дә калды, аның бу сәер пациентка бик тә ярдәм итәсе килә башлаган иде.—Әйе, әйе, син бу очракта минем вариантны ничегрәк итеп күзаллыйсың?

Мондый тәкъдимне көтмәгән кызның болай да зур күзләре теннис шары кадәр булган иде. Ул нәрсә дип тә җавап кайтарырга белмәде.

—Белмим...—дип, бераз сүз әйтерлек хәлгә килде ниһаять.

—Бар, сенлем, белгәч керерсең,—диде табиб, журналын кабат кулына алып. Аның тагын ачуы чыга башлады.—Әмма иртәгә иртәннән дә калма!

* * *

...Кабырга астына китереп төрттеләрмени—Илфар кинәт кенә сискәнеп уянды, шундук торып утырды, ялан аяклары салкын идәнгә тию белән йокысы да бердән ачылып китте. Түшәгенең ахыры әллә өнгә әйләнгән инде—теге кызый янында ята икән. Тик нигә соң аның инбашлары калтырый? Әллә елый ук инде...

Аны юатып маташырга вакыты юк, ирнең үтереп эчәсе килә иде. Бер башмагын аягы кармаланып тапты, икенчесе каядыр олаккан, ахрысы. Эзләп тормады, ялан аягын боздай идәнгә тидермәскә тырышып, сикергәли-сикергәли, кухняга чыкты.

Чәйнек авызыннан гына эчү кебек алама гадәтенә тугры калып, берәр стакан чамасы чөмергәч, чәйнеген газ плитәсенә шап итеп утыртты да урындыкка чүмәшеп, «уф!» дип куйды. Әмма шундук сикереп торып йокы бүлмәсенә тәпиләде—кызыйның ник балавыз сыгып ятуын беләсе килә иде аның.

Гадәттә, Илфарның бергә үткәргән төннән соң янындагы хатын-кызга карата бернинди хис-тойгысы калмый, шундук суына иде. Иртән елыймы ул, көләме—анысы ирне кызыксындырмый, калганы аның өчен чүп кенә. Бер үк хатын-кыз белән икенче тапкыр йоклаганы булмады аның. Бәлки, бу көнгә кадәр өйләнми йөрүе дә шул сәбәптәндер?

—Йә, ник бәбәгеңне юешлисең инде тагын?—диде ул мөмкин кадәр йомшак булырга тырышып, башмагының икенче сынарын диван астыннан алырга маташканда.

Җавап ишетелмәде. Илфар, янына утырып, кызның беләгеннән сыпырды, кулын тотып алып, иреннәренә тидерде. Тегесе ни кулын тартып алмады, ни иркәләүгә охшаш бу хәрәкәткә җавап бирмәде. Иргә бу ошамады, әлбәттә. Үпкәләгән булып дәшми-тынмый гына торып китәр дә иде—бердән, әле бик иртә, юньләп яктырып та бетмәгән, икенчедән, бүген—ял көне. Телефонын да кичтән үк өзеп атты, димәк, эшенә чакырып бимазаламаячаклар, дигән сүз. Әмма йокы да качкан. Ул кабат диванга сузылды да, горурлыгын бер читкә этәреп, җәймәгә чорналып беткән кызны кочагына алды.

—Гөлмәрьям! Йә инде, бер сүз булса да әйт?

Кыз башта күзләрен ачты, озын керфекләре гөлгә кунган күбәләк канатларыдай җилпенеп алдылар. Күзе артыннан авызы да ачылды:

—Сүзем юк...

—Ник юк?

Ирнең күңеленә кинәт кенә якын булып киткән бу бер көнлек хатынын сөйләштерәсе килә иде.

—Син борчылма, барысы да яхшы булачак. Мин гел шулай, операциягә кадәр өч көн алдан бер төш күрәм. Бүген дә миңа шул төш керде. Сөйлимме?

Кыз жавап итеп керфекләрен генә тибрәндереп алды.

—Имеш, кыя читендә үк нәзек кенә бер агач үсеп утыра икән. Аның үлән сабагы кебек сыгылмалы ботагына бер кошчык оя корган. Шул уймак кадәрле генә ояда яна канат чыгара башлаган бердәнбер кош баласы калган. Ул, оя читенә тәпиләре белән тотынып, упкынга тәгәрәп төшәргә тора икән. Мин исә, тезләремне, кулларымны каната-каната, кыяга үрмәлим, менеп житеп, теге нәни кош баласын кире оясына төртеп кертергә ашыгам, имеш. Менә гел шулай: әгәр кошчыкны оясына этеп кертә алсам—операция уңышлы уза, авыруым савыга. Әгәр, мин менеп житкәнче, кошчык кыядан төшеп китсә—иң начары, димәк, пациентым операция өстәлендә үлә дигән сүз. Бүген мин кыяга кошчык упкынга ычкынганчы менеп өлгердем. Бу—яхшы фал...

Илфар, шул урында туктап, жинел сулап куйды. Тик ул төшенең ахырын сөйләп бетермәгән иде...

Кызга ул башкача сүз катмады. Төшенең дәвамын уйлап ята торгач, кочагындагы хатынының иннәренә сибелгән чәчләренә битен куеп, кабат йокыга талды.

Ул уянып киткәндә тәрәзәдә кояш иде инде. Илфарның кочагында жәймәсен калдырып, кыз да юкка чыккан. Аш бүлмәсендә бик тәмле булырга тиешле ризыкның күнелле генә лебердәп кайнаганы ишетелә. «Әни килгән, ахры»,—дип уйлап алды ул, канәгатьләнеп.

Әнисе гел шулай, ял көнне иртүк килеп, малае торганчы берәр тәмле әйбер пешереп куярга ярата. Аннары инде, өстәл янына утырып, ялгызлыкның бер дә файдалы әйбер түгеллеген, күптән инде башлы-күзле булырга кирәклеген иплән кенә, ризыкка кушып, улына сеңдерә башлый. Шулай иткәч, ниһаять, башына барып житәр, дип уйлыйдыр инде бичара ана. Әмма ашалган ризыкның һич тә баш тарафына китмәгәнен белми микәнни?

Әнисе килеп уята башлаганчы дип, тиз генә торып, юыну бүлмәсенә шылды Илфар. Йомшак халатына төренеп, күңелле көй сызгыра-сызгыра кухняга килеп керсә, аптырап китте: анда әнкәсенең эзе дә юк. Аның чуар алъяпкычын бәйләп тәрәзә янында басып торучы—Гөлмәрьям иде.

—Әни кайда соң?—дип соравын сизми дә калды Илфар.

—Мин беркемне дә күрмәдем,—диде кыз тоник тавыш белән.

—Ә нинди тәмле әйбер пешердең?—Илфар, песи сыман сузылып, һаваны иснәп алды һәм, жавап көтеп мәшәкатьләнмәстән, нәкъ менә шулай тиеш кебек итеп, өстәл янына кунаклады.—Тизрәк бүлеп бир инде мина, үлеп ашыйсым килә!

Кыз никтер куырылып куйды, дәшми генә, өлеш тәлинкәләренә пешергән ризыгын матурлап салды. Бу—кызыл, сары, яшел төсләрен пешкәч тә югалтмаган, тутырылган татлы борыч иде.

Бер-икесен пешә-пешә чәйнәп йоткач, ирнең бәясе кыска булса да, катгый яңгырады:

—Шәп!

Көмеш кашык белән стакандагы чәен болгатканда, болай гына сорыйсы да итте:

—Ә син минем нәкъ менә шушы ризыкны яратканны каян белдең?

—Мин үзем яратканны пешердем,—диде кыз, пышылдап диярлек.

Аз сүзлелеге өстенә, ул, никтер, Илфарга күтәрелеп тә карарга кыенсына иде.

—Ә ничек пешерергә уйладың?

—Белмим...

Илфарның кызны сөйләштерергә тырышуы бернинди дә нәтижә бирмәде. Аның жаваплары «әйе», «юк», «белмим» кебек «тирән эчтәлекле» сүзләрдән генә тора иде.

Гөлмәрьямне өенә озатып куйгач, Илфар чәчәкләр күргәзмәсенә китеп барды. Аның чәчәкләр яратуын белгән хезмәттәшләре дә, пациентлары да берәр сәбәп белән дә, сәбәпсез дә хирургларына гөлләр китерәләр иде. Бүген дә ул бер бәйләм лаләләр сатып алгач, гадәтенчә өенә кайтып китмәде, яз һавасын сулап урамнар буйлап йөрде. Аннары кинәт борылып Гөлмәрьямнең фатирына китте. Ишек кыңгыравына чыккан олырак яшьтәге апага, Гөлмәрьямгә тапшырырга кушып, чәчәкләрен тоттыргач, баскычтан төшеп барганда, карале, кызның исемендә дә гөл сүзе бар бит, дип уйлап, бу ачышына бик канәгать калды.

* * *

...Операция уңышлы үтте. Икенче көнне Гөлмәрьям күзләрен ачуга, тәүге күзе төшкән әйберсе чәчәкләр булды. Сарылы-кызыллы таҗлары киртләч-киртләч булып торган мондый лаләләрне беренче тапкыр күрүе иде әле кызның, бу яз хәбәрчеләренә күзләре талганчы карап ятты ул.

—Сиңа бу чәчәкләрне докторың үзе китерде!—дип сөйләнә-сөйләнә ишектән шәфкать туташы килеп керде, «үзе» дигән сүзгә аерым басым ясап, җөмләсен пациент янына килеп баскач та бер кабатлап алды.

Бу сүзләргә авыруның әлләни исе китмәвен күргәч, аптырап, капельницасын рәтләгән булып, кызга тагын бер кат карап килде. Хастаханә тарихында беренче тапкыр булган мондый хәлгә гаҗәпләнмәгән кеше кем икән, диде бугай.

Илфар исә көн саен Гөлмәрьямгә чәчәкләр китерде. Тегесе рәхмәтен керфек сирпүе, күз карашлары аша житкерә иде. Торып йөри башлагач, табиб аның белән берничә тапкыр сөйләшеп аңлашырга тырышып карады, тик юкка—кыздан юньле-башлы бер җөмлә дә алып булмады. Илфарның горурлыгына тия иде бу хәл: аның артыннан чабып йөрүче хатын-кызлар күп, әлбәттә, ләкин базда үскән бәрәңге сабагы кебек нәзек һәм ап-ак чырайлы шушы кызый сиңа карата битарафлык күрсәтеп маташсын имеш?

Кызның хәле яхшырганнан-яхшыра барды. Хастаханәдән чыгасы иртәдә ул, табиб янына кергәч, соңгы көннәрдә үзендә тойган сәер үзгәреш хакында әйтмәкче булган иде дә, Илфарның карашын күтәрә алмыйча, күзләрен яшерде һәм, бары рәхмәт кенә әйтеп, ишеккә борылды.

Аның әйтелеп бетмәгән сүзләре калганлыгын сизенсә дә, барлык ирләргә хас булган ваемсызлыгы сәбәпле, Илфар аны тиз онытты. Тормышы бер эздән-тәгәрәде дә тәгәрәде. Яше барган саен, нәрсәнедер үзгәртү хәленнән килми иде инде аның.

* * *

Төн уртасында өзгәләнеп чылтыраган телефон тавышына, гадәттәгечә, йокылы-уяулы җавап ишетелде:

—Килиммени?

—Һәм тизрәк, доктор!—диде дежур табиб.—Ашыгыч операция кирәк! Машина хәзер килеп җитәр.

Кичәге мәҗлеснең шаукымы башыннан китмәгән иде әле. Суыткычтан бер кисәк боз алып килде дә, тәрәзәдән карап машина көткәндә, аны әле чигәләренә, әле күз төпләренә тидергәләп, шактый гына рәткә кереп өлгерде.

Баласы операция белән алынырга тиешле хатынның Гөлмәрьям икәнен таныгач, ир шундук айныды. Табибның кулы автомат рәвештә үз эшен башкарса, башы, тырышып-тырышып, беренче операциянең кайчанрак булганын хәтерләргә маташа иде. Җиде ай! Сигезенчесе яңа башланган! Кан басымы артык югары булу сәбәпле, башкача юл юк, дигән иде бит дежур врач ашыгыч операциягә әзерләнгәндә. Димәк, менә шушы минутта кулларына алган бу кашык кадәр генә нарасый—аның үз улы?! Табиб, җавап көтеп, Гөлмәрьямгә карады. Әмма ананың хәле чиктән тыш авыр иде. Нәзек кенә тавыш белән еларга маташкан баланы янындагы шәфкать туташына биреп, хирург, өлгер хәрәкәтләр белән киселгән урынны текте дә калган эшне ярдәмче табибларга калдырып, малаен карарга китте. Бокстагы төрле яшәтү аппаратларына тоташтырылган сабыйдан үз чалымнарын эзләп маташты.

—Нишләп суламый соң бу?—дип, шундагы сестраларны аптыратты.

Тегеләре: «сулый ул, сулый, болай булгач, яши инде, моннан кечкенәләрне дә терелтәбез әле»,—дигәч, тынычланган кебек булып, кабат Гөлмәрьям янына керде.

Ул арада анага кан салырга кирәклеге беленде. Илфар, тагын берәр ярдәмем тимәсме дип, бераз көтеп торган иде дә, инде хәлләр җайланып килә, дигәч, озатучы машинаны да көтмәстән, өенә тапиләде.

Коридордан «һавага тотынып» акрын гына атлаган хатынның йөзендә утырып калган күзләреннән генә элеккеге Гөлмәрьямне таныды Илфар. Ике кулы белән аның иңнәреннән тотып, бары бер генә сорау бирде ул:

—Бала минекеме?—диде.

Хатын, раслап, баш каккач, аны сак кына кочагына алды һәм, иреннәрен колагына ук терәп:

—Ник аны монарчы әйтмәдең?—дип пышылдады.

—Белмим...—диде Гөлмәрьям, аннан да шыпыртрак тавыш белән.

...Хастаханә бүген иртәдән үк гөр итеп торды.

—Кара син аны, мыштымны, өйләнгәнен дә, баласы туганын да шушы көнгә кадәр әйтми йөргән бит!—дип аптырашты хезмәттәшләре, йөгерә-йөгерә хирургларына чәчәк ташыганда.

Илфарның исә, шәфкать туташы кулыннан тере төенчекне үрелеп алуга, никтер, келт итеп, сигез ай элек күргән төше исенә төште. Анын үзенә сәер тоелган ахырын шактый гына уйлап та йөргән иде әле.

Теге вакытта төшендә ул, кош баласын оясына утыртырга үрелгәч, кире уйлап, нәни канатларын җәеп учына сыенган җан иясен, төшеп китмәсен өчен икенче кулы белән каплап, үзе белән алган иде бит...

## Сөембикә кыйссасы

Бәхетен бер йомарлансамы?! Язмышына, керпе сыман, энәләре белән төртә дә тора икән ул... Мөселман балалар бакчасы тәрбиячесе Сөембикә туташның бәхет гөлен кайчан кырау сукты соң әле? Әти-әнисе юл һәлакәтенә очрап, дәү әнисе кулында калган каһәрле төндәме? Әллә давыл чыгып, дәү әнисенен сәҗдәгә киткән тавык кетәклеге кадәр генә өе ишелгәчме?

Бер бәхетсез—гел бәхетсез,
Тагы да калдым ятларга...

дип көйли торган иде мәрхүмә дәү әнисе.

Кызнын исенә еш төшә бу җыр.

Менә бүген дә, озын күлмәк итәкләренә урала-чалына өенә чапкан Сөембикәнен күзендә яшь булса, телендә шул җыр сүзләре иде. Янгыр коеп яуганда тәрәзәдән аккан гөрләвек сыман, күз яшьләре кызнын битләреннән бертуктаусыз тәгәриләр һәм мөселманча бәйләгән яулыгынын ияк астында гына тукталыш ясыйлар...

* * *

...Дәү әнисен җимерекләр арасыннан көч-хәлгә җыештырып җирләгәч, коточкыч кайгыдан агарып каткан Сөембикәне бу хәсрәтле дөньяда берәр атна чамасы дарулар белән генә тоттылар. Аннары, бераз рәткә кергәч, ул теләсә-теләмәсә дә, үз шәһәренә китеп барды. Кайчандыр ул туган баракны инде шактыйдан җир белән тигезләп, кешеләрен фатирларга таратканнар. Бирелә җан асраган һәр гаиләгә фатир тиеш булса да, Сөембикә ише ятим-үксезләр күптән җан исәбеннән сызып ташланган. Тоткасы-терәге булмаган кыз бу буталчык хәлләрнен очына чыга алмады, әлбәттә. Җепнен очы адәм түгел, шайтан да таба алмаслык итеп чуалтылган иде...

Шәһәрдәге балалар бакчасында эшләү өчен диплом кирәк булып чыкты. Сөембикә укырга керә алды тагын, институтнын тулай торагына да урнаштырдылар үзен, әмма стипендия кебеге ашарга да җитми иде.

Йомшак күнелле әбекәе белән үсүнен файдасыдыр инде, ана телен камил белүе өстенә, изге карчыкнын кич яткач йоклап киткәнче ятлата торган догалары да кызыйнын җанына онытылмаслык булып кереп урнашкан. Шуларнын барысы ярдәмендә мөселман балалар бакчасына нянечка булып урнашу кыенлык тудырмады. Әмма хезмәт хакы аз, стипендия белән кушканда ашарга җитсә дә, өс-башны рәтләү хакында уйларга да бирми иде.

Укуны тәмамлауга, кыз институт тулай торагыннан артты һәм ана шундук яшәр урын кирәк булды. Анысын бакча мөдире чагыштырмача җинел хәл итте: ерак та түгел нинди дер бөлгән заводнын тулай торагы бар иде, шуннан «каравать» табып бирде.

Бүлмәдәшләренен берсе—укытучы иде, икенчесе исә кайда эшләвен әйтеп мәшәкатьләнмәде, кичтән китә дә иртән кайта. Сөембикәнен аны рәтләп күргәне дә юк. Укытучы кыз ике ставкага эшли, кич кайта да дәфтәр тикшереп, план

язып төннәр буе утыра. Үзе дә ике смена «сөреп» кайткан Сөембикәнең (ул хәзер тәрбияче дә, нянечка да), еш кына сөйләшергә дә кешесе булмый иде.

Шулай «күнелле» генә яшәп ятканда, әлеге серле хезмәт башкаручы кызның фатирга китүе мәгълүм булды.

—Сөембикә!—дип, беренче тапкыр ачылып дәште ул бүлмәдәшенә.—Кайчанга кадәр кеше балаларының артын сөртеп, чүлмәк түгеп яшәргә җыенасың син? Эшләгәнең шушы тимере кәкрәйгән караватына түләргә дә җитми бит!

—Нишләргә кинәш бирәсең инде?—дип сорауга сорау белән җавап кайтарды кыз. Дөресен генә әйткәндә, ул бер кысага кереп кенә барган тормышын үзгәртергә курка иде.

—Әйдә, минем белән. Синең фигураң да ярыйсы гына, укыганда биюгә дә йөрдем дип сөйләгән идең бервакыт. Гомерең үтә бит бала-чага көе көйләп... Беркая барганың, бернәрсә күргәнең юк. Ашаганың да—шул бакчадагы сыек манный боткасы. Анысы, мин үзем дә шундый тормыштан чак-чак котылып киләм әле... Шулай да, нәкъ менә сиңа ярдәм кулы сузарга булдым, чөнки син ул кадәр үк өметсез түгел. Мин моны теге укытучы булып туганга әйтеп тә мәшәкатьләнмим, барыбер колагына кермәячәк, чөнки ул Ленин сызган туры юлдан мәктәбенә бара да кайта, бара да кайта. Шулай бирედә үлеп тә китәр...

Сөембикәнең бу озын кереш сүзне тыңлап бетерергә түземлеге җитмәде, бүлмәдәшен бүлдереп, үз соравын кыстырды:

—Нәрсә тәкъдим итәсең соң?

—Мин эшли торган төнге клубка биючеләр кирәк!—дип ярып салды кызый, туры сорауга туры җавап, дигәндәй.—Хуҗа инде шактыйдан бирле сайлана, килгән бер озын ботлыны бора да чыгара. Рухы туры килми, ди. Ул нинди рухтыр инде, башка нәрсәсе булса, бер хәл иде... Йә, барасыңмы?

Сөембикә дәшмәде. Моның ишеләрне ишеткәне бар иде аның. Биш вакыт намаз укыса да (мөселман бакчасында шунсыз булмый!), замана кызы бит ул.

—Әгәр сине анда эшкә алсалар, акчаң да чагыштырмаслык дәрәҗәдә күп булачак,—дип дәвам итте бүлмәдәше, Сөембикәнең дәшми торуын кыюсызлыкка чутлап,—өс-башыңны да карарсың, юньлерәк ризык ашарсың, өстәвенә, бу тараканлы общагтан котылырсың... Әле син монда тора гына башладың, белмисеңдер, кышын күренми башлый ул мыеклы җанварлар, батареялар җылытмый, таракан катырырлык суык була. Чакрымга сузылган коридорның теге башындагы юынгычта да, берданбер бәдрәфтә дә су бозлана, ишектән үтеп булмый.

Сөембикәнең бер дә көләсе килми иде. Үз-үзеннән көлсенмени ул! Әмма нишләргә соң?!

Кинәт кенә аның күңелендә ике «мин» әйткәләшә башлады. «Мондый форсат тагын кайчан чыга, әллә барыйм микән?»—дип икеләнде «мин»нең әле генә туганы.

«Дәү әниемнең рухы рәнҗер, өйрәткән догалары башыма каргыш булып явар»,—дип каршы төште үз «мин»е.

«Төнге биючеләрнең барысы да фахишә түгелдер минем дә кешечә яшисем килә бит...»—дип челтерәде яңа «мин», көчәйгәннән-көчәя барган тавыш белән.

«Дәү әниемнең рухы рәнҗер...»—дип пышылдады иске «мин», җиңелә баруын тоеп.

«Икенче сменада гына калып булса да тәрбияче булып эшләрмен,—дип тынычландырды аны яңа «мин».—Намазларымны да калдырмаска тырышырмын, аннар әле мине дәү әнием...»

Сөембикә, авыр сулап, бүлмәдәшенең күзләренә карады. Ул да, ятимә кызның күңелендә барган тарткалашны аңлаган сыман, тынып калган иде.

—Мин риза...—диде Сөембикә, кинәт кенә карлыгып калган тавыш белән.

Шуннан китте инде тормыш тәгәрмәче капма-каршы якка тәгәрәп!

Кызны ин шаккатырганы баш түбәсенә чүкеч белән суккандай тәэсир калдыручы шашкын музыка булды. Беренче кичтә үк шул музыка сихеренә тышауланып, Сөембикә хуҗа алдына килеп басканын сизми дә калды. Тегесе, симез күзләрен тагын да кыса төшеп, бераз кызга карап торды да:

—Алам!—дип кинәт бармак шартлатты.—Читлек эчендә биерсең... Курыкма, бездә сиңа бармак белән дә орынучы булмас.

Кызга тәҗрибә белән бергә осталык та килде. Сөембикәне карарга дип клубка махсус йөрүчеләр ишәйде. Бии-бии, чишенә-чишенә, биленәчә калын

толымлы бодай саламыдай чәчләрен дә таратып салганлыктан, читлек эчендәге кызның шәрәлеге күзне вәсвәсәләндерүче утлар яктырып киткәндә генә чагылып ала. Әмма тән төсендәге ике нәзек баудан гына тегелгән эчке киемен барыбер салмый Сөембикә. Һәм, читлектән чыгып, залдагы ир-атларның тезенә дә утыра алмый. Читлектәге кызлар залга төшеп, ирләр алдында бии башлауга, сүнеп-янып торган утларның карангылана төшүен чамалап кына тора да, чыга да сыза читлектән. Күрми дә калалар Сөембикәнең хәйләсен.

Ләкин күрмиләрме соң! Иң элек, хужа кисәтү ясады. Янәсе, залга төшсәң ни булган, бай абзыйларның трусигына меңәр тәңкә кыстырырга атлыгып торганнары да бар, имеш. Сөембикә аны-моны дәшми генә аска карап торды.

Тора-бара Сөембикә иске бер тиен сыман шомарды. Хәзер инде аның «торып торырга» дип бер елга алдан түләп куйган унайлы фатиры, анда кирәкле бөтен әйбере бар. Бакча тәрбиячесе хезмәтен генә ташлый алганы юк. Стриптизерша булып гомер буе эшли алмасын чамаламый түгел кыз. Әмма төнге тормышы хакында бакчада сизенсәләр, тәрбияче һөнәре тирәсеннән үзен пумала белән куачакларын да белә. Эшләгән кешегә эш бетмәс, анысы. Әлеге мөселман балалар бакчасында Сөембикәне сабыйлар мәхәббәте тота. Гөнаһсыз нарасыйларның «Тәти апам!» дип килеп сыенулары, догалар өйрәткәндә, ипләп кенә намазниязга төшендергәндә самими ихласлык белән тыңлаулары, аның артыннан тигезле-тигезсез нәзек тавыш белән кабатлаулары төне буе колак тондыргыч музыка дәһшәтеннән башы әйләнгән, чарасызлыктан ике тормыш белән яшәргә мәҗбүр ятимә кызның йөрәгенә шифа, жанына ял бирә.

...Биюче кызларның кием алыштыру бүлмәсенә шакымый-нитми генә хужа килеп кергәч, Сөембикә, нидер тоенгандай, сискәнеп куйды. Дөрес сизенгән булган икән: хужа, дорфарак кына итеп, Сөембикәгә бүген башка кызлар белән залга биергә төшәргә һәм эштән соң тиз генә кайтып китмәскә кушты. Синең белән якыннанрак танышырга теләүче бар, диде. Клиентлар арасында андый теләк белдерүчеләрнең монарчы да булуын, әмма бу хәлнең клуб эчендә рөхсәт ителмәвен белгән Сөембикә куркып калырга тиеш булса да, берни булмаган сыман, битараф кына буйсынды. Ул инде башкалар кебек зомбига әверелеп бара иде... Залга Сөембикәнең төшүе күпләрне таң калдырды. Капшап карарга үрелүчеләр дә байтак күренде. Әмма кыз әрсез куллардан шома балык сыман житез генә шуып чыга барды.

Аның белән якыннанрак танышырга теләүче утыз биш яшьләр чамасындагы адәм иде. Ул свитер белән чалбар киеп куйган кызның күкрәгенә япкан калын толымнарына томырылып карап алды. Үзен Саша дип кенә таныштырды да кыздан сорау алырга керешге: кем ул, кайдан килгән, әти-әниләре нинди кешеләр, кайда һәм кемнәр белән тора һәм башкалар. Бүтән кешеләрдән әллә ни аерылып тормаган бу ир-егетне Сөембикә башта журналист-фәләндер дип уйлаган иде. Юк икән. Ишек төбендә үзләренә әзмәвердәй ике адәм ияргәч һәм хужага кызны үзе озатып куясын әйткәч кенә, Сөембикә аның ни житте генә кеше булмавын аңлады.

Кыз яши торган йорт янына килеп туктауга, Сөембикә белән Саша артыннан машинадан теге әзмәверләрнең берсе төште һәм алардан ике-өч адымга гына калышып бара башлады. Кыз арыган иде, ирне өенә чакырырга кирәк тапмады, тиз генә саубуллашып, керү ягын карады. Башка вакытларда башы мендәргә тиюгә йоклап китә торган кызның күзләре бүген шырпы белән терәтеп куйган кебек ачык. Ул ачы язмышының тагын бер борылышы алдында торуын сизә һәм аны берничек тә үзгәртә алмаячагын да тоя иде...

Көннәр үтте. Сашаның төнге клуб «түбә»ләреннән берсе икәнен дә белде. Кыз хәзер үзенең ныклы күзәтү астында икәнен, ана беркемнән дә куркыныч янамаслыгын белеп бии. Әмма Саша белән алар төнге клубта гына очрашалар, ул Сөембикәнең көндезге тормышы хакында хәбәрсез иде. Кыз үзенең мөселман балалар бакчасы тәрбиячесе булуын яшерде, әйтмәде. Мөнәсәбәтләре артык тирәнгә китмәгәнлектән, Сөембикә Сашаны үзенең төнге тормышы кешесе дип кенә исәпли иде. Әмма соңгы вакытта кызның уйларына әлеге серле ир-егет көндезләрен дә керә башлады. Ләкин Саша кызның тормышына ничек кинәт килеп кергән булса, шулай ук тиз юкка да чыкты.

Ул аны оныта да башлаган иде инде. Көннәр барысы бер төрле агалар да агалар. Бакча—төнге клуб—йокы... Бакча—төнге клуб—йокы... Әмма көннәрдән

бер көнне шул чылбыр өзелде—бер сабыйны алырга килмәделәр. Мөселман бакчасында мондый хәлнең булганы юк иде әле. Кыз сабыйның өенә шылтыратты, ләкин телефон дәшмәде. Инде бакчада каравылчы гына калды, Сөембикәнең исә баланы аңа калдырып китәргә хакы юк. Дәүләт исемле биш яшьләр чамасындагы бу малай бакчага күптән түгел генә йөри башлады әле. Әнисен бала тәрбияләү хокукыннан мәхрүм иткәннәр. Аны әтисенең туганнары гына карый икән. Димадан Дәүләткә әйләнүен дә, әнисе юкка чыкканнан соң, әтисенең дә юньле-башлы күренмәвен бик авыр кичерә иде бала. Сабыйның язмышын үзенекедәй санап, кыз аны аеруча якын күрә, балага назны күбрәк бирергә, җае чыкканда кочагына кысарга, башыннан сыйпарга тырыша иде.

Малай белән бергәләп чәй эчеп алгач, Сөембикә аңа тагын әкиятләр укыды, әлифбадан таныш хәрефләрне дә эзләп утырдылар. Караңгы төште. Тәти апасы аны йокларга салырга гына җыенганда, телефон шылтырады. Каравылчы агай баланы алырга килүләрен әйтте.

Кыз, баланы җитәкләп, абына-сөртенә барып, ишекне ачып җибәрде. Ишектә Саша тора иде. Ул йөгереп килгән улын кочагына алды. Тегесе дә бертуктаусыз «әти, әтием!» дип кабатлый иде.

Тәрбиячегә рәхмәт әйтергә теләп, ир аңа күтәрелеп карады һәм... улын чак кына кулыннан төшереп җибәрмәде.

—Сөембикә...

—Саша...—дип пышылдады кыз.

—Юк, мин Сәгыйть исемле...—дип, татарча пышылдады ир.

Кыз исә шатланырга да, борчылырга да белмичә бераз торгач, кинәт кенә йөгереп чыгып китте. Малайның «Тәти апам!» дип, Саша-Сәгыйтьнең «Сөембикә!» дип кычкыруларына да борылып карамады. Ул менә шушы минуттагы югалтутабышларын да аңламаслык булып йөгерде дә йөгерде. Яңгыр коеп яуганда тәрәзәдән аккан гөрләвек сыман, күз яшьләре кызның битләреннән бертуктаусыз тәгәриләр һәм мөселманча бәйләгән яулыгының ияк астында гына тукталыш ясыйлар иде...

## Миңа ул кирәк...

Үзәкләрне өзеп искән кышкы ачы җилдән юка пәлтә белән бер кат яулык кына ышыклап бетерә алмый шул. Күзләргә бәреп яуган ярмадай каты кардан бераз гына булса да саклар дип, пәлтә якасын ялан кулы белән күтәргән, икенчесе белән күкрәгенә кадерле төенчекне кысып, җилгә аркан борылган Хатын олы юл кырыеннан ук атлавын сизми дә калган икән. Янына ук «чажт!» итеп килеп туктаган машинага таба әйләнеп карарга өлгергәнче, ишеге кайчан ачылган булгандыр, нииндидер көч аны эчкә суырып алды. Хатын кычкырырга да өлгерә алмады хәтта. Көчле куллар башыннан яулыгын сыпырып төшерде. Бер мизгел эчендә нәрсә булганын төшенгән Хатын шуннан файдаланды да: тиз генә песи баласы сыман бөтерелеп, Ирнең күкрәгенә сыенды, ябык куллары белән аның муеныннан кочты. Бусын ук көтмәгән Ир бермәл аптырап калды, ул арада Хатын, иреннәрен аның колагына ук терәп:

—Бор машинанны, киттек мина, мин барысына да риза...—дип пышылдады.

Ир, зур коңгырт күзләрне артык якыннан күрү аркасында бераз йомшадымы, әллә алардан агылган сихри караш тәэсиренә бирелеп киттеме, сүзсез генә ризалашты, алдагы көзге аша шоферга ишарә ясап, борылырга кушты. Монарчы мондый кыю тәкъдимне башлап ишеткәне булмагач, аңа кызык иде.

Керфеген дә селкетмичә тыныч кына утырып барган Хатын исә күпне күргән булырга ошый иде... Ул, шактый җир киткәч, туктарга кушты. Җиргә сенеп ук беткән баракны күреп, Ир тагын гаҗәпләнде. Шоферга көтеп тормаска әйтеп кул изәгәч, йөгереп диярлек атлаган Хатынга иярде. Берданбер күгәнендә Ходай ярдәме илә генә асылынып торган барак ишегенә аптырабрак карап килә иде шул. Хатын кай ара кереп тә югалды. Ир исә, ишек төбенә җәелгән сары бозлавык өстен кырпак кар каплаганлыктан, күрмичә, таеп китте һәм тәбәнәк ишекне исәпләп бетермичә борыска башын бәрде. Унҗиде катлы сүгенү астында кыйммәтле бүреге шактый еракка тәгәрәгән иде, аны куып җитеп, култык астына кыстырды да, икегә бөкләнеп, ишектән кереп китте. Хатын качмаган, төенчеген күкрәгенә кысып, читтәрәк көтә икән. Башкалада торакның мондые әле дә булса

калгандыр дип уена да кертмәгән Иргә, ленолеумы ашалып-ямалып беткән идәндә сөртенгәләп, кызу-кызу атлап киткән Хатынга иярүдән башка чара калмады.

Томалап пешерелгән кәбестә, кыздырылган бәрәнге, ачыган аш исләре бергә кушылып бөркелгән кухня янәшәсендәге бүлмә янына туктадылар. Хатын кесәсеннән ачкычын чыгарды. Янында таптанган Иргә күтәрелеп тә карамыйча, җәһәт кенә бүлмәгә үтте һәм, кулындагы төенчеген өстәлгә ташлап, стена буендагы бала караватына иелде. Сабыенның тынычлап йоклап ятуына чын-чынлап ышангач, бушлыкка мөрәҗәгать иткән сыман, салкын гына:

—Өс-башынны сал, җылы бездә,—дип дәште.

Ир исә, бүлмәнең кечкенәлегенә һәм фәкыйрьлегенә шаккатып, бүреге белән тунын куярга да урын тапмыйча, аларны күтәргән килеш ишеккә сөялгән иде. Элгеч эзләп бераз карангач, ишек яңагындагы кугәргән кәкре кадакка тунын эләктерде, бүреген шундагы киштә кебегрәк нәрсәгә ташлап, тәпиләре чалшаеп беткән өчаякка сакланып кына артын төртте.

Хатын, төенчеген чишеп, аннан шешә белән сөт, кефир, эремчек кебек ризыклар алды да, тәрәзәнең бер катын ачып, шуларны тәрәзә арасына урнаштыра-урнаштыра:

—Сине бирегә чакыруым—шушы балам хакына,—дип сүз башлады.—Әгәр шул вакытта югалып калсам, ни булганын шәйләп өлгерә алмасам, үзем генә түгел, балам да харап булачак иде...

Ул пәлтәсе белән яулыгын салып урындык артына элде, югарып, агарып беткән итеген батарея өстенә куйганнан соң, шешә белән сөтне дә тәрәзә арасыннан алып, ак чүпрәккә төреп шунда ук урнаштыргач, аның сүзләрен бөтенләй дә ишетмичә, әлегә бары ябыклыгына гына хәйран калып күзләре түгәрәкләнгән Иргә сынап карап алды.

Тегесенә бүген гел аптырап телсез калу язган икән: үтәли күренерлек арык бу ханым—кайчандыр шәһәрне дер селкетеп торган, ярты ел чамасы элек разборка вакытында үтерелгән бер «крутой»ның чибәрлеге белән дан тоткан хатыны икән бит! Сөйләгәннәр иде аны, иренең «әҗәт»ләре исәбенә кертелгән дә, шуна риза булмаганга, малае белән үзен дә ире артыннан теге дөньяга озатканнар икән, дип. Димәк, бу хәбәр дөрес булмаган?

—Нәрсә сүзсез калдын? Күзең белән күргәненә акылын ирешеп бетмиме әллә?—диде Хатын, Ирнең тануын тоеп һәм ирен чите белән көлемсерәп куйды.

—Син исәнмени соң? Ирең артыннан юл тоткансың дип ишетелгән иде бит?—Иргә тәкәллеф саклап тору дигән нечкәлекләр хас түгел иде, шунлыктан ул турыдан «бәрде».

—Хәзерге жан асравыбызны яшәү дип атарга яраса...

—Шулай да, бирегә ничек килеп эләктең соң?—Ир иркенләп тынларга әзерләнде.

—Ничек, ничек? Бик җайлы гына итеп.—Хатынның сүз озайтып торыр исәбе күренми иде. Шулай да, әлеге барак белән бер яшьтә күренгән калай чәйнекне эләктереп чыгып барышлый, тагын бер җөмлә әйтүне кирәк тапты:—Адәм баласы михнәткә чыдый икән ул...

Үзе генә калгач, Ир, иң элек, бала караваты янына килде. Түм-түгәрәк малай нәкъ әткәсенең күчермәсе икән. «Үзе ач булса да, баласын сакларга тырыша ахры, бичаракай»,—дип уйлап алды ул. Ирдә Хатынны машинага сөйрәгәндәге дәрт әллә кая юкка чыккан иде. «Ничек яши икән соң болар?»—дип сөйләнде үз-үзенә, бүлмәне җентекләп күздән кичергәч. Таяк болгасаң да берни эләкмәслек дәрәҗәдә шып-шыр булса да, таракның кечкенәлеге кычкырып тора. Димәк, бирегә элеккеге мул тормыштан бернәрсә дә ияреп килмәгән. Шкаф, суыткыч ише көн дә кирәкле әйберләр юк, булсалар да сыймаслар иде бирегә. Бар булган җиһаз: агач диван кебек нәрсә, бала караваты, ике кечкенә тумбочка һәм бер өстәл белән берсе—терәгечле, икенчесе артсыз ике урындык. Әле тәрәзә төбендә бер гөл дә үсеп утыра. Суыткыч хезмәтен башкарган тәрәзә арасында—балалар сөт кухнясының ризыклары гына, башкача ашамлык заты күренми. «Иң мөһиме—җылы монда,—дип уйлап куйды Ир никтер, үз-үзен юаткандай.—Һәм чиста да...»

Ишектә Хатын күренде, сүзсез генә өстәл тартмасын ачып, борыны китек кечкенә чәйнек алды, халат кесәсеннән гәҗиткә төрелгән, берәр кашык чамасы гына калган чәйне алып сүткәч, шунда салды. Шул ук тартмадан кара ипи чирегe тартып чыгарып, аны кисеп куйды. Үзе тагын кухняга чыгып китте. Таңга калган

Иргә берни дә җәелмәгән өстәл өстендә бер пар чәшкә, стаканга бастырып куелган бер—зур, ике кечкенә әлүмин кашык, тешләре бөгелгән чәнечке сыман нәрсә, сапсыз пычак кебек «сервиз»лардан башка әйбер чалынмады. Анын, аптырап, теге өчаякка артын төртүе булды, бала караватында кыштырдаган тавыш ишетелде. Әйләнеп караса—малай торып баскан һәм, әнисенеке сыман зур коңгырт күзләрен мөлдерәтеп, ана карап тора икән. Ул арада тиз генә Хатын килеп керде һәм баласы белән гөрли-гөрли сөйләшә дә башлады. «Карасана, моның тавышы бик матур икән бит»,—дип уйлап алды Ир, ананың баласын ашатырга җыенуын күзәтә-күзәтә. Хатын батареяга җылытырга куелган шешәне алып, җәһәт кенә чүпрәгеннән чиште дә, имезлек кидереп, сабырсызланып биеп торган баласын караватына утырткач, шешәне аның кулына тоттырды. Бала ашый башлауга, тагын чыгып китте. Ул арада чәйнекне алып кереп, чәй пешерде һәм, уңайсызланудан читкә карап кына, Ирне өстәл янына дәште.

Кырып юылган өстәл өсте чын мәгънәсендә чип-чиста: чәшкә астына тезелгән өч телем кара ипидән һәм куе чәй салынган чокырлардан башка, кычкырып еласаң да берни табып булмаслык иде.

Ир, Аллага тапшырып, чокырны үрелеп алды, кайнар чәйне бер уртлагач, тамагын кырып, тагын сорау алырга керešте:

—Бу «улучшенкаң» күпме тора инде?

—Биредән куып чыгармасыннар өчен, мин шушы баракны җыештырам...

—Шушы олы марҗаның арты хәтле бүлмә өченме?—Аптыраудан, Ирнең күзе авызы зурлык ачылган иде.

—Әйе, ник гаҗәпләнәсең аңа. Әле монда да «танышлык буенча гына» эләктем. Шушыннан артык миңа беркем дә, берничек тә ярдәм итә алмый. Бу—шулай куелган... Бала өчен бирелгән тиеннәрне ничек тә җиткерергә кирәк бит. Киемнәремнең барысы да диярлек «әҗәт» исәбенә керде, калган иске-москыларның да рәтләрәген сатарга туры килде... Мин үзем ничек тә түзәм әле, ә менә баламны аякка бастырырга тырышачакмын. Улымны яслегә бирә алсам, анда да җыештыручы булып урнашам, Алла теләсә. Югары белемем булса да, яшь балам белән мине кайда да эшкә алмыйлар бит... Әмма барыбер теге җанкыярларның астына кермәячәкмен, алар исә минем елап килгәнемне көтәләр. Юк, ачка үлсәм үләм, әмма баш иеп алар катына барудан Ходай саклар мине. Бүгенге игътибарсызлыгымның да сәбәбе бар—минем бүген туган көнем. Аны узган елгысы белән чагыштырып бара торгач, онытылып киткәнмен...

Хатын, ачылып сөйләвен үзе үк килештермәгән шикелле, чәен чайпалдырып чокырын этеп куйды да, торып, тәрәзә янына китте. Аннан кинәт борылып Иргә карады—Хатынның күзләреннән зәһәр очкыннар чәчелә сыман иде.

—Нәрсә утырасың, кирәгеңне ал да ычкын, минем идән юарга чыгасым бар,—диде ул, кинәт кычкырып.

Баланың әнисенен мондый халәтен күргәне юк идеме, тавыштан курыктымы, кычкырып елап җибәрде. Хатын аны кулына алды, көйләп-көйләп юата башлады.

Ир, авыр сулап урыныннан торды да, туны белән бүреген кия-кия чыгып китте. Артыннан ук «шелт» итеп ишек келәсе элενгәне ишетелде. Урамга чыккач, беравык кай якка атларга белми торды, аннары, тукталышны чамалабрак, шул якка таба тәпиләде. «Да,—дип кычкырып уйлады ул,—дөньяда мондый хатыннар да бар икән бит әле. Ә миңа кем кирәк соң? Күпме болай яшәргә мөмкин?»

Тукталыштагы кибеттән сумкасы сыйдыра алган кадәр ризык төяп чыккач, кабат барак ягына юл тотты. «Мине кертмәс инде ул,—дип уйлады Ир, ашыгып атлый-атлый,—ул чакта боларны ишек төбендә калдырып китәрмен. Көн саен килеп йөри торгач, бер көнне эрер әле... Миңа ул кирәк... Бәлки, аңарга да мин кирәктер, әлегә үзе генә төшенеп бетмидер...»



## Фирая Зыятдинова

### ТЫНМА, ҖАНЫМ!

**Җирне сагынып...**

**Күккә мендем,**
**Йолдызларга җиттем—**
**Йолдыз буранына уралдым.**

**Җирне сагынып,**
**Кире Җиргә төштем—**
**Уйлар урманында югалдым...**

**Ни булган бу Табигатькә,**
**Ни булган бу дөньяга?—**
**Йә кар катыш яңгыр ява,**
**Йә яңгырлы кар ява...**

**Ни булган бу Табигатькә,**
**Ни булган бу дөньяга?—**
**Батмаска чыкканмы кояш—**
**Елмая да елмая!..**

---

Фирая ЗЫЯТДИНОВА—*шагыйрә, «Матур буласым килә», «Язгы ярсу», «Мин Кояшка елмаям» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Яшьлек

Бер кыз килә көлә-көлә
Чәчәкләр арасыннан.
Күзләреннән чишмә булып
Җылы нур ага сыман.

Болын буйлап бер кыз килә.
Унсигездә ул. Көлә...
Мин дә елмаймакчы булам.
Никтер елыйсы килә.

*

Боздай карашларны күрдем,
Чыгармадым яшемне.
Әрнүемне, сагышымны
Күңелемә яшердем.

Бер җылы күз карашыннан
Күңел-елгам ташыды.
Бер җылы сүз иелдерде
Иелмәстәй башымны.

*

Көн белән төн чиратлашып тора,
Яхшы-яман белән дөнья тулган.
Яхшысын да, яманын да татып,
Берәм-берәм кешеләр дөнья куя.

Мәхәббәт һәм нәфрәт ялкыннары...
Кеше йөрәгенә бар да сыйган.
Җир йөзендә бары бер нәрсәгә—
Ялгызлыкка күнегеп булмый сыман.

## Тилмертмәгез гөлләрне!

Сулар сибеп үстермәсәң,
Гөл кояшка үрләрме?—
Сусыз калып сулмасыннар,
Тилмертмәгез гөлләрне!

Гөл чәчәге күләгәдә
Ялкын булып дөрләрме?
Гел кояшка карасыннар—
Тилмертмәгез гөлләрне!

*

Тыны-көне бетеп
Йөгерә берәү—
Узып барган
Яшьлеген туктатмакчы!
«Ду» китереп
Урам себерә берәү—
Дөньяны чистартмакчы...
И гомерләр!..

Җирне ямьләп торган гөлне
Давыл килеп изеп китә.
Һич булмаса, яфракларын
Берәм-берәм өзеп китә.

Үтә гомер—сизелми дә,
Сизелми дә үтә көннәр...
Гел көрәш тә гел бәрелеш—
Ничек түзә нәфис гөлләр?!.

Бирсә бирә Ходай:
Кимендә
өч шатлык килә рәттән.
Тик...
кайгысы да ялгыз гына йөрми:
Иптәшен ияртқән!

## Эссе җәйдән соң

Сибәли дә сибәли
Көзге яңгыр.
Ахры, болытларның
сабыр савытлары
Тулгандыр.

Канатларын көйдерәсен белсә,
Килмәс иде утны күрәсе дә—
Бер күбәләк, янган утка кызыгып,
Гел әйләнә учак тирәсендә...

Баш очымда болыт куера—
Кысылышлар китә йөрәкләр:
Тик чылатып кына үтәр микән,
Кояр микән әллә чиләкләп?...

## Көньякка киткәндә

Нигә болай бик ямансу әле?
Күңелләрдә—сагыш?—
Туган якның моңсу көзен ташлап,
Җәйгә китеп барыш...

## Болыт

Болыт канаты тия дә
Кояш нурын чылата.
Шул бер кара болыт инде—
Кояшны шул елата...

Сорады бер Болыт назлы Гөлдән:
—Нигә болай боек син һаман?
Әйтте Гөлкәй, башын аска иеп:
—Мин Кояшка гына елмаям.

Кемдер яна көл булганчы,
Кемдер бөтенләй дә янмый.
Үзгәртергә маташмагыз—
Ул бүтәнчә була алмый.

Үргә мендем, дип куанма,—
Үр артында үрләр бар...
Серен алдым дип юанма,—
Сер артында серләр бар...

Акыллылар нык күбәйде,
Хыялыйлар гына сирәк...
Җирне ямьләп яшәр өчен
Бераз «сәер» булу кирәк!

Хыял бераз хәйләле дә,
Бераз гына алдалый да.
Тик нигәдер җиңелрәк күк
Яшәү Җирдә—хыялыйга...

Безнең урамда да бәйрәм булыр—
Ап-ал таңнар атар,—
Җырын, моңын чорлар чоңгылында
Югалтмаса татар.

Бүтән нәрсә миннән эзләмәгез—
Мин шигырьдән торам.
Кояш тулы күңелемнең йортын
Мин шигырьдән корам.

## Ап-ак кәгазь. Каләм. Кара.

Күктә—Кояш, Җирдә—гөлләр.
Язлар әллә үтеп бара?
Сабыр гына көтеп ята
Ап-ак кәгазь. Каләм. Кара.



# Фирүзә Җамалетдинова

ӨР-ЯҢА ӘКИЯТ

## Казаннан кайткач

Синдә, Казан, булыр иде кебек
Бераз гына җиңел сулап та...
Кол Шәрифең уңда каршы алса,
Чиркәүләрең кала сул якта.

Синнән минем күңел аерылмаган,
Киткән еллар сыймый дистәгә.
Азаннарга оеп барган җаным
Чиркәү чыңнарыннан сискәнә.

Әллә ничек мин узасы юлга
Шомлы карый кебек тәресе.
Ә бәлки бу сукмак тарихларны
Тыңлап, гыйбрәт алу дәресе?..

Их, студент чакта урамнарга
Яшьлек булып керә идек без.
Баумандагы чиркәү бинасында[1]
Ераклыкка сикерә идек без.

Казаннарда—илем, дияр кемнәр,
Тарихыңны ятлар учлагач.
Сикереп кенә ерак төшеп булмый
Канатланып җаның очмагач.

Үзгәргәнсең, Казан! Бик гүзәлсең...
Тәреләрең арткан үзәктә.
Бәргәләнә җаным... Килми калмам,
Китә алмам куллар изәп тә.

Без күбебез читкә сикергәнбез,
Шактый читкә изге Казаннан.
Илһам алыр Казан азаннан да,
Бер узар күк язмыш язганнан.

Фирүзә ЖАМАЛЕТДИНОВА—*яшь шагыйрә, «Утлы җил», «Яшен күзләре» исемле китаплар авторы. Чаллыда яши.*

**Сагынганмын, Казан! Җырлап булмый,**
**Елап булмый хәтта үкереп.**
**Һавалардан җиргә төштем әле,**
**Җиргә төштем гүя сикереп...**

**Кемнәр бүген бриллианттыр**
**Алтын йөзек кашында?**
**Бер фикере кирәк түгел**
**Мең акыллы башның да.**

**Моң ургый, ургый, агыла,**
**Күзләрне теләк итеп.**
**—Иркенсең, дөнья! Үземне**
**Тоям шыр җүләр итеп.**

**Гармуннар тарткандай тартам**
**Күңелемнең күреген.**
**Ярылсаң да чикләп булмый**
**Җыр җүләрнең ирегең.**

**...Канунга көй язам, дисәң,**
**Сугачаклар түбәгә.**
**Түбәләргә суккан саен**
**Сары йортлар күбәя.**

**Ташлар сары, җыр саргаймый,**
**Җырлар мәңге кипмәгән.**
**...Әлегәчә ничек йөрәк**
**Шагыйрь булып типмәгән?!**

*Дөнья матур!*
Һ. Такташ

**Килен булып төшкән мәле кышның,**
**Җил очырта ап-ак күлмәген.**
**Мин үләрмен кебек иде кышта,**
**Тунсыз көе тагын үлмәдем.**

**Кул әрнесә, тешләремне кыстым,**
**Җаным туңса, ирен тешләдем.**
**Ак карлардан учак тергезәләм—**
**Килен булып бүген төшмәдем.**

**Кышлар салкын диеп күпләр үтте,**
**Ачы, усал, имеш, зәмһәрир.**
**Ә язмышлар безгә ни язса да,**
**Ни сызса да—үзе мөхәррир.**

**Аһ, үзебез язар идек тә соң,**
**Хаталанмас идек—гыйлем аз.**
**Карлар ява, сибелеп карлар ява,**
**Һәр бөртектән ява күпме наз!**

**...Нәселгә бер түрәсе дә юк шул,**
**Кул сузардай юк шул кеме дә.**
**Дөнья матур!**
**Кемгә рәхмәт әйтим икән кышның**
**Килен булып төшкән көнендә?!**

---
[1]КДУ студентларынын физкультура дәресләре совет чорында спортзал итеп үзгәртелгән чиркәү бинасында үтә иде.

## Юл кичүе

Ашыгудан юлда кешеләрне
Ера-ера үттем бу төндә.
Кулын сузып теләнчеләр калды,
Яшьләр калды зәңгәр төтендә.

Чыңлап калды сыра шешәләре,
Кичүдәге кибет эчендә.
Суык төндә их, арканы терәп
Җылынасы дөнья мичендә.

Газлы заман һәм төтенле заман,
Авылда да мичләр сүтелгән.
Безнең чынлык әкиятләргә күчкән,
Әкияти еллар үтелгән.

Адымнарга тизлек күрсәтергә,
Йөрәкләрдә очар ук ята.
Кемне сыра, йә тәмәке кибете,
Кемне теләнчеләр туктата.

Сөйләнгән сүз, вәгъдә, мәгънә, антлар,
Яшьләр барсын төргән төтенгә.
Илсезләр дә, җирсезләр дә сыйган,
Өйсезләр дә сыйган бу төнгә.

Кемгә эндәшсәм дә ишетмәсләр,
Мин гади бер үтеп баручы.
Бу кичүдән уңга чыгып була,
Сулга алып чыга бер очы...

Бер акыллы затың бармы, дөнья,
Уң һәм сулны аерып бирерлек?
...Иркен сулап өр-яңа бер әкият
Тыңлыйсылар килә, бирелеп.

## Бизмәнче карт

Базар юлы. Бизмәнче карт.
Бии үлчәү телләре.
Яфрак куып менгәнмени
Ябык заман җилләре.

Яшәгән дә соң кешеләр
Үз хәлләрен белмичә.
Бизмәнче картны күрмичә,
Иң гаҗәбе—үлмичә.

Бар төрлесе. Җаны белән
Бизмәнгә сыймаганы.
Бар сыеп та сыйганлыгын
Танырга кыймаганы.

Күзләрен биетеп ала,
Бизмәнче тере генә.
Бу бәлки бар һөнәренең
Җитмештән бере генә.

Читләп үтә алмас аны
Татар, урыс, чегәне.
Картның юк менә бер кат та
Түрәләр үлчәгәне.

Ничек әйләнмәгән дөнья,
Кемнәр галим булмаган.
Түрәләр үлчәр бизмәннәр
Уйланып табылмаган...

Тормыш кебек кайный базар,
Бизмәнгә күзен салып.
Чал тарихтай сакаллы карт,
Үлчәнә гади халык...



# Ольга Левадная

## ЮКА БОЗДА МИННӘН ЭЗ ДӘ КАЛМАС...

### Очыш

Көтү-көтү болыт очып уза
Черем иткән йортлар өстеннән.
Шигырь тулы төннең уртасында
Ым-ишарә көтәм мин синнән.
Комсыз көннәрдән мин китеп барам.
Ярлыкалырмын дип өмет итәм!
Һәм очам мин тупыл мамыгыдай,
Бәхетемә тияр-тимәс үтәм.

### Вакыт

Җәйнең сискәнүле сулышында
Онытылып калган Вакыт тибри.
Амфорада борынгы бер бөртек,
Терелгәндәй, яктылыкка үрли.
Мәңгелектә аулак иде юкса.
Ни җитмәде икән ул бөртеккә?—
Ул үзенә язган гомер юлын
Тома караңгыда дәвам итә.

*

Алтын бөртек чүпли оча-куна
Таңның ак кошчыгы таң алдында.
Узган җәйнең яфраклары шавы
Калган посып күңел ышыгында.
Берсен-берсе тоймас хисләр оча,
Җирдә тамырларга салкын иңгән.
Орынмыйча хәсрәтле бу җиргә
Оча тулган алма кара төндә.

Ольга ЛЕВАДНАЯ—*Казанда яшәүче рус шагыйрәсе, «Пройти заколдованный круг», «В ожидании снега живу» исемле китаплар авторы. Журналыбызда беренче тапкыр басыла.*

## Хатын-кыз

Хатын-кызда нинди сер бар?
Аны ни серле итә?
Көче аның—зәгыйфьлектә,
Акылы—тинтәклектә.
Куллары—сынган канаттыр...
Очмак булып уянган!
...Очыш ләззәтен тоя ул
Түбән томырылганда.

## Юлларның яралмышы

Ничек ярала бу юллар?
Алар кая илтә?
Җандагы шом кемгә китә?
Ул шомны кем күтә?
Яктылык һәм караңгылык
Җанны дер селкетә,—
Куаныч белән кайгы гел
Чәбәләнеп бетә.
Озатам кошлар төркемен...
Алар бара сыман
Гүяки җәннәт багына—
Ходай тарафына.

## Ялвару

Ялварам: чум син хыялга!
Ваклыклар онытылсын,
Кышкы зәмһәрирдә туңган
Күңел эрерлек булсын!
Ялварам: ашык, гүяки
Башлана гына гомер!
Хисләр әле бөтен, камил!..
Ашык! Һәм тылсым килер...

## Сайрар кош

Сайрар кош сайрамый, елый...
Ятлар аны балдаклаган.
Төн карасы... мәңгелекме
Кош төненә канат салган?
Арыдыңмы, кошчыккаем,
Ашкынганда иртәгәңә?
Җан ашкынган килеш син дә
Картайдыңмы, көтмәгәндә?

*

Япа-ялгыз барам әле
Шаулы төркем
Уртасында...
Оҗмахка юл
Бар да сыман,

Оҗмахка юл
Юк та сыман.
Оҗмахка юл эзләгәнне
Сакла, язмыш!
Барсын, тапсын!
Иблисләрнең
Күзләрен син
Капла, язмыш!

## Өйгә кайтыр сукмагым

Бөреләр керфек кыстылар...
Кояш бигрәк якты.
Үрелә шигырь юллары
Җылы җәйгә чаклы.
Шпаллы юл... кача-поса
Вакыт әзәрлекли.
Эшләр гел генә уңмый шул...
Арыдым. Хәл бетте...

*

Буйсынып чит ихтыярга
Һаман бәхет өләшәмен.
Күп чәчтем дә аз урдым мин...
Бу җирдә мин ник яшәдем?
Ходай кушканча була гел.
Яхшыгамы, ямангамы?
Көз килде. Яфрак коелды.
Буш оялар ачык калды...

## Көз

Диварлары саргайган йорт.
Тәрәзәдә ватык өлге.
Ташландык бакча—ялангач.
Йорт җылыта һаман мине.
Тәүбәсез бу язмыш өчен
Акланулар миңа нигә?
Күнәм шәфкатьсез язмышка.
Өзеләм мин—тулган чия...

## Таң

Иртәнге тымызык тынлык
Саркый тәрәзәмнән.
Сизәм, илаһи гарештән
Миңа нидер иңгән.
Сабыйларда үз-үземне
Тоям, таныйм, тынам.
Мәчетләрдә хур кошлары
Чутылдаша сыман...

...Гади сүз тулы тормышка
Кабат кайтам инде...
Әгәр дә таң кайтса төнгә
Шулай кайтыр иде...
Гөмбәзләргә соңгы карлар
Куна, бетә эреп!
Шәһәремә шаукымлы яз
Шулай килә кереп...

ЗӨЛФӘТ *тәрҗемәләре.*

*Дөнья әдәбияты җәүһәрләре*

## «ДЕТЕКТИВ КОРОЛЕВАСЫ»

*Агата Кристи әсәрләренең күбесенең эчтәлеге тиз онытыла диләр. Аларның бер-берсенә охшаган булуын әйткән дә юк инде. Шуңа да карамастан, аның әсәрләре феноменаль уңышка ирешә. Кристи үзе исән чакта ук инде «детектив королевасы» дигән титулга ия булган иде. XX йөз инглиз әдипләре арасыннан аны Британиянең үзендә дә, аннан читтә дә иң күп укыла торганы дисәк, һич тә арттыру булмас. Һәм, менә инде 1952 елдан бирле, аның «Тычкан тәбесе» дигән пьесасы Лондон сәхнәләреннән төшми.*

*Эш нәрсәдә соң? Нишләп әле аның әсәрләре—кулдан, пьесасы—сәхнәдән төшми?*

*Агата Кристиның әтисе Фредерик Миллер чыгышы белән америкалы була. Озак вакыт ул Англиядә яши.*

*Агата 1890 елда туа. Аңа унике яшьләр чагында әтисе үлеп, гаиләнең матди хәле начарлана, һәм бала әллә ни системалы белем ала алмый. Шулай да, Агата музыка, җыр белән шөгыльләнә. Ул хәтта җырчы булу турында уйлаштыра, ләкин аңа оялчанлыгы комачаулый. Шунысы кызык, Кристи гомере буена оялу хисеннән котыла алмый. 1958 елдан 1976 елга кадәр детективчылар клубы президенты булып торганда да нотыклар яисә тостлар әйтү хокукын ул бүтәннәргә бирә торган була.*

*Бала чакта Агата бер дә язучылык эшенә омтылмый. Югыйсә аларның гаиләсенә Генри Джеймс яисә Редьярд Киплинг кебек олы язучылар килеп йөри. Ул салмак хәрәкәтле, сүзгә оста булмаган, күп сөйләшми торган бала була. Аның яза башлавы да очраклы гына килеп чыга. Нindидер чирдән терелеп килгәндә Агата үзенә шөгыль таба алмыйча каңгырып йөри. Шулчак әнисе аңа хикәя язарга киңәш итә. Гаиләдә исә әни белән бәхәскә керү гадәте юк. Шулай итеп, Агата эшкә тотына. Өстәвенә аның апасы хикәяләрне язып кына карамаган, ә бәлки журналларда бастырып та чыгарган була.*

*«Серле вакыйга» (1920) дигән беренче детективын Агата уеннан уймак чыгарган кебек кенә итеп яза. Ничектер бервакыт апасы аңа: детектив яза алмыйсың син, чөнки ул бик авыр эш, дип әйтә. Апасы һәрвакыт өстен чыга торган булганга, бу юлы Агата үзенең нәрсәгә сәләтле икәнен күрсәтергә тели. Ул романны язып бетерә һәм... рәттән алты нәшир аны кире кага, җиденчесе генә көчкә бастырып чыгара. Булачак «детектив королевасы»ның туую искәрмиi дә калалар: нибары ике мең данә чамасы китабы сатыла, гонорары да 25 фунт кына була. Хәлбуки, үзен профессиональ язучы дип исәпләмәсә дә, Агата Кристи шул вакыттан бирле язуын дәвам иттерә.*

*Алтмыш еллап язучылык иткән гомерендә—ул 1976 елда вафат була—Агата Кристи 68 роман, йөздән артык хикәя, 17 пьеса яза. Аның күп романнарының төп герое булган шымчы Пуаро турындагы соңгы «Пәрдә» дигән романы (ул анда инде һәлак тә була) 1975 елда нәшер ителә. Шундый ук хатын-кыз герое Марпл турындагы соңгы романы (ул анда исән килеш кала) авторның вафатыннан соң, 1976 елда басылып чыга. 1977 елда Агата Кристиның автобиографиясе дөнья күрә. Аның әсәрләре дөньяның 103 теленә тәрҗемә ителгән, татарчасы 104 нчесе була торгандыр, мөгаен...*

# Агата Кристи

# ГАЕПЛӘҮЧЕ ШАҺИТ

ХИКӘЯ

Кыпшы дип әйтерлек дәрәҗәдә күркәм итеп киенгән, тәбәнәгрәк буйлы, чандыр гәүдәле кеше—суд эшләре вәкиле Мейхерн әфәнденең тышкы кыяфәте менә шундый иде. Аның көчле адвокат дигән даны бар. Бөтен дөньяны үтә күрердәй итеп карый торган үткен соры күз карашыннан әңгәмәдәше шактый акыллы кеше белән эш итүен чамаларга тиештер. Клиентлары белән адвокат беркадәр корырак сөйләшә, әлбәттә, ләкин аның тонында бервакытта да усал ният сизелми.

Бүген Мейхерн яклый торган адәм кеше үтерүдә гаепләнә.

—Минем бурыч—хәлегезнең чиктән тыш мөшкел икәнен һәм бөтен дөреслекне ачыктан-ачык сөйләп биргән очракта гына үзегезне коткара алуыгызны тагын бер кат исегезгә төшерү.

Тирә-юньдәге хәлләргә бөтенләй катнашы булмагандай, берни дә күрмәгәндәй утырган утыз өч яшьләрендәге Леонард Воул дигән ир салмак кына итеп күз карашын Мейхерн әфәндегә төбәгәнче тагын берникадәр вакыт үтте.

—Беләм,—диде ул тонык кына тавыш белән.—Сез инде мине кисәткән идегез. Ләкин... шундый да кансыз, кабахәт рәвештә кеше үтерүдә гаепләнүем белән берничек тә килешә алмыйм.

Мейхерн әфәнде фактларга таянырга өйрәнгән, хискә бирелү аның өчен ят нәрсә. Ул пенснесын салды да башта аның бер пыяласын, аннары ашыкмыйча гына икенчесен сөртте.

—Шулай, Воул әфәнде, сезне мажарадан йолып алу өчен безгә тырышырга туры килер. Бары да рәтләнер дип уйлыйм. Әмма мин сезгә каршы куелган дәлилләрнең ни дәрәҗәдә көчле икәнлеген һәм яклауның нинди ысулы ышанычлырак булуын белергә тиеш.

Бу эшне чуалчык дип һич тә әйтеп булмый иде, һәм шик астындагы кешенең гаебе берәүне дә икеләндермәслек дәрәҗәдә ачык иде. Берәүне дә икеләндермәслек дәрәҗәдә, әмма хәзер Мейхерн әфәнде үзе икеләнә башлады.

—Сез мине гаепле дип уйлыйсыз инде,—дип дәвам итте сүзен Леонард Воул.—Һич юк, мин моны Аллаһы Тәгалә исеме белән ант итеп әйтәм. Әлбәттә, монда миңа бөтен нәрсә каршы. Җәтмәгә эләккәнмендер сыман, кая таба борылсаң да, ычкына алмыйсың. Ләкин мин үтермәдем! Ишетәсезме—үтермәдем!

Мондый хәлдә кем генә инкяр итмәс икән үзенең гаебен! Мейхерн әфәндегә бик тә таныш хәл иде бу. Әмма нәкъ менә хәзер әлеге егетнең кеше үтерүендә иманы камил түгел иде аның, һәм моны ул үз-үзенә икърар итүдән курыкты. Ахыр чиктә бит Воулның чыннан да үтермәгән булуы ихтимал.

—Әйе, Воул әфәнде, бөтен дәлилләр сезгә каршы. Хәлбуки мин сезгә ышанам. Фактларга әйләнеп кайтыйк әле. Эмили Френч ханым белән ничек танышканыгызны сөйләгезче.

—Оксфорд-стритта булды бу хәл. Карт кына бер ханым урам аркылы чыгып бара иде. Төргәк-төргәк әйбер күтәреп юл уртасына килеп кергәч, ул аларны кулыннан төшереп җибәрде. Шуларны җыя башлаган иде, әздән генә автобус астына керми калды һәм ничек кирәк алай тротуарга чыгып житте. Мин аның төенчекләрен җыештым, тузаннарын кагыштым. Бер төргәкнең чишелеп киткән бавын бәйләп куйдым да хуҗасына тоттырдым.

—Гомеремне саклап калдыгыз дигән сүз булмадымы?

—Нишләп инде, юк, әлбәттә! Гадәти хәл бит инде. Әдәп йөзеннән булышу. Дөрес, ул бик җылы итеп рәхмәтләр укыды, мондый ярдәмчеллек

хәзерге яшьләрдә сирәк очрый торган хәл, дип, мактап та алды бугай әле. Шулайрак инде, аермачык хәтерләп тә бетермим. Аннары мин үз юлыма киттем. Берәр вакыт аның белән очрашырбыз дигән уй башыма да килмәде. Әмма тормыш алдыбызга көтелмәгән сюрпризлар да китереп куйгалый. Шул көнне үк мин аны үземнең бер танышымда кичке аш янында очраттым. Ханым шунда ук мине танып алды һәм безне таныштыруларын үтенде. Шунда мин аның Эмили Френч икәнен һәм Криклвудта яшәгәнен белдем. Без бераз гына сөйләшеп алдык. Мин аны бөтенләй ят кешеләрне дә якын итә ала торганнардан дип уйлыйм. Менә шул. Аннары мин, барып, аның хәлен белергә тиеш булдым. Мин, ничек тә берәр кереп чыгармын әле, дип җавап бирдем, ләкин ул көнен үк тәгаенләргә кушты. Барасым килмәсә дә, баш тартырга уңайсызландым, аннары тәрбиясезлек тә була бит әле ул. Шимбә көнне очрашырга дип килештек, һәм шуннан соң ул озакламый китеп тә барды. Дусларым аның хакында бик бай һәм бик тә гаҗәеп кеше дип сөйләделәр. Аның зур йортта яшәвен, бер хезмәтчесе һәм сигез мәчесе булуын да мин шулар сөйләгәннән белдем.

—Ничек, хәлле кеше икәнлеге сезгә чыннан да ул киткәннән соң гына мәгълүм булдымыни?—дип сорады Мейхерн әфәнде.

—Әгәр мине махсус сораштырган дип уйласагыз...—дип, кызып-кызып акланырга тотынмакчы иде Воул, Мейхерн әфәнде ана әйтеп бетерергә ирек бирмәде:

—Мин берни дә уйламыйм. Мин фәкать гаепләүчедә нинди сораулар килеп туу ихтималын күзалларга тырышам. Френч ханым уртача гына тормышта яшәгән бит ул, фәкыйрь үк димәсәң әле,—читтән караган кеше аны берничек тә мал-мөлкәтле кеше дип уйлый алмас иде. Аның акчалы булуын сезгә кем әйткәнен хәтерләмисезме?

—Дустым Жорж Гаври әйтте.

—Ул моны расլый аламы?

—Белмим. Вакыт күп үткән бит инде.

—Менә күрдегезме, Воул әфәнде. Гаепләүченең беренче бурычы—сезнең акча мәсьәләсендә кысынкылык кичерүегезне һәм, бу ханымның бай икәнен белеп алгач, аның белән танышырга омтылуыгызны исбатлау булачак.

—Ләкин алай түгел бит!

—Күп нәрсә ул дустыгызның хәтеренә бәйле булачак. Шундый сүз булганын хәтерли микән ул?

Леонард Воул берникадәр вакыт эндәшми утырды, аннары, башын чайкап, әкрен генә, ләкин бик каттый итеп, болай диде:

—Хәтерләмидер дип уйламыйм, Мейхерн әфәнде. Өстәвенә әле безнең сөйләшкәнне берничә кеше ишетеп тә торды һәм, бай карчыкның йөрәгенә хуҗа булмакчысыңмыни, дип, кайсысыдыр шаяртып та алды.

—Кызганыч, бик кызганыч.—Адвокат күңеле кайтуын яшермәде.—Ләкин мина дөресен әйтүегез ошый, Воул әфәнде. Шулай итеп, сез Френч ханым белән таныштыгыз. Танышлыгыгыз бер визит белән генә төгәлләнмәде, сез Криклвудта булуыгызны дәвам иттердегез. Ни сәбәпле? Ни өчен менә сез, сөйкемле, спорт сөюче яшь кеше, шулхәтле дусларыгыз була торып, олы яшьтәге бер ханымга шундый зур игътибар күрсәттегез? Аның белән нинди дә булса уртак нәрсәсе бар идеме?

Леонард Воул бик озак кына кирәкле сүзләрен таба алмыйча торды.

—Дөресен генә әйткәндә, мин үзем рәтләп белмим. Беренче баруымда ул ялгызлыктан зарланды, үзен онытмавымны үтенде, мине якын күрүен ачыктан-ачык сиздерде, һәм мин, үземне бик уңайсыз хис итсәм дә, тагын килермен дип вәгъдә бирергә мәҗбүр идем. Аннары инде кемгәдер кирәк булуымны, берәүнең мине улы кебек итеп кайгыртуын аңлау да күңелле иде.

Мейхерн әфәнде ничәнче тапкыр инде пенснесенең пыялаларын сөртергә тотынды,—бу аның тирән уйга калуы билгесе иде.

—Аңлатмагызны кабул итәм мин сезнең,—диде ул ниһаять.—Психологик яктан нигезләнгән, дип уйлыйм. Хәер, гаепләүченең фикере башкача булырга мөмкин. Үтенәм сездән, дәвам итегез. Эшләрендә булышуыгызны Френч ханым сездән кайчан үтенде?

—Әлбәттә, беренче баруымда түгел. Ул кәгазьләр белән эш итүдә белеменең сай булуын, салынган кайбер капиталлары турында борчылуын әйтте.

Мейхерн әфәнде Воулга җәлт кенә үткен караш ташлап алды.

—Френч ханымның хезмәтчесе Жанет Маккензи исә хуҗасы хакында эшләре ничек барганын белә торган төпле кеше иде, дип сөйли. Банкирлары да шул фикердә.

—Мина ул бөтенләй башкача сөйли иде.

Мейхерн әфәнде Воулга тагын бер карап алды. Хәзер ул аңа элеккегә караганда ныграк ышана иде. Йөрәген әлеге чибәр егет биләп алган бу Френч ханымны ул аермачык итеп күз алдына китерде; егетне үз өенә китерер өчен сәбәп табу ханымга җиңел булмаганын чамалый иде ул. Акча эшләрендә үзен томана итеп күрсәткән булуы бик мөмкин аның, һәм егеттән булышуын үтенү—сәбәп түгелмени бу? Алыштыргысыз ярдәмче булуын күрсәтеп, егеткә ярарга тырышкандыр. Хатын-кыз буларак моны гына уйлый алырлык рәте булган әле аның. Леонард аның никадәр бай икәнлеген дә аңларга тиеш булгандыр, күрәсең. Тәвәккәл характерлы Эмили Френч, бар мәсьәләгә дә житди карап, һәрвакыт бөтен нәрсәгә дә чын бәясен түли торган булган.

Воулга карап Мейхерн әфәнде менә шуларны уйлап алды, әмма аның йөзендә берни дә чагылмады.

—Димәк, сез Френч ханымның кәгазьләре белән үзенең үтенүе буенча эш иттегез?

—Әйе.

—Воул әфәнде,—адвокат, әйткән һәр сүзенә басым ясап, сөйли башлады—хәзер мин бик җитди сорау бирәм, һәм миңа иң хак, иң дөрес җавап кына кирәк. Финанс мәсьәләсендә сезнең хәлләр шәптән булмаган: әйтергә кирәк, көймәгез комга терәлгән булган. Шул ук вакытта карт ханымның финанс кәгазьләре белән сез эш иткәнсез, ул исә, үзенең әйтүенә караганда, финанс эшенең бер дә рәтен белмәгән. Бер генә тапкыр булса да, ничек кенә итеп булса да кулыгыздагы кыйммәтле кәгазьләрне үз кирәгегезгә файдаланмадыгызмы? Җавап биргәнче яхшылап уйлагыз.

Әмма Леонард Воулның бер генә минут та уйларга теләге юк иде.

—Шелтәләр урын юк мине. Бөтен эш хәрәмсез эшләнде; алай гына түгел, мин һәрвакыт Френч ханым мәнфәгатьләрен якларга тырыштым.

—Күрәм, бу эштә алдашыр өчен сез артык акыллы кеше.

—Шулай булмыйча!—диде Воул.—Аны үтерергә минем бернинди сәбәбем юк иде. Акчасын алырга исәп тотып, танышлыкны өзмәгәнмен дип фараз итсәк тә, аның үлеме минем өчен бөтен өметләремнең чәлпәрәмә килүе булыр иде.

Адвокат тагын пенснесен сөртә башлады.

—Френч ханым төзегән васыятьнамәдә сезне бердәнбер мирас алучысы итеп билгеләве сезгә мәгълүм түгел идемени, Воул әфәнде?

—Нәрсә?!

Воул, урынынннан сикереп торды да, Мейхерн әфәндегә шаккатып карап тора башлады.

Мейхерн әфәнде сүзен янадан кабатлауны кирәк тапмады, бары тик баш кына какты.

—Васыятьнамә турында берни дә белми идем, дип әйтмәкче буласызмы?

—Әйе шул! Минем өчен бу бөтенләй көтелмәгән нәрсә.

—Ә мин сезгә Френч ханымның хезмәтчесе бөтенләй башкача сөйли дип әйтсәм? Нияте хакында сезнең белән киңәшүен дә аңа әйткән, имеш, Френч ханым.

—Жанет ялганлый! Ул бик шикләнүчән карчык, өстәвенә көнчел. Френч ханымның өендә бер залим кебек иде инде ул. Бер дә өнәми иде ул мине.

—Сезгә яла ягарга сәләтле дип уйлыйсызмы аны?

—Юк инде, нәрсәгә ул аңа!—Воул аптыраган кебек күренә иде.

—Анысы миңа да мәгълүм түгел,—диде Мейхерн әфәнде.—Әмма сезгә карата бик тә ачулы ул.

—Коточкыч хәл бит бу! «Френч ханымның күнеленә кереп алган да, үз файдасына васыятьнамә язарга мәҗбүр иткән һәм, ялгыз вакытын туры

китереп...»—дип сөйләячәкләр инде минем турыда... Ә иртәгесен аны үле хәлендә табалар. Йа Раббым, исен-акылын китәр!

—Өйдә Френч ханымнан башка кеше булмаган дип, сез хаталанасыз, Воул. Хәтерегездәдер, ул кичне Жанет гадәттәгедән иртәрәк кайтып китә, чөнки анын ял көне була. Шулай да, унынчы яртыда ул кире әйләнеп килә. Жанет өйгә арт ишектән кереп өскә күтәрелә һәм кунак бүлмәсендә тавыш ишетә. Берсе хуҗабикә тавышы, икенчесе ир кеше тавышы була.

—Ә бит унынчы яртыда мин...—Воулдагы әүвәлге рух төшенкелегенең эзе дә калмады.—Унынчы яртыда бит!.. Мин котылдым!!!

—Котылдым дисезме? Сез нәрсәне күздә тотасыз?—Мейхерн әфәнде анын сүзенең мәгънәсенә төшенмәде.

—Бу вакытта мин өйдә идем инде. Моны минем хатын раслый ала. Тугыз туларга егерме минутларда мин Френч ханым белән хушлаштым да унынчы егерме минутта инде өемдә кичке ашны ашарга утырдым. Аллаһынын рәхмәте түгел диген!

—Алайса Френч ханымны кем үтергән соң?

—Кем булсын, карак! Жанет ахмакларча шикләнеп, мина карата шул хәтле нәфрәтле булмаса, полиция, мина вакытын әрәм итеп, ялгыш юлдан китеп йөрмәс иде.

—Шулай микән, уйлап карагыз әле, Воул әфәнде,—диде адвокат.—Сез унынчы яртыда өйдә идем, дисез, хезмәтче исә аермачык ирләр тавышы ишеткән. Френч ханым карак белән сөйләшеп торыр микән?

—Әйе, ләкин бит...—дип, ни әйтергә белмичә Воул югалып калды. Алай да, ул үзен тиз генә кулга алды.—Һәрхәлдә, минем монда катнашым юк. Минем алибием бар. Сезгә, һичшиксез, Ромейн белән очрашырга кирәк. Ул минем сүземне раслар.

—Һичшиксез,—дип килеште Мейхерн әфәнде.—Сезнең хатынызыз белән мин баштук очрашмакчы идем, ләкин ул Лондоннан каядыр киткән булып чыкты. Мина мәгълүм кадәресе—Воул ханым бүген кайта һәм, сезнең белән сөйләшеп бетерүгә, мин анын янына китәм.

Воул канәгать булып башын какты, анын хәзер тәмам тынычланган булуы күренеп тора иде.

—Гафу итегез, Воул әфәнде. Бик яратасызмы хатынызызны?

—Әлбәттә.

—Ә ул сезне?

—О, Ромейн минем өчен жанын фида кыла. Минем хакта ул теләсә нишләргә әзер.

Воул хатыны хакында рухланыбрак сөйләгән саен Мейхерн әфәндене күнеле тынычсызлана барды. Үлеп ярата торган хатыннын мәгълүматларына ышанырга мөмкин микән?..

—Сезнен унынчы егерме минутта өегезгә кайтып барганыгызны күрүче булмадымы? Хезмәтчегез, мәсәлән?

—Безнен хезмәтчебез килеп-китеп кенә йөри. Сәгать жидедә ул инде эшен бетерә.

—Урамда берәрсе очрамадымы?

—Танышлардан берәүне дә очратмадым. Хәер, ярты юлны мин автобус белән кайттым. Кондукторнын хәтерләве мөмкин.

Мейхерн әфәнде икеләнеп башын чайкады.

—Хатынызызнын гуаһлыгын таныклардай берәр кеше юкмы сон?

—Юк. Ләкин бит монын кирәге дә юк, минемчә?

—Монын хажәте булмас дип ышанам—мин дә...

Мейхерн әфәнде урынынан торып Воулга кулын бирде.

—Бернигә дә карамастан мин сезнең гаепсез булуызызга ышанам, һәм без моны исбатлый алырбыз дип өметләнәм.

Воул әчкерсез елмаю белән елмайды.

—Мин дә шуна өметләнәм. Минем бит ышанычлы алиби бар.

Мейхерн әфәнде жавап кайтармыйча бүлмәдән чыгып китте...

Воуллар Пэддингтон-Гриннан ерак булмаган кечерәк кенә бер шыксыз йортта торалар иде. Мейхерн әфәнде шунда юнәлде.

Ишекне аңа авыр гәүдәле, яшь булмаган бер хатын ачты. Күрәсең, бу шул Воул әйткән килеп-китеп йөри торган хезмәтчедер инде.

—Воул ханым кайттымы әле?

—Әйе, берәр сәгать элек. Тик кабул итә алыр микән ул сезне?

—Кабул итә алыр дип уйлыйм. Сез аңа менә шушыны күрсәтегез.— һәм Мейхерн әфәнде аңа үзенең визит карточкасын бирде.

Хатын аңа шикләнеп кенә карап куйды, кулын алъяпкычына сөрткәләп, иплән кенә карточканы алды. Аннары адвокатны тышта калдырып, аның борын төбендә генә ишекне ябып куйды. Берничә минуттан ул кире чыкты; аның Мейхерн әфәндегә мөнәсәбәтендә аз гына үзгәреш бар иде.

—Рәхим итегез.

Адвокат хатын артыннан зур булмаган җыйнак кына аш бүлмәсенә үтте. Аны зифа буйлы озын брюнетка каршылады.

—Мейхерн әфәндеме? Сез минем иремнең эше белән шөгыльләнәсез бугай. Ул җибәрдеме сезне? Рәхим итеп утырыгыз.

Сөйләшә башлауга сизелгән телендәге җиңелчә акценты аның чит ил кешесе икәненә ишарә ясый иде.

Игътибар белән карагач, Мейхерн әфәнде аның яңак сөякләренең кинчәрәк, йөзенең кирәгеннән артык дәрәҗәдә ак булуын, күзләренең гаҗәеп матур икәнен, кулларына үзенә бер төрле үзенчәлекле хәрәкәт хас икәнен искәрде. Бөтен кыяфәтеннән аның инглиз булмыйча, ниндидер бер чит ил кешесе икәне күренеп тора иде.

—Воул ханым, сез өметсезлеккә бирелмәскә тиеш,—дип сүзен башлаган адвокат туктап калды. Воул ханым өметсезлеккә бирелергә җыенмый да иде.

«Сәер хатын. Шундый тыныч тота үзен, хәтта үртәлә башлыйсың»,— дип уйлады Мейхерн әфәнде. Бу хатын белән көрешүнең беренче минутларыннан ук үзен тынычсыз, ышанычсыз тоя башлады. Чамалавына караганда, аның каршында—чишәргә көче җитмәстәй табышмак иде. Мейхерн әфәнде Воул белән сөйләшкән сүзнең эчтәлеген әйтеп бирде. Хатын вакыт-вакыт башын кагып, игътибар белән тыңлады.

—Димәк,—диде ул, адвокат сүзен сөйләп бетергәч,—димәк, ул үзенең унынчы егерме минутта өйгә кайтып керүен миннән раслатмакчы була?

—Ләкин бит ул шул вакытта кайткан!

—Анда түгел хикмәт. Минем сүземә ышанырлармы соң? Моны берәрсе раслый аламы?

Мейхерн әфәнде каушап калды. Мәсьәләнең асылын шулкадәр тиз тотып алырга кирәк бит! Юк, бу хатында үзенне үз урынында итеп тотарга комачаулый торган нидер бар иде!

—Берәү дә раслый алмый.

Бер-ике минутлар Ромейн сүзсез утырды, ә аның ирен читләрендә ниндидер сәер елмаю сизелеп торды. Нәрсәгә елмая соң ул? Мейхернның күңелендәге шомлану хисе көчәя төште.

—Воул ханым, мин сезнең ирегезгә тугрылыклы икәнегезне беләм...

—Гафу итегез, ничек дидегез?

Бу сорау бичара адвокатны бөтенләй аптырашта калдырды, һәм ул инде сүзен артык рухланмыйча гына кабатлады:

—Сез бит ирегезгә тугрылыклы...

—Моны ул әйттеме сезгә? Шулхәтле томана булыр икән бу ирләр!— диде хатын, гарьләнеп һәм урыныннан торды.

Мейхерн әфәнде көткән дәһшәт алга килде.

—Күралмыйм мин аны! Ишетәсезме, сез?! Күралмыйм! Асып куйганнарын күрсәң иде!

Мейхерн әфәнде бер генә сүз дә әйтә алмады. Хатын аңа таба якын килде; аның тавышы, күз карашы, бөтен барлыгы нәфрәт чәчә иде.

—Әгәр дә мин теге кичне ул өйгә унынчы егерме минутта түгел, ә унберенче егерме минутта кайтты, дисәм? Васыятьнамә турында белә иде, шуна күрә үтерергә булды, дисәм? Һәм боларны миңа ул үзе—үзе!—әйтте, дисәм?! Судта менә шуларның барысын да әйтсәм?

Аның күзләре Мейхерн әфәндене үтәли көйдерәләр иде. Адвокат авыр-

лык белән генә дулкынлануын жиндә һәм мөмкин кадәр катгый итеп әйтте:

—Сез ирегезгә карата мәгълүмат бирә алмыйсыз. Законы шундый.

—Ул мина ир түгел!

Мейхерн әфәнде ялгыш ишеттемме әллә дип уйлады.

—Ир түгел!—дип кабатлады хатын, һәм озак вакытка тынлык урнашты...—Мин Венада актриса булып эшли идем. Кияүдә идем, минем ирем хәзер дә исән, ләкин ул... юләрләр йортында. Күргәнегезчә, Воул белән безнең никах гамәлдә дип танылa алмый. Һәм хәзер мин бик шат!—Ул, үрталгәндәй итеп, Мейхерн әфәнденең күзенә карады.

—Минем сездән бер генә нәрсә ишетәсем килә,—Мейхерн әфәнде өр-яңадан адвокат Мейхернга әйләнде, һәм ул инде яңадан хисне белми торган бер кеше иде:—Ни өчен сез Воул әфәндегә шулкадәр каршы?

—Минем моны сезгә әйтәсем килми. Ул минем серем булып калсын.

Мейхерн әфәнде ютәлләп куйды.

—Бу сөйләшүне дәвам иттерүнең хаҗәте юк. Клиентым белән сөйләшкәч, мин сезгә хәбәр итәрмен.

Элек Воул дип йөртелгән ханым Мейхерн әфәндегә таба якын ук килде, һәм әфәнде яңадан да бик якыннан аның гүзәл күзләрен күрде.

—Дөресен генә әйтегез әле, монда килгәндә сез Воулның гаепсез икәненә ышана идегезме?

—Әйе.

—Мин сезне бик кызганам.—Һәм ул тагын сәер елмаеп куйды.

—Мин хәзер дә ышанам,—диде Мейхерн әфәнде.—Хушыгыз.

Урам буйлап барган чакта аның күз алдында Ромейнның йөзе торды. Аңлашылмый торган сәер хатын. Куркыныч хатын!..

Полиция участогында тикшерү эшләре тиз барды. Төп гаепләүче шаһитләр—мәрхүмнең хезмәтчесе Жанет Маккензи һәм Леонард Воулның хатыны булып исәпләнә торган Австрия гражданкасы Ромейн Хейльгер булды.

Воулның эше судка чыгарылды. Иртәгә суд буласы дигән көнне Мейхерн әфәнде сәгать алтыдагы почтадан хат алды. Пычранып беткән конверт, арзанлы кәгазь, аннан-моннан сыздыйк-быздыйк итеп кенә язылган язу. Хатның мәгънәсенә төшенер өчен Мейхерн әфәндегә аны ике кат укып чыгарга туры килде. Язманың «артык мәгънәле» итә торган урыннарын төшереп калдырып, инглиз теленә күчерсәң, хатның эчтәлеге түбәндәгегә кайтып кала иде: «Кадерле әфәнде! Теге бичара эше белән шөгыльләнәсез бугай. Аның чит илдән килгән мәткәсе турында кайбер кызыклар беләсегез килсә, бүген Степнигә килегез. Анда, уналтынчы йортта (Шоу әфәнде йорты) Могсон ханымны сорагыз. Үзегез белән ике йөз фунт акча ала килегез».

Мейхерн хатның серле юлларын кат-кат укыды. Бу бер шаярту гына булырга мөмкин иде, ләкин уйлана торгач, адвокат шаярту булмаска тиеш дигән карарга килде. Шулай ук Воулның котылуга шансы да шуңа бәйләнгән булуын аңлады. Ромейн Хейльгерне намуссыз дип исбатлау гына ул биргән мәгълүматларның дөреслеген шик астына куйдырта алыр иде.

Һәм Мейхерн әфәнде барырга карар кылды...

Кирәкле йортны эзләп тапканчы фәкыйрьлекнең тәмсез исен иснииснитар урамнар буйлап шактый озак барырга туры килде аңа. Бу—кыйшаеп, тузып беткән өч катлы йорт кәмәше иде. Мейхерн әфәнде шакшыланып беткән чүпрәк-чапрак белән тышланган ишекне шакыды. Җавап бирүче булмады. Тагын бер тапкыр шакыганнан соң гына эчтән кыштыр-кыштыр иткән аяк тавышы ишетелде, ишек яртылаш кына ачыла төште,—кемдер адвокатны башыннан аягына хәтле күзеннән кичерде,—аннары, ишек тулаем ачылып киткәч, ишек төбендә бер хатын пәйда булды.

—Ә, синмени бу?—диде ул карлыккан тавыш белән.—Үзен генәме? Алайса кер әйдә.

Икеләнеп торганнан соң Мейхерн әфәнде кечкенә генә, бик шапшак бер карангылы-яктылы бүлмәгә килеп керде. Почмакта җыелмаган урын, урта бер жирдә аннан-моннан гына корыштырып куелган өстәл белән иске генә ике урындык тора. Ярымкараңгыга бераз күзе ияләшкәннән соң гына адвокат бу фәкыйрь торакның хуҗабикәсен күрә алды. Бик шапшак киенгән,

урта яшьләрдәге бөкшәйгән бер хатын иде бу. Күптән тарак күрмәгән, төсен дә чамаларлык булмаган чәче як-якка тырпайган иде. Йөзе күзенә кадәр чуар шарф белән капланган. Мейхерн әфәндене ачыктан-ачык кызыксынып караганын күреп, хатын көлеп куйды.

—Йә, нәрсә текәлдең? Ник йөзен яшерә дип аптырыйсынмы? Аздырыр дип курыкмасаң, кара әйдә минем чибәрлегемә.

Шул сүзләрне әйтүгә ул шарфын сүтеп җибәрде, аның сул як яңагындагы котсыз алсу җөйләрне күрүгә адвокат ирексездән чигенеп куйды. Могсон ханым йөзен кабат шарфы белән каплады.

—Йә, үбәсең килмиме мине? Юкмы? Үзем дә шулайдыр дип уйлаган идем аны. Ә бит кайчандыр мин бик чибәр идем... беләсеңме минем бу бизәгем кайдан? Купоростан, башы беткеренең...—Аның авызыннан җирәнгеч сүгенү сүзе агылды.

Ниһаять, ул тынып калды, тынычланды, һәм әлеге дулкынлануы кулының тартышуыннан гына сизелә иде.

—Җитте,—дип тынлыкны бозды Мейхерн әфәнде.—Аңлавымча, сез миңа Леонард Воул буенча ниндидер әһәмиятле хәбәр әйтмәкче буласыз. Мин көтәм.

Могсон ханым хәйләкәр генә күзен кысты.

—Акчаң кая, кадерлем?—диде ул карлыккан тавышы белән.—Әйткәнемчә ике йөз булса, синең өчен ни дә булса табылуы ихтимал.

—Нәрсә соң ул?

—Хатынының хатлары. Шушыңа син ни әйтерсең? Тик чур, миңа ничек килеп эләккәнен сораштырасы түгел! Ике йөз фунт, һәм хатлар синеке.

—Ул хатларның чыннан да миңа файдасы тиярлек булса, ун фунттан бер тиен дә артык түгел.

—Нәрсә?! Нибары ун фунтмы?—Хатын тагын кычкыра башлады.

—Егерме булсын. Бу минем соңгы сүзем,—диде Мейхерн әфәнде.

Адвокат бумажнигыннан акча чыгарды.

—Телисең икән—аласың, теләмисең икән—юк, бөтен акчам шушы.

Акча хатынга көчле тәэсир итте: ул кызыгуын җиңәр хәлдә түгел иде.

Адвокатны каһәрли-каһәрли Могсон ханым бирелергә мәҗбүр булды. Караватт янына килеп, матрасын күтәрде.

—Мә, чукын!—дип, ул өстәл өстенә төргәге белән хатлар ташлады.

—Сиңа кирәклесе—өстәгеседер.

Мейхерн әфәнде, бауны чиште дә, хатларны берәм-берәм актарып чыкты. Аның кулында Ромейн Хейльгернең мәхәббәт хатлары иде, ләкин алар Воулга түгел иде.

Хатларның кайберсен Мейхерн башыннан ахырына кадәр укыды, кайберләрен караштыргалап кына алды, өстә яткан хатны ул ике кат куып чыкты; аның язылу көне куелган: бу—Воул кулга алынган көн иде.

—Ничек килеп эләкте болар сезгә?

—Барысы да түгел әле бу. Ул сөйрәлчекнең әлеге кичтә кая булганын белеш син. Лайэн-роудтагы кинотеатрдан барып сора. Анда хәтерләргә тиешләр аны. Дөмеккере!

—Кемгә язылган бу хатлар?

—Миңа менә бу тамганы салып калдырган кешегә,—Могсон ханым кулын җәрәхәт эзе калган йөзенә таба китерде, аның бармаклары Мейхерн әфәндегә инде таныш булган хәрәкәтне кабатлады.

—Шуның эше менә бу. Күпме еллар үтсә дә, онытылмый. Бу килмешәк миннән тартып алды бит аны! Бер мәлне мин аларның эзенә төштем, һәм ул ата куян ачудан минем йөземә ниндидер бер шакшы нәрсә сипте. Ә бу маржага шул кызык булды. Барысы өчен дә үч алырга дип шактый озак көтәргә туры килде. Эзенә басып йөрдем мин аның! Хәзер инде ул минем кулда, барысы өчен дә бирер җавабын. Шулай бит, әфәндем!

—Антын бозган өчен ябып куюлары ихтимал.

—Бугазын тыгылдырырга иде аның. Әй, кая киттең? Акчаң кая?

Мейхерн әфәнде өстәлгә унар фунтлы ике кәгазь акча куйды да чыгып китте. Ишек янында әйләнеп карагач ул Могсон ханымның акчаны алырга үрелгән фигурасын күрде.

Вакытны әрәм итеп тормыйча, адвокат Лайэн-роудка барасы итте. Анда фотографиясеннән швейцар шундук Ромейн Хейльгерне таныды. Ул кичне алар кинотеатрга уннан соң килгәннәр. Бер ир кеше белән булган ул. Дөрес, швейцар анысының төсен-битен хәтерләми, ә хатынны яхшы хәтерли. Ул әле: нинди фильм күрсәтелә, дип тә сораган. Сеанс сәгать уникенчедә генә беткән; болар ахырга кадәр утырганнар.

Мейхерн әфәнде үзен бик канәгать хис итте.

Ромейн Хейльгернең мәгълүматлары башыннан ахырына кадәр ялган булып чыкты. Сәбәбе—Воулга карата нәфрәт. Ни белән шулкадәр ачуын китергәндер. Хатын дип йөргән кешесенеңниләр сөйләгәнен белгәч, бичараның бөтенләй рухы төште. Моңа аның һич тә ышанасы килмәде.

Хәлбуки, баштарак каушап калуына карамастан, Воулның каршылык күрсәтүе ихлас булмады кебек тоелды Мейхерн әфәндегә. Һичшиксез, Воул барысын да белгән. Белгән, ләкин башкаларның белүен теләмәгән. Аларның сере икесенең генә сере булып кала биргән.

Берәр вакыт аны Мейхерн әфәнде белә алыр микән?..

Эмили Френчны үтерүдә гаепләнә торган Леонард Воул өстеннән ясалган суд процессы бик шау-шулы булды. Беренчедән, гаепләнүче яшь тә, чибәр дә иде; икенчедән, бу сөйкемле кешене артык кансыз рәвештә үтерүдә гаеплиләр иде; ниһаять, әлеге суд утырышы белән шулкадәр каты кызыксынуның өченче сәбәбе дә бар иде: монысы—гаепләүнең төп шаһите Ромейн Хейльгер булуы. Күп кенә газитләр хатынның фотографияләрен бастылар, матбугатта шулай ук аның үткәне турында «ышанычлы» мәгълүматлар күренде.

Башта барысы да гадәттәге тәртип белән барды. Иң элек экспертлар үзләре чыгарган нәтиҗәләрен укыды.

Аннары Жанет Маккензины чакырдылар. Ул исә тикшерүчегә сөйләгәннәрен түкми-чәчми кабатлады. Шунда өстәп сорау биргәндә яклаучы берике тапкыр аның мәгълүматларының каршылыклы булуын фаш итте. Төп игътибарны ул, Маккензи, ирләр тавышы ишеткән очракта да, әлеге тавышның нәкъ менә Воул тавышы икәнен раслый торган бернинди дәлиле дә булмавына юнәлтте. Суд утырышчыларын ул тагын хезмәтче биргән мәгълүматлар нигезендә фактлар түгел, ә гаепләнүчегә карата нәфрәт, дошманлык хисе ятканына ышандыра алды.

Төп шаһитне чакырдылар.

—Сезнең исемегез Ромейн Хейльгерме?

—Әйе.

—Сез Австрия гражданинымы?

—Әйе.

—Соңгы өч елда сез гаепләнүченең хатыны булып яшәдегезме?

—Әйе.

Сорау алу дәвам итте. Ромейн судка коточкыч хакыйкатьне ачып салды: үтерү булган төнне гаепләнүче үзе белән өеннән бәләкәй лом алып чыгып киткән. Унберенче егерме минутта өйгә әйләнеп кайтып, ул кеше үтерүе хакында сөйләп биргән. Җиннәре кара канга батып беткәнлектән, күлмәген утка ягарга туры килгән. Куркытып, Воул аны эндәшмәскә мәҗбүр иткән.

Башта яхшы нияттә булган присяжныйлар гаепләнүченең коточкыч портреты ачыклана башлагач, кинәт кенә фикерләрен үзгәрттеләр. Икенче бер нәрсә дә күзгә ташланды: Ромейнга карата мөнәсәбәт үзгәрде, чөнки аның чыгышына ихласлык, риясызлык житми, һәр сүзендә ачу, кинә, нәфрәт чагыла иде.

Дәһшәтле кыяфәт белән яклаучы торып басты. Ул: шаһит әйткән бөтен сүзләр—мәкерле ялган, дип белдерде. Әлеге хәтәр кичтә ул өйдә булмаган һәм, табигый ки, Воулның кайчан кайткан булуын белә дә алмый. Яклаучы шулай ук, икенче бер ир Ромейн Хейльгернең сөяркәсе булып тора, шуның хакына хатын гаепләнүчене пычрата һәм кылмаган җинаятe өчен аны үлемгә дучар итмәкче була, дип тә әйтте.

Ромейн үзенә карата әйтелгән гаепләүләрне искиткеч салкын канлылык белән кире кага барды.

Шул мәлне залда Ромейн Хейльгернең хаты укылды:

«Макс, сөеклем! Язмыш үзе аны безнең кулга тапшыра. Ул кулга алынган! Ниндидер бер карчыкны үтерүдә гаеплиләр; чебенне дә рәнҗетми торган кешене! Их, ниһаять, үч алу вакыты җитте! Мин, теге төнне ул өйгә канга баткан хәлдә кайтты һәм кылган эше хакында үзе сөйләп бирде, дип әйтәчәкмен. Аны дар агачына озатырлар һәм үзен мин, Ромейн Хейльгер, җибәргәнен аңлар. Шунда инде, сөеклем, безгә бәхет капусы ачылыр. Ничәмә еллардан соң... Бәхетебезгә бу безнең, Макс!»

Экспертлар, шундук ант эчеп, кульъязманың Ромейнныкы икәнен расларга әзер иделәр, ләкин моның хаҗәте булмады. Ромейн Хейльгер Воулның дөресен сөйләвен, үзенең, ягъни гаепләүче шаһитнең, алдаган булуын икърар итте.

Воулдан янадан сорау алдылар һәм ул бер тапкыр да ялгышмады, өстәмә сораулар биргәндә дә буталмады. Гәрчә барлык фактлар да аның файдасына сөйләмәсә дә, присяжныйлар, киңәшеп тә тормыйча, гаепсез дигән карар чыгардылар.

Мейхерн әфәнде Воулны җиңү белән котларга ашыкты. Аның янына үтәрлек тә булмаганлыктан, Мейхерн әфәнде халык таралганын көтәсе итте. Пенснесен сөртергә тотынуына караганда, ул бик нык дулкынланган иде. Мейхерн әфәнде шуны искәрде: әз генә дулкынландымы—пенснесенә тотына. Хатыны да шулай ди әнә. Бигрәк кызык нәрсә инде бу гадәт дигәнең!

Шулай да, бик кызык очрак бу! Әлеге хатын, Ромейн Хейльгерне генә кара инде... Ничек кенә тыныч күренергә тырышмасын, судта ничаклы нәфрәт чәчте!

Мейхерн әфәнде күзен йомуга аның күз алдына каядыр ашкына торган кыяфәте белән озын буйлы, ак чырайлы ханым образы килеп баса. Мәхәббәттерме ул, нәфрәттерме... Аннары бу кулларның сәер хәрәкәте...

Ул бит тагын кемдәдер шушындый сәер хәрәкәтне искәргән иде. Кемдә соң? Күптән генә түгел югыйсә...

Мейхерн әфәнденең исенә төшүе булды, тыны кысылуы булды: Степнидәге Могсон ханым!

Булмас ла! Булыр микәнни?

Хәзер аның фәкать Ромейн Хейльгерне күрәсе килде.

Әмма аларга очрашырга шактый озак вакыттан соң гына туры килде. Шуна күрә кайда очрашкан буллуларының әһәмияте юк.

—Димәк, сез эшнең нидә икәнен төшендегез,—диде Ромейн.—Йөземне ничек итеп үзгәрттем, дисезме? Бу әлләни кыен эш түгел иде, ә калганы... Мин бит актриса идем, шуны онытмагыз.

—Нәрсәгә кирәк булды соң бу?

—Ник алай иттем, дисезме?—дип сорады хатын, иреннәре белән генә елмаеп.—Мин аны коткарырга тиеш идем. Өзелеп сөя торган һәм чиксез турылыклы хатын биргән мәгълүматка кем ышаныр иде соң? Моны анларга сез үзегез ярдәм иттегез бит миңа. Ләкин мин үзем дә кешеләрне яхшы аңлыйм; нинди дә булса гаеп эшләгән дип, шуны танырга мәҗбүр итсеннәр, нинди дә булса хурлыклы кыланышымны фаш итсеннәр, һәм гаепләнергә тиешле кешегә караганда мин гел әшәкерәк булыйм, гел аңа лаеклы булмыйм, менә шул чакта ул кешене аклаячаклар.

—Ә хатлар?

—Иң өстәге бер хат кына ялган хат иде. Шул хат бөтен эшне хәл итте.

—Ә Макс дигән кеше?

—Андый кешенең булганы да юк.

—Шулай да, бу спектакльдән башка да, гәрчә бик яхшы уйналган булса да, без аны коткара алган булыр идек, дип уйлыйм мин.

—Мин бу эшне куркыныч астына куя алмый идем. Аңлыйсызмы, сез бит аны гаепсез дип уйлый идегез.

—Аңлыйм, Воул ханым. Без уйлый идек, ә сез белә идегез аның гаепсез икәнен.

—Бернәрсә дә аңламагансыз икән сез, хөрмәтле Мейхерн әфәнде. Әйе, мин белә идем! Мин аның... ГАЕПЛЕ икәнен белә идем!..

**Саимә ИБРАҺИМОВА**
*сүз башы һәм тәрҗемәсе.*



*Мәгълүм хакыйкать: Балык Бистәсе төбәгеннән чыккан каләм ияләре соңгы дәвер татар әдәбияты үсешенә сизелерлек йогынты ясадылар. Бу якта туып-ускән шагыйрь, прозаик, драматургларны дистәләп санарга мөмкин. Прозаик, шагыйрь, публицист Рәшит Гариф та шушы як кешесе. Ул 1933 елның 22 мартында Балык Бистәсе районының Чирмешән авылында туган. Казан педагогия институтын тәмамлаганнан соң ул гомеренең төп өлешен журналистикага багышлый. Төрле елларда «Октябрь юлы» (Балык Бистәсе), «Байрак» (Буа) газеталарының баш редакторы, «Социалистик Татарстан» газетасының әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире вазифаларын башкара, шулай ук, партия өлкә комитетында һәм таткиновидео берләшмәсендә җаваплы эшләрдә була. Соңгы елларда Рәшит Гариф актив иҗатчы буларак танылды: бер-бер артлы «Кояш чыгар алдыннан», «Инану», «Көт мине, Гөлчәчәк», «Болытлы көннәр», «Болыннарда дулкын» дип исемләнгән китаплары басылып чыкты. Үз вакытында Татарстан китап нәшриятында «Украин халык әкиятләре», «Болгар халык әкиятләре» китаплары да аның тәрҗемәсендә дөнья күрде.*

*Рәшит Гариф—Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.*

*Бу көннәрдә язучы Рәшит Гарифка 70 яшь тулды. Редакция хезмәткәрләре һәм каләмдәшләре аны юбилее уңаеннан ихлас котлый, иҗат уңышлары, сәламәтлек, озын гомер тели.*

---

## Рәшит Гариф

### Ак манара

Болгар җире... Ак манара...
Ул ничек исән калган?
Асылда бердәнбер шаһит
Канлы чор-гасырлардан.

Йөрәге аша уздырган
Аяусыз яуларны ул.
Гомерен күкләрдән сорап,
Ялварып алгандыр ул.

Узса да кырып-җимереп
Шәһре Болгарны заман,
Манара, керсез догадай,
Ак төсен саклый һаман.

## Сыйпадым кабер ташларын

Шәһре Болгар хәрабәсен
Карап йөрибез икәү...
Ялтыратып тәреләрен
Каршылый безне чиркәү...

Үләксә йоткан козгындай,
Муенын сузган биек.
Тора... сабый йөрәгенә
Кадалган сөңге кебек.

Корганнар чиркәү нигезен,
Кабер ташларын тезеп.
Ташта—ярымай, кемнеңдер
Сытылган күзе кебек...

Чит илләр килә... Карыйлар
Ары да бире килеп.
Сыйпадым кабер ташларын
Шул нигезгә иелеп...

## Тәрәзә пыялам чатнады

Саксызмы кагылдым ялгышып,
Тәрәзә пыялам чатнады.
Ничә кат җилемләп карадым—
Беренчел хәленә кайтмады.

Тырыштым, тырыштым, тырыштым,
Чатнаган шушы эз бетсен дип.
Пыяла икегә бүленде,
Хезмәтем шул булды бары тик.

Әйттең син миңа бер авыр сүз—
Мин калдым җавапсыз, чарасыз.
Инде бит мең матур сүзең дә
Ялгамый йөрәгем ярасын.

## Карлыгачлар

Авыл иңләп инеш ага...
Ярлары кырач кына.
Шул кырачка карлыгачлар
Ел саен оя кора.

Беркемнән дә курыкмыйлар,
Янамыйлар беркемгә.
Оча алар көннәр буе
Зәңгәр күкләр иркендә.

Онытылып карап торам
Мин шушы манзараны.
Бизисе иде кошлардай
Безнең бу замананы.

Уйларымны җөпли сыман
Кошларның дөньялары.
Кәрәзләр кебек тезелгән
Карлыгач оялары.

## Мәңге яшел агач

Болгар илен дошман пыр туздырган,
Габдулла хан янган ялкында...
Хан уллары Галим һәм Алтынбәк
Уй йөрткәннәр кайгы чагында
Яңа кала төзү хакында...

Иске Казан! Халкым тарихында
Син ничәнче икән башкала?
Әгәр берсен килеп җимерсәләр,
Нигез салган халкым башкага,
Үсеп чыккан күпме башкала!

Без беләбез: мәңге яшел агач
Кискән саен һаман калыккан.
Татар да бит үзе янган көлдән
Кабат калка торган халыктан,
Шуңа татар дигән дан тоткан!

## Кыек сүз

Сиңа матур бер сүз әйттем—
Гөлләр уянды...
Күреп гөлләр елмаюын,
Җаным юанды.

Сиңа изге теләк әйттем,
Догама кушып.
Төште шулчак ай яктысы
Учыма очып...

Сиңа ялгыш бер кыек сүз
Әйтеп ташладым.
...Купты давыл, өзеп атты
Чәчәк таҗларын.

Әdəbi miras
Әдәби мирас



## Мәхмүт Хәсәнов

# БИЧУРА ҖИҢГИ

*хикәя*

## I

Юл газабы—гүр газабы... Язгы юл өзелгәндә машинабыз белән ничәмә-ничә тапкырлар батып, ватылып, баштанаяк чыланып, кыскасы, мең төрле бәлаләр кичереп, район үзәгенә барып кергәндә, төн урталары якынлашып килә иде инде. Беренче каралтылар башлану белән машинаны туктатып, шофер белән тизрәк исәп-хисапны өзеп, төшеп калу ягын карадым. «Газик» тирә-якка изрәгән пычрак чәчрәтеп китеп тә барды...

Күзенә төртсәң күренмәслек караңгы төндә, гомеремдә беренче тапкыр аяк баскан, шунын өстенә бер генә таныш-белешең дә булмаган район үзәгенә килеп төшеп, юл чатында басып калу хәлләрен, бары тик үз башыннан кичергән кешеләр генә аңлый алырлар. Җитмәсә, тагын кулларым туңып-күшегеп, бернәрсә дә сизмәс булганнар.

Бу районга Авыл хуҗалыгы министрлыгыннан язгы чәчү чорына командировкага килүем иде.

Райком кешеләрен эзләп табып, аларны уятып йөрергә соң иде инде. Шунлыктан мин: «Бер төнгә куныл чыгарга кем дә кертер әле. Иртәгә урын табып урнаштырырлар»,—дип уйладым. Бер кичкә—кер мичкә, диләр бит. Хәзер миңа бүгенгесе кадерле иде.

Шундый уйлар белән чемоданымны култык астыма кыстырдым да, каршыда—юл буенда гына торган йортка таба юнәлдем. Аның башкаларга караганда олырак та, каралтыларының да һәйбәтрәк икәнлеген төн булса да чамалап алган идем инде.

Зур «урыс» капка бикле иде. Мин тимер келәне җиңелчә генә шалтыратып шакый башладым. Күп тә үтмәс, хуҗалар уяныр да, тәрәзәдә ялт итеп ут кабынып, якты сукмаклар булып урамга аркылы ятырлар дип

көткән идем. Тик мин уйлаганча булмады. Бер шакыдым, ике шакыдым; соныннан инде түземлегем бетеп, аякны да «ходка» җибәрдем... «Әллә инде дөмектеләрме?»—дип сукранып та куйдым.

Шул вакыт кемнеңдер искәрмәстән генә янымда: «Эһем-эһем-м!»—дип тамак кыруына сискәнеп киттем. Карасам, күләгә кебек кенә булып, койма буенда бер хатын-кыз басып тора иде. Ул инде мине байтак вакыт күзәтеп торган булса кирәк. Аның шулай җир астыннан яки койма ярыгыннан гына чыккандай каршымда кукыраеп торуы, мина бераз сәер булып тоелды.

—Берәр юлаучы, таныш-белеш дип әйтимме?—дип сүз башлады ул, мөлаем гена тавыш белән.

Мин анар башлаган сүзен әйтеп бетерергә дә ирек бирмәдем. Үземнең таныш-белешләр түгеллегемне, шәһәрдән эш белән килүемне әйттем һәм бер генә кич кунып чыгарга мөмкин булмасмы икән, дип гозеремне белдердем.

—Урындагы кеше буласын икән алайса,—диде ул, үзенчә нәтиҗә ясап.—Ник мөмкин булмасын, ди. Бик мөмкин! Кеше шулай кешегә сыена инде ул. Әйдә, кер! Менә моннан... Башынны иебрәк кер... бәрелмәсен.

Каршымда койманың өч кенә тактасы ачылып китте. Бу хәлдән соң күңелемдә шиккә охшаган әллә нәрсә уянгандай булды. Тик ике уйлап торырга вакыт юк; тизрәк жылыга кереп, чыланган өс-башны алыштырып берәр чынаяк чәй эчү теләге ул минутта минем өчен бар нәрсәдән дә кыйммәтрәк иде.

Без таш җәйгән киң ишек алдыннан узып өйалдына, аннан инде япъякты бер жыйнак кына бүлмәгә кердек.

Ишектән кергәч тә, уң якта, зур гына мич; анарга кушып кечкенә генә плитәле галанка салынган. Түрдә өстәл. Сул якта эре бизәкле чаршау эленгән—ятак урыны булса кирәк. Пөхтәлек, чисталык күзгә бәрелеп тора. Бу—карчыкның үз бүлмәсе икән.

Яктыга кергәч күрдем: каршымда кырык-кырык ике яшьләрдәге хатын басып тора. Тик үз-үзен тотышын, минем белән керешли үк өйалдыннан жиз комганын эләктереп керүен, өстенә «әби патша» заманындагы фасон белән тегелгән бишмәт кигәнен, шуның өстенә аягына биек куныччлы кәвеш киеп, штан балагын чыгарып йөрүен күргәч: «Әллә бераз өлкәнрәк тә микән?»,—дип уйлап куйдым мин.

Ул да мине тагын бер тапкыр күздән үткәрде. Аннары, гадәттән тыш нәрсә күргән кебек өтәләнеп, кирәгеннән артык хафаланып, минем турыда кайгырта башлады.

—Һай-й, Алла!.. Балакай! Ыспай туңмас калтырар, дигәндәй кем инде мондый юлга шулай юка киеп чыга. Һай-й, сез яшьләрне!

Ул шунда ук юешләнеп авырайган киемнәремне салдырып алып, җәһәт кенә мич буена элеп тә куйды. Аягымнан ботинкаларымны салырга да өлгермәдем, күптән хәзерләп куелган диярсең, каяндыр жылы киез каталар да чыгарып бирде. Аннары:

—Карының да ачкандыр инде. Кая, бистовканы гына ягып, берәр нәрсә дә хәзерләп бирим әле үзенә,—диде, кечкенә пич астына ут төртеп. («Бистовка» дип ул, шул кечкенә мичен әйткән икән.)

Учак астында дөрләп ут уйный башлагач, плитә өстенә чәйнек белән таба да китереп куелгач, өй эче тагын да җыйнакланып киткәндәй булды. Юеш киемнәрдән арынып, аякка киез-катаны да элеп алгач, мина да җан керде. Тел ачылды. Аллан гафу үтенгән булып, фатир хуҗасының исеме белән дә кызыксынып куйдым.

—Минкамал атлымын. Минкамал жинги дип йөртәләр.—Аннары елмаеп, оялгандай итеп, алга таба чөеп бәйләгән яулыгының почмагы белән генә авыз тирәләрен каплап, өстәп куйды:—Халыкта Бичура жинги дип тә йөрткәлиләр.

«Бичура жинги!»—баштарак мин бу сүзләргә әллә ни дикъкать итмәдем. Авыл жирендә һәркемнен диярлек үзенә күрә кушаматы була. Кушаматларның заманында бик тапкыр яңгырап та, соңыннан, буыннан-буынга күчә башлагач көчсезләнеп, әйтелә торган кешесенә бөтенләй диярлек ябышмый торганнары да еш кына очрый. Кыскасы, аның бу сүзләре сынар колагыма керде, сынар колагымнан чыгып та китте.

Миңкамал жиңги минем шәһәрдәге тормышым, гаиләм, бала-чагаларым турында да сораштырып куйды. Үзен кызыксындырган сорауларга тулы җавап алгач, янадан минем турыда кайгырта башлады.

—Кара әле, кем, улым... Әллә сөт белән мәтрүшкә кайнатып эчертеп карыйм микән үзенә? Салкын тиеп куймасын берүк!..

—Зинһар, шулкадәр борчылмагызчы...

Бераздан минем алдыма майда гына кыздырган йомырка тәбәсе китереп куелды. Һәйбәт итеп пешерелгән такта чәйнең татлы хуш исе дә борыннарны кытыклый башлады. Шул вакыт Миңкамал жиңги елмаеп болай диде:

—Әгәр дә теләгең булса, мәтрүшкәдән дә болайрак нәмәстәм бар иде барын. Тик ошатмассың гына дип куркам. Шәһәр кешеләре бит алар бераз нәзберегрәк булалар. Килде-китте нәрсәгә бер дә исләре китми. Шулай да, кая, алып кереп карыйм әле...

Миңкамал жиңги минем: «Зинһар борчылмагызчы! Кирәкмәс иде...» диюемне ишетергә дә теләмәде. Өялдына чыгып, күз ачып йомганчы, озын муенлы чүлмәк алып кереп, өстәлгә китереп тә куйды.

—Биво шикелле нәрсә инде шунда...

«Биво» дигәне шул пиво, ягъни сыра сыманрак нәрсәдер инде, дип уйлап алдым. Бик кыстагач, салынган стаканны кулыма алдым. Гәрәбә төсендәге бу эчемлекнең хуш исе шунда ук борыныма килеп бәрелде. Ни булса, шул булыр дидем, дә җибәрдем. Чыннан да, бик шәп нәмәстә булып чыкты Миңкамал жиңгинең «бивосы». Берничә минутта маңгаемнан бөртек-бөртек булып тирләр бәреп чыкты.

Миңкамал жиңги исә бик канәгать кыяфәт белән каршымда утыра иде.

—Шул министрдан килгән кеше эчә торган гына нәмәстә инде ул!— дип, үзе рәхәтләнеп кеткелдәп көлә.

Шулвакыт мин беренче тапкыр Миңкамал жиңгинең йөзенә тулы караш ташладым. Һәм мина төбәлеп карап торган күзләрен күреп хайран калдым. Үз гомеремдә мина бик күп төрле күзләр күрергә туры килгәләде. Әмма андый, мәче күзенә охшашлы яшькелт төстәге, карчыганыкына охшаш үткер, зәһәр күзләрне моңарчы бер генә кешедә дә, бер генә тапкыр да күргәнем юк иде. Бу күзләр гади генә күзләр түгел иде, алар кешенә үтәдән-үтә күрәләрдер кебек тоелды мина. Күңел өшеткеч дәрәҗәдә салкын, күңел кайтаргыч дәрәҗәдә зәһәр иде бу күзләр. Миңкамал жиңги үзе чандыр гәүдәле. Тар йөзле. Янак сөякләре чыгыбрак тора. Юка, кысынкы иреннәренә мәетнеке төсле булып, күгелҗемлек йөгергән. Борыны шактый зур, туры, шулай да очы бераз өскә төртеп тора. Ияге исә очлы, чак кына алга чыккан. Алдан әйткәнемчә, шыксыз күзләрен исәпкә алмаганда, йөзе шактый мөлаем иде аның.

Ашап-эчкәч Миңкамал жиңги мине түр якка алып чыкты. Ут кабызды. Бүлмәнең монысы тегесенә караганда да пөхтәрәк итеп җыештырылган. Идәннәре һәйбәтләп сарыга буялган; тәрәзә төпләрендә гөлләр үсеп утыра. Һәръяктан хуҗабикәнең чисталыгы күзгә ташланып тора.

—Менә сиңа фатир,—диде ул.—Менә шушы куйкада ятарсың... Әгәр дә ошатсаң, фатирга үземдә генә туктарсың. Сиңа монда беркем дә комачауламас. Бала-чагаларыбыз юк. Язу-сызу белән шөгыльләнсәң, менә өстәл... Бары тик икәү генә торабыз. Кызым белән. Хәтирә исемле. Күрше авылда кибетче булып эшли. Кайткан көнне кайта; кайтмаса, эше күп булганда, икешәр-өчәр көн дә кайтмый. Кияүгә дә чыккан иде дә... әллә ничек кенә шунда, тормышлары көйләнеп китә алмады. Кызым турында әйтәм әле, белеме дә бар, урысчаны да су урынына эчә инде менә. Кияү тиешле кешебез дә шушы авылныкы иде. Мортаза атлы...

Миңкамал жиңги шулай сөйләнә-сөйләнә урын җәйде; ак пәрдә белән капланган шүрлектән сырган мамык юрган өстерәп төшерде. Эше беткәч:

—Утны үзең сүндерерсең инде,—дип, тыныч йокы теләп, балакларын җилфердәтә-җилфердәтә үз бүлмәсенә чыгып та китте. Юлда шактый гына ватылырга туры килсә дә тиз генә йокыга китә алмыйча яттым. Әллә нинди уйлар борчый башлады. Ирексездән Миңкамал жиңгинең: «Халыкта Бичура жиңги дип йөрткәлиләр»,—дигән сүзләре исемә төште. Барыннан да бигрәк

мине аның күзләре гаҗәпләндерде. Әгәр дә мәгәр менә шушы караңгы бүлмәдә күзенне ачып җибәргәндә, шул зәһәр күзләрнең өстенә иелеп торуларын күрсәң, йөрәгең ярылмаса да, шулай да берничә минутка өнсез булып калыр идең дип уйлап алдым мин.

Шулай да юлда ватылу, шуның өстенә Миңкамал җиңгинең «бивонсы үзенекен иткән, изрәп йокыга киткәнмен.

II

Икенче көнне иртән иртүк торып, табадан гына төшкән коймак белән тәмләп чәй эчкәч, райкомга юнәлдем. Анда, гадәттәгечә иң элек, минем командировкага килүемнең максаты, бурычларым белән кызыксындылар. Аннары мине берәр һәйбәтрәк квартирага урнаштыру турында кайгырта башладылар. Мин инде үземнең квартира табып урнашуым турында әйттем.

—Ничек?.. Әллә берәр танышыгыз, туган тиешле кешегез бар идеме?—дип сораштырдылар.

Мин үземнең ничек итеп төн уртасында килеп төшүем, ничегрәк итеп квартирага урнашуым турында сөйләп бирдем. Квартирамның чиста һәм иркен булуын да әйттем.

—Миңкамал җиңгиләрдә,—дип җавап кайтардым мин.

Шулчак барысы да минем якка борылдылар.

—Бичура җиңгиләрдә түгелдер ич?..—диде кайсыдыр, коточкыч хәбәр ишеткәндәй.—Аның да исеме Миңкамал бугай бит.

Минем нәкъ шул Бичура җиңгидә туктаганлыгымны белгәч, берничә кеше берьюлы үзләренең ризасызлыгын белдерделәр.

—Юк-юк, юк!.. Кая ул! Сезнең өчен ипле квартир түгел ул. Сезгә анда туктау ярамас. Белмәссең аны!..

Кемнеңдер: «Фатирның да асылын тапкан икән!»—дигән сүзләре дә колагыма чагылып китте.

Мин, фатир мәсьәләсе егерменче хәсрәт ул; мина барыбер күбрәк вакытымны район колхозларында үткәрергә туры киләчәк дип, хәзергә шул туктаган җиремдә генә калып торырга булдым. Турысын әйтергә кирәк, мине барыннан да бигрәк ни өчен Миңкамал җиңгине халыкта «Бичура» дип йөртүләре белән кызыксыну тапкан фатиремда калуга сәбәп булды. Шул көннән башлап мин мөмкин булган җирдән Миңкамал җиңги турында мәгълүматлар җыя башладым. Мәгълүматлар җыя башладым дигәч тә атап, сорашып йөргән икән дип уйлый күрмәгез. Юк!.. Бары тик аның турында сүз чыккан җирдә колагымны салыбрак тыңлаучан булып киттем.

Миңкамал җиңгинең биографиясенә дә әллә ни тирән керә алмадым мин. Үзеннән сорашырга ничектер кыенсындым. Мина бары тик шул каләресе генә мәгълүм булды: кыз чагында ул ике балалы хатынын аертып, Абдуллаҗан исемле ир урталарындагы бер кешегә кияүгә чыккан. Үткен, зәһәр Миңкамал белән кушылгач йомшак табигатьле Абдуллаҗан абзыебыз ничектер каушабрак калыпмы, тормыш алып бару сәләтен югалткан кебегрәк була. «Хатынның теле узса, иренең кулы уза»,—ди мәкаль. Тик Абдуллаҗан абзый белән киресенчәрәк була. Тормыш алып баруны, икенче төрле итеп әйткәндә, дилбегәне Миңкамал үз кулына ала. Кеше таба алмый торган җирдән кирәген таба, теләгәнен ала. Йөге-йөге белән утынын дисеңме, печәнен дисеңме, ташып кына тора. Күп тә үтми, Абдуллаҗан абзыйга да «Абдуллаҗан җиңги» дигән шәфкатьсез кушамат тагыла. Чөнки тормыш көтүне хатыны үз кулына алганнан бирле анар мичкә ягып, ашарга хәзерләү, идән юу кебек эшләр генә калган була. Әгәр дә инде Миңкамал ат белән утын яки печән төяп кайтканда Абдуллаҗан абзый капканы ачып тормаса, эш харап. Аннары: «Сина әйтәм, каты телең белән рәнҗетмә инде мине»,—дип ялынып-ялварырга гына кала.

Хәтирә исемле бердәнбер балалары кул арасына керерлек булып килгәндә, Абдуллаҗан абзый япь-яшь хатынын тол калдырып, бу фани дөнья белән саубуллаша. Шул көннән башлап Минҗамал ялгыз кала. Яшьли тол

калуның ачысын-төчесен бары тик башыннан кичергән хатын-кызлар гына белә торгандыр.

Ул елларда инде Миңкамалга да «Бичура» дигән кушамат тагылып, ил теленә кереп, даны чыгып өлгергән була. Бәлки шуңа күрәдер, тормыш көтәргә гаять дәрәҗәдә сәләтле булуына да карамастан, кабаттан кияүгә чыкмый ул. Ни әйтсәң дә, усал дигән яман аты чыккан була шул. Үзенә йортка кертергә ир-ат эзләве турында Миңкамал жиңги карчык-корчыкларга да сүз катып карый. Тик өйләнергә атлыгып торучылар табылмый. Карчыклар исә: «Телеңнән куркалар»,—дип хәбәр ташыйлар. Ул да җавапсыз калмый: «Йөзе каранын гына теле кыска була анын»,—ди.

Тел дигәннән, әле дә халыкта мондый бер хәл турында мәзәк итеп сөйлиләр. Шул ук авылда бик ачы, яман телле, авызыннан төшкәнне эт ашамаслык сүзләр белән әйтешүче Факиһә исемле бер хатын булган. Шул Факиһә капка төбенә чыгып утыра икән дә, узган бер кешегә җыен кирәкмәгән сүзләр кычкырып, сүгенеп, тегесе күздән югалганчы эт урынына өреп кала икән. Берәр кыз-кыркын узса: «Ә-ә, чабата жанаш кызы килә икән әле. Йә, ничек?.. Галим ташладымы үзеңне? Башка белән йөри башлады дисең алай-са... Шул, шул! Ичмаса, кызның кызылын тапты. Ә син калдың... Син чабата жанаш кызы гына кирәк иде ди анар»—дип, бичара кыз берәр тыкрыкка кереп югалганчы талап озата. Шулчак, әле генә узган кызны ташлаган егет килеп чыкса-нитсә: «Ә-ә, Сасы күзән Галиме килә икән әле. И-и, нөрсез нәрсә. Борын асты кипмәс борын кызлар сайлаган була тагын. Ишкәнсең инде... Күгәрченне очырып, җирдә казынып йөргән тавыкка ябышкансын»,—дип кала. Көннәрнең берендә Факиһә ялгышлык белән (ялгышлык белән дип, кабатлап әйтәм) узып баручы Миңкамалга да тел тидерә. Тегесе туктап та тормый, Факиһәгә бары тик бер генә сүз әйтә. Әшәке телле хатын, кабыргасына кинәт сәнәк белән китереп кадаган чучка кебек чыйнап, сикереп тора да капкасын мангае белән генә бәреп ачып, өенә кереп тә китә... Шул көнне Факиһә чәчләрен йолкып, башларын стенага бәрә-бәрә елап, зәңкиләнеп беткән дип сөйлиләр. Тик шунысы кызык, Миңкамалның Факиһәгә нинди сүз әйткәнлеге, хәзергәчә сер булып калган. Эт ырлашып белешә, ди мәкаль. Шул көннән башлап, Факиһә урамның икенче башында ук Миңкамалны күрә калса, ут капкандай урыныннан кубып, өенә кереп яшеренә торган була.

Нәкъ шул елларда Миңкамал жиңгинең орынып торган күршесе—чатан Галинең хатыны үлеп китә. Эчми-тартмый, бары тик яхшы яктан гына телгә алына торган абзый зур алма бакчасында тезелешеп торган утызлап баш умарталары белән япа-ялгыз утыра да кала. Менә шул чатан Галине кулына төшерүне максат итеп куя да инде Миңкамал жиңги. Ниләр генә эшләми ул! Татлы теллеләнү турында әйтеп тә торасы юк. Билгеле булганча, татлы тел еланны да өеннән чыгарган, ди. Хәтта үзенең атаклы «биво»сын да ходка җибәреп карый. Тик шунысы гажәп, анын тырышулары нәтиҗәсез була. Бичура жиңги дә эшлим дигәнен эшләмичә калыр икән!

Яхшылык белән күршесен үзенә карата алмагач, Миңкамал жиңги чатан Галигә «сугыш игълан итә». Ике күрше этле-мәчеле яши башлыйлар. Миңкамал жиңги кебек зәһәр хатынга Галинең каршы тора алмаячагы көн кебек ачык була. Һәм ул шулай була да. Миңкамал жиңги бик тиз арада анын кеше күзенә күренерлеген дә калдырмый. Галинең ирлек намусына тап төшерүдән дә тартынмый ул. Явызлык эшлим дигәндә, Миңкамал жиңги бер дә ике уйлап тормый. Теше үтәрлек жирне чамалый ул; аннары елан кебек нәкъ шул урынны чага. Кеше исә сыны каткандай була, өнсез кала.

Галине дә нәкъ шулай итә ул. Халык арасында яшәрлеген калдырмау белән генә чикләнми, анын да алгандай итә. Үзенең сабырлыгы белән башкаларга үрнәк булырлык кеше, алыштырып куйгандай була. Эчүгә үк сабыша бит, бичара! Үзе исә Миңкамалга карата нинди дә булса начарлык эшләү турында башына да китерә алмый. Анын үч алуы, бераз эчеп кайткач, күршесе өе ягына карап каргаудан узмый:

—Мөртәт, Бичура!.. Кара жылан! Телең чергере!.. Иренне кабергә куып керттен дә, хәзер инде башкаларга ябышасынмы... Тәмуг кисәве! Ходай

кушып, бер көл булып күккә очкан көннәренне күрергә язганмы икән... Һәй-й, теленә тилчә төшкән нәрсә...

Минкамал аның шулай җикеренүен колагына да элми. «Карга каргаганга карап, чәүкәнең кай җире нишләмәгән»,—ди ул. Яки: «Карагыз әле, кара! Анда авызын күтәреп нинди эт өреп тора?»—дип, бот чабып көлгәләп тә куйгалый икән.

Минкамал җиңги сүз көрәштерүне озакка сузмыйча, бу шау-шудан файдаланып калырга булган. Иң элек ул кечкенә искергән йортын зур гына суммага страховать иткән. Аннары ике арадагы киртә аша күршесе белән кычкырышып, аны котырткан. Шуннан соң аның эчеп кайтачагын бик яхшы белә инде ул. Ә эчеп кайткач, Гали чатанлап яңадан киртә буена килә икән дә, гадәттәгечә әйтә торган сүзләрен кабатлый икән:

—Зобаный!.. Көл булып күккә очканынны бер күрер көн булырмы икән... Хәер бирер идем. Өч баш... Биш баш умартамны бирер идем...

Минкамалга шул гына кирәк иде дә. Ул шунда ук авыл советына барып: «Чатан Галиегезне тыегыз! Ут төртеп яндырам дип куркыта. Ут салдырырга биш баш умартам җитәр, ди. Әнә, шаһитләр дә бар. Ул чатан шайтанга ышанма. Белмәссең аны. Юаштан юан чыга, ди бит. Тәки харап итеп куяр...»,—дип барып «җәвет» итеп тә куя. Бер бара, ике бара, өч бара. Галине чакыртып алып кисәтеп тә куялар.

Көннәрнең берендә, җиде төн уртасында, халыкны шомлы чаң авазы уята. Тәмле йокыларыннан уянышып, шаулашып урамга чыкканда инде Минкамал белән чатан Гали өе шаулап торган ут эчендә була...

Бу янгында Минкамал җиңги бер нәрсә дә югалтмый, кисәү агачына кадәр чыгарып өлгергән була. Аның каравы, чатан Гали—урыныннан ничек сикереп торган булса, шул көе кала. Протезына кадәр яна мескеннең. Шуның өстенә әле ут төртүдә гаепләп, алты ай чамасы судтан-судка өстерәп тә йөртәләр үзен.

Минкамал җиңги шул ук көзне страховой акчага шакмак кебек итеп алты почмаклы йорт салдырып керә. Сандык кебек итеп каралтылар рәтли. Тик чатан Гали генә авыр ел кичерә. Көч-хәл белән төрмәдән котылып кала ул. Страховой акча бирелми анар. Аннары, бу ыгы-зыгыдан бераз арынгач, әтисе-бабасыннан калган туган нигезен, авылда бер җимеш бакчасын ташлап, авылның икенче башына ук күчеп йорт урыны ала.

—Бу Бичура зобаный белән каберен якын булмасын,—ди ул. Шуннан бирле ул Минкамалның үзен күрү түгел, аның исемен генә ишеткәндә дә тетрәп китә торган булып кала. Минкамал анар ниндидер коточкыч бер тереклек иясе, албасты, дөньяның җыен бәхетсезлекләренең чыганагыдыр кебек булып күренә башлый. Шулкадәр җанына төшкән була ул аның. Гали абзыйның хәзер дә әле:

—Әгәр җәннәт дигән нәрсәгә Бичура керә икән, җәннәте-ние дә кирәкми,—дигән сүзләрен, мина үз колагым белән ишетергә туры килде.

## III

«Тел астында теле бар, җир астында юлы бар ул Бичураның»,—дип әйтәләр икән аның турында. Аның чыннан да шулай булуына мин тиз арада төшендем.

Аларда тора башлавыма атна чамасы гына узган иде әле. Иртәнге чәй вакытында гадәттәгечә минем каршыма килеп утырып, Минкамал җиңги тормыш-көнкүреш турында сүз кузгатты, ир-атсыз йорт-җирне тотуның никадәр авыр булуы турында зарланып алырга да онытмады. Аннары үзенең карчыганыкы кебек зәһәр күзләрен мина төбәп, болай дип куйды:

—Урманда кисеп куелган агачларым бар иде. Әллә ни күп тә түгел үзе. Трактор бер йөккә сыйдыра алыр иде. Менә шул агачларны ничегрәк итеп алып төшәргә икән дип тора идем әле.

Тик шунысы кызык. Ул моны ярдәм сораган кебек итеп әйтмәде. Андый очсызлы ярдәмнәргә генә Минкамал җиңгинең мохтаж түгеллеген

мин белә идем инде. Шулай ук гади генә киңәш итүгә дә охшамаган иде аның бу сүзләре.

Мин үз фикеремне аңардан яшермәдем. Язгы чәчү чоры булу сәбәпле, хәзер трактор түгел, колхоздан ат алуның гына да никадәр житди мәсьәлә икәнлеген ачыктан-ачык әйтеп бирдем. Тик минем гажәпләнүемә каршы шул ук кичне «С—80» маркалы зур трактор үзенең тимер чанасына тау кадәрле итеп төзү материалы төяп Миңкамал жингинең капка төбенә килеп туктамасмы! Үзе дә шунда иде ул. Ыштан балакларын жилфердәтеп, гаять зур эш башкарган кыяфәт белән жил-жил килеп йөри бирә. Йөкчеләр дә дәүләт күләмендәге әһәмиятле эш башкаргандай башларын да калкытмыйча тырыша. Бүрәнәләрне ишек алдына кертеп бушатып өеп куйгач, чыгып китмәкчеләр иде дә, Миңкамал жинги аларны шып туктатты: гаять зур сер әйтергә теләгән кебек бармагы белән генә чакырып алып, кече бүлмәсенә алып кереп тә китте. Тракторчы егетләрне үзенең «биво»сыннан авыз иттерде булса кирәк.

Аның шулай иркенләп сулыш алырга да вакыт булмаган кызу эш чорында трактор ала алуы, аннан да бигрәк шундый һәйбәт агачлар кайтарып ташлавы, мине тәмам хәйранга калдырды.

Ничегрәк итеп аның аласы әйберен алмыйча, эшлисе эшен эшләмичә калмавын мин бары тик соңыннан гына төшенә башладым. Ул болай итә икән: иң элек йомышы төшәсе кеше турында кирәкле мәгълүмат жыя. (Билгеле, кешене мактап, күккә чөяр өчен жыйналмый ул мәгълүматлар.). Өстәп тагын шуны да әйтергә кирәк: йомышы төшкән кешенең үзе турында гына түгел, аның атасы, бабасы, әгәр дә кирәксә, бабасының бабасы турында да кирәк сүзләр таба икән. Бары тик шуннан соң гына ул үзенең «корбаны» янына бара. Баргач та әле бервакытта да кинәт кабынып китеп, туарылып ташламый. Сүзен ипләп кенә, жайлап кына башлый. Туйганчы тәмле телләнә, каршында утырган кешене тәмам балавыз итә икән. Үзенең: «Ал һәм тәләкәй, Бичура жингән бәләкәй, син зур...»,—дигән яраткан сүзен кыстырып куярга да онытмый.

Бу юлы төзү агачы кирәк булгач та ул иң элек урманга китә. Урман каравылчысы турында гына түгел, леспромхоз хужалары турында да Миңкамал жинги кирәгеннән артык мәгълүматлар жыеп өлгергән була. Мәсәлән, ул урман каравылчыларының кешеләргә кай вакытта һәм күпме агач урлап сатулары турында бисмилласын ятлагандай белә. Аның белән генә дә чикләнми әле, сүз арасында берәр агач сатып алган кешенең «саксызрак кылануын» әрләп куярга да онытмый. Ә урманнан аңар бик һәйбәт киңәш биреп жибәрәләр. Янәсе, Миңкамал жинги, тиктомалга урманнан агач төяп жибәреп булмый. Бигрәк тә төзү агачын. Шунар күрә райплан бүлегеннән биш-алты гына бүрәнәгә дип язылган, кош теле кадәрле генә кәгазь кирәк, имеш. Шул кәгазь кисәге булса, эш жайланачак икән.

Миңкамал жинги райплан бүлеге мөдире янына китә. Кеше фәрештә була алмас, диләр бит. Һәркемнең нинди дә булса йомшак ягы була шул инде. Бәлки үзенең шул кайбер кимчелекләрен сизенгәнгәдер, Миңкамал жингине күрү белән райплан бүлеге мөдиренең йөрәге «жу-у» итеп китә. «Бу карчыга нәрсәгә йөри тагын?»—дип уйлап ала ул. «Бичура» кадәр Бичураның тикмәгә генә йөрмәгәнлеге көн кебек ачык ич.

Бүлек мөдире, элек-электән ул нинди генә йомыш белән кермәсен, «Бичура»ны кире борырга була. Монарчы әле бәлки аны беркемнең дә болай кире какканы булмагандыр; ә менә мин борырмын, дип уйлый иде ул. Борырмын булгач, борырмын!.. Белсен әле кемнең кемлеген...

Райплан бүлеге мөдире шундый уйлар белән мавыгып утырган арада, Миңкамал жинги аның каршына ук килеп, ипләп кенә килеп кунаклап, сандугач булып кына сайрамый инде. Мөдир эре кыяфәт белән аны бүлә:

—Кара әле, Миңкамал жинги, сүзеңне кыскарак тотсаң иде. Минем бит ләкәтә сатып утырырга вакытым юк.

Миңкамал жинги андый юк-барга үпкәли «белми». Ул бернәрсә дә булмаган кыяфәт белән болай ди:

—Ни, кем, Фәсхи туган, озын сүзнең кыскасы шул. Миңа мунчамны сипләтергә биш-алты гына агач кирәк иде...

Фәсхи анын авызы ябылганны да көтеп тормый, Минкамал жингинең үтенечен кире кага:

—Һәй-й, Минкамал жинги! Тапкансың вакытын да... Нинди агач ди ул. Хәзерге вакытта аерым кешеләргә, аерым хужалыкларга диик инде, төзү материалы бирү аеруча четерекләнде. Әй-йе!.. Югарыдан шундый указание бар. Башка йомышың белән кергән булсаң, «эх-х» тә итмәгән булыр идем. Булмый, Минкамал жинги. Минем кулдан килмәслек эш бу. Булмый!

Минкамал жинги кашын да жыермый. Урыныннан торып, бер дә исе китмәгән кыяфәт белән болай ди:

—Ярар, ярар, кем, Фәсхи туган! Ярар! Юкка суд юк, ди. Синең кадерле вакытынны алып, борчып йөрүем өчен ачулана гына күрмә инде. Ялгышлык белән генә синең янга кергәнмен мин. Һай-й, бар да шул карангылык, томаналык бәласе инде, кем, Фәсхи туган. Бу йомыш белән башка жиргә керергә кирәктер дип мин аны башта ук уйлаган идем дә бит. Һай-й, бу башкайларымны!.. Кая алайса, чыгып, Әсмабикәдән белешеп керим әле. Ул ничегрәк итеп алды икән...

«Әсмабикә» сүзен ишеткәч Фәсхиебез яшен суккандай була. «Чукынып кына кит инде!—дип уйлап ала ул.—Кара инде, ә... Хәерсезнең теле тел генә булса бер хәер иде. Пычаксыз суячак бит бу, пычаксыз суячак!.. Авызын тутырып «Әсмабикә» дип торуын күр әле син аның, ә! Эх, шайтан алгыры! Әллә, хәерсез, чыннан да берәр нәрсә сизендеме икән? Сизенгәндер, сизенмиме соң?! Аннары эшләр харап... Бу жылы урыннан гына түгел, кайбер зуррак «нәрсәннән»дә колак кагып куюың бар. Йөрерсең аннары авызынны күтәреп... «Әсмабикә» ди бит. Соң бит ул үзенең тол хатын Әсмабикә белән якын мөгамәләдә булуын беркем дә белми, белү түгел, хәтта сизенмиләр дә дип уйлап йөри иде. Эх, шайтан гына алсын инде!..»

Ишек янына барып житкән Минкамал жингине тизрәк кире бора ул.

—Кара әле, Минкамал жинги! Ни... Ни дип торам. Эш кәгазь язып бирүдә генә түгел бит әле. Аны язып бирергә дә була. Авыр эш түгел ул. Леспромхозда нәрсә диярләр бит. Коры кәгазьне тотып калуың да бар...

Минкамал жинги кире борыла. Анын бары тик зәһәр, яшькелт күзләре генә эшен башкарганлыгын, канәгатьлеген белдереп чаткыланып торалар.

—Һәй-й, кем, Фәсхи туган! Анысына гына калгач, Ходай Тәгалә үзе ярдәм итәр иде әле. Әй-йе!..

Кирәкле кәгазьне кулга төшереп, урманда күпме кирәк шулкадәрле агач хәзерләткәч, аны алып кайту эше генә кала. Минем белән сөйләшкәннән соң ул РТСка барып, туп-туры өлкән механик янына керә. Һәйбәтләп, олы кешеләргә генә хас булганча озаклап исәнлек-саулык сорашканнан соң, Минкамал жинги читләтеп кенә үзенең пәрәвезен кора башлый.

—И-и, кем, Әхмәтжан энем, исән-сау гына яшисеңме! Һай, Алла! Япь-яшь башың белән шушындый зур урында утырам диген инде, ә. Менә бит ул, акыл дигән нәрсә кешене нишләтә! Әтиен дә бик башлы кеше иде, мәрхүм. Акыл иясе иде инде менә. Авыр туфраклары жинел булсын, берүк. «Минкамал килен»,—дип өзелеп тора иде инде. Килен дигәннән, хатынын Газизә киленне әйтәм әле. Һаман да шундый ук, кыз вакытындагы кебек үк сылу, яшь. Суга төшкән жирләрендә артыннан сокланып карап калам үзенә. Й-ә, бәхетен дә бар икән, кем, Әхмәтжан энем! Тормышыгызга карап сокланып туймаслык инде менә.

Артыграк «ләкәтә» сатуын Минкамал жинги үзе дә сизенә башлаган иде инде. Тик нишлисең соң! Шундыйрак, тел-теш тидерә алмаслык кешесенәрәк туры килде шул. Бу дөньяда барлык кешеләр дә шушы Әхмәтжан кебек булсалар, нишләрсең, мин сина әйтим! Әле дә ярый, Әхмәтжанга карата да анын гайбәт капчыгында нәрсәдер бар төсле. Нәрсә соң?.. Нәрсәме? Шушы көннәрдә генә Әхмәтжаннар өендә жәнжалга охшаган бик зур шаушу булып узганлыгы турында ишеткән иде ул. Гауга Әхмәтнен бердәнбер нәни улын, кинәшеп-нитеп тормыйча сөннәткә утыртуларыннан килеп чыккан икән. Әхмәтжан бабасын: «Малайны чирләтүең генә житмәгән, минем исемемә дә тап төшерергә телисенме?»—дип сүккән ди.

РТС баш механигының эшеннән туктап, иркенләп сөйләшеп утыра алачагына өметен җуйды Миңкамал җиңги. Әледән-әле телефон шалтырап торды. Ул да булмады, ниндидер кәгазьләр алып ашык-пошык кына сызгалый да башлады. Бәлки шуңа күрәдер, Миңкамал җиңги сүзен кыскарта төшеп үзенең урмандагы агачларына күчерде.

—Кем, кем дип торам, Әхмәтҗан энем. Мунчамны сипләтеп алырмын дип, агач яздырып, шуны кистереп куйган идем,—диде ул.—Җитмәсә, тагын агачларым бигрәк инде юл өстендә калганнар иде. Үткәне-барганы да салып киткәли башлар дип борчылып торам. Менә шул агачларны алып кайтырга ярдәм итмәссенме икән, дип килгән идем.

Әхмәтҗан аның нинди йомыш белән килгәнлеген белгәч, кесәсеннән әйбер эзләгәндәй, урындыгында селкенгәләп куйды. Аның бу хәрәкәтләре Миңкамал җиңгинең дә зәһәр күзләреннән читтә кала алмады, әлбәттә. «Кире кагарга тели, ахрысы...»,—дип уйлады ул. Һәм сүзен бераз кискенрәк чабулатып булса да икенчегә борып җибәрде:

—Син инде, кем, Әхмәтҗан энем, шушындый, арка кашырлык вакыт таба алмаслык кызу эш чорында килеп борчып йөри дип, ачулана күрмә. Һәркемнең үз тугызы—тугыз, дигәндәй, һәркайсыбызның да үзенә күрә хәсрәте, үзенә күрә кайгысы була. Сезнең дә бердәнбер балагыз чирләбрәк тора дип ишеткән идем әле. Әй-йе!.. Ул-бу булып куя күрмәсен, Ходай Тәгалә берүк үзе сакласын инде...

Бу сүзләре Әхмәтҗанга әллә ни тәэсир итмәгәч, Миңкамал җиңги соңгы «козерын» чыгарырга булды.

—Моннан ике-өч көн генә, теге мәчет карты—Мөтәвәлине күргән идем әле. Әй-йе!.. Улыгызны бер дә мактап туя алмаган иде инде. Шалкан кебек ап-ак тәнле, тупырдап торган ир бала ди...

Миңкамал җиңгинең бу сүзләре дә көткән нәтиҗәне бирмәде. Әхмәтҗанның сыны кату түгел, керфекләре генә дә селкенмәде, ичмасам! «Эх, чүп өстенә чүмәлә булырлык, тагын берәр нәрсә генә булсачы!»—дип зәһәрләнеп уйлап куйды Миңкамал җиңги.

Аның гаҗәпләнүенә каршы «чүп өстенә чүмәлә» булырлык, яки нәкъ үзгенә барып тиярлек сүзнең кирәге дә булмады. РТСның баш механигы, алдында яткан кәгазьләрне читкәрәк этәреп, болай дип сорап куйды:

—Кара әле, Миңкамал җиңги. Синең ул агачларың Яңасала кырыннан әллә ни ерак түгелдер ич?

—Юк, юк!.. Каян килеп ерак булсын ди. Урманның авызына чыгарып ук куелган. Кыр башына орынып ук яталар инде менә. Юл өстендә ук...

Әхмәтҗан аны бүлде:

—Алайса, менә нәрсә. Тагын берәр сәгатьтән тимер чана таккан трактор Яңасала кырына менәчәк. Мин әйтермен, агачларыңны салып төшерерләр.

Кирәк нәрсәне бу юл белән дә алу мөмкинлеге ничектер сәер булып тоелды Миңкамал җиңгигә. Ул ышанмаганрак кыяфәт белән урыныннан теләр-теләмәс кенә торды. «Онытып куймасмы икән?»—дигән уй туды. Юк! «Салып төшерләр»,—диде ич. Әхмәтҗан әйттеме, аның сүзен һичкайчан да җиргә салмаячакларын Миңкамал җиңги белә иде инде.

Миңкамал җиңги, хәзер үк үзенең дә трактор белән бергә кырга менәчәген һәм мең тапкыр рәхмәтләрен әйткәннән соң, Әхмәтҗанның колагына иелә төшеп, сер әйткәндәй өстәп куйды:

—Син, кем, Әхмәтҗан энем, бер дә борчылма. Улыгызны әйтәм әле... Шуннан соң берәр атна чамасы тынычсызланыр инде ул. Бернәрсәсе дә юк аның. Була торган хәл. Ата-бабаларыбыздан калган йола, нишләтер хәлең дә юк. Ярар, кем, Әхмәтҗан энем... Бу яхшылыкларыңны гомеремдә онытмам инде,—дип, алга таба бәйләгән яулыгын рәтләп, җилкәсенә төшебрәк торган җирләрен артка таба ташлады да, җил-җил килеп атлап та китте...

## IV

Үземә дүрт-биш көн буе рәттән районның ерактагы колхозларында булырга туры килде. Кайтышлый ук Бичура җиңгиләрнең бик зур бәхетсезлеккә дучар булганлыклары турында ишеттем. Күз көеге булып йөрмәскә дә уйлаган идем дә, тик өйдә кайбер кирәкле кәгазьләрнең калган булуы кайтырга мәҗбүр итте.

Минкамал җиңги бернәрсә дә булмаган кыяфәт белән каршы алды. Гадәттәгечә, комганга җылымса су салып, өялды ишеге өстенә кызыл башлы, чип-чиста сөлге чыгарып элде. Юынып өйгә кергәндә өстәл өстендә, кузгалып китәргә җыенган паровоз кебек пошкырып, тирә-якка пар бөркеп кайнап кына чыккан самавыр утыра иде.

Бары тик Минкамал җиңгинең кызы Хәтирә генә таный алмаслык булып үзгәргән. Курмичә торган шул дүрт-биш көн эчендә ябыгып та, картаебрак та киткән кебек тоелды ул миңа. Әнисенеке кебек җыйнак, юка йөзе җитдиләнгән. Кашлары чак кына җыерылып күз кабаклары өстенә ук төшеп ятканнар. Әнисенеке кебек яшькелт күзләре ничектер тоныгаеп калган.

Өстәл тирәсенә утырыштык. Бу юлы чәй янында уен-көлке дә, шаян сүзләр дә булмады. Мин дә авызыма су капкандай, тик кенә утыра бирдем. Теге яки бу нәрсә турында сүз башларга кыймадым. Андый вакытта җыен килде-китте сүзнең ничектер урынсыз булып чыгуы бар бит.

Актык чиктә Минкамал җиңги үзе сүзгә керешге.

—Көтелмәгән хәл булды бит әле, кем, энем,—диде ул.

Үз чиратымда мин дә кайтышлый ук шунар охшашлырак нәрсәләр ишеткәнлегем турында әйттем.

—Хәтирәнең, әнә, кибетен басканнар. Кимендә мең сумлык товар юк, ди. Менә, ике көн булды, бер дә андый-мондый хәбәрнең ишетелгәне юк...

Минкамал җиңги бик гади бер нәрсә турында хәбәр әйткәндәй тыныч кына сөйли. Ясап куйган чәенә бөтенләй диярлек кагылмыйча тик кенә утырган Хәтирә ягына борылып:

—Каравылчы юк идемени?—дип сорап куйдым мин.

—Бар... Бер карт тора иде. Үч иткән кебек ике генә көнгә дип, авырып урын өстендә яткан сырхау кызы янына җибәргән идем үзен. Башка авылда аның кызы...

—Шул инде ул,—дип сүз кыстырып куйды Минкамал җиңги.—Кеше көен көйләсәң шул була ул...

—Үләргә ята дип, бик инде ялынып сораган иде,—диде Хәтирә, акланырга теләгән баласыман итеп.

Сүз янадан шул таланган кибет тирәсендә чуалды. Минкамал җиңги урланган товарларны да санаштырып алды: биш-алты ящик аракы очкан, башка товарларның да бер дә иге-чиге юк икән инде.

—Кибет олы юл өстендә...—дип куйды Минкамал җиңги.—Машинага төяп кенә озатканнардыр.

Әй-йе, бу гаять дәрәҗәдә җитди эш иде. Моның нәрсә белән бетәчәген Минкамал җиңги дә, минемчә, бик яхшы белә иде булса кирәк. Аллагы ике-өч көн эчендә табылмагач, хәзер инде югалган әйберләрнең эзенә төшү икеле иде. Шулай да Минкамал җиңги үзен тыныч тотты. Әгәр дә мәгәр хәзер аның урынында башка берәү булса нишләр иде икән, дип уйлап та куйгаладым мин. Юк дигәндә елап, зәнкиләнеп, әллә ничә тапкыр инде һуштан язарга өлгергән булыр иде.

Минкамал җиңги үзе тыныч булу белән генә чикләнмәде, чандыр җилкәләрен чыгарып, башын иеп утырган кызына да җикеренеп алды.

—Зинһар, тәресен югалткан маржа кебек кара коелып утырма әле. Дусы бар, дошманы бар дигәндәй... Нәрсә ул кадәр һуштан яздың? Шулкадәр җебегән дә булырсың икән! Кемгә охшап шундый булдың син? Ташла!.. Дөньяның асты-өскә килмәгән ич. Берәр җае чыгар әле...

—Кешеләр, әнә, җыен тузга язмаган нәрсәләр сөйлиләр. Шушы ике көн эчендәниләр генә ишетмәдем инде...

Кызының елауга охшап, сузып-сузып әйткән бу сүзләрен бүлеп, Миңкамал җиңгинең көр, күтәренке тавышы яңгырады:

—Тел бәрәнге түгел, изелми, теләсә ни сөйли.

Мине Миңкамал җиңгинең урынлы һәм тапкыр әйткән сүзләреннән бигрәк, аның салкын канлылыгы, анардагы ихтыяр көче гаҗәпләндерә иде. Әгәр дә бу хатын тормышта вакланмыйча, кешеләрнең йомшак ягы белән, яки кешеләрнең очраклы ялгышлыкларын җим итеп, кирәкмәгән гайбәт җыеп, шуларны үзенең вак теләкләрен тормышка ашыруга файдаланмыйча, чын эшкә юнәлдерсә ниләр генә эшли алыр иде ул дип, еш кына уйлый идем.

Көннәр узды. Көннәр узган саен Миңкамал җиңгинең башы өстендәге болытлар да куерганнан-куера барды. Следствие—тикшерүләр башланды. Хәтирәне кулга алдылар. Миңкамал җиңги ялгыз калды. Бу хәл, бәлки, Миңкамал җиңгине бөгәр дип уйладым мин. Тик мин уйлаганча булмады. Ул һаман да үзен гадәттәгечә төз тотты, башын имәде.

Халыкның үзенә карата мөнәсәбәтен белгәнгәме, ул кешегә киңәш-нәсихәт дип кермәде. Шуның өстенә: «Кибет басылу башка берни дә түгел, Бичураның үз эше генә»,—дигән яман хәбәр дә таралып өлгерде.

Бу эшнең юшкынынннан мин дә читтә кала алмадым. Ни өчендер халыкта «Түрә Галәвие» дип кушаматы чыккан ревизор мине очратып туктатты да тизрәк башка квартирага күчүемне сорады.

—Тентүләр, конфискацияләү, тегесе-монысы башланачак,—диде ул. Эш шулай ук зурга китәр микәнни, дип кызыксынган идем:

—Һәй-й, эшнең башы гына әле,—диде Галәви.—Бу Бичураның оясын күптән туздырырга вакыт иде инде.

Галәви бу эшкә үзенең якыннан торып катнашачагын да әйтте. Ул үзенең канәгать икәнлеген яшерә алмады; дөресрәге, яшерергә теләмәде дә. Берниндн тартынусыз ул мыегын сыпыргалап кеткелдәп көлеп тә җибәрде. Аның ат кадәрле эре гәүдәле булып та, тавык кебек кенә кыткылдап көлүе, ничектер бик үк килешеп бетми иде.

—Күптән кызыгып йөри идем,—дип өстәде ул кулларын угалап.—Менә, ниһаять, килеп тә капты... Шап итте! Бу юлы инде ычкына алмас...

«Түрә Галәви» заманында райбашкарма комитеты аппаратында ярыйсы гына урын тоткан дип сөйлиләр. Тик «нәчәльниклыкны» үлеп яратуына да карамастан, элеккеге югарылыгында кала алмаган ул. Ниндидер сәбәпләр аркасында партиядән дә чыгарылган. Бер килсә килә бит ул, хәерсез. Хатыны да моны ташлап башка кешегә кияүгә чыккан. Шуннан бирле ул бер урыннан икенчесенә күчеп, соңгы вакытта, һич югында ревизорлыкны кулыннан ычкындырмау нияте белән район үзәгендә, туган сеңлесе янында тора иде.

Миңкамал җиңгинең дошманнары чын-чынлап шатлыклы көннәр кичерәләр иде. Чатан Гали турында әйтеп торасы да юк. Ул ачыктан-ачык, берниндн тартынусыз: «Йа, Ходай! Бу зобани Бичураның нигезе какшавын да күрәсе көнебез бар икән!»—дип, авылның бер башыннан икенче башына очып кына йөрде.

Мортазаның—Миңкамал җиңги киявенең дә авызы ерылды. Ул икенче хатын алып, яңа гаилә корып җибәрүенә дә карамастан, бик канәгать кыяфәт белән Миңкамал җиңгиләрнең бу хәленнән туйганчы көлде:

—Борыннарын бик күтәргән булганнар иде. Шул була ул! Мин аларның кара эш белән шөгыльләнүләрен алдан ук сизенә идем. Шунар күрә араны тиз өздем мин... «Бичура кияве» дигән яманатлы исемнән тизрәк арыну ягын карадым...

Шунысы гаҗәп, бер генә кеше дә Миңкамал җиңги яклы түгел иде. Бер генә кеше дә аның хәленә керергә теләмәде. Киресенчә, аның шундый көнгә калуына барысы да ачыктан-ачык куаналар иде. Хәтта мәчет карты Мөтәвәли дә үзенең кәҗәнеке кебек сакалын сәлперәйтеп, кәкре башлы таягы белән Миңкамал җиңгиләр өенә таба төртә-төртә җикеренде:

—Шул кирәк ул Бичура динсезгә! Бер генә дә кызганырлыгы юк. Бик, бик күп кешеләрнең теңкәсенә тиде. Бик күп кешеләрнең канына тоз салды. Кеше каргышы, кеше күз яше җирдә ятмый ул! Ходай барысын да күрә...

Анын сүзләрен башкалар бары тик көчәйтеп кенә тордылар. Шулай да кайберәүләр. «Бичурамы, ул судан да коры чыгар, күрегез дә торыгыз менә. Утка салсаң, утта янмас, суга салсаң, суга батмас ул Бичура!»—дип әйтүчеләр дә булгалады.

Кызык бу кеше дигәнең, шунда да бит әле Минкамал жинги янына килеп кемнәрнең нәрсә диюен, ниләр сөйләвен чәчми-түкми китереп тапшыручылар да табылып торды. Ул гайбәт сүзләре Минкамал жингигә әллә ни тәэсир итмәде. Ул үзенең юка, кысынкы иреннәрен аз гына ерып, тыныч кына тыңлый иде. Сер бирмәде ул.

Шулай да Минкамал жинги ялгыз калганда яки тавыкларына жим биргәндә үзалдына сөйләнгәли иде. Кияве Мортазаны да кешелектән чыгарып сүгеп ташлады ул: «Фәлән-фәлән дип, авызын ерган була икән бит әле, хәчтерүш! Ул да кеше булып сөйләнгән була икән, тавык жиме ашап үскән нәрсә. Тукта!.. Алай бик күп теленә салына башласаң, маңгаеңа ишәк типкәндәй итәрмен. Нәрсез! Үтмәс балта белән юнып ясаган нәрсә! Шул башын белән фәлән-фәлән иттем дип, гайбәт саткан буласың икән әле, үзенә калганда. Гарьләнүеннән шартлап үләрсең тегеләй! Чук кебек кызымны ташлап, башкага өйләнеп, туйлар ясап мыскыл итүең генә житмәдемени әле... Булдыксыз! Ике бозауга кибәк аера алмаган башың белән... кыланган буласың икән. Ярар, жил кубызы! Жан көеге! Адәм актыгы! Алайса, үзенә үпкәлә...»

Билгеле, Түрә Галәвие дә өлешсез калмады: «Биво мичкәсе!.. Каныкты бит, бер кавым. Тәмам тенкәгә тиде. Хәтирә янына килеп, кибеттә жаны чыкканчы эчүләрен онытты микәнни! Ялгыз, тол хатын, яклаучысы юк дип, алай бик батырайма әле. Тормыш бу... Син дә аяз көнне яшен суккандай булырсың тегеләй!»

Бик күпләргә янады, бик күпләрне тиргәде ул. Мәчет карты Мөтәвәлигә дә эләкте. Аны да: «Коръән чәйнәп йөргән була бит әле, үзенә калганда! И-и, карт төлке... Мөртәт!»—дип сүкте.

Мин исә: «Ай-һай, Минкамал жинги! Япа-ялгыз башың белән бик күпләргә яныйсың янавын. Тик шушы кадәрле дошманнарына каршы нәрсә генә эшли алырсың икән соң!»—дип уйлап куйгалый идем.

## V

Минкамал жинги хурланган башын имәде, горур тотты. Анын бары тик карашы гына бераз үзгәрде. Соңгы вакытта ул сагаебрак, табышына ташланырга жыенган карчыга кебек текәлебрәк, берүк вакытта сынаган кебегрәк итеп карый торган булды.

Бөтенләй көтмәгәндә тентү белән дә килеп керделәр. Бу хурлыклы хәл генә бераз анын жанын сыкратты, әрнетте, ахрысы.

—Менә шулай нахак бәла белән тенкәгә тияләр инде,—диде ул мина.

Аны: «Кибетне аналы-кызлы үзләре генә басканнар»,—диген гайбәттән бигрәк, шулай тентүләр ясап хурлап йөрүләре генә бераз гарьләндерде булса кирәк.

Тентү, тикшерү эшләре белән чыннан да ревизор Галәви житәкчелек итте, ахрысы. Ул түшен киереп, бик зур эш башкарган кыяфәт белән чын «нәчәльникларча» кыланды. Жаен табып, Минкамал жингине тагын да мәсхәрәләргә теләгәндәй, жикеренгәләп тә алгалады. Минкамал жинги дә этләнсә этләнде, әмма сер бирмәде. Киресенчә, шаярган сыман итеп, мәзәк сүзләр ычкындыргалап, Галәвине чеметкәләп тә алгалады.

—Йа-а, тырыштың да инде, кем, Галәви. Булгандыр инде. Актарынмаган, казынмаган урын калмады бугай бит инде. Әллә ачып, күтәреп карамаган берәр жирем бармы әле?.. Ә? Ха-ха-ха...

Дагалаган күн итеге белән каты-каты басып йөргән ревизор, каш астыннан гына карап, янап та алды.

—Күп теленә салынып тор әле...

—Зинһар, ачулана күрмә инде, кем, Галәви туган...

Ревизор аны шунда ук бүлде:

—Каян килеп мин синең туганың булыйм, ди. Синең туганың, әнә, станциядә, төрмәдә утыра...

Минкамал жиңги һаман елмая иде.

—Ачуланма, кем, Галәви! «Туган» дип үземә калганда якын итеп кенә әйтүем иде. Билгеле, ал һәм таләкәй, Бичура жиңгән бәләкәй, син зур...

Минкамал жиңгинең теле бу сүзләрне әйтсә дә, аның үз-үзен тотышы, бигрәк тә күз карашлары бөтенләй башка нәрсә турында сөйлиләр иде. Гүя ул: «Тукта!.. Өйрәтермен мин сине, «биво» мичкәсе! Шаклар катарсың... Бу кылануларыңны бер исенә төшерермен әле»,—ди иде.

Мин исә: «Ничек соң ул үзен шулай тыныч тота ала? Шулкадәр гайбәтне күтәрү уен эш түгел ич. Кибетне басуда әллә чыннан да үзләре үк гаепле микән?»—дип уйлаштыргалап та куйгаладым.

Тентүләр узгач, Минкамал жиңги бераз тыныбрак калгандай булды. Тик бу тынычлану, «инде бар да бетте»,—дип, өметсезләнүдән, көчсезләнеп кулларын төшерүдән туган тынычлану түгел иде. Киресенчә, бу—нindидер чиксез зур эш башкару алдыннан, бераз тын алуга охшаган тынычлану иде. Көчле давыл алдыннан да табигать шулай тынып калучан була бит.

Аның шулай нindидер эш хәзерләвен мин бөтенләй көтмәгәндә сизендем. Тентүләр үткәннең икенче көнендә үк мин искәрмәстән аның бүлмәсенә барып кердем. Минкамал жиңги койкасы өстенә утырган килеш иелеп, үзенең аяк киемнәре өстеннән тагын нindидер ир-ат туфлиләре киеп утыра иде. Мине күргәч тә ул берни дә булмаган кыяфәт белән туфлиләрне аягы белән генә этәреп койка астына яшерде.

Мин үземнең бик ашыгыч рәвештә ике-өч көнгә авылларга чыгып китәчәгемне әйттем.

—Әллә хәзер үкме?—дип сорады ул.

—Әйе.

—Соң ник аны алданрак әйтмәдең?! Юлыңа бирәр нәрсә хәзерләгән булыр идем... Кая әле, бистовканы гына элдереп булса да бирәр кайнар нәрсә хәзерләп ашатыйм үзеңә.

Хәзер үк чыгып китәм дип, мин аны бу эшеннән бүлгәч, ул баздан катык белән сөт өсте генә алып менәргә булды. Мин аның бу тәкъдимен дә кире кактым.

—Ике-өч көнгә дисеңме әле?—дип сорап куйды ул кабат.—Мин дә иртәгәләргә Хәтирә янына станциягә—төрмәгә барып кайтырга уйлап тора идем әле. Передач диләрме әле, бераз ашарына-эчәренә илтеп кайтырга кирәк балакаемның. Бичаракаем! Очратмыйча, күрештермичә теңкәләремә тияләр инде. Следствә диләрме әле үзен, тикшеренүләрен әйтә торганнардыр инде, шулар беткәч кенә очраштырачаклар, ди.

—Аннары нәрсә, суд буламы?—дип сорап куйдым мин.

«Суд» сүзен ишеткәч, бәлки Минкамал жиңги бераз үзгәрер дип көткән идем мин. Тик мин көткәнчә булмады. Ул бик гади нәрсә турында сүз алып баргандай җавап кайтарды.

—Эшне судка кадәр җибәрәсе түгел иде шул. Аныңчы Ходай Тәгалә үзенең бирәр төрле шәфкатен күрсәтеп куймасмы әле.—Бу сүзләрне әйткәндә аның нindидер корылган планы барлыгы аермачык булып сизелде. Күзләрендә дә зәһәрлек чаткылары чагылып киткәндәй булды аның. Җинаять эшләргә җыенганда да теленә «Ходай Тәгаләсен» ала бит әле, дип уйлап куйдым мин.

Эшнең барыбер судка җитәчәген уйлап, мин аңар бер дә булмаса яхшырак адвокат ялларга киңәш бирдем.

—Сезне турыдан-туры гаепләрлек бернинди дә дәлилләр юк ич,—дидем мин.—Шикләнүгә таянып кына кешене гаепләмиләр.

Ул кулын гына селтәде:

—Ышан син! Гаепләмәсләр...—Аннары башыннан нindидер фикер уздыргач, өстәп куйды:—Юк инде. Аблокат та берни дә кыра алмас. Аңар калгач булмый инде ул...

Шулвакыт капка төбенә җигүле ат килеп туктаган тавыш ишетелде.

Мин Миңкамал җиңги белән саубуллашып, хәерле юл теләдем дә, Хәтирәгә миннән сәлам әйтергә кушып чыгып киттем.

Трантас пычрак юлга тирән тар эз салып алга тәгәри. Әле генә кардан арынган тәссез кырлар өстендә ачы язгы җилләр уйный. Көзге көнне хәтерләтеп түбәннән генә соры болытлар йөзә. Төнгә каршы көннең шулай бозылуын яратмыйм мин. Үтәдән-үтә бәреп кергән җилдән ышыкланыбрак утырдым да, кожанымның башлыгын күтәреп кидем. Шулай бераз җайлабрак урнашкач, яңадан уйлар иркенә биреләдем.

Юл буе диярлек Миңкамал җиңги турында, аның хәзерге хәле, үзенүзе тотышы турында уйланып бардым. Торган саен минем өчен ул бары тик башваткыч бер табышмакка әверелә генә барды. Нинди әрәк кеше соң ул? Күпме генә тырышсам да мин аны барыбер җентекләп аңлый алмамдыр кебек булып тоелды. Бер караганда, кеше өчен үлеп тора кебек. Күршеләге дә бар. Бик сирәк керүләренә дә карамастан, йомыш белән кергән кешене кире бормый ул. Билгеле, аңар теге яки бу йомыш белән бик сирәк, үзе әйтмешли, «килеп терәлгәч кенә» керәләр. Шулай да кеше күңелен күрер өчен тиресеннән чыгардай булып тырыша ул. Бала-чагаларын да ярата. Очратса: «И-и, балакаем! Күз нурым...»—дип аркасыннан сөймичә озатмый. Шул ук вакытта аны халык күрә алмый, яратмый; җыен әшәкелекнең, җыен җинаятьнең чыганагы итеп карыйлар аңар. Икенче яктан, аның уңганлыгына, булдыклыгына сокланалар да. Шул Миңкамал җиңги турында бит инде: «Сусыз юып, җилсез киптерә торган хатын ул. Агачтан сандугач кына ясамый инде. Югын бар итә, барын бал итә ул Бичура»,—диләр.

Миңа район авыллары буйлап шактый гына йөрергә туры килде. Үзләрендә генә түгел, хәтта тирә-яктагы авылларда да, берәрсе яхшырак бал әчетсә: «Шә-әп!.. Бичура җиңгинең «биво»сыннан бер дә ким булмаган бу»,—дип мактап әйткәләгәннәрен миңа үземә үк ишетергә туры килгәләгәне булды. Ничек кенә булмасын, Миңкамал җиңги минем өчен байтак вакытка кадәр ватылмас чикләвек булып кала бирде. Юлга чыгар алдыннан гына булган вакыйга үзе генә дә мине хәйран калдырды. Төнгә каршы үз аяк киеме өстенә тагын ниндидер ир-ат туфлие киеп маташа бит! Нәрсә булыр бу?.. Кем туфлиләре икән ул? Нәрсәгә кирәк булган алар?.. Кыскасы, алданрак боларның барысы да миңа баш җитмәслек табышмак булып тоелдылар. Актык чиктә, барыбер бер нәрсә дә төшенә алмам дип, ул турыда уйламаска булдым.

Авылларда, алда әйткәнемчә, ике-өч көнгә генә түгел, ә дүрт-биш көнгә якын булырга туры килде. Инде кайтыйм дип кенә торганда, район буенча адәм ышанмаслык сүз таралды. Янәсе, Бичура җиңги кызы Хәтирә янына барган җирендә, ревизор Галәвинең үзен үк төрмәгә утыртып кайткан, имеш. Минем андый имеш-мимеш дип сөйләнгән сүзгә ышанасым килмәде.

Кайберәүләр бу сүзгә тәмам ышанып та өлгерделәр. Кем-кем, ә Бичура җиңгинең законы үз кулында. Анардан теләсә нәрсә көтеп була, имеш.

Ирексездән мин дә аның тавыкларын ашатканда: «Тукта!.. Алай бик батырайма... Тормыш бу! Син дә аяз көнне яшен суккандай булырсың, тегеләй!»—дип Түрә Галәвиен суккән сүзләрен исемә төшердем.

Бу адәм ышанмаслык сүзнең хак икәнлеген мин бары тик кайткач кына белдем. Миңкамал җиңги исә бернәрсә дә булмагандай, йорт эшләре белән әвәрә килеп йөри иде. Аның бары тик күзләре генә нәрсә беләндер бик канәгать иделәр. Тагын да чаткыланып, тирә-якка ут атып торалар иде аның күзләре.

Мин Галәви белән булган вакыйганың ничегрәк килеп чыгуы турында кызыксына башладым. Миңкамал җиңги исә үзе бу турыда беркемгә дә, бернәрсә дә сөйләмәде. Гомумән, аның мактанып, өйдән-өйгә йөреп гайбәт җыеп, юк-барга ләчтит сатып йөри торган гадәте юк иде.

Ул хәл болайрак булган икән: Миңкамал җиңги станциягә барып җитәргә ике-өч километрлар чамасы каларак машинадан төшеп кала. Станциядән капмакаршы якта урнашкан төрмәгә ул турыдан гына чыгарга була. Юлны тотырып тау кадәр булып алданрак барган кешене дә куып җитә ул. Карасаң, Түрә Галәвие икән.

—Ә-ә!..—ди тегесе көр тавыш белән.—Шулай жил уйнатып кем килә дисән, Миңкамал жиңги икән әле. Кая баруың бу?..

Миңкамал жиңгинең җавабы коры:

—Утырмага түгел, билгеле...

—Үпкәлисеңме?..

—Үпкәлим, кем, Галәви. Теләсә нәрсә әйт, күрәләтә торып газиз балакаема чокыр казуыңа бер дә ризалыгым юк. Хәтиреңне әйтәм, килеп чыксан-нитсәң зурлап каршы ала иде үзеңне. Каныктың бит бер кавым... Алай кешегә чокыр казымыйлар, кем, Галәви. Үзеңнең төшеп куюың бар.

Ревизор да җавапсыз калмый.

—Беренчедән, Миңкамал жиңги, минем беркемгә дә чокыр казыганым юк. Теге яки бу җинаятьне тикшерү, аны ачыклау, белгәненчә, минем бурычым ул. Шуңар күрә ревизор диләр бит мине. Әгәр дә инде кызың, син әйткәнчә, чыннан да гаепсез икән, берни дә булмас, чыгарырлар. Безнең Совет законнары бер дә юкка кешене җәзаламый.

Янәшә атлаган Миңкамал жиңги телләнүен белде:

—Совет законнары җәзаламас та. Тик менә кайбер кешеләр, телләре үтүдән файдаланып, акны кара итеп күрсәтеп, кешене юкка да батырып куйгалыйлар. Син дип әйтмим, билгеле.

—Беләм, беләм! Кем бакчасына таш атуыңны да бик яхшы аңлыйм. Әйе, әйе! Син мине казыган чокырга төшеп куйма, дип куркытма, яме.

—Янап әйтүем түгел.

—Менә шул! Мин алай бик тиз өркә торганнардан түгел. Шулай ук тиз генә чокырга да төшерә алмаслар. Әй-йе, алмаслар!..

Миңкамал жиңги аны бүлеп, кыстырып куя:

—Тәүбә диген, кем, Галәви. Шакай булырсың, тегеләй!

—Булмам!..

—Булырсың! Дөнья ул...

Бичураның үсзүзләнүе Түрә Галәвиенең тәмам ачуын чыгара.

—Булмам!..—дип кабатлый ул.—Мең тапкыр кабатларга да хәзермен, булмам! Мин сине менә ничәмә-ничә еллар буе гел күзәтә килдем. Синең ниндиерәк җинаятьләр эшләгәненне әллә белмиләр дип уйлаган иденме? Ю-юк, барысын да белә идем. Бер мин генә түгел, бар да беләләр. Тик эләктереп алырга һаман да җае чыкмыйчарак тора иде. Итләч балык кебек шома, кулдан шуып чыгып котыла килдең. Монарчы бәхетеңә каршы шулай булды. Бу юлы инде алай тиз генә ычкына алмассың. Ю-юк!..

—Шулай укмыни?..

—Шулай!

Миңкамал жиңгинең дә тавышы калтырабрак киткәндәй була.

—Син әле, кем, Галәви, шулай укмыни... Кара әле, ә! Ә мин тагын синең турында башкачарак фикердә идем...

—Төкерәм мин синең фикереңә...

Бәхәсләре шулай кызып житкәндә, зур булмаган әрәмәлектән чыгып житәргә дә әллә ни күп калмаган иде. Уң якта, якында гына тракторларның да күнелле генә гөрелдәгәне ишетелә. Аның гына түгел, кешеләрнең чыркылдашып сөйләшүләре, көлешеп алулары да аерым-ачык булып ишетелә башлаган иде инде. Нәкъ шул вакытта булды да инде, теге, адәм әйтеп ышанмаслык хәл. Миңкамал жиңги үзенең әсәрләнгән күзләре белән Галәвигә туп-туры карап, тыныч кына сорап куя:

—Телисеңме, биво мичкәсе... мин синең үзеңне кызык итәм? Менә, хәзер үк...

«Тенкәгә генә тиде бит, Бичура... Очрап торуын күр әле син аның! Бәла аяк астыннан чыгар ди шул»,—дип уйлап ала Галәви. Шулай да ул кырт кисеп, өзеп җавап кайтара:

—Юк, анысы булмас инде.

—Була!

—Юк!

—Юкмы?.. Карап карыйк. Мә, алайса...

Шул вакыт Миңкамал җиңги кулындагы төенчеген бер читкә ташлап, ачы тавыш белән кычкырып җибәрә дә, тырнакларын Галәвинең йөзенә батыра. Ул да булмый шыксыз, яшелле-күкле тавыш белән кычкыра-кычкыра башындагы яулыгын йолкып алып, алъяпкычын аерып җибәрә. Аннары чәчләрен тузгытып: «Коткарыгыз!.. Ах-х! Үтерә!»—дип, акыра-акыра кешеләр тавышы ишетелгән якка йөгерә башлый...

Таза гына ике тракторчы егет йөгерешеп аңа ярдәмгә килеп тә җиталәр.

—Нәрсә?..

—Нәрсә булды, апакай?..

—Әнә!.. Әнә... Теге явыз... көчләргә ябышты,—дип җавап кайтара Миңкамал җиңги.

Вакыйганың мондый борылыш алуын бөтенләй көтмәгән Галәви «бала-казадан баш-аяк», дип бер читкә шылмакчы да була. Тик тракторчыларның берсе ике сикерү белән аны куып тотып, аяк чалып ега да якасыннан эләктереп ачык кыр өстенә алып чыга. Шул арада ыгы-зыгы куба. Галәвинең болай да шыбыр канга баткан танавына кемдер менеп тә төшә.

Ә Миңкамал җиңгинең үз кырыгы кырык:

—Иң элек кызымның башына житте. Төрмәгә утыртты... Хәзер инде үземә ябышты, оятсыз,—дип елап җибәрә ул.—Җир бит! Аю кебек килде дә ябышты...

Аларның икесен дә яңа гына чәчү орлыгы алып менгән машинага утыртып станциягә, милиция идарәсенә алып төшеп китәләр.

Бары тик юлда гына, бераз аңына килгәч, Галәвинең теле ачыла.

—Миңкамал җиңги... Миңкамал җиңги, дим! Ни кылануың бу, ә?.. Шулай итәләр димени?.. Чыннан да харап итеп куюың бар ич...

Миңкамал җиңги анар авыз ачарга да ирек бирми.

—Ярар, ярар! Теленә салынган булып утырма... Шыңшыган була тагын. Алдан карыйлар аны. Тикшерерләр, ачыкларлар... Гаебең юк икән, җибәрерләр. Совет законнары юкка гына кешене җәзаламый...

Милиция идарәсендә коточкыч акт төзеп, унбишләп шаһиттән кул куйдырып, Галәвине алып та калалар. Тракторчылар, суд-фәлән була калса, үзләренең шаһит булып киләчәкләрен белдереп, Миңкамал җиңгигә борчылмаска кинәш биреп, үз эшләре белән китеп бардылар.

Шушы вакыйгадан соң Галәвине районда бүтән күрүче булмаган.

## VI

Нәкъ шул көннәрдә, һәркемгә аяз көнне күк күкрәгәндәй тәэсир иткән, икенче бер вакыйга булды. Моннан соң, беренче карауга чуалып, буталып беткән жеп йомгагы кинәт сүтелеп киткәндәй булды. Миңкамал җиңги, кызы Хәтирә янынннан кайтып, өс-башын да алыштырырга өлгерә алмый, кәкре тыкрык Мәймүнәсе ут капкандай атылып килеп тә керә.

—Минкамал... Минкамал дим! Ни булыр бу?.. Иртә белән кияүләренә.. Тфү-ү!.. Мортазаларга мунчаларын сорарга кердем. Ягып җибәреп, сулар ташып куйгач, «кая инде, идән-ләүкәләрен дә себереп, юып чыгарыйм», дип иске себерке эзли башладым. Кул астыннан гына тапмагач, мунча алдына чыгып, эскәмиягә бастым да чормага күз салган идем... Шаклар каттым! Алдан нәрсә дип уйларга да белмәдем. Карасам, түбе оялап ясаган аракы әрҗәсе... Шунда ук ватылган шешә пыялалары да аунап ята. Почмактарак, нәрсәдер күмелгән, ахрысы... Түмгәкләнеп тора... Менәргә курыктым. Күнелем шикләнеп, синең янга йөгереп килүем иде. Әллә мин әйтәм... Ә?..

Минкамал җиңги бу хәбәрне бераз гажәпләнгән кебек кабул итә. Шулай да күршесенең хәтерен калдырмаслык итеп кенә сорап куя ул:

—Хак сүзме бу, кем, Мәймүнә?..

—Ике күзем чәчрәп чыксын менә. Кояштыр! Баскан җиремнән купмыйм әгәр...

—Мин үзем дә нәрсәдер сизенгән идем аны сизенүен.

Бөтен урамны бер итеп шау-шу кубарып, Мортазалар мунчасына таба кузгалып өчен шул житкән иде инде. Юлда аларга башка хатын-кызлар, бала-чагалар да иярә. Күз ачып йомганчы мунча камап та алына. Мортазалар алдан: «Нәрсә чәүкә кетүе кебек шаулашасыз? Нәрсә күрмәдегез?.. Аю биетәләрме әллә?»—дип, жикеренеп тә карыйлар, аннары бу көтелмәгән хәлдән аптырап тынып калалар.

Минкамал жиңги исә, парад белән житәкчелек итүне үз кулына алгандай, команда гына биреп тора.

—Кем... Мәймүнә! Милиция идарәсеннән килеп житкәләгәнче, чорма тирәсенә беркемне дә якын жибәрмә. Аларга аяк эзләре, кул таплары, тегесемонысы дигәндәй, барысы да бик кирәк. Әй-йе! Хәзер барысын да ачыкларбыз. Әйткән идем аны... Шулдыр, шулдыр! Хәтерәмнен курчак кебек киенепясанып йөрүенә эче көеп, нишләргә дә белмичә котырынган иде аны. Актык чиктә, әнә, нинди юл белән балакаемнын башына житәргә уйлаганнар. Ююк! Алай гына булмый ул. Закон бар!..

Шул арада, бик эшлекле кыяфәт белән ике милиционер да йөгерешеп килеп життеләр. Кара болыт кебек булып жыелган халыкны ерып мунчага үтәләр. Шунда ук халык арасыннан шаһитләр сайлап алып, эшкә дә керешәләр. Чорма почмагыннан, күмелгән жирдән бишме, алтымы шешә аракы табыла. Аларны казып алганчы, чормадагы эзләрне сантиметрлар белән үлчәп, хәтта «карточкага» да төшереп алалар. 42 нче размерлы ир-ат эзләре икән. Ике туфлясынын да үкчәсенә, кыек басканлыктан кыйгачлап набойкалар кагылган. Бер сынар туфлясының ике кадагы төртеп тора икән. Барысын, барысын да жентекләп язып алалар. Аннары, аракы ящигын караштыргалаганнан сон, мунчага төшәләр. Пич белән стена арасыннан башлары янган икеме, өчме такта—ящик тактасы табалар.

—Мунчаны, әйтәм, коры такта белән генә якканнар икән, ә?

—Мортаза яши белә ул!..

—Һәй-й, дурәк! Мөфти Мортазасы диләр ич аны!..

Халыкнын бу сүзләре милиционерлар колагыннан да читтә кала алмый, әлбәттә. Түгелгән көл өеменнән янган ящик калайлары да табыла. Кыскасы, барысы да жентекләп уйланып, бик зур акыл белән эшләнелгән...

Тентү өйгә дә күчә. Ак жәймә кебек агарынган Мортаза, куркудан телдән кала. Печәнлектән бер жиде-сигез метрлар чамасы атлас та табып төшәләр. Ул да булмый, өялдыннан, ишек артыннан, мунча чормасында эз калдырган туфляларны да табып алалар.

—Бу кем туфлялары?—дип сорый милиционер житди генә.

Мортаза үз тавышын үзе танымыйча жавап бирә:

—Минекеләр...

Милиционернын өлкәнрәге коры гына итеп әмер бирә:

—Алайса, кем, Мортаза... Әйдә, киен. Безнең белән идарәгә барырсың.

—Нәрсәгә анда?.. Минем бернинди дә гаебем юк.

—Анысы турында идарәдә сөйләшербез...

Шулай итеп, Мортазаны кулга алалар. Ике көн дә үтми, Хәтирә дә төрмәдән котылып кайта. Ул элеккеге урынында, янадан кибеттә эшли башлый.

Минем дә китәр көннәрем килеп житте. Үзем тәмам аптыраушта идем. Хәер, бер мин генә түгел, башкалар да хәйран калганнар, нәрсә дип уйларга да белмиләр иде. Бу, һичшиксез, Минкамал жингинен үз эше иде. Анын: «Тукта!... Адәм актыгы... Маңгаена ишәк типкәндәй итәрмен. Алайса, үзенә үпкәлә»,—дип Мортазага янаганын да исемә төшердем. Тик моны ничек исбат итәргә сон? Нинди дәлилләр белән? Шундый уйлар белән мин милиция идарәсе начальнигы белән дә сөйләшеп карадым. Иң элек мин: «Кибет басылуда сез чыннан да Мортаза гаепле дип уйлыйсызмы?»—дип сорап куйдым. Анар мин берничә көн элек кенә әле Миңкамал жингинең ниндидер ир-ат туфлялары киеп утырганлыгын күргәнемне дә, күнелемдә шик барлыгын да сөйләп бирмәкче идем... Тик ул сүзен коры тотты:

—Без иң элек дәлилләргә таянып эш итәбез,—диде ул.

Билгеле, эш дәлилләргә генә терәлеп калса, Миңкамал җингинең бер урынына мен дәлил табачагын мин бик яхшы белеп өлгергән идем инде.

Иртәгә иртә белән китәм дигән көнне кызыклы гына бер сөйләшүнең шаһиты булырга туры килде миңа. Чемоданыма әйберләремне тутырып, Миңкамал җинги янына кереп чыгыйм әле дип, ишекне ачкан идем, тик баскыч төбендә аның кем беләндер сөйләшүен ишетеп, уемнан кире кайттым. Миңкамал җинги мәчет карты Мөтәвәли белән сөйләшеп тора иде. Тегесе, кайчандыр аңар каршы каты сүзләр әйткәне өчен гафу үтенергә килгән икән. Миңкамал җинги дә алай бик тиз генә кайтып төшәргә ашыкмый, киресенчә, гайрәтләнә-гайрәтләнә картның тетмәсен тетәме-тетә иде:

—Телең авызыңа сыймаса, мин бик тиз кыскартырмын аны. Татар теленнән табар, ди мәкаль. Үзең Коръән чәйнәп йөргән буласың тагын...

Мөтәвәли өтәләнеп, ялынып ялвара:

—Сөяксез тел нәрсә әйтмәс, кем, Миңкамал килен. Ачуым килгәч, ялгыш ычкындырганмындыр инде...

—Синең ачуың минем аяк-чуым.

Карт еларга җитешкән:

—Харап итә күрмә инде, кем, Миңкамал килен. Картлык хакына гына булса да... Һай-й, бу телем! Анда, Миңкамал килен, синең белән бер дә инде әчелешле буласым килмәгән иде. Бер генә юлга кичерсәнче!

Актык чиктә Миңкамал җинги бераз кайтып төшкәндәй була.

—Ярар,—диде ул.—Билгеле, ачу йоту—тау йоту, ди. Нишлисең бит инде. Телеңне озынайткан өчен үзеңне бер утлы табага бастырып биетермен дигән идем дә, ярар инде...

Мөтәвәли карт аждаһа яки газраил кулыннан ычкынып котылгандай, куанычыннан нишләргә дә белмәде.

—Рәхмәтләр генә төшсен инде, үзеңә, кем, Миңкамал килен. Моннан соң, Ходай кушса, үзеңә түгел, балаларыңның балаларына да тел-теш тидермәслек итеп васыять әйтеп калдырырмын. Һай-й, рәхмәтләр генә төшсен инде үзеңә...

Мөтәвәли карт кәкре башлы таягы белән ишек алдына җәйгән ташка шакы-шокы китереп бәргәләп, капкага таба юнәлде. Мин дә Миңкамал җинги янына чыктым. Картның нинди йомыш белән килгәнлеген юри генә сораган булдым.

—Фытыр сәдакасын биреп чыгардым әле үзеңә. Ни дисәң дә, дини картыбыз ич...

Бу сүзләрне әйткәндә Миңкамал җингинең төссез, кысынкы иреннәре кырыенда гына поскан елмаю чагылып киткәндәй булды. Кыскасы, соңгы көннәрдә Миңкамал җинги чын-чынлап тантаналы көннәр кичерә иде.

Иртәсен Миңкамал җинги мине озата чыкты. Саубуллашканда сандугач булып кына сайрамады инде.

—Син инде, кем, гаепләп китә күрмә. Үзеңне рәтләп сыйлап та булмады. Үзең шаһит булдың, бераз борчулы көннәр дә кичерергә туры килде. Ходай кушса, икенче юлы туп-туры үземә кайт. Үз өеңә кайткан кебек, бас та кер. Синең кебек күп күрмәгән, күп телеңә салынмаган кешеләрне яратам мин.— Аннары тавышын үзгәртә төшеп, болай диде:—Шулай инде, кем, тормыш булгач төрлечә булгандыр. Үзем шундый кеше инде мин. Гомерем үтте, әмма кеше ашына катык була алмадым. Хәер, андый кешеләрне яратмыйм да. Нишлисең бит, төрле вакыт булгандыр. Алдалашу, хәйләләшү дисеңме... Әй-йе! Хәйләсез, дөнья файдасыз ди бит...

Мин киттем, шулай да Миңкамал җингине күздән яздырасым килмәде. Шул районнан килеп чыккалаган кешеләрдән мин һаман да аның турында сораштырып тордым.

—Бичура җингиме?! Бичура җинги ул тирә-юньне тетрәтеп яши бирә,— дип әйтәләр иде аның турында.

⁂

*"Мәгариф" журналына 90 ел*



## Фәрит Шәрифуллин

# ҮТКӘН ЕЛЛАРГА БЕР КҮЗ САЛСАК...

Безнең халкыбыз һәрчак аң-белемгә, мәгърифәткә омтылып яшәгән. Октябрь революциясенә кадәр үк ул Россиядә укый-яза белү ягыннан империядәге халыклар арасында маяк булып торган. Кульязма әдәбият киң таралган. XIX гасыр урталарында ук инде безнең зыялы затларыбыз газета-журналлар чыгарырга омтыла. Тарих фәннәре докторы Равил Әмирхан язганча, "әмма инициаторларның башына "ярамый" күсәге төшеп торган". Шулай да ул гасыр ахырында кайбер кульязма һәм басма газета-журналлар, ярым яшерен төстә булса да, дөнья күрә башлый.

1905 елгы революция ялкыны кабынгач, татар матбугатына да юл ачыла. Шул елның 2 сентябрендә Петербургта "Нур" газетасы дөнья күрә. Ике ел эчендә андыйларның саны 30га якынлаша. 1907 елның 1 гыйнварында Мәскәүдә—"Тәрбиятел-этфаль" ("Балалар тәрбиясе"), 1908 елның 1 февралендә Казанда "Тәрбия" журналы чыга башлый. Кызганыч, боларның беренчесенең—5, икенчесенең 4 кенә саны чыгып кала. Төрле сәбәпләр аркасында алар ябыла. Ләкин татарча педагогик журналлар чыгарырга омтылыш сүрелми. Казанда гына түгел, Россиядә татарлар күпләп яши торган башка төбәкләрдә, шәһәрләрдә дә бу уңайдан җитди адымнар ясала. 1909 елда, мәсәлән, Оренбургта "Мәгариф" исемендә педагогик журнал нәшер ителә. Шул ук елның 1 гыйнварыннан август аена кадәр һәм 1910 елның башында Әстерханда "Мәгариф" дигән журнал чыгарыла. Аның 14 саны дөнья күрә.

Гомумән, зыялы, абруйлы олуг затларыбыз тәгълим-тәрбия мәсьәләсен күз уңында тоталар, татарча чыгып килгән башка газета-журналларда да укыту-тәрбия, мәгариф проблемаларын киң яктырталар. Әмма махсус фәнни-педагогик журнал булдыру зарурлыгын да алар һич тә истән чыгармыйлар.

Ниһаять, 1913 ел башында Казан губернаторы канцеляриясе "Сабах" нәшриятында Шиһабетдин Шәрәфетдин улы Әхмәровның җаваплы редакторлыгында "Мәктәп" дигән педагогик журнал чыгарырга рөхсәт бирә.

---

Фәрит ШӘРИФУЛЛИН— *"Мәгариф" журналының баш мөхәррире, Татарстанның атказанган укытучысы, Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, журналистларның Х. Ямашев исемендәге республика премиясе лауреаты. 1999 елда "Ватан алдындагы хезмәтләре өчен" II дәрәҗә орден медале белән бүләкләнде.*

Шиһаб Әхмәров. Мин бу олуг шәхесне күреп беләм. Гаҗәпләнмәгез. Халкыбызның сөекле шагыйре Габдулла Тукайның тууына 80 еллыкка әзерлек барган көннәр-айларда Казанда Матбугат йортында Язучылар берлеге идарәсе рәисе бүлмәсенә аның замандашларын җыйганнар иде. Көтмәгәндә, мине, һәвәскәр фотографны, аларны фотога төшерергә чакырдылар. (Мин ул чакта "Совет мәктәбе" журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли идем. Күрәсең, профессионал табылмагандыр.) Очрашуны, әңгәмәне шагыйрь иҗатын тәфсилләп өйрәнүче, шуның белгече Ибраһим Нуруллин алып барды. Шунда мәгърур йөзле (бәлки, миңа шулай тоелгандыр), кара мыеклы, үткер күзле бер кеше игътибарымны җәлеп итте. Башкаларга караганда ул үзенең буй-гәүдәсе һәм көр тавышы белән дә үзгәрәк булып тора иде. Фоторәсемдә дә шактый әйбәт (минемчә) чыкты кебек тоелды. Берничә ел узгач кына белдем: бервакыт шул фотоларны карап торган чакта редакциягә Афзал Шамов килеп керде. Фотосурәтләргә бераз күз йөрткәч, Тукай замандашларының мондагы исем-фамилияләре белән таныштырды. "Ә менә бу кара мыеклысы— "Мәктәп" дигән журналның редакторы, Тукай белән якыннан аралашкан кеше Шиһаб Әхмәров. Алар "Болгар" гостиницасы номерларында күршедәш булып та яшәгәннәр",—диде.

Ул елларда "Совет мәктәбе" журналының, ягъни хәзерге "Мәгариф"нең юл башы Октябрь революциясенә кадәр чыккан "Мәктәп" икәнлеге турында әйтергә, язарга ярамый иде. Беренчедән, идеология комачаулык итте. Икенчедән, бу журналлар тарихын ныклап, тәфсилләп өйрәнүчеләр дә булмагандыр. Ә бит 1913 елның 21 февралендә дөнья күрә башлаган "Мәктәп" татарча беренче җитди фәнни-педагогик журнал булып тора. 1918 елның 7 ноябрендә 1 нче саны чыккан "Мәгариф"нең тематикасы да "Мәктәп"неке белән бик уртак. Икесендә дә бер үк диярлек авторлар катнашкан. (Бу хакта матбугатта фәнни дәлилле мәкаләләр булды, әле тагын да булыр дип уйлыйбыз.)

Нәкъ менә шушы Шиһаб Әхмәров "Сабах" нәшрияты хуҗалары бертуган Габделвәли һәм Мөхәммәтвәли Әхмәдуллиннар хисабына чыга башлаган "Мәктәп" журналының редакторы була.


مكتب

اولوغ يوبيلى

*«Мәктәп» журналының беренче саны тышлыгы.*

Шиһабетдин Шәрәфетдин улы Әхмәров 1882 елның 30 декабрендә Сембер губернасы Буа өязенә караган Чүпрәле волостеның Яңа Задур авылында крестьян гаиләсендә туган. Буа мәдрәсәсендә белем алгач, Әлмәттә мөгаллим булып эшли. Әмма схоластик тәртипләргә нигезләнгән тәгълим-тәрбия системасы аны канәгатьләндерми башлый. Ул дөньяви фәннәр укыту, балаларны тормышка әзерләү, яңа төр дәреслекләр төзү кирәклелеге турында уйлана. Шиһаб Әхмәровның үзендә дә дәреслекләр төзү теләге уяна.

Күрәсең, хөр фикерле булуы өчен аны Әлмәттә бик өнәп бетермиләр. 1908 елда ул Казанга күчеп килә. "Болгар" кунакханәсе номерларына урнаша. Бертуган Габделвәли һәм Мөхәммәтвәли Әхмәдуллиннар 1902 елда оештырган "Сабах" нәшриятының китап кибетендә эшли. Өстәмә рәвештә аңа мәктәп-мәдрәсәләр өчен дәреслекләр һәм матур әдәбият авторлары белән элемтә урнаштыру, әсәрләрне сайлап алу, типографиядә бастыруны оештыру вазифалары да йөкләнгән була. Ш. Әхмәров үзе дә дәреслекләр язу эшен дәвам иттерә. Аның "Мөнтәхиб әлифба" дигән ике кисәктән торган дәреслеге 1908 һәм 1909 елларда аерым китап булып басылып чыга.

Ш. Әхмәровның шул елларда дөнья күргән "Матбагачылык тарихы" дигән хезмәте дә бу өлкәгә караган беренче зур китап булып тора. Анда

татарча китаплар чыгару белән шөгыльләнгән һәр басмаханәнең кыскача тарихы яктыртылган, күп кенә фактлар китерелгән. Бу яктан да аның әһәмияте зур, дияргә кирәк.

Шиһаб Әхмәров Казанга килгәч, 1908 елдан башлап, шагыйрьнең вафатына кадәр аның белән даими аралашып, фикерләшеп яшәгән. Өйләнгәнче, Ш. Әхмәров "Болгар" кунакханәсендә Г. Тукай белән янәшә бүлмәдә гомер кичерә. (Хәзерге Татарстан урамында Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры каршындагы бинада.) 1912 елда ул Салих Сәйдәшевнең апасы Әминәгә өйләнә һәм квартирага күчә. Г. Тукай кунакханәдә яшәп кала. Әмма ул Шиһаблар квартирасына еш килә. Булачак мәшһүр композиторыбыз Салих Сәйдәшев белән дә шунда очраша, аның гармунда бик матур итеп уйнавына соклана. Салих унбер-унике яшеннән шушы җизнәсе тәрбиясендә үсә (аның әтисе Салих туарга 15 көн кала үлеп киткән була). Шиһаб аңа рояль сатып алып бирә, музыка грамотасына өйрәтү өчен күренекле музыкант Заһидулла Яруллинны җәлеп итә, яшүсмер Салихны театрга, "Шәрык клубы"нда төрле очрашуларга, музыка кичәләренә алып бара торган була.

Татар зыялылары белән даими аралашуы, үзенең дә дәреслекләр төзүе, мәгърифәтебез турында фикер алышулар, бәхәсләшүләр дә, әлбәттә, тәгълим-тәрбия мәсьәләләренә багышланган махсус педагогик журнал оештыру турында нәтиҗәгә китергәндер.

Ш. Әхмәров һәм аның дуслары, фикердәшләре тәкъдиме белән, татар матбагачылыгын үстерүгә зур өлеш керткән Әхмәдуллиннар, журнал чыгарырга рөхсәт сорап, губернаторга мөрәҗәгать иткәннәр. Әлбәттә, моның өчен башта аның программасын төзергә кирәк була. 28 бүлектән торган ул программада педагогик тәрбия мәсьәләләре, урта һәм түбән классларда укытыла торган фәннәрне укыту методикасы, мәктәп-мәдрәсәләргә карата руханилар һәм җәмәгатьчелекнең тоткан урыны, аларда гомуми белем бирү һәм аны дәүләт гимназиясе программасына яраштыру, мөселманнарга техник белем бирү, мөселман балаларына мәҗбүри башлангыч белем бирү, хатын-кызларны укыту кебек пунктларны күрәбез. Алардан тыш, "Мәктәп" журналының программасы буенча журналда аерым фәннәр буенча лекцияләр, мәкаләләр, авыл хуҗалыгына караган яңалыклар, татар мәктәпләренең үткәне, хәзергесе һәм киләчәге, татарларда башлангыч белемнең торышы, татар мәктәпләре системасы, мәктәп-мәдрәсәләр өчен мөгаллим һәм мөгаллимәләр әзерләү, татар уку йортлары һәм хөкүмәтнең аңа карашы кебек темалар яктыртылырга тиеш дип уйланыла... Шул ук вакытта журнал мәктәп-мәдрәсәләр, педагогика, методика буенча төрле телләрдә чыккан хезмәтләр турында рецензияләр, күзәтүләр, күренекле педагог, укытучылар турында очерклар басуны һ. б. шундый күп нәрсәләрне яктырту бурычын алган.

Әлеге программаны төзүдә Ш. Әхмәров та, аның фикердәшләре дә катнашкандыр, дип ышанабыз, чөнки шунсыз журналның редакторы булырга ризалык бирмәс иде.

Әйткәнебезчә, "Мәктәп"нең 1 нче саны 1913 елның 21 февралендә (яңа стиль белән 6 мартта) дөнья күрә. 1914 елның октябрендә, Беренче бөтендөнья сугышы бару сәбәпле, чыгудан туктый.

Әмма бу журнал татар педагогика фәне тарихында зур әһәмият казанып өлгерә, галим-педагогларда вакытлы матбугат белән кызыксынуны көчәйтә. Аның авторларыннан Галимҗан Ибраһимов, күренекле галим Мөхетдин Корбангалиев, язучы һәм педагоглардан Нәҗип Думави, Фатих Сәйфи-Казанлы, тарихчы Газиз Гобәйдуллин һ. б. шундый күп кенә атаклы шәхесләрне санап узарга мөмкин. Ул авторларның күбесе 1918 елда чыга башлаган "Мәгариф"тә дә бик актив язышалар. Бу журнал "Мәктәп" программасын гамәлгә ашыруны дәвам иттерә, тик анда дини тәгълим-тәрбия мәсьәләләре генә төшеп кала. Сәбәбе: революциядән соң идеология үзгәрә.

Идеология дигәннән, Ш. Әхмәров редакторлыгындагы "Мәктәп"тәге материаллар турында губернатор һәрчак хәбәрдар була: цензура аның һәр саны белән таныштырып тора. Шиһаб Әхмәров үзе дә яшерен күзәтү астына алына.

Татарча беренче фәнни-педагогик журнал редакторы 1966 елның 30 апрелендә 84 яшендә вафат була. Халкыбызның мәдәнияте, мәгарифе тарихында якты эз калдырган олуг затларның берсе ул.

* * *

1918 ел. Сентябрьдә—Казан шәһәре, октябрьдә губерна җире дошманнан азат ителә. Шушы елның 7 ноябрендә "Мәгариф" журналының 1 нче саны дөнья күрә. Аның тышлыгының өченче битендә: "7 ноябрьдән башлап Казанда, Мәркәз мөселман Комиссариаты янындагы "Гыйльми һәйәт"нең органы булган "Мәгариф" исемле журнал чыга башлады. "Мәгариф" журналы: рәсми, тәрбияви, әдәби, фәнни бүлекләрдән гыйбарәт булып, айга ике тапкыр чыгачак" диелгән һәм анда нинди мәсьәләләр яктыртылачагы күрсәтелгән.

Шуңа игътибар итик: "Мәктәп"нең беренче санында үз мәкаләсе белән актив катнашкан Галимҗан Ибраһимов 1918 елның ноябрендә дөнья күргән "Мәгариф" журналын оештыручы, аның беренче мөхәррире була. Башка авторлар да безнең журналга бик теләп язышалар. Педагог-галимнәр, тарихчылар "Мәгариф" журналының тарихы нәкъ әнә шул "Мәктәп" журналыннан башлануын исбатлый-дәлилли алдылар. 1936 елның октябреннән "Мәгариф"нең—"Башлангыч мәктәп", 1938 елдан 1990 елның августына кадәр "Совет мәктәбе" исемендә йөрүе дә ул журналларның рухи, тематик яктан бертөрле булуы хакында сөйли. Аларның һәммәсе дә диярлек төрле сугышлар аркасында беркадәр вакыт чыгудан тукталып торган. Әйткәнебезчә, "Мәгариф" журналы 1918 елда Мәркәз мөселман Комиссариатының Мәгариф бүлеге каршындагы Гыйльми һәйәт органы буларак дөнья күрә. Гражданнар сугышыннан соң ул 1921 елның апреленнән Татарстан Мәгариф Халык Комиссариатының айлык гыйльми-педагогик журналы сыйфатында чыгарыла башлый.

Бөек Ватан сугышы башлангач, "Совет мәктәбе" чыгудан туктый. 1945 елның май аеннан аның урынына Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты органы булган "Халык мәгарифе буенча җитәкче һәм педагогик-методик материаллар җыентыгы" нәшер ителә башлый. Әлеге җыентык ике айга бер тапкыр 4000 данә тираж белән чыгарылган. Аның 1 нче санындагы "Редакциядән" дигән белдерү эчтәлегеннән күренгәнчә, җыентык вакытлыча журналны алыштырып торган, анда педагогик-методик мәсьәләләр, алдынгы тәҗрибә яктыртылган.

1949 елның 4 маенда республика җитәкчелеге, "Совет мәктәбе" журналын яңадан чыгара башларга рөхсәт сорап, Мәскәүгә мөрәҗәгать итәргә була. Ниһаять, рөхсәт алына. Татарстан АССР Министрлар Советы да 1949 елның 9 сентябрендә Татарстан Мәгариф министрлыгына "Совет мәктәбе" журналын ике айга бер тапкыр 6 мең данә тираж белән биш табаклы итеп чыгарырга рөхсәт бирә. 1956 елның 1 июленнән әлеге журнал ай саен чыгып килә. ("Мәгариф" журналы тарихына караган материаллар белән "Совет мәктәбе"нең 1941 елгы 4 нче, 1957, 1958, 1968, 1978, 1988 нче елгы 11 нче, шулай ук 1975 елгы 5 нче һәм "Мәгариф"нең 1993 елгы 4—11 нче саннарыннан танышырга була.)



"Мәгариф" журналының чыга башлавына 90 ел тулган бу көннәрдә аның төп дирижерларының—баш мөхәррирләренең кайберләрен искә алып узу да урынлы булыр, дип уйлыйбыз. Әйткәнебезчә, "Мәктәп"нең җаваплы мөхәррире—Шиһаб Әхмәров, 1918 елда ул журналның дәвамчысы—"Мәгариф"нең баш редакторы Галимҗан Ибраһимов була. Күренекле журналист, мәгариф халык комиссары Шәһит Әхмәдиев аңа зур ярдәм итә, журналның 1 нче санында ук аның да мәкаләсе басыла.

1921 елның апрелендә "Мәгариф" яңадан чыгарыла башлагач, аның мөхәррире итеп—Вәли Шәфигуллин, җаваплы сәркатибе итеп Мөхәммәтхан

Фазлуллин билгеләнә. Аннары Гаяс Максудов (1923—1924 елларда), мәгариф халык комиссары Мөхәммәт Таһиров (1925), Н. Мөхетдинов (1927), И. Габдрәшитов (1937), Г. Бакиров (1937), Ш. Башкиров (1937), М. Вәлидова (1938—1941), Хәсән Хәйри (1949—1950), Ф. Махиянов (1951—1960), Ф. Ибраһимов (1960— 1977), В. Зыятдинов (1977—1989) кебек педагоглар, журналистлар әлеге катлаулы, бик тә җаваплы, кыен эшне әйбәт кенә башкаралар.

* * *

Гомумән, "Мәгариф" журналы да чорыбыз белән бергә, сикәлтәле юллар үтте. Әмма ул укытучыларга, тәрбиячеләргә, мәгариф хезмәткәрләренә, яшь буынга һәрчак тугрылыклы булып калды, үз кыйбласын югалтмады. Аларга мөмкин кадәр педагогик-методик ярдәм күрсәтте, алдынгы тәҗрибә мөнбәре булды, укыту-тәрбия эшендәге яңалыкларны, үзгәрешләрне, шулай ук фән казанышларын үз вакытында яктыртып барырга омтылды.

"Мәгариф"нең беренче саннарында ук укыту-тәрбия эшен заман таләпләренә җавап бирердәй итеп оештыру, аны яңа рухта алып бару, мәктәпнең тормыш белән элемтәсен ныгыту, укытучыларның белемен һәм педагогик осталыгын күтәрү, хөкүмәтнең мәгариф өлкәсендәге сәясәтен пропагандалау мәсьәләләре шактый киң яктыртылган. Ул мәкаләләрдә мәктәпләрдә тупланган беренче уңай тәҗрибәләр, балалар һәм яшүсмерләргә гомуми башлангыч белем бирүне гамәлгә ашыру, ана телен укыту, татар алфавитын, орфографиясен, терминологиясен камилләштерү, яңа укыту планнары, яңа программалар һәм дәреслекләр төзү мәсьәләләре һ. б. белән танышырга мөмкин.



*«Мәгариф» журналы хезмәткәрләре. 2002 ел.*

Утызынчы елларда—яңалифкә күчү, укый-яза белмәүчеләр һәм аз белемле укучылар белән эшләү, укыту-тәрбия эшенең сыйфатын яхшырту, аерым фәннәрне ничек укыту турында киңәш-тәкъдимнәр, дәреслекләрне стабильләштерү, мәктәпләрнең матди нигезен ныгыту мәсьәләләре турындагы мәкаләләр зур урын алган.

Илленче—алтмышынчы елларда да журналда мәгариф өлкәсендәге иң җитди проблемалар, алдынгы педагогик тәҗрибә киң яктыртыла, методик киңәшләр бирелә. Илленче еллар ахырында "СССРда мәктәпнең тормыш белән элемтәсен ныгыту һәм халык мәгарифе системасын тагын да үстерү турында

Закон" кабул ителгәч, мәктәпләрне үзгәртеп кору, укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләп алып бару, фән нигезләренең ныклы үзләштерелүенә ирешү, эштә яңа методлар куллану турындагы мәкаләләргә игътибар арта.

Алтмышынчы еллар башында Казандагы 27, 85 нче, соңрак 1 нче мәктәпләрдә, укытуда яңа методлар, ысуллар кулланып, укучыларның танып-белү активлыгын, мөстәкыйльлеген үстерү, дәресләрнең нәтиҗәлелеген күтәрү юнәлешендә галимнәр ярдәмендә фәнни-тикшеренү эшләре киң җәелдерелә. Бу эшләрнең уңай нәтиҗәләре Казанда гына түгел, республика мәктәпләрендә дә киң яклау таба. Ул тәҗрибә, "Совет мәктәбе" журналы аша илебездәге башка республикаларга, өлкәләргә дә барып ирешә.

Алтмышынчы еллар урталарыннан башлап, укыту-тәрбия эшенең нәтиҗәлелеген күтәрү, укучыларның танып-белү активлыгын үстерү, татар теле һәм әдәбиятын укытуны камилләштерү, программалаштырылган укыту, дәресләрдә техник чаралардан файдалану һ.б. шундый мөһим мәсьәләләргә багышлап, республика фәнни-гамәли конференцияләре узды. Математика укытучыларының Бөтенроссия конференциясендә иң алдынгы тәҗрибәләр гомумиләштерелде. Бераз соңрак проблемалы укыту, яңа дидактик система буларак, киң педагогик җәмәгатьчелеккә танылды. Бу эшләрдә, һичшиксез, "Совет мәктәбе" (хәзерге "Мәгариф") журналының өлеше гаять зур булды. Һәр яңалык аның битләрендә киң яктыртылды, шулай итеп, барлык татар мәктәпләренә барып ирешә торды.

Җитмешенче—сиксәненче елларда да укыту-тәрбия эшендә үзгәрешләр, яңалыклар күп иде.

Туксанынчы еллар башында Татарстан Республикасы суверенлыгы турында Декларация кабул ителгәч, мәктәпләребез тормышында, укыту-тәрбия эшен оештыруда, милли мәктәпләрдә аның кыйбласын билгеләүдә, Татарстан Республикасы халыкларының телләре турындагы Законны гамәлгә ашыру барышында яңалыклар, укытучыларга, тәрбиячеләргә ирештерелергә тиешле мәгълүматлар, төрле төрдәге мәктәпләрдә татар телен һәм әдәбиятын укыту алымнары, ысуллары турындагы методик киңәшләр бинаһая булды. Аларның һәммәсе дә диярлек журналда киң чагылыш тапты.

Сезне 1992 елда ук журнал турында әйтелгән бер фикер белән таныштырып узасы килә:

"Мөгаллимдер мөгаллимгә,
Киң күңелле бер җан ул.
Чибәргә дә нур өстәүче
Җәүһәр таштан мәрҗән ул",—

дип әйтәсе килә "Мәгариф" журналы турында.

Әле дә хәтеремдә: татар мәктәпләрендә булганда, укытучылар фәнни һәм методик эшкәртмәләрнең юклыгы турында моң-зар белән сөйлиләр иде. "Ярый әле үз журналыбыз бар. Сулыш алырга һава ничек кирәк булса, эшебездә ул да шулай кирәк",—диләр иде...

... 1990 елның 30 апрелендә журнал тарихында матур бер вакыйга булды: Татарстан Республикасы Хөкүмәте аны үз канаты астына алды, ягъни журналны оештыручыларның берсе булуы турында карар кабул итте. Шул ук елның сентябреннән, редакциянең хезмәт коллективы тәкъдиме белән, журнал үзенең иң баштагы исемнәренең берсе—"Мәгариф" дип чыга башлады.


Туган тел һәм әдәбиятны, төрле фәннәрне укыту, класстан тыш эшләр оештыру мәсьәләләрен күз уңында тоту белән беррәттән, "Мәгариф" балалар бакчаларында һәм гаиләдә сабыйларга тәгълим-тәрбия бирүчеләргә ярдәм күрсәтү кирәклеген дә онытмый. Алар өчен журналда "Мәктәпкәчә тәрбия" дигән махсус бүлек бар. "Сезгә, әти-әниләр, мөгаллимнәр" рубрикасында һәм башка бүлекләрдә урнаштырыла торган мәкаләләрдән дә алар уңышлы файдаланалар.

Кыскасы, "Мәгариф" бик күптөрле мәсьәләләрне яктырта, һәркем диярлек аннан үзен кызыксындырган сорауларга җавап таба ала, дип уйлыйбыз. Туган телебезне, әдәбият һәм тарихыбызны, мәдәниятебезне өйрәнүгә кызыксыну нык көчәя барган хәзерге шартларда "Мәгариф"не укучылар саны тагын да артыр, дигән ышаныч редакция хезмәткәрләренә, журнал белән язышып торучы зыялыларыбызга көч-куәт, яңа дәрман бирә.

Kitap kuzətu
Китап күзәту

# ХӘЗИНӘДӘ—АЛТЫН БӨРТЕКЛӘРЕ

Татарстан Фәннәр академиясе каршындагы Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының яна һәм иң яна тарих бүлеге мөдире тарих фәннәре докторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Равил Әмирханның исеме киң катлау Татарстан зыялыларына гына түгел, читтә яши торган милләттәшләребезгә дә билгеле. Киң колачлы бу галимнең «төп» иҗат юнәлеше XX гасыр башы татар милли матбугатын өйрәнү. Шул ук вакытта аның Казанда чыккан рус матбугаты турында да әһәмиятле һәм күләмле хезмәтләре бар.




Кыскасы, галимнең иҗат офыклары киң һәм ул еллар үткән саен киңәйгәннән-киңәя генә бара. Төп юнәлештәге эзләнүләре белән берррәттән, Равил Әмирхан тагын революциягә кадәрге хакимият чорында татарларда халык мәгарифе, милли югары уку йортлары проблемалары, 1905—1907 еллардагы революция тарихы һәм аның белән бәйләнешле рәвештә үсеш алган татар иҗтимагый-сәяси фикере, культурасы, дәүләтчелек тарихы, татарларның милли азатлык көрәше, вөҗдан иреге, милли фикерләр язмышы, катнаш никахлар турында да күп язды. Шул ук вакытта ул тел, әдәбият мәсьәләләре хакында да тирән фикерле йөрәккә үткәреп язылган мәкаләләр бастырды. Кадерле мираска әйләнгән, Казан каласының борынгылыгын раслаган тарихи һәйкәлләр—йортлар, урамнар, мәйданнар турында да мәкалә артыннан мәкалә иҗат итте.

Равил Әмирхан халкыбызның иҗтимагый фикере һәм культурасы өлкәсендә эшләп шөһрәт алган Х. Әмирхан, Г. Баруди, Г. Еникеев, С. Максуди, Г. Исхакый, Ф. Туктаров, Ш. Мөхәммәдев, Ф. Әмирхан, Г. Тукай, М. Бигиев, З. Бигиев, Г. Әхмәров, И. Камалов, И. Әмирхан, М. Гали һ. б. турында язып, алар биографиясендә әле халыкка билгеле булмаган үзенчәлекләрне ачты. Бу затлы исемнәр йолдызлыгында Р. Фәхретдин һәм З. Вәлиди кебек олуг шәхесләр дә бар; галим аларның тормышларын һәм игелекле иҗатларын тасвирлаган берничә китап һәм күп санлы мәкаләләр бастырып чыгарды.

1980 еллар уртасында Равил Әмирхан житлеккән, мәртәбәле тарихчы-галим булып житеште; татар халкының күп гасырлык рухи-мәдәни мирасын, тарихын, шөһрәтле зыялыларын барлау күзлегеннән язылган хезмәтләренең саны 500 дән артып китте. Шуларның унбишкә якыны—китап-монографияләр.

Менә тагын безнең китап киштәләребездә Равил Әмирханның әле күптән түгел генә дөнья күргән «Революциягә кадәрге татар матбугаты (Көнчыгыш—көнбатыш контекстында. Рус культурасы үсеше мисалында)»[1] дип аталган чираттагы хезмәте урын алды. Китапның «Кереш» өлешендә автор, үткәннәр тәҗрибәсеннән чыгып киләчәккә атлауның никадәр кирәк

---

[1] **Равил Әмирханов**. Революциягә кадәрге татар матбугаты (Көнчыгыш—көнбатыш контекстында. Рус культурасы үсеше мисалында). Таткитнәшр, Казан, 2002, 240 б.

һәм урынлы икәнлеген, бер геополитик, икътисади һәм рухи яссылыкта яшәгән халыкларның бай тарихи мирасларын житди итеп, өр-яңадан анализлауның зарури булуын дәлилли. Ул монархчы әле житәрлек дәрәжәдә күтәрелмәгән катламнарны намус белән кадерләп өйрәнү һәм шул нигездә «тарих белән» тәрбияләү принцибын мөмкин кадәр тулырак, үтемлерәк итеп гамәлгә кертүнең бүгенге көн таләбе икәнлеген раслый. Бигрәк тә күп милләтле Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы шартларында бу культураларның варисларын, ягъни безнең чордашларыбызны интернациональ, патриотик һәм әхлакый-эстетик яктан тәрбияләүне үзәк мәсьәләләрнең берсе итеп күтәрә.

Әйе, XX гасыр башында, бигрәк тә 1905—1907 елгы революциядән соң, дөнья цивилизациясе хәзинәләре белән актив рәвештә таныша башлаган татар милләтенең рухи мирасын жентекләп өйрәнүне галим үзенең иҗади максаты итеп куйган. Татар халкы үзенең прогрессив интеллигенциясе эшчәнлеге нигезендә төрле халыкларның һәм илләрнең культура тәҗрибәләренә тәнкыйди күзлектән һәм новаторларча карап фикер йөртә алган. Житлеккән бөек культура, автор бик дөрес ассызыклаганча, милли чикләргә һәм тел киртәсенә карамыйча, һәркемнең йөрәгенә үтеп керә һәм аның күнелен яулап ала. Галимнәр фикеренә караганда, XX йөз башында татар әдәбияты шундый югарылыкка күтәрелә ки, аның бөтен дөньядагы әдәби процессына кушылып китүе бәхәссез күренеш-факт итеп бәяләнә.

Туган телдә басма сүз булдыру өчен тырышлык гасыр дәвамында алып барылган һәм 1905—1907 еллардагы революциядән соң барлыкка килгән татар матбугат басмалары бу фалның күркәм нәтиҗәсе булып торганнар.

1905—1907 еллардагы революция дулкынында иҗадилыкка юнәлеш алган яңа буын интеллигенция вәкилләре фикеренә караганда, бөтен дөнья культурасы казанышларын үзләштерү нигезендә милли культура алга таба тагын да үсә һәм чәчәк ата. Моңа дәлил итеп галим Г. Ибраһимов фикерен мисал итеп китерә: «Безгә Гомер, Данте, Шекспир, Шиллер, Гете, Байрон... кебек гений-бөекләрнең тәржемәләре кирәк... Милли кабыгыбызда тончыгырга теләмәсәк, гомумкешелек культурасы казанышларына таянып, акылыбызны һәм фикерләребезне аның сүнмәс уты белән яктыртырга теләсәк, бу тәржемәләрдән башка берничек тә алга китеп булмый».

1905—1907 еллардагы татар матбугаты чын мәгънәсендә кин кырлы, универсаль була. Гасыр дәвамында (1808 елдан) кара көчләр белән алып барылган максатчан көрәш нигезендә һәм революция дулкынында туган татар матбугат басмаларының татар мәнфәгатьләрен кайгыртуын, әмма шул ук вакытта татар зыялыларының төрки телле тугандаш башкорт, казакъ h.б. халыкларның да милли проблемаларын, ижтимагый һәм рухи ихтыяжларын калку һәм тирән итеп чагылдыруны намус эше итеп санаганлыгын автор матур мисалларда нигезли. Төрле сәяси, иҗтимагый, икътисади, рухи-дини h.б. кыйблалар тотып, төрле партия, сыйныф, клан-корпоративлар эшчәнлеген үз итеп дөнья күрүләренә карамастан, газета-журналларның житди матбугат басмалары буларак, кеше эшчәнлегенең бөтен якларын дөнья цивилизациясе, бигрәк тә интеллектуаль яктан алга киткән милләтләр дәрәҗәсендә хәл итү мәсләгендә бер яссылыкта торганлыгын галим инкяр итеп булмаслык дәрәҗәдә дәлилли. Татар матбугатындагы фикерләрнең төплелеге һәм төрлелеге (плюрализм) татар менталитеты өчен хас булган уңай күренеш дип бәяләнә.

Шул ук рәвешле революциягә кадәрле татар матбугатын төрле яклап комплексны өйрәнү галимгә, томаналыгы сәбәпле татар жәмгыяте үз эченә бикләнеп яшәгән, ябык тормыш алып барган, дини фанатизмга бирелеп, христиан Ауропасы һәм рус культурасы кыйммәтләрен кире каккан дигән уйдырманы жилгә очырырга мөмкинлек биргән. Равил Әмирхан тикшеренүләре күрсәткәнчә, XIX гасырның икенче яртысында ук татар жәмгыяте кызу темплар белән дөнья цивилизациясенә катнашып китә. Мондый кинәтлек белән Аурупа һәм урыс культурасына эшмәкәрлек дөньясына килеп керүнен кайбер күренешләре хәзерге заман кешеләрен дә гажәпләндерерлек дәрәҗәдә барган. Әйтик, татар сәүдә капиталы Аурупа һәм дөнья базарларына үтеп керә, көнбатыш илләрендә төрле типтагы идарәләр ачыла (Сәйдәшевләр, Хөсәеновлар, Казаковлар h. б. эшчәнлеге моңа ачык мисал булып тора). Коммерция-сәнгать һәм интеллигенция вәкилләренен байтагы (мәсәлән, И. Гаспринский, З. Рәмиев, Ф. Кәрими, С. Максуди, М. Алмаев h.б.) «кояш батышы илләренә» юл алалар, көнбатыш илләренен фәнни-техник һәм интеллектуаль тәжрибәләрен өйрәнәләр, сәяхәтләре һәм күргәннәре турында китаплар бастырып чыгаралар. Күп кенә

яшьләр Бохара, Төркия, Сүрия, Мисыр кебек традицион мөселман илләренең генә түгел, Аурупа һәм «Океан арты» илләренең югары уку йортларында укый.

Әйткәнебезчә, 1905—1907 еллардагы революция ташкыны тагын да алга сикереш ясар өчен зур этәргеч була һәм йөзәрләгән татар зыялылары Париж, Льеж, Лейпциг, Фрайбург, Нью-Йорк, Сан-Франциско, Вальпараисо, Токио һ. б. шәһәрләр университетларында һәм колледжларында белем алалар (Г. Максудов, Г. Сәгъди, Х. Фәйзи, М. Бигиев, З. Кадыйри, З. Камали, Г. Бубый, И. Камалов, И. Рәмиев, Х. Байбулатов, И. Әмирхан, М. Кәримбаев, Г. Кәримов һ.б.). Париждагы данлыклы Сорбонна университетын ир-егетләр генә түгел (Й. Акчура, С. Максуди), ә бәлки кайбер хатын-кызлар да (С. Шакулова) тәмамлый. С. Сыртланова, М. Габдрахманова Женева университеты дипломын алалар. Шулай ук Россиянең классик гимназияләрендә, укытучылар хәзерләү институтларында төрле профильдәге махсус уку йортларында һәм иң югары дәрәҗәдәге университетларда йөзәрләгән татар егетләре һәм кызлары белем алганнар.

XX гасыр башында татар интеллигенциясе вәкилләре алты-җидешәр тел белгәннәр. Ф. Кәрими, Һ. Максуди татар, рус, төрек, фарсы, гарәп, француз һәм башка телләрдә иркен сөйләшкәннәр. Ф. Әмирхан исә көнчыгыш телләрен белү өстенә, француз телендә әйбәт анлашкан Г. Тукай немец телен өйрәнүдә уңышларга ирешкән.

XX гасыр башында «Мөхәммәдия», «Иж-Бубый», «Хөсәения», «Галия», «Рәсүлия», «Касыймия» милли һәм алдынгы фикерле мәдрәсәләр үз укучыларына дөньяви белемнәр дә биргәннәр. «Хөсәения», «Иж-Бубый» кебек кайбер мәдрәсәләрдә рус, гарәп, фарсы телләре белән беррәттән немец һәм француз телләре дә укытылган. Бу мәдрәсәләрдә рус теле укытуга зур әһәмият бирелә, мәсәлән, Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең урта сыйныфларында рус теле атнага алты сәгать укытыла, ә авыл мәдрәсәсе «Иж-Бубый»-да ул 12 сәгать укытылган. Шушындый мәгълүматлардан соң татар халкының милли чикләнгәнлеге, дини хорафатларга ябышып ятканлыгы, уку йортларында христиан диненә карата тискәре мөнәсәбәтләр булу турында сөйләү һәм язу татар тарихы үсешенә яла ягу булыр иде дип, нәтиҗә ясый галим.

Әйе, революциягә кадәр дә татар халкы грамоталы булган. Бу хәл Казан губернаторлары, уку округы инспекторлары хисапларында чагылыш таба. Грамоталы булган татар халкы газетә һәм журналлар, гомумән, матбугат аша яңалыклар белән танышып бара, чорның, дәвернең алдынгы күренеш-фикерләрен «йотып» торган.

Шул рәвешле, татар халкының Аурупа дәрәҗәсендәге белемле, интеллектуаль яктан алга киткән һәм хәзерлекле катламы барлыкка килгән. 1905—1917 еллардагы татар матбугаты үз халкын кешелек җәмгыятенең алтын баганалары исәпләнгән Аристотель, Сократ, Платон, Декарт, Дефо, Скотт, Кант, Данте, Гегель, Гете, Шиллер, Мольер, Эдисон, Руссо, Байрон, Мопассан, Спенсер, Гюго, Гейне, Бэкон, Сенкевич, Дойль, Андерсен, Тагор, Ибн Фазлан, Нәваи, Хәйям, Әбүгалисина, Аверроэс, Ибн-Баттута, Ибн Арабшах, Ибн Халдун, Хамави, Физули, Фараби, Низами, Ширази, Истахри, Бируни һ. б. бөекләрнең тормыш юлларын һәм иҗади эшчәнлекләрен яктырткан.

Әстерханда чыккан «Идел» газитәсе, мәсәлән, үзенең бер санында, редакция фикеренчә, татарлар белергә тиешле Аурупа язучыларының, галимнәрнең һәм фикер ияләренең исемнәрен бастырып чыгара. Менә алар: Гомер, Пифагор, Ксенофонд, Сократ, Теофраст, Фукидид, Эсхил, Софокл, Еврипид, Аристофан, Плутарх, Цицерон, Сенека, Марк Аврелий, Тацит, Тит Ливий, Гороций, Шекспир, Локк, Ньютон, Юм, Гиббон, Адам Смит, Маколей, Вальтер Скотт, Лейбниц, Кант, Гегель, Гете, Шиллер, Монтень, Декарт, Боссюэ, Мольер, Корнель, Расин, Монтескье, Жан-Жак Руссо, Гизо, Тьер, Тьери, Вильмен, Мест, Мишле, Жюль Симон, Бартелеми, Тассо, Петрарка, Макиавелли, Данте, Сервантес, Франклин.

Татар матбугаты, чыгышы белән төрки һәм мөселман дөньясы «баласы» буларак, географик һәм рухи яктан ул ике бөек цивилизация—Көнбатыш һәм Көнчыгышның дөньякүләм танылган кыйммәтләрен тоташтыра торган үзенә күрә бер кыйммәтле күпер вазифасын үтәгән. Галим, бу ике мәдәниятнең татар матбугатында чагылышын әтрафлы итеп күрсәтә алган.

Автор шушы рәвешчә 1905—1917 елларда нәшер ителгән татар матбугатын күздән кичерә, патша цензорларының һ.б. күзәтчеләрнең татар матбугатына мөнәсәбәтеннән өзекләр китерә, үзенә кадәр бу өлкәдә эшләгән галимнәрнең теманы

өйрәнүгә керткән әһелләрен тәфсилләп анализлый. Бу очракта ул Г. Ибраһимов, Ф.-С. Казанлы, Ж. Вәлидов (Ж. Вәлиди), С. Атнагулов, Г. Сәгъди, И. Рәмиев, Васильев һәм М. Корбут, С. Таһирова, А. Рәхим, А. Сафаров, С. Залкинд, Е. Чернышев, М. Г. Халитов (Г. Халит), М. Гайнуллин, Р. Нәфыйгов, К. Фасеев, Р. Хәкимова, Х. Хәсәнов, А. Беннигсен һәм Ш. Лемерсье-Келькеже, Е. Бушканец, Ф. Гыйльманова, И. Таһиров, Р. Вәлиев, И. Нуруллин, Ә. Кәримуллин, Ш. Садретдинов, Р. Нуруллина, У. Гыймадиев, Э. Нигъмәтуллин, Р. Мөхәммәдиев, Ф. Газизуллин, М. Госманов, Ф. Әгъзамов, М. Мәһдиев, Д. Госманова һ. б. хезмәтләренә таяна. Үзе файдаланган чыганакларны санап үтә һәм алдына куйган максатын ачык итеп аныклый.

Аңлашылса кирәк, монографиянең төп бурычы: 1905—1917 еллардагы татар матбугатында дөнья күргән материаллар нигезендә рус культурасы тарихын өйрәнү. Төп бурычтан чыккан максат: милли проблемалар кысасында гомумән татар җәмәгатьчелеге, шул исәптән аның матбугаты хакында тудырылган милли чикләнгәнлек турындагы мифны юкка чыгару. Кыскача ул түбәндәгеләргә кайтып кала:

—матбугат булдырудагы тырышлыклар һәм көрәш барышы тарихын, аның беренче адымнарын, алга үсешенең төп этапларын, нәшер ителгән гәзитә һәм журналларның таралыш ареалларын билгеләү;

—идея юнәлешләре буенча басма матбугатка гомуми сыйфатлама бирү һәм классификация ясау;

—рус культурасының әдәби-публицистик һәм философик проблемаларын яктырту;

—рус сәнгате мәсьәләләрен анализлау;

—мәгариф һәм фән проблемаларын тикшерү.

Кыскасы, галим куйган проблемалар зур һәм җитди, әлбәттә. Аларны анализлау, төбенә төшү өчен гарәп графикасын әйбәт белү, сабырлык һәм зур хәзерлек зарур. Ә галим бу сыйфатларга тулысы белән ия.

Беренче бүлектә галим татар матбугатының тууын, аның беренче адымнарын, аякка басуын, матбугат үсешенең төп этапларын һәм таралыш ареалларын ачыклый.

Шунысы игътибарга лаек, татар матбугатын булдыру хәстәре рус интеллигенциясенең алдынгы карашлы шәхесләре тарафыннан да күрелгән. Казан университеты профессоры М. И. Запольский, Казан университетының көнчыгыш бүлегендә белем алган М. Г. Никольский, Эчке эшләр министрлыгында тәрҗемәче булып эшләгән, коллежский асессор П. И. Пашино, Азиат департаменты тәрҗемәчесе, христианлык кабул иткән гарәп И. Нафаль, рус армиясе капитаны В. С. Курочкин әнә шундыйлардан.

XIX гасырның 60 елларыннан башлап, татар матбугатын булдыру өчен татарлар үзләре дә көрәш мәйданына керeп китәләр. Алар арасында мәгърифәтче К. Насыйри һәм литография хуҗасы М. Яхин, Х. Фәизханов, А. Котлыяров, С. Әхмәров, Г. Ильяси, Г. Гаязитов, З. Бигиев, О. С. Лебедева, Ш. Әхмәров, Х. Максудов, И. Терегулов, З. Таһиров, Г. Апанаев, А. Г. Ильяшенко, Х. Сосновский һ. б. бар.

XIX гасырда Эчке эшләр министрына, Матбугат эшләре буенча баш идарәгә, Санкт-Петербургның цензура комитетына, Казан губернаторына татарча гәзитә һәм журналлар бастыру мөмкинлеге сорап 20 үтенеч кәгазе (прошение) язылган. Шуларның берсенә дә унай җавап бирелмәгән.

XX гасыр башында, ягъни 1905 елда күтәрелгән революция дулкыны татар матбугаты барлыкка китерү өчен бәрәкәтле җирлек тудыра. 1907 елда Россиянең 7 шәһәрендә 28 атамада басма матбугат дөнья күрә, шуларның 18е гәзитә, 10 атамалагысы журналлар исәпләнә. 1905—1917 елларда илдә барлыгы 100 дән артык гәзитә һәм журнал чыгып килә. Бу елларда 18 мең татар кешесенә бер басма туры килә. Татарлар илнең төрле төбәкләренә сибелгәнгә күрә, матбугат басмалары таралуның географиясе искиткеч киң була. Бер «Әлгасрелҗәдит» («Яңа гасыр») журналы гына да 76 торак пунктына таралган: Алушта, Әстерхан, Барнаул, Бакчасарай, Бөре, Алабуга, Зайсан, Казан, Кузнецк, Кустанай, Оренбург, Орск, Пермь, Петропавловск, Ростов, Самара, Саратов, Сембер, Троицк, Тургай, Төмән, Уфа, Феодосия, Чимкент, Чистай, Царицын һ. б.

Бу бүлектә галим милли матбугатны идея юнәлеше ягыннан бүлүгә зур игътибар бирә. Ул кабул ителгән дүрт идея юнәлешен (социаль-демократик, революцион-демократик, либераль-буржуаз, төрле вариантлары белән клерикаль-монархистик) татар матбугатын сыйфатлау өчен җитәрлек түгел дип саный һәм үз классификациясен тәкъдим итә. Автор классификациясе җиде идея юнәлешне үз эченә

ала: 1) социал-демократик; 2) революцион-демократик; 3) радикаль-демократик; 4) либераль-демократик; 5) либераль-буржуаз; 6) чамалы-консерватив; 7) консерватив (клерикаль-монархистик). Автор матбугат басмаларының шушы юнәлешләрнең кайсына булса да хезмәт итүләрен күрсәтә, дәлилли. Бу юнәлешләр Россиядә барган сәяси вәзгыятьне чагылдырулары белән дә зур әһәмияткә ия.

«Рус культурасының әдәби-публицистик проблемалары» дип аталган икенче бүлектә автор татар җәмәгатьчелеге һәм, аерым алганда, аның матбугаты турында таратылган милли чикләнгәнлек, тарлык, искелеккә, дини фанатизмга ябышып яту кебек уйдырмаларны матбугаттагы күп фактик материаллар нигезендә юкка чыгара, каләм тибрәткән татар интеллигенциясенең югары интеллектуаль дәрәҗәгә ия икәнлеген матур итеп, тыныч кына, осталарча күрсәтә. Интеллектуаль хәзерлекнең югарылыгын дәлилләү өчен автор татар матбугатында чагылыш тапкан, XVIII гасырдан XX гасырның башларына кадәр булган хронологик кысалардагы рус культурасының әдәби-публицистик, философик проблемаларын, рус сәнгатенең, мәгарифе һәм фәненең төрле аспектларын беренче тапкыр тарихи динамикада яктырта.

Татар матбугатында Лев Толстой турындагы мәкаләләрнең саекмас чишмәдәй бик күп басылып чыгуын автор, татар фикер ияләренең иҗтимагый һәм интеллектуаль яктан тәмам житлегүеннән, бөек каләм остасы иҗатының гуманлыгын, гаделлеген, кеше анының югары дәрәҗәгә житүен күрүләре, ягъни күңел күзләренең «жете»ләнүен тасвирлый торган бер фал, дигән нәтиҗәгә килә. Бу бүлектә галим 1905—1917 еллардагы татар матбугатында рус әдәбияты, дини фәлсәфи фикер үсеше тарихын, проза, публицистика, драматургия, театр халәтен яктырта. Толстойның татар җәмәгатьчелегендә гаҗәп дәрәҗәдә популярлыгы мәсьәләләрен күтәреп чыгуны һәм хәл итүне тәфсилләп нигезли. Матбугат басмаларында шактый гына фикер каршылыклары булуга да карамастан, алар замананың көн кадагына суга торган кардиналь мәсьәләләрен хәл иткәндә, рухи тормышның яна агымнар белән баетылуында, гомум кешелек культурасы нормалары үрнәкләрен тарату трибунасы вазифасын әйбәт башкарганнар дигән нәтиҗәгә килә автор.

«Рус сәнгате мәсьәләләре» дип аталган өченче бүлектә автор музейлар, «күргәзмәләр» һәм архитектура һәйкәлләре—сәнгать турындагы мәкаләләрне анализлый.

Татар матбугаты рус сәнгатенең иң әһәмиятле өлкәләре белән кызыксынып тора. Бу кызыксынуның нәтиҗәсе булып матбугат битләрендә сәнгатьнең барлык төрләренә багышланган күп санлы мәкаләләр басылып чыгу тора. Мондый мәкаләләр халыкны сәнгать өлкәсендә тәрбияләү өчен гаять әһәмиятле булганнар. Татар укучысы бу мәгълүматларга таянып, классик культураның башлангыч чорлары белән танышу мөмкинлеге ала. Шул ук вакытта халык шушы белемнәргә нигезләнеп, үзенең милли культурасы турында житди итеп уйлана ала, гомумкешелеккә һәм аерым милли даирәләргә хас кыйммәтләргә күпер сала. Матбугат битләрендәге мондый чыгышлар халыкны тәрбияләү өчен бик тә зарур булган.

Дүртенче бүлек матбугатта яктыртылган мәгариф һәм фән мәсьәләләренә багышланган. Чор белән бергә атларга теләгән татар интеллигенциясе игътибар үзәгенә Мәскәү университеты турындагы тәфсилле мәгълүматларны үрнәк итеп ала. Шул ук вакытта бу бүлектә укытучылар хәзерләү институтларының, медицина училищеларының эчке тәртипләре һәм эшчәнлекләре дә яктыртыла. Татар халкы сату-алу белән шөгыльләнергә яратканлыктан, яшьләр сәүдә һәм авыл хуҗалыгы мәктәпләренә дә чакырылалар.

Болардан чыгып без шуны әйтә алабыз: бу хезмәтне галим иҗатының «төп» юнәлеше, ягъни XX йөз башындагы татар милли матбугатын өйрәнүенең чираттагы игелекле һәм гаять дәрәҗәдә фәнни-теоретик югарылыкта язылган бер күркәм нәтиҗәсе дип бәяләргә нигез бар. Нигез—китаптагы мәгълүматларның урнаштырылуы, эчтәлеге һәм эчтәлекне укучыга житкерү ысулы. Татар мәдәниятында әлегә кадәр билгеле булмаган мәгълүмат ташкыны матур һәм йөгерек, уйнаклап тора торган тел белән язылган. Ә иң әһәмиятле үзенчәлек шунда, галим гарәп графикасында нәшер ителгән газитәләрне «сөреп» чыккан, кирәк урында гарәп, фарсы, гомумтөрки берәмлекләр белән «шыплап» тутырылган текстларны татарчага тәрҗемә иткән һәм кулны тота торган текстологик эшне ялт иттереп, егетләрчә эшләп куйган. Китап искиткеч гүзәл, ләкин автор эшләгән «кара эш»не күзаллау гына да укучыны «тиргә батыра». Бу эшнең авырлыгын белсә дә, үзе эшләгән, аның ни икәнен үз җилкәсендә татыган кеше генә беләдер, мөгаен.

Китапның башыннан алып ахырына кадәр галим татар халкының тарихын октябрьгә кадәр басылып чыккан матбугат басмалары аркылы (матбугатның үз тарихын да!) объектив рәвештә нечкәләп һәм тәфсилләп яктырта. Татар һәм аның матбугаты тарихының катлаулы, авыр, ләкин бай, югары дәрәҗәдә икәнлеген күп мисаллар җирлегендә барлап, бер ноктага җыя. Менә шуның өчен дә бу хезмәт китап-монография булу белән беррәттән, кыйммәтле тарихи чыганак итеп тә бәяләнергә тиешле. Чөнки бу китапны мондый югарылыкта язу өчен ул беренчел чыганаклар—менәрләгән газетә һәм журналларны берәмтекләп карап, укып, анализлап-тикшереп чыккан. Әйе, бу хезмәт—татар һәм аның матбугаты тарихы турында затлы тарихи чыганак, ул татар һәм башка милләт зыялылары өчен өстәл китабы, фәнни тикшеренүләр өчен күркәм өлге булып тора.

Тау-тау газетә-журнал беркетмәләрен берәмтекләп карау һәм конспектлау, үзенә кирәк материалны бал корты сыман җыю—гаҗәеп сабырлык, түземлелек һәм игътибарлылык сорый. Галимдә бу сыйфатлар һәм затлы зыялык артыгы белән бар. Ул Ходай тарафыннан бүлеп бирелгән вакытын бушка үткәрмәгән; мәсләге—Хезмәт, Галиҗәнәп тарихка хезмәт итү. Ул Мәскәү архивларында, үзебезнең Милли архивта бик күп вакытлар «чокчынып» утырган; Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивында Фатих Әмирхан, Мөхәммәт Гали фондлары белән җентекләп танышып чыккан.

Китап галимнәргә, югары уку йортлары һәм мәктәп укытучыларына, студентларга, журналистларга, гомумән, татар халкының рухи байлыгы тарихы белән кызыксынучыларга файдалы рухи чыганак булыр дигән өметтә калабыз.

**Фирдәвес ГАРИПОВА,**
*филология фәннәре докторы.*

---

# КЕШЕ КҮҢЕЛЕ—КАРУРМАН...

Хәерле булсын, без шундый заманга килеп кердек ки, яшәгән кадәр гомеребез әллә нинди аңлаешсызлык мөһере сугылып тарихка күчеп калды, киләчәгебезне куе томан сарган, барыр кыйблабыз төн караңгылыгына кереп югала, бүгенгебез исә—саташкан, фикер-карашлар чуалган, болганчык чор—бары тик җан асрау чоры гына кебек. Исен-акылың китеп, хәйранга калып утырасың-утырасың да, яман төштән уяныргa теләгәндәй бер талпынып, кузгалып куясың. Чынбарлыкның төш кенә түгеллеген исбатлап борчу-мәшәкатьләре, күңелсез, өшеткеч хәбәрләре, өметсез күренешләре белән чираттагы көн башлана.



Андый вакытта күңел төпле сүзгә җилкәгә кагылып «яшәү дәвам итә, туган» дигән ышанычка аеруча мохтаҗ. Шундый мизгелләрдә мин җанга гел салкын өреп кенә тора торган газета мәкаләләреннән, телевизион тапшырулардан тәмам гаҗиз булып, шигырь китапларын кулыма алам. Мәктәптә укыган чагымда ук калган бер самими ышанычым бүген дә әле төсен җуймаган: шагыйрьләрне мин нигәдер пәйгамбәрләр затыннан дип кабул итәм. Алар бик күп сорауларга җавапны инде әллә кайчан тапканнардыр, заманны уятырлык, өшегән җаннарны җылытырлык сүз аларның каләм очыннан тамам-тамам дип кенә торадыр кебек. Хәер, хәзер инде мин шагыйрьләр арасында шигырьчеләр

барлыгын да, укучы күңелен адаштырып иләсләндерүче рифма калыплаучыларның сирәк булмавын да аңлый барам, төшенә киләм... Бу болганчык заман (әтием сүзләре) кысасында бәргәләнгән чагымда мин дәһшәтле тормышка тап булып та, шигъри аһәңнәрен җуймаган гына түгел, тагын да бөегрәк дәрәҗәгә күтәрелеп, Галиҗанап Шагыйрь булганнар иҗатына Коръән сүзләренә ышангандай ышанам. Ачы тормыш тәҗрибәсе аша кан-яшь, әрнү, иман ныклыгы сеңгән юлларны укыганда тормыш мәгънәсезлегеннән ике кулы салынган үзем өчен бик тә читен булып китә.

Кулыма шагыйрә Флера Гыйззәтуллинаның «Йөрәгемдә шаулый карурман»[1] дигән шигырьләр җыентыгы килеп кергәч, ничектер йокымсыраган халәтемнән айнып, сискәнүле-тетрәнүле бер хис кичердем. Шагыйрьнең иҗаты белән азмы-күпме таныш идем анысы, җырларын тыңлап хозурланганым да бар. Әмма бер үк вакытта сагышлы да, әрнүле дә, сокланулы да, сөенечле дә халдә калганым юк иде әле. Китапның соңгы битен япканда әнә шундый халәттә идем мин. Шуңа да үземнең соңгы вакытта гомер юлдашыма әверелә язган күңел төшенкелегем өчен уңайсыз булып куйды. Әмма оят түгел! Мин моны аклый да, аңлата да алам! Мин дә замана баласы!

Әле тарихка күчеп өлгермәгән XX гасырның 80 еллар ахыры—90 еллар башында «үзгәртеп кору» дигән процесска мөнәсәбәттә күрелмәгән дәрәҗәдә милли күтәрелеш булган иде. Милли-азатлык хисе кысан бүлмәләрдән, митинглардан ялкын алып республикабызның иң югары рәсми даирәләренә үтеп кергән заман иде бит ул! И-и, кинәнгән иде коргаксыган җан шул вакытта! Нинди якты өметләр уянган иде күңелдә! Ә хәзер... Мәскәү тарафыннан шомлы, җан өшеткеч җилләр исә башлагач, кителдә дә куйды шул күңел дигәннәре... Ф. Гыйззәтуллинаның китабын кат-кат укый торгач, мин тарихтан нindидер параллельләр тоя башладым. Әйе, тарих кабатлана! Фаталь рәвештә кабатлана! 1905 ел вакыйгаларыннан соң бер күтәрелгән иде бит инде халкым! Инкыйлабны милли җирлектә мәгърифәт һәм азатлык өчен көрәш программасы итеп кабул иткән иде бит татар милләте! Аннан соң кара реакция чоры башланды. Әзәрлекләүләр, башбаштаклык, тапталган милли хисләр, җимерелгән хыяллар... Тукай әрнеп, газапланып «китте җаннар азыгы һәм кайтты истибдад кире», дип бәя биргән иде ул вәзгыятькә. Күпме милләтпәрвәрләрнең күңеле сынды, өмет шәме сүнде ул вакытта! Әнә шул чакта—милләтнең асыл ир-атлары кыйбла тапмый бәргәләнгән бер заманда—халкымның ханымнары аваз салды. Тарихи факт: «Әл-ислах» газетасында *(1907 ел, 10 сан)* Маһруй Мозаффариянең «Мәшһүр хатыннар» исемле шигыре басыла. Татар хатын-кызлары исеменнән зур горурлык белән язылган бу әсәр түбәндәге юллар белән тәгалләнә:

Сездә Сәмин булса, бездә Сәминә бар,
Сездә Әмин булса, бездә Әминә бар,
Мөселманда булмаса да булмас, әмма
Башкаларда богка каршы богиня бар!

Шушы шигырьне укыгач, Сәгыйть Рәмиев гаять тәэсирләнеп «Юк, үлмим! Торам әле!» (1907) дигән рецензия характерындагы лирик прозасын иҗат итә. Шагыйрь, башлыча, анда яза:

«Барча кызыктан бизгән, барча өмидләремнән кул селтәгән, барча галәмнән аерылган, тик үләсем генә, ничек тә булса бу галәмнән китәсем генә килә иде.

Кинәттән күзем бер шигырьгә төште. Шигырьнең башы «Мәшһүр хатыннар» дип башлап, ахыры «Әль иҗтиһад мөгаллимәсе Маһруй Мозаффария» дип беткән иде.

...Ихтыярсыз җанландым. Янадан торасым килә башлады, кул селтәгән өмидләрем янадан кайттылар. Мин тагы бик зур өмидләргә чумдым.

Рәхмәт сезгә, хатыннар, мине тергездегез!»

Мин, бүгенге чор татар баласы, күңеле сынганнарга йөрәк кайнарлыгын бирергә әзер янә бер милләт хадимәсе, заман шагыйрәсе Флера ханым Гыйззәтуллинаның шигъриятенә эндәшергә киңәш итәм. Нинди язмыш сынауларын үтеп тә җанында ышаныч, өмет чырагын сүндерми, шигъри учагын сүрелдерми саф күңелен саклап кала алган Шагыйрә иҗатына чакырам. Китапка кереш сүзне авторның үзе язуы гаять тә отышлы, ул—иҗат дөньясына иң хак, иң тугры юл. Башка кеше язган—башканың сүзе инде ул! Нинди талантлы каләм булса да «йөрәгендә шаулаган карурманның» аһәңен шагыйрәнең үзеннән дә үтемлерәк итеп сөйләп булмый. Җан авазын тоеп булмый. Булмый! Тукай турында никадәрле әсәр-кыйсса язылган, әмма шагыйрьнең «Исемдә калганнар»ын уздырып бирү дә сүз әйтә алмады. Һәм алмаячак та! Бу—тормыш законы, язмыш кануны. «Совет Татарстаны язучылары» дигән биобиблиографик белешмәдә әйтелә: «Флера Гыйззәтуллина поэзиягә тормышның үзеннән бай хезмәт тәҗрибәсе туплап килгән шагыйрә». Ә ул тәэсек, йөгерек, шома сүзләр артында никадәр әрнүле борылышлар ята! «Ятимлек ачысы, Себер

[1] **Флера Гыйззәтуллина**. Йөрәгемдә шаулый карурман.—Казан: «Рухият», 2001.

шахталары, юл төзү эшләре, урман кисү газаплары...» Бөтен җаны белән талпынган шәһри Казанга сузылган озын-озак юл... Сынмаса сынмый икән адәм баласы: «Ничек кенә имәнгеч, авыр булмасын, минем һич тә үз язмышымны хурлатасым килми, чөнки мин аның хуҗасы!» Ачы язмышы белән үчләшә-бәхәсләшә йөрәк утын дөрләтә шагыйрә

Яна-яна ялкын җыйдык, акыл җыйдык,
Тирән итеп тамга уйдык яшен-хиска...
Ярдан-ярга без узасы тасма күпер
Җете зәңгәр, кызыл-сары, яшел төстә

...Әгәр кинәт төсләр уңып, нурлар сынып,
Юкка чыкса менеп килгән күперебез...
Без янадан ургып янган ялкын аша
Язмышлардан узмышларга сикерербез.

Ә инде «күкрәгендә шушындый да дуамал, кайнар холык, җыр-моң йөртә торып та, гашыйк булмау, яшәешне, тормышны сөймәү мөмкинме соң?» Бу инде бунтарьлык хисе, бу–икейөзлелек белән, хөсетлек, куркаклык, хыянәт, кара шовинизм, милли мескенлек белән аяусыз көрәшкә чыккан җан авазы.

Үз иленең иркен сөймәүчегә
Ирексезләп сүзем такмамын.
Җирдән алган җан байлыгым белән
Калкан булып үргә калкамын.
...Шигъриятең, телең, бөтен илең
Сынау «сират»ларын гизгәндә,
Илгә тиңдәш биеклектән килү
Тиештер бит инде бездән дә!

Ил тарихы, халык язмышы шагыйрә иҗатыннан аерылгысыз. Минем искәргәнем бар, туган төбәгенә урау юллар узып кайткан кешедә милли хис аеруча куәт ала, изге Ватанын сагынып яшәүчедә миллипәрвәрлек язмышыннан узар дәрәҗәдә югары була. Бу–кырыс хакыйкать. Читтә урталык юк. Яки, тамырларыңа балта чабып маңкортка әвереләсең, ипле, тук, ышыклы җан асрау юлына разый буласың, яки кыйнала-кыйнала, бәгыреңә яралар өсти-өсти, әрни-ярсый милли горурлыгыңны маяк итеп, заман караңгылыгына юл ярасың.

Флера Гыйззәтуллина шул «яки»ләрнең икенчесен кыйбла итеп алган шәхес:

Үлемсез ил җыры,
Гасырлар зынҗыры
Аерылмый моң-зарлы татардан.
Кай юлдан узсак та,
Кемгә кул сузсак та,
Сүзне без башларбыз Ватаннан.

Юллары урау булгангамы, әллә инде үз язмышын халкының сикәлтәле тарихыннан аерып карамагангамы, шәхси бәхетенә зур сынаулар аша килә шагыйрә Хәер, Ф. Гыйззәтуллина кичерешләрендә «монысы–хосусый, ә бусы–гомуми хис» диган бүлгәләүләр юк та. Шул бер бәгырь, шул бер йөрәк бит инде ул!

...Тормышны гизсәң,
Югына түзсәң,
Сау булса йөрәгең, өметең...
Кисәккә бүленми:
Җан бит ул һәркемдә
Җир шары шикелле бербөтен!

Әнә шуңа да шагыйрә тануынча: «мәхәббәт, мәрхәмәт, рухи бөеклек тормыш нечкәлеген аңлаган һәр кешедә үҗәтлек һәм нәфрәт белән янәшә килергә тиеш».

Пар аккошлы күл дә түгел минем күңел!
Сагышымда шаулый бары карурманнар...
Ал син мине,
карурманнар кичкән чакта
Хәтеремә кояш булып сарылган яр!

Тормышның каршылыклы янә бер кырыс кануны: мәхәббәт һәм нәфрәт–бербөрсен инкяр итүче ике хис–кеше җанында һәрвакыт янәшә яшиләр. Кушылырга мөмкин түгел! Аерып куярга мөмкин түгел! Нишләмәк кирәк, дөнья бу, йа! «Дөнья булгач арага хыянәт тә керергә мөмкин. Үзеңдә аның ачы газапларын кичерерлек көч тапсаң (ул кичердәй булса), аны шәфкать, миһербан белән тәрбияли алсаң, мондый мәхәббәт тә синең ышанычлы терәгеңә әверелергә мөмкин бит!»

Кавыша да аерыла парлар,
Әверелә сөю мәхшәргә
Син бит минем ярым!..
Әйт әле, әйт:
Мәхәббәтсез ничек яшәргә?

Әйе, әрнегән йөрәкне дә, әрнүләрдән теткәләнгән халык җанын да юатырга сүз таба алу–олуг шагыйрьләр язмышына гына язган. Йөрәгендә янган хисләрен шигырь юллары аша укучысына җиткерү омтылышы тарткандыр да әле шагыйрәне туган иленә Тукай рухы чакыргандыр аны. Юкка гына бу төбәкне «хаҗ кылу төбәге», «сафлану үзәге» дип атамый бит ул. Анык, ачык сәфәргә чыккан шагыйрәне бернинди көч тә туктата алмаячак. Аның җанын бөек максатлар җилкендерә:

Илләр белән якынайтып араны,
Язмышларны дәвалыйсы бар әле...

Менә исемсез бер шигырь. Укыйм. Уем-җаным аша уздырам. Кабат шигъри юлларга әйләнеп кайтам. «Язмыш миңа ятимлеген биргән...», «Язмыш миңа үги ана биргән...». Нәтиҗәсе нәфрәт тулы нәгъре булырга тиеш дип көтәм. Шигырьнең соңгы

юллары исә минем мантыйгымны чәлпәрәмә китерә:

Язмышларым—әкияттәге төсле,
Әкиятләрнең азмы чыннары?!

Йа, Хода! Нинди әкият?! Әкиятләр бит һәрвакыт әйбәт тәгәлләнәләр, аларда бит һәрвакыт ак көчләр тантана итә! Ә биредә шагыйрәнең сер бирергә теләмәвеме? Югыйсә «Ятимлек» шигырендә әйтә бит: «Ятимлек ул—кадап куйган хәнҗәр Йөрәктәге тере ярага...» Сон, шулай булгач? Бу инде зарлануудан, каргануудан арынып Кеше булып калуны аңлата. Ник дисәң:

Каралып карыйсың,
Кемнедер каргыйсың,
Нигә син кара төс сайлыйсың?
Каргышлар барыбер
Куалмый кешенең
Эченә сыймастай кайгысын.

Түбәнлекләргә, вак ыгы-зыгыларга уралмый гына якты максатлар дөньясында кала алуны дәлилли автор. Ә бу биеклеккә шагыйрәне ике канаты—хыял һәм саф сөю хисе—алып менә. Шушы ике канат аны җаны керләнүдән саклый. Әгәр инде канатлар сынаta калса...

Хыялым мине алдаса,
Чәчәген ата-ата...
Тормышның ялганы белән
Киләм якага яка.

Бу тартышта шагыйрәгә терәк булып «ил догасы» тора, шуңа да ул зур ышаныч белән «догам—куәт чыганагы» дип белдерә.

Ф. Гыйззәтуллинаның бөтен иҗаты шуны раслый: адәм баласы хыялларыннан аерылмаска тиеш! Дөрес, хыялларның да төрлесе бар. Буш, нигезсез хыяллар белән дә мавыгырга мөмкин. Алданып, шул баллы ялган тәэсирендә изрәп рәхәт чигеп тә яшәргә мөмкин. Булды, булды, шагыйрьләр дә шәп алдадылар безне. Үз ялганнарына ышана-ышана алдандылар да, алдадылар да. Ф. Гыйззәтуллина иҗатындагы хыял исә, өмет чырагын үрләтүче ышаныч буларак кабул ителә. Аның биекларны юатыр сүзе дә ачы тормыш тәҗрибәсе аша туа. Хыяллар белән җилкендергән вакытында да шагыйрә гел искәртә, һәрдаим кисәтергә ашыга: дөнья фани, фани... Дөнья кырыслыгын да тану, кабул итү зарур. Кеше шуны онытмаска тиешлеген Ф. Гыйззәтуллина күп шигырьләре аша раслый: «Чынлык», «Яфрагын коя карурман», «Яшеннәрнең күз яше», «...Бер хәсрәтсез изрәр чаклар түгел», «Йөрәгемдә—мәхшәр...», «Гомер үтте...», «Әҗәл йөге йөртәм иңемдә», «Шигъри гамь...», «Язмышлары ачы татарның» һ. б.

Ф. Гыйззәтуллина, ятимлек ачысын, сугыш чоры авырлыкларын кичкән кеше буларак бүгенге вәзгыятькә аналар күзе белән карый, сугыш уты котырган бу заманга да ачы тәҗрибә аша бәя бирә.

...Ятимне мин күз яшеннән таныйм,
Тол ананы—боеклыгыннан.
Без кичергән авыр ул еллардан
Азмыни соң илдә танышлар?
Кем күрсә дә сугыш сагышлары—
Күздән китми торган сагышлар!

Ф. Гыйззәтуллинаның яшьлегендә бәгыренә канлы төер булып оешкан сугыш ятимнәре, сугыш толлары безнең көннәрнең дә чынбарлыгына әверелде, саташкан заман тормышыбызның нигезенә ятты. Шуңа да шагыйрә җанында—бетмәс моңсулык, шигырь юлларында—әрнү, әрнү... «Заманның кинәт үзгәреп, мәхшәргә әверелүеннән файдаланып, күпме манкорт чүп-чар рифмалардан оештырып олау-олау «шигырь» тукыганда, кайбер «акыл» ияләре, куштаннар шуны хуплап һәм мактап, күкләргә чөеп укучы күңелен адаштырып иләсләндергәндә, каняшь саркып торган шигырь юлларын кабул итү читенрәктер шул... Әмма дөнья бүгенге көн белән генә чикләнмәгән, минем язмышыма охшаш язмышлар, ятимнәр, әнә чүпрә урынына күпереп үрчи...»—дип яза шагыйрә үзенең кереш сүзендә.

Ятимлек ул—кылыч!—
Милләтемнең
Борынгыдан җанын айкаган.
Күз-яшь катыш кан дәрьясы сыман
Кайгы чоңгылында чайкалам.

Замандашым! Син дә, мин дә бүген юллар чатында. Алда—карурман. Исән-имин чыга алырбызмы без ул ешкынлыктан? Ниләр көтә безне карурманнар аръягында?

Замандашым! Бу буталчык, хәвефле заманда миңа синең иңнәреңне тою бик кирәк. Карурман куркытмый мине, ялгыз гына үтәргә туры килү шомландыра, бер ялгызың бару сискәндерә. Бергә булыйк, бердәм булыйк! Бездән алда төн караңгылыгын ерып сәфәр чыкканнарның җан яктысын маяк итеп алыйк.

**Фәрит БӘШИР,**
*филология фәннәре докторы.*

Sәngәt
Сәнгать

# БАТЫРЛЫККА СУСАУ

КОМПОЗИТОР РАФАЭЛЬ БЕЛЯЛОВНЫҢ (1940—1999) ТОРМЫШ ЮЛЫ ҺӘМ ИҖАТЫ ТУРЫНДА КАЙБЕР УЙЛАНУЛАР

Мәгълүм ки, Татарстан композиторлары һәм музыка җәмәгатьчелеге арасында Рафаэль Белялов шәхесенә карата төрлечә карашлар, бер-берсенә һич тә охшамаган имеш-мимешләр яшәп килә. Бу аның иҗатына гына түгел, эшчәнлегенең башка юнәлешләренә, хәтта тормышта үз-үзен тотышына һәм дөньяга карашына да кагыла. Композиторның шәхси үзенчәлеге, татар музыкасы үсешенә кертkән өлешен аңлау, бәһаләүдәге мондый каршылыкның нигезләре дә юк түгел иде, әлбәттә. Әйе, аның иҗаты һәм тормыш юлы бигрәк сикәлтәле һәм катлаулы булды шул...

*Дөрес*, Рафаэль Белялов калдырган мирасны ул кадәр бай һәм киң кырлы дип әйтеп булмас иде. Композитор, нигездә, камера-инструменталь музыка өлкәсендә иҗат итте; ике соната, татар халык көйләренә нигезләнгән өч сюита, уннарча оригиналь пьеса һәм фортепиано өчен җиде дуэт—иҗади омтылышларының бер өлеше шуннан гыйбарәт булды. Моннан тыш скрипка һәм фортепиано өчен берничә концерт, кантата, мюзикл һәм берничә романс, җыр да аның тарафыннан тудырылды. Шул ук вакытта чын мәгънәсендә сәнгатьчә югарылыкта эшләнгән әсәрләр белән бергә, йомшаграк итеп әйтсәк, авторның бик үк камил булмаган әйберләре дә дөнья күрде.



Композиторның ана гына хис стиле турында нигезле сүз әйтүе җиңел эш түгел, чөнки аның иҗатчы буларак өлгереп җитүе озак һәм үзенчәлекле булды. Яшьлегендә ул шалтыравык додекафония белән мавыкты, аннары джазга мөрәҗәгать итте һәм соңыннан фольклорга «килеп егылды»; композитор, әйтерсең лә, үсеш юлын кире юнәлештән башлады—катлаулы сонатасимфоник әсәрләр иҗат итүдән гадирәк сюита формаларына күчте.

Рафаэль Беляловның дөньяга карашы да үзенчәлекле формалашты, ул үзенең кискен фикер-кыланмышлары һәм бер яктан икенче якка ташлануы белән күпләрне гаҗәпкә калдыра торган иде. Кырык яшьләргә кадәр композитор коммунистик идеалларны кире кагучы «нигилистик» карашлы яшьләр сафында булды, түрәләр каршында бил бөгеп яшәргә әзер торучы «малайларга нәфрәт» белән карады, әмма бишенче дистәне ваклагач, бөтенләй көтелмәгән борылыш ясады, ягъни КПСС сафларына басып, үрнәк партия әгъзасы булып китте. Әмма тиздән, партия тарала башлагач та, беренчеләрдән булып ишекне «аяк белән тибеп» ябып чыгып китте.

Озак та үтмәде, Рафаэль Белялов милли хәрәкәткә килеп кушылды, хәтта Татар иҗтимагый үзәге идарәсенә әгъза булып сайланды. Бу вакытта ул туган телен начар белә иде, татар мәдәнияте белән дә аз кызыксынды. Шуңлыктан, ахрысы, дәүләтнең милли сәясәтне үзгәртүе өчен чын күңелдән җан атып йөрүенә ышануы да кыен иде.

Дөрес, үзе белән бер сафта булмаганнарны, сәяси ялкау-битарафларны рәхимсез рәвештә камчылавына караганда, аның омтылышларының ихлас булуына ышанасы килә иде. Ул вакытта композитор танылган һәм өлкән аһәнсазларны, шул исәптән Рөстәм Яхинны да, вакытлы матбугатта тәнкыйтьләп чыкты, аны халык традицияләрен инкарь итеп, украин һәм рус аһәннәреннән файдалануда гаепләде.

Алтмыш яшькә килеп житкәндә, композитор дөньяга карашында тагын да ныграк үзгәрешләр кичерде—ул Ислам диненә мөрәжәгать итте. Монарчы актив-хәрәкәтчән яшәү рәвеше алып барган кеше кинәт кенә басынкыланып китте, хәтта әйтергә мөмкин, чынбарлыкны кабул итүендә тәкъдиргә ышану чаткылары сизелә башлады. Дус-ишләре белән аралашып-очрашкан чакларында ул «Бисмилләһир-рахмәнир-рахим» дип, мөселман халыкларының традицион сәламләшү йоласы гыйбарәсен гарәп телендә кабатларга ярата торган булып китте.

Рафаэль Беляловның шәхси тормышы исә, авыр һәм фажигале булды. Әйтергә дә куркыныч, әнисе кеше (әтисе) кулыннан китеп барды, сеңлесе үзенә-үзе кул салды, әтисе психик авыруга дучар булды, ахыр чиктә акылдан шашкан мәлендә бертуган абыйсы композиторның гомерен өзде һәм соныннан үзе дә үз теләге белән, акылдан шашкан мәлендә, теге дөньяга китеп барды. Болар турында язуы авыр, бик тә авыр, ләкин хакыйкатькә тугры булып калсак, дөресрәге, тугры булып калырга теләсәк... Нишлисең, композиторның гаилә тормышы да барып чыкмады. Башта ул гомерен житлеккән шәхес, талантлы пианистка, консерватория укытучысы, хәзер исеме бөтен дөньяга танылган композитор Суфия Гобәйдуллинаның бертуган сеңлесе Идия Гобәйдуллина белән бәйләде, аларның кыз балалары туды (булачак композиторның ижади новаторлык рухы белән яшәүче Гобәйдуллиннар гаиләсе белән аралашырга омтылуы очраклы хәл түгел иде, әлбәттә, бу аның эчке омтылышларыннан килеп чыккан нәтиҗә иде.)

Аннары яшь-яшь бер кызга өйләнде, алма кебек икенче кызы туды, ахырда... ул аларны да калдырып чыгып китте, калган гомерен исә, «картларча» тыныч кына кичереп, ыруг-нәсел дәвамчысы булырлык бер малай турында хыялланып яшәде. Әйе, аның мәгъшукалары күп иде, ләкин композиторга кабаттан гаилә корып жибәрү бәхете насыйп булмады. Гәрчә дусларына һәр яна танышын: «Ниһаять, үзем теләгән алиһәне таптым!»—дип тәкъдим итсә дә...

Рафаэль Беляловның тормышына һәм ижатына кагылышлы хәл-вакыйгаларны ул тудырган «имидж» белән бәйләп карасак, һәм композиторның сурәт-портретын кешеләр күнелендә калыплашкан тәэссоратлардан чыгып кына тергезергә тырышсак, ялгыш нәтиҗәләр ясавыбыз да ихтимал. Бу очракта Рафаэль Белялов турында сөйләгәндә, татар музыкасы үсешенә билгеле бер өлеш керткән гади бер композитор, нәселдән килгән авыру аркасында таланты ачылып житмәгән ижат әһеле дип тә котылып булыр иде. Ләкин композиторның кабатланмас шәхси рухияте үзенчәлекләренә тирәнрәк төшенә барган саен, башкачарак фикергә киләсең. Баксаң, Рафаэль Беляловтан сирпелгән күренмәс дулкыннар, гомумән, татар музыкасы үсешенә дә, аның үзен чолгап алган мохиткә да көчле вә унай йогынты ясаган икән.

Кеше жанын анларга омтылу юлында Гете тудырган фәнни нигезләмәгә таянсак, мондый нәтиҗәгә килүебезнең алшартлары үзеннән-үзе анлашыла булса кирәк. Кеше тышкы дөнья белән өч төрле ысул аша бәйләнештә торырга мөмкин дип искәртә бөек фикер иясе: биологик жан иясе буларак; эстетик кичерешләргә сәләтле шәхес буларак; ижади фикер йөртүче илаһи зат буларак. Әйтик, аерым бер шәхеснең болын буйлап жиләк-жимеш, гөмбә яисә чәчәк-үлән жыеп йөргәндә тирә-юнь белән үзенә файда эзләү күзлегеннән чыгып кына бәйләнешкә керүе ихтимал. Ләкин моннан тыш ул әйләнә-тирәнең эстетик ягына игътибарын юнәлтеп, табигать күренешләре белән хозурланырга, шуның нәтиҗәсендә күнелендә туган хис һәм кичерешләр дөньясына кереп чумарга мөмкин. Әмма Кеше дигәнең, фикер иясе буларак, үсемлекләрнең төзелешенә һәм микродөнья белән макродөнья арасындагы үзара бәйләнешләр закончалыгын өйрәнеп, чынбарлыкны танып белүдә тагын да югарырак, дөресрәге, тирәнрәк ачышлар ясауга ирешә ала. Бу очракта инде ул шәхси кичерешләр кысасыннан читкә чыга һәм шул рәвешле шәхес Яратылыш һәм Яшәеш закончалыкларын өйрәнүче сыйфатында күз алдына килеп баса; ул үзенә яна бер дөнья ача, ә бу исә физик һәм кичерешләр дөньясыннан югарырак баскычта тора.

Шушы ноктадан торып күзәтеп, Кеше үзенең биологик жаныннан тыш кичерешләр дөньясы да барлыгын ача. Үз чиратында кичерешләр дөньясының

дәвамында рухи дөнья ята; жанны нәкъ менә ул саклап, тәрбияләп тора—аны кечерешләрдән алып, кичерешләргә сала, гади күзгә күренмәгән максатларга юнәлтеп, нык ихтыярлы булырга өйрәтә. Кайчакта кирәкмәс булып тоелган газаплар һәм кайгылар кичерү, рухи дөнья кузлегеннән чыгып караганда, жанның яшәү рәвеше, табигый халәте булып торалар; физик тән-бәдәнгә физик күнегүләр ясау ничек шифалы тәэсир итсәләр, алар жанга шулай ук көч вә ныклык тупларга ярдәм итәләр.

Рафаэль Беляловның тормыш юлын һәм ижади эзләнүләрен әлеге закончалыклардан чыгып бәяләгәндә, шундый нәтиҗәгә киләсең: композиторда көчле рух, ижади жан хөкем сөргән икән. Чынлап та, көчле рухлы ижади шәхес буларак, ул үз өлешенә тигән авырлыкларны сынмыйча вә сыгылмыйча күтәреп бара алды, язмыш сынавына бирешмәде. Үзенең ижатында композитор яналык алып килергә сәләтле булуы белән бергә, жимергеч башлангычларга да ия булган куәтле агымнарга да мөрәҗәгать итте һәм, аяусыз көрәшкә чыгып, аларга Рух нуры өрә алды.

* * *

Рафаэль Белялов белән мин үткән гасырның 50 еллар ахырында, Казан музыка училищесында укыган вакытта танышкан идем. Ул өлкәнрәк яшьтә иде, мин беренче курска укырга кергәндә ул инде «танылып өлгергән» өченче курс шәкерте иде. Яшьләребез арасында шундый аерымлык булуга да карамастан, без тиздән дуслашып киттек.

Әйтергә кирәк, Рафаэль бик тә сәләтле укучы санала иде. Училищега укырга кергәнче үк ул, мәктәптә әдәбият дәресләре алып барган укытучысы Аркадий Мельников сүзләренә якты аһәнле беренче жырын ижат итеп, шәһәрнең яшь композиторлары бәйгесендә беренче урынны яулаган булган. Шуның өстенә рояльдә яхшы уйный, училищеда хәтта концертмейстер вазифасын да башкара иде. Ул күп кенә йомыкый укучы татар «композиторларыннан» аермалы буларак, кешеләр белән тиз арада уртак тел таба, очрашып сөйләшүгә үзе жай-сәбәп эзли. Төс-кыяфәтенә һәрвакыт игътибар итә, акча ягы такыр булуга да карамастан, модадан артта калышмаска тырыша: ул минем хәтеремдә балагы тарайтылган чалбар, ачык төстәге галстук, бизәкле күлмәк кигән килеш саклана. Ләкин Рафаэль шамакай «стиляга» түгел иде. Аннан көч-куәт, дәрт-дәрман бөркелеп тора. Характер-табигатендә эчке ныклык, ирләрчә буйсынмас ихтыяр да сизелә, бу исә кайбер очракларда үз фикерендә катып калганлыкка да китерә иде. Болар, үз чиратында, үзенчәлекле сыгылмалылык һәм сизгерлек таләп ителгән концертмейстерлык хезмәтендә беркадәр комачаулык та тудыра иде.

Әмма нәкъ менә эчке какшамас ныклык композиторлык һәм аерым башкаручанлык эшчәнлегендә ана ярдәмгә килде дә инде. Ул партитура өстендә тәүлекләр буе эшли, фортепиано артында сәгатьләр буе утыра ала иде. Үҗәтлек белән бергә Ходай Рафаэльгә теләсә нинди вә физик, вә рухи авырлыкларны да җиңеп чыга алырлык саулык-сәламәтлек тә биргән иде шул. Куелган максатына ирешү юлында әлеге сыйфатлар, сүз дә юк, ышанычлы терәк булдылар. Шуна күрә дә ул сәхнәгә чыгар алдыннан була торган дулкынлану, тамашачыдан, билгесезлектән «курку» кебек хисләр кичермәде дә кебек. Әйе, ихтыяр көче анда хисләрне баса килде. Гадәттә ул шау-шулы музыка тынларга ярата төште, сәгатьләр буена ижатына хас булган токката яки бию ритмы өермәсенә кереп чумарга мөмкин иде; бәхетенә күрә дигәндәй, XX гасыр музыкасының үзенчәлекле бер сыйфаты да шуннан гыйбарәт булды. Рафаэльнең ихтыяри ныклыгы, үзен-үзе һәрдаим, һәр өлкәдә сынап карарга омтылуы аның нинди спорт төре белән шөгыльләнүендә дә чагылыш тапты. Ул ерак араларга йөгерүне (һәм чаңгыда йөрүне) барыннан да өстен күрде һәм музыкантларның төшенә дә кермәгәнчә, ярышларда Казанның спорт уку йортларында укучы студентлар да көнләшерлек күрсәткечләргә ирешә.

Рафаэль белән училищеда укыган елларда башланган дуслык мин Мәскәүгә укырга китеп баргач бераз өзелеп торды. Ләкин Казанга кайтып төшүемә, без тагын бер-беребезне эзләп табыша торган идек. Шундый очрашуларның берсендә ул мина скрипка һәм фортепиано өчен язылган сонатасының кульязмасын бүләк итте. Татар музыка тарихында икенче соната иде ул (беренчесен А. Монасыйпов 1954 елда ижат итте). Ана бераз хас булганча, Рафаэль ноталарын вәкарь белән тапшырды да «тиз арада өйрәнүемне» һәм «Мәскәүдә пропагандалавымны» өмет итүен белдерде. Чынлап та әсәр башкалада башкарылды һәм минем тарафтан гына түгел. Әйтик, танылган скрипкачыларыбыз Халидә Әхтәмова һәм Зариус Шихмурзаева әлеге әсәргә күп

тапкырлар мөрәҗәгать иттеләр.

Алтмышынчы еллар ахырында Казанга бөтенләй әйләнеп кайткач, Рафаэль белән безнең дуслык яна төсмерләр алып дәвам итте. Ә аннан соңгы утыз ел эчендә мина композитор белән якыннан торып хезмәттәшлек итәргә туры килде, 70-80 елларда исә, Р. Беляловның композиторлык осталыгы аеруча киң колач алып үскән чорларда, язмыш безне бигрәк тә якынайтып җибәрде. Ул дәвердә Казанда аерым башкаручы—солист скрипкачылар бармак белән генә санарлык иде һәм шуңлыктан безгә ул иҗат иткән әсәрләрнең скрипка партияләрен бергәләп «редакцияләргә», радио һәм телевидениедә яздырырга, әлбәттә, концертларда башкарырга туры килде. Рафаэль татар композиторларыннан фортепианода иң яхшы уйнаучылардан санала иде һәм без еш кына бергәләп чыгышлар да ясадык. Безне СССРда, Россиядә һәм Татарстанда уздырылган төрледән-төрле музыка форумнарына чакыралар иде—әйе, республика композиторлар оешмасы ул елларда милли музыканы пропагандалау буенча зур эшләр башкара иде. «Җилнел аяклы» Рафаэль, әлбәттә, биредә дә өлгерлек күрсәтте, ул һәртөрле җыелма концертларда бик теләп катнашты, үзенең иҗат кичәләрен дә даими рәвештә үткәрә килде.

Җитмешенче еллар уртасында Казаннан «ябык шәһәр» дигән мөһер алып ташлангач, ана еш кына чит илләрдән дә рәсми һәм рәсми булмаган делегацияләр килә башлады һәм кадерле кунакларга концерт-тамаша хәзерләү республика композиторлар оешмасының җаваплы һәм шул ук вакытта үзенчәлекле бер шөгыленә әверелде. Чит илләрдән килгән кунакларны—алар арасында «гади халык» белән бергә сәясәтчеләр, бизнесменнар, мәдәният хезмәткәрләре дә була торган иде—күбрәк халык иҗаты үрнәкләре һәм милли музыканың заманча яңгырашы кызыксындырды. Р. Белялов татар композиторларыннан берләнбер дип әйтерлек авангард музыка тарафдары булып исәпләнгәнгә күрә, партия-совет җитәкчеләре концерт программаларына һәрдаим аның әсәрләрен дә сыендыралар иде. Әйтергә кирәк, һәртөрле музыкаль агымнарга сизгер даирә ул әсәрләрне бик тә җылы һәм тирәнтен аңлап кабул итә торганнар иде. Аларны Рафаэльнең чын Европа музыкаль алымына тартым аһәне, хәрәкәтчән, калку образлары әсир итә иде. Бер америкaн музыкантның, атаклы скрипкачы Яша Хейфец ансамблендә уйнаган альтистның, чираттагы концертны тыңлаганнан соң, үзәктән ерак бер почмакта заманча язу үрнәкләрен нечкәләп өйрәнгән шундый да үзенчәлекле талант иясен очратып гаҗәпсенүен әле дә хәтерлим. Һәм, әйтергә кирәк, Рафаэльгә мондый соклану фикерләрен аз ишетергә туры килмәде.

Шуна да карамастан, Р. Беляловның музыкасы Татарстанда, туган илендә әллә ни зур казаныш ала алмады. Йөзәр еллар дәвамында тәмам калыплашкан бер тавышлы, асылда саф пентатоника йогынтысында тәрбияләнгән милли тамашачы «мелодист» аксакалларны күнеләнә якынрак күрде. Әмма, ни генә булмасын, 60 еллардан башлап татар музыкасы стиль янарышы чорына килеп керде. Шул нәүбәттән, яшь композиторлар төрле юнәлештә эзләнүләр алып бардылар. Аерым алганда, Рөстәм Яхин романтикларның һәм импрессионистларның гармония «телен» өйрәнүгә керешге, Алмаз Монасыйпов шәрекъ музыкасына таянып янадан-яна әсәрләр тудырды, Ренат Еникеев исә ерак бабайларыбызның аһәнен үзләштерү һәм аларга яна рух өрү белән мәш килде. Шул ук вакытта аксакалларның да, яшь буын композиторларның да узган дәверләрнең эстетик карашлары белән сугарылган, асыл нигезендә кичерешләр сулышы сулкылдап торган, иске традицияләргә таянган музыка әсәрләре дөнья күрә килде.

Шушы традициягә «күкрәк куеп каршы тору» сыйфатында, татар музыкасының мәһабәт бинасын тетрәткән Рафаэль Белялов иҗаты кабынып китте. Дөрестән дә, аның музыкасы татар милли музыкасының көчле агымына килеп кушылган тын вә тыныч «ерганаклардан» үзенең кискен борылышлары белән аерылып тора иде дә инде. Авангардлык, хәтта тональләшеп җитмәгән, татар колагына читрәк тоелган аһән белән сугарылган бу музыка, күңелгә рәхәт моңсулык бирә торган сыгылмалы музыкадан аермалы буларак, ниндидер бер ят күренеш, «какофония» дип кабул ителде. Шуна да карамастан, ул яшәвен дәвам итте һәм... шул ук вакытта үткәннәргә барып тоташучы «борынгы» агымнарны шактый гына какшатуга да ирешге. Шәһәр мохитында тәгәрәп үскән һәм чын мәгънәсендә «интернациональ» тәрбия алган Рафаэль халыкчан кичерешләрне бөтен тулылыгында вә катлаулылыгында кабул итүдән ерак тора иде әле. Аның җаны, барлык вөҗүде бар булганны үзгәртеп кору, кискен борылышлар ясау рухы белән тулышкан иде дисәм, һич тә арттыру булмастыр, мөгаен. Әйе, ул җаны-тәне бер белән 50-60 еллардагы «Хрущев җепшеклеге» заманында совет музыка

сәнгатендә, боз астыннан бәреп чыккан жылым кебек үзенә юл ярган додекафония һәм джаз стиленә мөкиббән китте.

Рафаэль Белялов татар композиторларыннан беренчеләрдән булып, татар музыкасы офыкларын киңәйтеп жибәрергә сәләтле, әмма жимергеч көчкә дә ия булган хәтәр агымнарга кереп чумды. Әйтик, кичерешләрне ялангачландырып, абстракт вә коры исәп өстенлек иткән, чынбарлыкны берьяклырак кабул итүгә корылган додекафония тональсез системадагы торгынлыкны күпмедер күләмдә жанландырып жибәрергә бурычлы зәмин хезмәтен үтәргә алынды. *Ләкин* бу «зәмин» үзенең табигате белән бик тә шикле булганлыктан һәм камил рухлы шәхескә юнәлдерелмәгәнлектән, кайчак яшерелмәгән, хәтта ки шәрә шамакайлыкка кайтып калды, аның башлангычында математик өслүбле исәп-хисап ята иде. (Шулай да бер нәрсәне онытмыйк, додекафония стилендә дөнья күләмендә мәшһүр сәнгать әсәрләре аз ижат ителмәде, шушы хәл-әхвәл янарышка сусаган яшь композиторларны алгысытты, яңа үрләр яуларга жилкендерде дә инде.)

Рафаэль зур саклык белән «математик» серияле техниканы үзләштерүгә алынды. Баштарак ул шушы алым файдаланылган берничә әсәр ижат итте: скрипка өчен язылган соната әнә шундый рухтагы әсәрләрнең беренчесе иде (1963), биредә искечә һәм яңача музыкаль фикерләү төсмерләре уңышлы кулланылды дип әйтсәсе килә. Бу әсәрнең тууы композитор ижатында да, гомумән, татар музыка тарихында да истәлекле вакыйга булды. Беренче уңышлардан канатланып киткән композитор... бары тик унбер елдан соң гына тулаем додекафония стиленә нигезләнгән музыка ижат итте. Скрипка һәм симфоник оркестр өчен язылган дүрт кисәкле концерт-симфония (1974) шуның ачык мисалы булып тора. Биредә композитор додекафониянең хәтәр тоткынлыгыннан котылып, аның абстракт-төссез табигатен жиңә алды; шушы юнәлештәге эзләнүләрендә ул милли пентатоника аһәңенә нигезләнгән яңа серия, мәкам таба алды һәм татар музыкасында додекафония стилен үзләштерүгә ул ярдәмче вә юл күрсәтүче хезмәтен үтәде. Нәтижәдә, математик төгәл өслүбле, милли төзелешкә буйсынмаучан табигатьле додекафония тукымасына дәрт-дәрман, хис вә жан өртелгән милли рух килеп кушылды.

Дөрес, бу концерт-симфониядә житешсез яклар да юк түгел иде. Әйтик, циклның баш һәм ахыргы өлешләре беркадәр бертөрлерәк килеп чыкканнар. *Ләкин* концертның урта-интермеццо һәм perpetuum mobile өлешләре—һичшиксез, авторның уңышы булып саналырга хаклы. Соңрак бу өлешләрне ул, скрипка һәм фортепианода башкару өчен «көйләп», «Адажио һәм скерцо» дигән исем астында бертуган апасы *Луиза* Нури кызы



*Композитор Альберт Леман (алда, уңнан беренче) үзенең шәкертләре арасында. Икенче рәттә сулдан дүртенче—Рафаэль Белялов.*

Белялова истәлегенә багышлап бастырып та чыгарды. Шул рәвешле композитор яшь вә талантлы татар скрипкачысы—вакытсыз якты дөньядан китеп барган якын кешесен югалту белән бәйләнешле кичерешләрен чагылдыручы пьесаның асыл сыйфатын ача алды. Күрәсең, тирән хәсрәт кичерү нәтиҗәсендә туган көчләр Рафаэльгә додекафония табигатенә салынган беркадәр салкынлыкны «җылытырга» ярдәм иткәннәрдер. Адажио музыкасында гаҗәеп кешелекле хисләр дөньясы ачыла: әйтерсең лә, космик-галәми кинлекләрдән ингән бер Гали Зат чынбарлыкның барлык кайгы-хәсрәтләрен үзенә сыйдырган да, шуның белән Кешелекнең сагышын уртаклашырга вә җиңеләйтергә тели... Әйе, әсәрдә үтә дә нечкә төсмерләрдән алып, ташкындай гайрәтле хисләр кинлегенә кадәр җәелгән катлаулы кичерешләр гаммасы чагылыш тапкан. Токкаталы куәтле аһәң, ихтыяр көченең дәртле очышлары белән сугарылган скерцо исә, әсәргә бөтенләй яңа, көтелмәгән дәрт-дәрман өсти. Шушындый галәми яңгыраш җанның иң караңгы почмакларына, билгесез төпкелләренә кадәр үтеп кереп, аны җирдәге Яшәү ярларына кайтара. Әсәрнең кыскача драматургиясе менә шуннан гыйбарәт. Аннан аңлашылган, хисләр төпкеленнән саркып чыккан төп фикер белән тормыш чынбарлыгы тәңгәл килә: өметсезлек җанга үзенең кара канатлары белән кагылып үткән бер мәлдә, авыр кичерешләрне бары тик туктаусыз рухи эшчәнлек нәтиҗәсендә генә җиңәргә мөмкин!.. Ничек кенә сәер тоелмасын, акыл-кичерешләрнең туктаусыз хәрәкәте рухи чынбарлыкның үзенчә бер чагылышы, нигезе ләбаса.

Бу пьесаны Рафаэль белән бергәләп Россиянең бик күп шәһәрләрендә башкарырга туры килде. Ул һич икеләнүсез Бөтенсоюз фестивальләре һәм чит ил кунаклары хөрмәтенә оештырылган концертлар программасына кертелә торган иде. Әйтергә кирәк, әсәр тыңлаучылар тарафыннан зур кызыксыну һәм кайнар алкышлар белән каршыланды. Аның хакында атаклы совет композиторлары да яхшы фикердә булдылар. Ни хәл итәсең, үзебезнең Татарстанда, туган илендә генә бу әсәрнең әле һаман лаеклы урынын алганы юк.


Додекафония өлкәсендә житди уңышларга ирешкәч, Р. Белялов кинәт үзенең эзләнүләр юнәлешен үзгәртеп җибәрде—джаз музыкасы ташкынына ташланды. Рух-рухият турындагы өйрәтмәләр күзлегеннән чыгып караганда, мондый борылышның сәбәпләре бик тирәндә ята: ни өчен дигәндә—әле генә санап үтелгән ике агым да музыканың «олы баганалы» төп үсеш юлыннан капма-каршы юнәлешләргә алып баралар. Әгәр додекафония берьяклырак фикерләү рәвешенә юнәлтелгән булса, джаз исә—ихтыяр чоңгылларына мөрәҗәгать итә. Икенче төрле итеп әйткәндә, кешегә хас рухи көчләрнең өчлегеннән—фикерләү, хис һәм ихтыярдан—әлеге агымнар капма-каршы билгеләрне (анда да берьяклырак рәвештә) үзләренә «юлдаш» итеп алалар. Шул ук вакытта, әлеге билгеләрнең берәрсе (әйтик, ихтыяр көче яки фикерләү) өстенлек алганда, рухи көчләрнең тәңгәллеге бозыла һәм, ахыр чиктә, «Мин—акыл иясе»нең формалашуына хәлиткеч авыр йогынты ясый. Чөнки, аңлашылса кирәк, «Мин—аң иясе» генә Кешедәге рухи көчләрне берләштерүче үзәк булып тора. Алдынгы Аурупа мәдәнияте нәкъ менә шундый «Мин»не формалаштыруга юнәлдерелгән дә инде; аның асыл максаты—шәхси кысалар белән генә чикләнмичә, Мәңгелекнең чиксез кинлегендә галәми (иҗатчы!) рухи көчләр белән дә берләшүен күздә тоткан «Мин—аң иясе»н тәрбияләү.

Кешелек табигатенең инстинктларына, күңел чоңгылларына гына тәэсир ясауга корылган Африка культурасының архаик элементлары йогынтысына бирелү, билгеле бер күләмдә, хәзерге заман сәнгате үсеше өчен зур куркыныч тудыра. Бу күренеш түбән башлангычларның «чәчәк атуына» һәм кешелек рухиятенең иң чик дәрәҗәдәге эгоизм баткаклыгына кереп батуына китерергә мөмкин. Мәҗүси гыйбадәт-табынуларның атавизм элементлары джаз музыкасында бик тә ачык чагылыш таба; хәтта кайбер яклары белән ул борынгы татар халык иҗаты сәнгатенә дә килеп тоташырга мөмкин һәм хәзерге торышына йогынты ясап, аның алга табан үсешен туктатуы да ихтимал.

Рафаэль Беляловка килсәк, ул яшьлек елларыннан ук джаз белән мавыкты, еш кына америка композиторларының киң таралган пьесаларын яратып пианинода уйный иде, бигрәк тә Глен Миллерның «Кояшлы үзәнлек серенадасы» кинофильмыннан алынган музыкасын җаны-тәне белән «сөя» иде. Ләкин 70 еллар ахырында гына ул чын мәгънәсендә беренче джаз әсәрләрен иҗат итәргә керешә. Күрәсең, додекафония белән булган кебек үк, джаз музыкасы зилзиләләренә иярү, аның хәтәр йогынтысын тәмам тоя һәм үзендә аларның каршылыгын җиңә бару, ахыр чиктә, үзенең шәкли

омтылышларын гамәлгә ашыру—тәгаен бер карарга килү өчен вакытлар үтү кирәк булгандыр.

Шулай итеп, 1978 елда джаз стилендә ике фортепиано, бәрмә уен кораллары һәм контрабас өчен язылган «Рапсодия» дөньяга пәйда булды... Тик ни хәл кылмак кирәк, джаз музыкасы тарафдарлары тарафыннан алкышлап каршы алынуына да карамастан, композиторның әлеге әсәренә карата музыка җәмәгатьчелеге битараф кала бирде. Югыйсә, «Рапсодия»нең якты тематизмы, очкындай көйлергеч-дәртле ритмы һәм күнелләрне камаштыргыч гармониясе артында композиторның ирек сөючән, бәйсез, әмма «кояшлы» җаны шәүләләнә иде дә бит... Композитор үзенең әсәренә татар музыкасы өчен гадәти булмаган 5/8 үлчәүне сайлады, ә болай үзе әлеге бишле үлчәм халык музыкасына бөтенләй үк ят күренеш түгел. Ул мөселманнарның рухани-дини җырларында, ягъни мөнәҗәтләрдә һәм (бик нык яшерелеп кенә!) биш стопалы иске, озын көйләрдә (мәсәлән, «Зиләйлүк», «Әллүки»дә) очраштыра. Ә гомумән алганда, бишле үлчәү халык көйләренең пентатоника ладын оештыруда да катнаша. Боларның барысын да исәпкә алсак, билгеле бер ышаныч белән әйтергә мөмкин: «Рапсодия»нең бишле үлчәү ритмына корылуы бер дә юкка түгел икән, ул эчке бер милли мәгънәгә ия булып тора булса кирәк.



*Төп Галәм символы буларак Кеше сурәте*

Рух-рухият турындагы фән шуны раслый: «5»ле саны җиһандагы бөтен эволюцион үсештә әһәмиятле урын алып тора *(Штайнер Р. Оккультные знаки и символы.—Казань.—С. 33)*. Пентаграмма яки йолдыз символының алгы очлыкларын (кулын) һәм башын Җирнең көче җәтмәсеннән ычкындырып, туры басып торучы Кешегә турыдан-туры бәйләнеше бар һәм мәшһүр рәссам, бөек гыйлем иясе Леонардо да Винчи үзенең атаклы рәсемендә Кешене ян-якка җәелгән очлыклары йолдызга һәм түгәрәккә сузылган кыяфәттә сынландыра да инде. Бу рәсемдә ин югары кимәлләге урынны—биш буынлы Кешенең бәйсез фикер иясе икәнлеген сынландыручы, Кешеләргә иреклe һәм бәйсез хаят бирүче, шул ук вакытта Яхшылык һәм Явызлык та тудырырга сәләтле Баш сурәте биләп тора. Димәк, бишлек мохитына үтеп керә алмаган, фикерләү өлкәсендә бәйсезлеккә ирешмәгән бер генә җан иясе дә тулаем Хөрлек яулый алмаячак; чөнки ул Яхшылык яки Явызлык тудырырга сәләтле түгел; шулай булгач, ул үзенең кылган гамәлләренә дә җавап бирә алудан мәхрүм. Шул рәвешле «5»ле саны бер үк вакытта, Кеше эшчәнлегенең табигатенә карап, бәйсезлек һәм явызлык символы булып хезмәт итә икән.

Р. Беляловның «Рапсодиясе»ндә чагылыш тапкан—халык музыкасының чишмә башыннан үк килә торган бишле үлчәм джазның кискен агымнарын тынычландыра һәм сафландыра төшә. Биредә автор тарафыннан табылган яналыклар—пентатоник аһәннең баетылуы һәм киңәйтелүе, музыка тукымасына Аурупа бию ритмнарын һәм интонацияләрен (аерым алганда, тарантелла бизәкләрен) кертеп җибәрү, үзенең матурлыгы һәм чисталыгы белән Моцартның илаһи мелодиясен төсмерләткән теманы кирәк урында гына өстәп кую да әсәргә кабатланмас янгыраш бирә. Әйе, биредә өч музыкаль катлам—джаз, милли һәм Аурупа музыкасы катламнары табигый рәвештә кушылып киткәннәр һәм алар Африканың мәҗүси культурасыннан саркып чыккан архаик башлангычларны бүгенге заман җирлегенә төшерергә ярдәм иткәннәр. Кыскасы, композитор бер генә музыка үрнәген дә кабатламаган, заманның рухи таләпләренә җавап бирерлек югары кимәлләге әсәр иҗат иткән; әйе, анда бүгенге рухи дөньяның асыл нисбәтен билгели торган ачкыч табылган. Бу күзлектән чыгып бәһа биргәндә, әлеге «Рапсодия» татар музыкасының гына түгел, ә бәлки, гомумән, дөнья сәнгатенең бер казанышы булып саналырга хаклы. Юкка гына ул 1995 елда Японияда үткәрелгән фортепиано дуэтлары өчен язылаcы әсәрләрнең халыкара конкурсында премиягә лаек булмады, лабаса.

Джаз музыкасын яхшы ук иярләп алгач, Р. Белялов бу чыгымчы чаптар өстендә озак утырып тормады, халык көйләрен эшкәртү белән мавыгып китте һәм 80 еллар башында аның татар халкы җырларына нигезләнеп скрипка һәм фортепиано өчен язылган атаклы «Фольклор-сюита»сы дөнья күрде; тагын да соңрак, рәттән диярлек, виолончель өчен язылган өч сюитасы пәйда булды (берсе скрипка сюитасының үзгәртелгән күчермәсе иде). Ул да булмады, фортепиано өчен берничә пьеса иҗат итте. һәм, ниһаять, композитор скрипка һәм оркестр өчен халык музыкасы темаларына нигезләнгән «Концерт-каприччио» (1984) тудырырга ирешә.

Билгеле ки, Р. Беляловның халык музыкасына мөрәҗәгать итүе очраклы хәл түгел иде. Аны бу юлга басарга татар халкының мәшһүр җырчысы Илһам Шакировның җырчы һәм оркестр өчен берничә татар көенә аранжировка ясарга, шәхсән үземнең республикада беренче буларак басылып чыгарга хәзерләнүче әлеге дә баягы «Яшь скрипкачы» (1977—1978) җыентыгына берничә халык көен эшкәртергә тәкъдим итүебез этәргеч булды. Ни гаҗәп, бу ике тәкъдим дә берьюлы диярлек ясалды һәм Рафаэль, башы-аягы белән дигәндәй, үзе өчен яңа булган рухият дөньясына кереп чумды (әйе, ул максималист иде). Композитор беренче чирканчык алу белән генә чикләнеп калмады һәм мине гаҗәпләндергәне шул булды—әлеге җыентык дөнья күргәч тә ул, «планнан тыш», мина багышланган биш кисәкле «Фольклор-сюита»сын китерде. Ә гаҗәпләнүем шуннан гыйбарәт иде, чөнки халык көйләрен эшкәртү ул заманнарда үтелгән этап булып хисаплана иде—чөнки көйсез-моңсыз музыка «модага» керә башлады. Шуна күрәдерме, яшь буын композиторлар бу эшкә бик сирәк алындылар һәм аксакаллар—Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Александр Ключарев кебек олуг композиторларның иске классик гармония традицияләренә нигезләнгән эшкәртмәләренең «теле» көндәлек музыка мохитында кануни төсмер алды.

Күрәсең, нәкъ шундый торгынлык чорында Рафаэльнең тынгысыз иҗади рухы фольклорга заманча яңгыраш өстәргә кирәклеген тоеп алган булгандыр. Әгәр дә алда санап кителгән аксакал композиторларыбыз бертавыштан халык мелодиясен мажор-минор системасы белән ялгаучы беренче карлыгачлар булсалар, Рафаэль исә яңа дулкынга нигез салучылардан саналды. Ул укытучысы, композитор Альберт Леманның яратып куллана торган: «Диссонанслардан курыкмагыз!» дигән шигарен үзенең иҗат алымы итеп күтәрде. һәм Рафаэль, модернистик гармония һәм диссонанслы яңгыраш-аһәңнәрне, традицияләрдән читкә тайпылган кискен ритмнарны кыю кулланып, халык көйләренә заманча «кием кигертте». Рух-рухият турындагы гыйлемгә нигезләнеп, без бүгенге мохиттә кешеләрнең җаны бер үк вакытта һәм Матурлыкны, һәм Явызлыкны күреп торганда гына дөрес формалаша һәм, әлбәттә, шушы җирлектә ныгый, дип әйтә алабыз. Ә инде сәнгать дөньясына килсәк, җанда мондый капма-каршы кичерешләрнең үзара керешеп яшәве хакыйкатькә якын торалар һәм эчке тотрыклылыкны тәэмин итәләр. Шулай булмаган очракта, идиллик матурлыкка гына табыну нәтиҗәсендә, алар кешене табигый чынбарлыктан аерылуга һәм тормыш авырлыкларыннан качуга китерергә мөмкиннәр; ә югыйсә, Җан галәме гармония көрәшендә иҗтимагый диссонанслар тоеп һәм кичереп яшәргә мәхкүм ителгән *(Штайнер Р. Миссия архангела Михаила.—М.: Антропософия.—2000.—С. 56-65).*

Шушы канун кысаларында иҗат ителгән «Фольклор-сюита» музыка мохитында бер тавыштан кабул ителде. Композиторлар союзында, филармониядә һәм радио комитетында үткәрелгән тыңлаулар вакытында бу әсәргә югары бәя бирелде һәм, ниһаять, Р. Белялов «татар тыңлаучысына йөз белән борылды» дип билгеләп үтелде. Аны, шулай ук, татар җәмәгатьчелеге дә җылы каршылады. Без бу әсәрне кайда гына башкарсак та, ул кайнар алкышларга күмелде. Ә шулай да... әсәр хакында кайбер бәхәс-тәкъдимнәр дә булды. Алар сюитаның язылу үзенчәлегенә, сәнгати кыйммәтенә түгел, нигездә циклның төзелешенә һәм бүлек-кисәкләр санына кагылдылар. Әйтик, композиторлар союзында тикшерү барышында мөхтәрәм композитор Нәҗип ага Җиһанов әсәрнең гармоник яңгырашын югары бәяләгән хәлдә, биш кисәктән торуына шик белдерде, аны өч-дүрт кисәккә калдырырга кирәк түгел микән дигәнрәк фикер әйтте һәм циклны драматик, салмак бетем белән түгел, ә бәлки бию өлеше белән тәмамларга кирәк, дип киңәш бирде. Шул исәптән, кайбер музыка белгечләре дә гадәти булмаган, традициядән читләшкән финал өлешенә каршы чыктылар. Чыннан да, «Бер алманы бишкә бүләек» дигән салмак аһәңле татар халык көенә нигезләнгән соңгы өлештә ярсулы көрәшне сурәтләгән матәм аһәңнәре чагылып-чагылып китә иде шул.

Сюитаны халыкка тәкъдим итәр алдыннан Рафаэль белән без бу хакта кат-кат әңгәмәләшеп алдык. Композитор үзе дә сюитаны ничек бар шулай калдырырга микән, әллә өлеш-кисәкләрнең урыннарын алыштырасы инде, дип шик-шөбһәләрен белдерде. Борчылу болытларын тарату максатыннан чыгып, без әсәрне төрле гавам алдында төрлечә вариантларда башкарып карадык һәм ахырдан баштагы нияттән кире кайтмаска кирәк дигән нәтиҗәгә килдек: ник дисән, «Бер алманы бишкә бүләек» җырының илаһи моны башка барлык өлешләрне дә күмеп китә иде шул. Җырның көендә һәм сүзләрендә «5»ле санының эчке символга мәгънәсе барлык тулылыгы белән чагылыш тапкан: Фикер иясе, Җан иясе буларак, Кеше кайбер очракларда ялгышлыклар җибәрү нәтиҗәсендә, Явызлык та, Яхшылык та эшләргә сәләтле: бер-берсенен ялгышлыкларын кичерә-кичерә, якыннарының кайгысын да, шатлыкларын да уртаклаша-уртаклаша, кешеләр күнел түренә поскан эгоизм гөнаһын җинә барырга, «бер алманы бишкә бүлешеп» гамәли иҗатның таҗына әверелергә, кичерүчән мәрхәмәтле мәхәббәтнен башлангычы булырга бурычлылар. Җырның тукымасына сеңдерелгән бу бөек мәгънә гасырлар тирәнлегеннән тибеп чыккан халык рухының «әбелхәят чишмәсе» булып тора. Шушы олуг хис «Фольклор-сюита»ны йомгаклап күеп, чорга тин иҗат үрнәкләрендә хис-гакылның бетмәс-төкәнмәс кодрәте чагылыш табу мөмкинлеген тагын бер кат раслый алды. Моны Рафаэль осталарча тотып ала белде һәм беркемнен дә фикер-карашларына игътибар итмәстән, үзенен новаторлык хасиятенә тугры кала бирде. Нәтиҗәдә, нинди генә каршылыкларга очравына да карамастан, «Фольклор-сюита»сын үзе теләгән вариантта бастырып чыгара алды.

Скрипка һәм симфоник оркестр өчен язылган «Концерт-каприччио»да, шулай ук, татар фольклорын кабаттан, бөтенләй яңа сурәттә тергезү юлында яңа бер адым булды. Татар музыкасы хәятында мона кадәр шушына охшаш нибары бер генә әсәр иҗат ителгән иде—ул Җәүдәт Фәйзи тарафыннан кечкенә концерт гармуны өчен язылган пьесадан гыйбарәт иде. Рафаэль исә, әлеге әсәрендә сюита билгеләре төсмерләнгән бер бүлекле, әмма шактый кин колачлы формасын кулланды. Мәгълүм булганча, концертта халык бию көйләре лирик мелодия белән аралашып килә. Шул ук вакытта композитор халык монына аһәнләш башка темаларны да файдаланды, ләкин алар саф пентатоника кысаларына гына сыеша алмыйча, күбрәк моңлы минор яки якты мажор төсмерләр белән баетылдылар. «Фольклор-сюита»дагы кебек ук,



*Композитор Рөстәм Яхинның 60 еллык юбилей кичәсеннән соң. Икенче рәттә сулдан тугызынчы—Рафаэль Белялов.*

бирелдә дә музыка тукымасы әсәрнен буеннан-буена заманча, бер-берсенә ярашмаган кебек тоелган авазлар гармониясе, кискен үзгәрүчән көчле тактларнын салмаклары белән алышынып килүче джаз ритмнары белән сугарылган. Концертта төп инструмент һәм оркестр партияләре шундый кимәлдә иҗат ителгәннәр ки, алар асталыкта һәм тәэсир көчендә бер-берсе белән ярыша-ярыша һәм бер-берсен тулыландырып чиксез мон дәрьясы тудыралар. (Бу хакта сүз чыккач, Рафаэль шаяртып, минем скрипка **һәм** оркестр өчен түгел, нәкъ менә скрипка **белән** оркестр өчен концерт иҗат итәсем килде, дигән иде.) Анлашылса кирәк, әсәр музыкаль гавам арасында зур уныш казанды һәм Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Россиянен тагын уннарча шәһәрләрендә кат-кат башкарылуы шул хакта сөйли булса кирәк.

Хакыйкать өчен искәртеп үтик, концертнын шундый зур унышка ирешүендә ике олуг останын—дирижер Фуат Мансуров белән скрипкачы Игорь Ойстрахнын файдасы әйтеп бетергесез зур булды. Фуат Мансуров әсәргә бераз кыскарту кертте, аерым алганда, икеләтә экспозициядән, ягъни төп теманын ике тапкыр оркестр һәм скрипка белән кабатлануыннан баш тартырга тәкъдим ясады, бу үз чиратында концертнын архитектоникасына төзеклек һәм назикълык бирде. Игорь Ойстрах исә, безнен башкаруда тынлаганнан сон, концертнын формасын тәнгәлләштерү һәм төп башкаруга инструментнын (скрипканын) мөмкинлекләрен ныграк ачу максатыннан чыгып, әсәрне төгәлләгәндә каденция кертергә кинәш бирде. Чынлап та, беренче вариантта кайбер эшләнеп житмәгән урыннар барлыгын без үзебез дә искәрә идек. Әйтик, тиндәшсез «Тәфтиләү» көенә нигезләнгән лирик тема концертта бер генә тапкыр, кереш өлештә генә кулланыла иде һәм анын реприза (кабатлану) өлешендә булмавы әсәрнен беркадәр өтеклегенә китерә иде. Әлеге тәкъдимнәрне кабул итеп, Рафаэль миннән «Тәфтиләү» темасына импровизация формасында (ягъни, халык скрипкачы осталары башкаргандагы кебек беренчел төсмерләрен саклаган хәлдә) каденция язуымны үтенде, ә үзе концертнын кодасын (сонгы тәмамлау өлешен) янабаштан язып чыкты. Әлбәттә, яна каденциянен пәйда булуы әсәрнен драматургиясенә үзгәрешләр кертте һәм композитор коданын беренче вариантыннан баш тартты: нәтиҗәдә, элек концерт ахырында музыка күкләргә ашып, эреп югалган булса, хәзер исә яна кода әсәргә дәртле бию ташкынын кире кайтарды. Һәм бу әсәрнен ике рояль өчен эшләнгән варианты, Япониядә үткәрелгән Халыкара конкурста «Рапсодия» шикелле үк, махсус бүләккә лаек булды.

«Концерт-каприччио»дан сон Р. Белялов фольклорга сирәгрәк мөрәҗәгать итә башлады. Сонрак татар халык көйләренә нигезләнеп скрипка һәм фортепиано өчен фантазия язып карады, ләкин, күрәсен, ул чираттагы, өченче жинүенә ирешкәнен бик яхшы анлагандыр һәм эзләнүләрен башка юнәлешләрдә дәвам итте.

* * *

Әйе, нәкъ менә шушы чорда Р. Беляловнын шәхси тормышында зур үзгәрешләр булды. Шуларнын берсе хакында мин тәфсиллерәк сөйләрмен, ахрысы. Шулай бер вакыт, безнен өйгә кунакка килгәч, минем эти белән сөйләшеп утырганда, Рафаэль һич көтмәгәндә үзенен этисе турында сүз кузгатты. Хәтерлим, монарчы анын бу хакта беркайчан да әнгәмә куертканы юк иде, хәзер исә бөтенләй чишелеп китте һәм безне шаккатырып, этисе белән икесе арасындагы мөнәсәбәтләрне тәмам өзүен, әнисенен вакытсыз үлемендә анын гына гаепле булуын әйтеп ташлады. Билгеле ки, мин ана каршы төшеп карадым, эти кешенен нинди генә шартларда да эти булып калуын, картлык көнендә аны шулай авыр хәлдә, ялгызын гына калдыру шулай ук гөнаһ эше икәнлеген исбатлап маташтым. Рафаэль урынында башка берәү булса, шундый да кискен гаепләүдән сон, сүз дә юк, кабынып-дөрләп китәр иде, ә ул, кем әйтмешли, «ударны» күтәрә белә иде һәм, бераз уйланып торды да, бөтенләй уйламаганча тәкъдим ясады: «Әйдә, алай булгач, хәзер үк анын янына барып кайтыйк әле!» Бераздан инде без саргылт төскә буялган, хуш исләр бөркеп утыручы яшеллеккә күмелгән кечерәк кенә йорт каршында басып тора идек. Өй тупсасыннан атлап керүгә, безне каршылыклы уйлар өермәсе чолгап алды. Караңгы вә шыксыз иде бүлмә эчендә. Йорт хуҗасы кайда микән сон дип ишек төбендә аптырап басып торган арада, базык кына гәүдәле өлкән яшьләрдәге берәүнен турдән безгә таба кузгалганы шәйләнде—чакырылмаган кунаклар килеп чыгуга ул да аптырабрак калган иде, ахрысы, хәрәкәтләре салмак вә ышанычсыз иде анын. Ата белән Ул беравык бер-берсенә телсез-өнсез карашып тордылар, аннары

ата кеше хисләреннән айнып киткәндәй, тышка бәреп чыккан кичерешләрен тыя алмыйча, үзен-үзе белә-бүлә авыз эченнән генә нидәрдер сөйләнә башлады. Бүгенгедәй яхшы хәтерлим, телгә килгәч, ул үзенең үткәндәге хаталары өчен улыннан гафу үтенде, шушы аерым-чоерым яшәгән озак еллар дәвамында газета-журналлардан аның турындагы кош теле хәтле хәбәр-өннәрне дә җыеп баруы, хәер, шуның белән генә юанып яшәве хакында бәйнә-бәйнә тезеп китте. Аннары агай бер кырыйда торган комодын ачып, аннан газета-журналлардан кисеп-кисеп алынган кәгазь кисәкләрен саклык белән генә кулына алды. Алар арасыннан юкарак кына бер китап та килеп чыкты һәм шулчак Рафаэль тетрәнеп киткәндәй булды. Ул әлеге ядкярне «кулына төшергәч», кош баласын тоткандай шатланып тышлыгын ачып карады һәм аннан сугыш елларында немец офицеры формасында төшерелгән бер ир-егетнең фотосурәтен алып, мина сузды. Рафаэль бу сурәт хакында болай дип аңлатты: «Яшьлек елларындагы кумирым бу минем. Мин аны хәзергә кадәр идеалым дип йөртәм. Миндә аның турында тулы бер фотолар коллекциясе тупланган...»

Әлеге китапчык «Это было под Ровно»мы, әллә «Подвиг разведчика» дипме атала иде, исеме тәгаен генә хәтердә калмаган; хәер, ничек аталса да аталгандыр, әмма анда Бөек Ватан сугышы каһарманы Николай Кузнецовның дошман тылында немец офицеры Пауль Зиберт исеме астында хәрәкәт итүе хакында бәян ителгән иде. Бу китап сугыштан соңгы буын яшьләр арасында бик тә популяр иде. Ул вакытта курку белмәс разведчик дан-шөһрәт, байлык җыю артыннан кумыйча, туган ватанына тугрылыклы хезмәт итү үрнәге буларак кабул ителде. Ватанпәрвәрлек идеясе Рафаэльнең халәте рухиясе һәм омтылышлары белән аваздаш булгандыр, күрәсең. Мина Рафаэльнең авыр чакларында кешеләргә ярдәмчел булуына, чын күңелдән аларның хәл-әхвәлләренә керә белүенә күп тапкырлар шаһит булырга туры килде. Менә хәзер дә, күзгә-күз очрашкач та, ул әтисенә ярдәм кулы сузарга әзер торуын күрсәтте. Булып узган авыр вакыйгаларның алар гаиләсе язмышына кара канатын салган авыру нәтиҗәсендә килеп чыкканлыгын аңлап алган бу минутларда аның әтисен тулысынча гафу иткәнлеге ачык күренеп тора иде. Рафаэль һич икеләнүсез әлеге авыруга каршы көрәшергә кирәк дигән катгый карарга килеп, ярдәмгә мохтаҗ әтисе белән абыйсы турында кайгыртуны үз өстенә алды.

Һай, гомерләр диген, ул чакта Рафаэль үзен бер-бер артлы бик тә олы кайгылар көткәнен аңлап житкерде микән? Ләкин ничек кенә булмасын, үз-үзенне, шәхси мәнфәгатьләренне корбан итү соралганлыгын бөтен вөҗүде белән тойгандыр сыман тоелды ул мина, чөнки Рафаэль яшьлек елларыннан бирле батырлыклар эшләү теләге белән янып яшәде, ләбаса. Чыннан да, композитор иҗатында соры һәм җансыз күренешләргә каршы басып, додекафония, джаз һәм фольклор өлкәсендә ачык буяулы, яшәүчән рух белән сугарылган әсәрләр тудыруы белән моның шулай икәнлеген озак еллар дәвамында раслап килде. Дөрес, гавам тарафыннан ул җинүче буларак кабул ителмәде, күп кенә очракларда аның иҗади алымнары кирәкмәгән имеш-мимешләр тудырдылар; кыскасы, аның әсәрләре үз вакытында «аңлашылып житмәде». Ни генә булмасын, ул житди, талантлы композитор иде. Хәзер исә, менә шушы кечерәк кенә бүлмә уртасында, батырлык эшләү теләгеннән гамәлгә ашыру мөмкинлеген язмыш ана үзе бүләк итте. Ә бу теләк еллар үткән саен, Рафаэльнең үз-үзен тотышында ачыграк төсмерләр алып җанлана торды. Һәм, әйтергә кирәк, мондый рухи Чистарыну өмете ниндидер бер томанлы сиземләү аша түгел, ә бәлки әхлакый әзләнү-кичерешләр, акыл хәрәкәте аша, ниндидер мистик көчләр катнашында (фәнни, житди мәгънәдә, әлбәттә) тәгаенләнде дисәк, һич тә хата булмастыр, ахрысы. Дөрестән дә, рухи яктан «күкнен башка катларында гомер кичерүче» иҗади шәхесләрдә бу шулай күзәтелә дә...

Гаҗәп түгел, Рафаэльнең тирә-юнендә үтә дә сизгерлеге белән аерылып торган шәхесләр житәрлек урала иде. Әйтик, көннәрдән бер көнне ул мине Чаллыда яшәүче бер «күрәзәче» шагыйрь белән таныштырды (Рафаэль үзе дә мондый сәләттән бөтенләй үк мәхрүм түгел иде булса кирәк). Ә икенче бер вакыт ул, кларнетчы Александр Романов белән сөйләшү барышында, саннарның язмышында символик мәгънәгә ия булуы хакында бәян иткән иде һәм әгәр дә ике катлаулы чикне җинеп үтә алсам (икенче «чик»не ул үзенә 60 яшь тулачак 2000 ел белән билгеләде), мин бик озак яшәячәкмен, дип белдерде. Баксан, икенче «чик» чынлап та хәвеф-хәтәрләр алып киләчәк икән ич... Фаҗига булыр алдыннан гына аның еракта, чит шәһәрдә яшәүче танышы (ә ул экстрасенсорлык сәләтенә ия иде) безне—Рафаэльнең дусларын—олы бәла-каза якынлашып килүе белән кисәтеп куйды, ләкин ни дә булса кылырга сон иде инде.

Сон иде... Соңгы елларда Рафаэль Беляловның иҗтимагый һәм иҗади активлыгы сизелерлек кимеде. Дөрес, ул яна әсәрләр тудырырга омтылыш ясап карады, ләкин

аларда (70-80 еллардагы кебек) көч вә куәт юк иде инде. Күрәсең, моны ачык тойган композитор 90 елларда язылганда иҗат иткән әсәрләренә мөрәҗәгать итә башлады, күп кенә өйрәнчек пьесаларын фортепиано дуэты өчен эшкәртеп чыкты. Әмма гомер «пьесасы» ахырына якынлашып килгән булган икән лә... Тормыш-көнкүреш мәшәкатьләре, кайгы-хәсрәтләр аның җелеген торган саен ныграк суыра барды: Рафаэль әтисен җирләде, әледән-әле ярсулы акылдан шашу халәтен кичергән абыйсының сәламәтлеге бик нык какшады. Рафаэль аны үз янына сыендырып, зур түземлек һәм күндәмлек белән тәрбия кылды һәм якын танышларыннан сирәк-мирәк кенә булса да үзенең исән-иминлеге хакында белешеп торуларын үтенде. «Өянәге кузгалган» берәр вакытта абыйсының ана кул салу ихтималын да Рафаэль яшереп маташмады. Әмма абыйсын «җүләрләр йортына» тапшырырга җөрьәт итмәде, дөресрәге, намусы кушмады.

Тышкы яктан сүлпәнләнә барган саен, Рафаэль күңел чоңгылларында казына торган булып китте һәм аның мондый рухи эзләнүләре эзсез үтмәде, билгеле. Аның җанын Коръән Кәрим өйрәтмәләренең сере биләп алды, шулай ук Рафаэль рух-рухият турындагы фән белән дә кызыксынып китте. Аның игътибарын бигрәк тә кеше язмышы, карма турындагы хезмәтләр җәлеп итте. Баштарак, аңлашыла ки, ул очраклы китапчыклар белән мавыкты; бераз тәҗрибә туплагач, антропософиягә нигез салучы Рудольф Штайнерның рухи дөньяга кагылышлы җитди хезмәтләре аның өстәл китабына әверелде. «Эзотерические рассмотрения кармических связей» китабы, мәсәлән, нәкъ шундыйлардан иде. Аларда, күп тапкырлар инкарнацияләнеп, ягъни кабатлана барып, шәхеснең югары көчләргә ия булуга һәм үзенең илаһи табигатен аңлауга китерәчәк рухи башлангычларның үлемсезлегенә иман нуры өртелә. Рух фәне нигезләгәнчә, инкарнацияләнүчән шәхес, нинди гамәлдә тууына карамастан, нәселдән килә торган авырулар нәтиҗәсендә килеп туарга мөмкин булган бәла-казалардан һәм уйланып җиткерелмәгән адымнар ясаудан коткарып калу өчен, гаилә әгъзаларының кармик мәшәкатьләрен хәл итүне үз өстенә ала. Шул рәвешле, шәхес үзенең эгоистик мәнфәгатьләрен корбан итеп һәм гомумкешелек әхлак югарылыгына күтәреп, нәсел генокодын дөрес юлга кертеп җибәрергә, рухи чистарынуга ярдәм итәргә, гөнаһлардан йолып алырга сәләтле.

Мондый карашлар системасы Рафаэль өчен мавыктыргыч, серле дөнья булып чыкты. Вакытсыз вафаты алдыннан гына без аның белән булачак 60 еллык юбилей концертларының программасы хакында әңгәмә корып утырган идек. Ә көндәлек мәшәкатьләргә күчкәч, Рафаэль яшәешнең асыл мәгънәсе турындагы уйларының тирәнлеге һәм киңлеге белән шаккатырган иде. Әйтерсең лә, гакыл иясе Хозыр Ильяс аңа сихерле рухы белән кагылып үткән диярсең.

Хәзер исә, шактый вакыт узганнан соң, Рафаэль Беляловның үткән юлга кабаттан күз ташлагач, тәгаен бер фикергә киләсең: аның барлык кылган гамәлләре дә гавам тарафыннан кабул ителгән әхлак кысаларына сыеп бетмәгән икән шул. Ни генә дисәң дә, рухи яктан чыгып бәһа биргәндә, аларның нигезендә игелекле башлангычлар яткан, ләбаса. Ул шәхси карашларын яклап мәңгайга-мангай сөзешүләрдән курыкмады, яшәеш каршылыкларын читләтеп узмады, ә бәлки бар булганын алга куйган максатына ирешүгә юнәлдерде. Моны гавам, күп очракта, карьеризм галәмәте дип юрады, тик бу хис аңа бөтенләй ят нәрсә иде. Ул Иҗат әһеле булып дөньяга килгән иде, калган гомерендә дә Иҗатчы булып яшәде.

Р. Беляловның иҗатына багышланган бер эссе-нәсердә автор аның җаны аша үткән эзләнүләр җегәрен «Музыкадагы кояш яктысы» дип атады. Уйлыймын ки, аның җаны, чынлап та, күзгә күренмәс җепләр аркылы рухият фәнендә «архангел Рафаэль» дип аталган (Җирнең утлы-ялкынлы халәттәге чорларына бәйләнешле фәрештә шулай гоманлана) Олуг Яктылык рухы белән тоташкан булгандыр. Һәм бу Рух, кешеләрнең тын алу эшчәнлеген тәртипкә салып, таза-төзек бәдән бүләк итеп, бүген дә чынбарлык хәятында яшәп килә. Тагын һәм тагын бер кат искәртәсе килә: боларның барысы да Рафаэль Беляловка хас күренешләр иде, ул җаны-тәне белән халык әйткән хаклыкны раслап яшәде: «сәламәт тәндә генә сәламәт рух була!» Композитор үзеннән соң килгән буынга яшәү дәрте белән өртелгән шат рухлы, сәламәт музыкаль мирас калдырды һәм шуның белән татар музыкасы үсешенә бәрәкәтле йогынты ясарлык өлеш кертте. Бер кеше гомере өчен бу инде аз түгел...

**Шамил МОНАСЫЙПОВ,**
*скрипкачы, Татарстанның халык артисты,*
*Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.*





# 40—МӨЭМИН (МӨЭМИН) СҮРӘСЕ

**Мөэмин сүрәсе 85 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. 56, 57 нче аятьләре Мәдинәдә иңгән.**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Ха. Мим. **(2, 3)** Бу Китап һәрвакыт җиңүче, барысын да белүче, гөнаһларны ярлыкаучы, тәүбәләрне кабул итүче, газабы—хәтәр, бәрәкәте—мул Аллаһ тарафыннан иңдерелде. Аннан башка *(Илаһи кодрәткә ия һәм)* Тәңре булырдай һичберкем юк. Кайтарылыш фәкать Аның хозурына. **(4)** Инкарьчылардан башка һичкем Аллаһның аятьләре хакында шик белдереп бәхәсләшмәс. Шәһәрләрдәге *(кяферләрнең рәхәт муллыкта)* яшәешләре сине кызыктырмасын. *(Аларның байлыгына, сәүдәдәге уңышларына алданма.)*

**5.** Алардан элек Нухның кавеме, алардан соң яшәгән *(Гад, Сәмуд, Лут)* халыклары да *(пәйгамбәрләрен)* ялганчыга чыгарган иде. Аларның һәр өммәте үз пәйгамбәрләрен харап итәр өчен, мәкерле тозаклар корды. Ялганны Хакыйкатьтән өстен чыгарыр өчен, гел сугышып тордылар. Нәтиҗәдә, Мин дә аларны тотып алдым *(да һәлак иттем)*. Әнә, бак! Минем газабым аларга ничек хәтәр булып төште. **(6)** Аллаһүнең:

—Инкарьчылар, һичшиксез, җәһәннәм әһеле булачак,—дигән сүзе хак булып чыкты. Алар җәһәннәм әһеле булды.

**7.** Гареш*(нең мәшәкатьле)* эшләрен үз өсләренә алган, Гареш әтрафындагылар *(фәрештәләр)* Раббыга мәдхия укыйлар вә тәсбих әйтәләр. Аллаһка инаналар.

—Йа, Раббыгыз, синең рәхмәтең вә гыйлемең һәр нәрсәне кочып алган. Шулай булгач, тәүбә иткәннәрне һәм Синең юлына юнәлгәннәрне ярлыка. Аларны җәһәннәм газабыннан коткар! *(Сөбхәналлаһи вә бихамдиһи)* **(8)** Раббыбыз, аларны да, аларның аталарын да, хатыннарын да, нәселләрендәге игелек кылганнарны да үзләренә вәгъдә иткән Гаден җәннәтләренә керт. Һич шик юк, Син һәрчак җиңүче һәм хаким булдың. **(9)** Аларны һәртөрле яманлык кылулардан сакла. Гөнаһлардан сакласаң, хактыр ки, ул Көнне *(Кыямәттә)* алар рәхмәтеңә ирешер. Бу алар өчен иң олуг котылыш һәм Сәгадәткә ирешү булыр иде.

**10.** Инкарьчыларга болай әйттеләр:

—Аллаһның газабы, хактыр ки, сезнең үзегезгә булган бүгенге нәфрәтегездән хәтәррәк. Сезне иман китерергә өндәделәр, ләкин сез баш тарттыгыз.

**11.** Алар:

—Раббыбыз, безне ике тапкыр үтердең, ике тапкыр терелттең. Без дә гөнаһларыбызны таныдык. Ичмасам, бер тапкыр гына булса да *(җәһәннәмнән)* чыгу юлы бармы?—дип әйтер.

*(«Беренче терелү—туу, икенче терелү—Кыямәттә. Беренче үлем—ана карынындагы яралгының җансызлык халәте, юклык. Икенче үлем—бу дөньядан китү».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**12.** Мондый җәза сезгә шуның өчен бирелде: сезне бер Аллаһка гыйбадәт кылырга өндәделәр, сез инкарь иттегез. Ана тиң дип, уртакларга табындыгыз.

---

Журнал өчен **Рабит БАТУЛЛА** әзерләде.

Инде хәзер хөкем бөекләрдән-бөек Аллаһ ихтыярында. **(13)** Сезгә аятьләрне күрсәткән, сезнең өчен Күктән ризык иңдергән—Улдыр. Аллаһ юлындагылардан башкалар бу эшләрдән гыйбрәт алмас.

**14.** Ягез, кяферләрнең һушына китмәсә дә, Аллаһка һәм дингә ихласлык белән гыйбадәт кылыйк.

**15.** Югары дәрәҗәле, Гарешнең хуҗасы Аллаһ, *(Кыяматтә)* кавышу көне белән куркытмак өчен, үзе теләгән колына вәхий иңдерде. **(16)** Ул Көнне алар каберләреннән кубарылып, мәйданга чыгар. Алар кылган гамәлләрнең берсе дә Аллаһтан яшеренеп калалмас.

—Бу Көндә хөкемдарлык кем ихтыярында?

—Кодрәтле һәм бердәнбер Аллаһ хозурында! **(17)** Ул Көнне һәркемгә үзе кылганнарның әҗере бирелер. Бу Көнне беркемгә дә гаделсезлек кылынмас. Шөбһәсез ки, Аллаһ хөкемен тиз тотар. **(18)** Якынлашып килә торган Көн *(Кыямәт)* турында аларны кисәтеп тор. Анда, утлы дәһшәт эчендә аларның йөрәкләре бугазларына тыгылыр. Залимнәрнең анда дусты да, сүзенә колак салырдай шәфәгатьчесе дә булмас. **(19)** Аллаһ хыянәтчене күз карашыннан ук таныр. Күңелләрендәге яшертен теләкләрен дә белеп торыр. **(20)** Аллаһ гаделлек белән хөкем итәр. Аны инкарь итеп, табынган нәрсәләре бернинди дә хөкем чыгара алмас. Шик юктыр ки, Аллаһ чыны белән ишетеп, күреп торучыдыр. **(21)** Алар Җир йөзендә йөреп тә, әүвәл яшәгән *(гөнаһкяр)* халыкларның ничек итеп һәлак булганнарын күрмәделәр *(күрсәләр дә, гыйбрәт алмадылар)*. Юкса, алар Җир йөзендәге корылмалары, сарайлары белән боларыннан күпкә өстен һәм куәтле иде. Шулай да, Аллаһ аларны *(гөнаһларына күрә)* җәзалады. Аларны җәзасыннан коткарырга тырышкан зат та булмады. **(22)** Чөнки пәйгамбәрләр аларга ап-ачык аятьләр-могҗизалар алып килеп тә, алар инкарь итте. Аллаһ та аларны газапка дучар итте. Хактыр ки, Аллаһ—кодрәт иясе, Аның газабы бик тә хәтәр булачак.

**23, 24.** Хактыр ки, Без мусаны могҗизаларыбыз вә ап-ачык дәлилләр белән Фиргавенгә, Һамәнгә, Карунга күндердек. Алар:

—Бу шыр чыккан ялганчы һәм сихерче,—диделәр. **(25)** Муса Безнең тарафтан үзләренә Хакыйкатьне алып килгәч, алар:

—Аңа ияреп, иман китергәннәрнең ир угылларын нәселе белән бергә үтерегез, хатыннарын-кызларын исән калдырыгыз,—диделәр. Әмма кяферләрнең тозагы гамәлгә ашмады.

**26.** Фиргавен:

—Үз ихтыярыма калдырыгыз, Мусаны мин үтерәчәкмен. Котыласы килсә, Аллаһсына ялварсын. Чөнки мин аның динебезне үзгәртүеннән һәм Җир йөзендә фетнә чыгаруыннан куркамын,—диде.

**27.** Муса:

—Мин Хисап көненә инанмаган һәр тәкәббер кешедән сезнең дә, минем дә Раббым булган Аллаһка аркаланам,—диде.

**28.** Фиргавеннең якыннарыннан булып та яшерен рәвештә иман китергән бер адәм болай диде:

—Сез бу адәмне: Раббым—Аллаһтыр, дигәне өчен генә үтермәкче буласызмы? Гәрчә, ул сезгә Раббыгыздан ап-ачык дәлилле могҗизалар китерсә дәме? Әгәр дә ул ялганлый икән, ялганы үз башына булсын. Әгәр дә ул дөресен сөйли икән, ул газапларның берәрсе килеп, сезне тотачак бит. Шик юк ки, Аллаһ хәттин ашкан ялганчыларны тугры юлга ирештермәс. **(29)** Әй, кавемем, бүген бу җирдә *(Мысырда)* сез—хаким. Һәм хөкем чыгару—сезнең кулда. Әмма Аллаһның җәзасы безгә бер китереп орыр, шул чагында безгә кем ярдәм итәр икән?

Фиргавен әйтте:

—Мин сезгә үз карашымны сөйләдем вә янә сезгә тугры юл күрсәттем,—диде.

**30, 31.** Теге иманлы адәм янә болай диде:

—Әй, туганнар! Дөресен әйтим, мин сезнең өчен куркамын. Нух кавеменең, Гад, Сәмуд вә алардан соң килгәннәрнең башына төшкән афәтнең сезгә дә килүенә шик юк. Аллаһ үзенең бәндәләренә беркайчан да яманлык теләми. **(32, 33)** Әй, халкым минем, чыннан да мин сезнең өчен куркамын. Акырып-

бакырып кирергә борылып качачак Көн килүеннән куркамын. Сезне Аллаһ газабыннан коткарырлык бер генә зат та юк. Аллаһ юлдан яздырган кешене тугры юлга бастырырлык башка бер генә көч тә юк.

**34.** Хактыр ки, аннан алда Йосыф та сезгә ачык дәлилле аятьләр китергән иде. Ул алып килгән аятьләргә сез һәрвакыт шикләнеп карадыгыз. Ниһаять, ул вафат булганнан соң, сез:

—Аллаһ моннан соң пәйгамбәр күндермәс,—дидегез. Менә, Аллаһ хәттин ашкан шикләнүчеләрне шулай адаштыра.

**35.** Колларында һичбер дәлилләре булмаган көе, Аллаһның аятьләре турында низаглашалар. Аларның бу гамәле Аллаһ тарафыннан да нәфрәт илә каршыланды. Масаеп, тәкәбберләнгән һәр залимнең күнелен Аллаһ мөһерләп *(биклап)* куя.

**36.** Фиргавен әйтте:

—Әй, Һаман, мина биек манара корып куй, бәлки, мин күкләргә менә торган юлны табармын. **(37)** Мусаның Тәңресен күреп төшәрмен,—диде.—Дөресен генә әйткәндә, мин аны ялганчыдыр, дип уйлыймын.

Шулай итеп, Фиргавен кылган яман эш яхшы итеп күрсәтелде һәм ул юлдан язды. Фиргавен корган мәкерле тозак юкка чыкты.

**38.** Баягы иманлы кеше әйтте:

—Әй, кавемем, сез мина иярегез, мин сезгә тугры юлны күрсәтәчәкмен,—диде. **(39)**—Әй, халкым минем, шик юктыр ки, бу дөньядагы тормыш бик тиз узып китүче бер мажара гына. Әмма Ахирәт, чыннан да, мәңгегә кала торган йорттыр. **(40)**—Яманлык кылган кеше яманлыгына бәрабәр җәзасын алыр. Кем дә кем, хатынмы ул, ир кешеме, мөэмин булып, игелек кылса, җәннәткә керәчәк. Анда кергәннәргә хисапсыз ризык биреләчәк. **(41)** Әй, халкым! Бу нинди хәлегез? Мин сезне нәҗаткә *(котылышка)* чакырамын, сез мине утка *(җәһәннәмгә)* кыстыйсыз. **(42)** Сез мине Аллаһны танымаска үгетлисез. Мин белмәгән, мин табынырга теләмәгән нәстәләрегезне Аңа тиңләштерәсез. Мин исә сезне кодрәте белән барчасын җиңүче һәм чиксез мәрхәмәтле Аллаһның тугры юлына чакырамын. **(43)** Хакыйкать шулдыр ки, сез мине табынырга чакырган нәстәгез фани дөньяда да, Ахирәттә дә игътибарга лаек түгел. Әлбәттә, Аллаһ хозурына кайтачакбыз. Хәттин ашканнар җәһәннәмнең үз кешеләредер. **(44)** Сезгә сөйләгән бу кисәтүләремне сез озакламый исегезгә төшерәчәксез *(җәзасын күргәч, үкенәчәксез)*. Мин исә эшләремне Аллаһка багышладым. Шик юктыр ки, Аллаһ бәндәләрен бик яхшы белеп тора.

**45.** Ахырда Аллаһ Тәгалә мөшрикләр корган мәкерле тозактан аны *(иман китергән бу адәмне)* коткарып калды. Фиргавен токымын исә хәтәр җәзага тартты.

**46.** Алар иртә-кич утка атылачак. Кыямәт купкан көндә:

—Фиргавен токымына җәзаның иң хәтәрен бир,—дип әйтерләр. **(47)** Ут эчендә янганда кяферләр үзара бәхәс куптарыр. Фәкыйрь һәм хәлсез булганнары тәкәбберләренә әйтер:

—*(Дөньялыкта)* без сезгә ышанып иярдек. Хәзер ут газабының ичмасам бер өлешен генә булса да бездән үзегезгә алыгыз, зинһар,—дип ялварырлар.

**48.** Дөньяда чакта әллә кем булып, күкрәк киереп йөрүчеләр әйтер:

—Дөрес, барыбызның да шушында булырга тиешлегебез расланды. Аллаһ бәндәләренә вәгъдә иткәннәрнең барысын да бирде,—диярләр. (49) Ут эчендәгеләр җәһәннәм сакчыларына әйтер:

—Безнең өстән бер генә көнгә генә булса да бу газапларны алып торсын, дип Раббыгызга гыйбадәт кылыгыз, зинһар,—дип ялварырлар. (50) Зобанилар әйтер:

—Сезгә пәйгамбәрләрегез ачыктан-ачык дәлилләр китердеме?—диярләр. Болары:

—Әйе, китерде,—дип әйтәчәк.

—Шулай булгач, Аллаһка ялварыгыз,—диярләр. Гәрчә кяферләрнең үкенү-ялваруы файда бирмәс.

**51.** Шик-шөбһәсез, пәйгамбәрләребезгә вә иман китергәннәргә һәм дөнья тормышында, һәм шаһитләрнең шаһитлек итәсе *(Кыямәт)* Көндә ярдәм итәрбез.

**52.** Ул Көнне залимнәрнең ярлыкау теләп ялварулары һичбер файда бирмәс. Аларга ләгънәт! Хәтәр йорт та *(җәһәннәм дә)* аларныкы булыр.

**53, 54.** Хактыр ки, Без Мусага тугры юл күрсәттек һәм гакылы башында булганнарга үгет бирүче вә тугры юл күрсәтүче Китап *(Тәурат)* ны Исраил токымына мирас иттек.

**55.** *(Рәсүлем)* хәзергә син инде *(авырлыкларга түз)* сабыр ит. Чөнки Аллаһның вәгъдәсе, һичшиксез, гамәлгә ашачак. Гөнаһларыңның ярлыкануын телә. Кич-иртә Раббыңны мактап, тәсбих тарт*(намаз укы)*.

**56.** *(Аллаһның аятьләрен ялганга чыгарырга)* кулларында ачык исбат булмаган көенчә, Аллаһ аятьләре турында алар бәхәс куптара. Шик юктыр ки, аларның күңелендә буй житмәс дәрәҗәдәге бөеклеккә омтылу, масаю һәм тәкәбберлектән башка һичнәрсә юк. Син Аллаһка аркалан. Шөбһә юк, Аллаһ—ишетеп, күреп торучы.

**57.** Әлбәттә, күкләрнең һәм Җирнең яралтылышы—кешеләрнең барлыкка килүеннән дә бөегрәк гамәлдер. Ләкин кешеләрнең күбесе бу турыда белми.

**58.** Сукыр белән күзле, иман китереп, игелек кылган кеше белән яманлык кылучылар бер булмас. Аһ, сез бу турыда уйлап та карамыйсыз.

**59.** Һичшиксез, Кыямәт көне киләчәк. Монда бернинди дә шик-шөбһә булуы мөмкин түгел. Ләкин кешеләрнең күбесе моңа ышанмый.

**60.** Раббыгыз шулай боерды ки:

—Миңа дога укыгыз, кабул итәчәкмен. Чөнки Миңа гыйбадәт кылуны ташлап, тәкәбберлеккә йөз тотканнар хурлыкка калып, җәһәннәмгә дучар булачак,—диде.

**61.** *(Инсаннар)* ял итсен, дип Аллаһ төнне, *(яктылык)* күрсеннәр дип, көнне яралтты. Шөбһәсездер ки, Аллаһ—инсаннарга карата юмартлык ияседер. Ләкин инсаннарның күбесе шөкер итми.

**62.** Бөтен нәрсәне юктан бар итүче Илаһ—ул Аллаһтыр. Аннан башка *(Илаһи кодрәткә ия һәм)* Тәңре булырдай һичберкем юк. Нишләп соң, алайса, сез Аннан йөз чөерәсез *(башка потларга табынасыз)*? **(63)** Аллаһның аятьләрен үҗәт рәвештә инкарь иткәннәр *(Хактан)* шулай читләшә.

**64.** Җирне сезнең өчен яшәү мәйданы иткән дә, Күкне дә сезнең өчен гөмбәз итеп ясаган, сезгә гүзәл рәвеш-кыяфәт биргән дә вә һәм сезне саф-пакь тәгамнәр белән ризыкландырган да—Аллаһтыр. Менә шул инде сезнең Раббыгыз. Галәмнәрнең Раббысы Аллаһ—бөекләрдән дә бөектер. **(65)** Ул мәңге тередер. Аннан башка *(Илаһи кодрәткә ия һәм)* Тәңре булырдай һичберкем юк. Шулай булгач, ихлас һәм самими кешеләр буларак, сез Аңа гыйбадәт кылыгыз. Һәртөрле мактау галәмнәрнең Раббысы Аллаһка гына махсустыр.

**66.** *(Рәсүлем)* әйт син:

—Раббымнан ап-ачык дәлилләр килгәч, Аллаһны инкарь итеп, сез табына торган *(сын)*нарга минем табынуым рөхсәт ителмәде. Галәмнәрнең Раббысына буйсынуым тәгаенләнде.

**67.** Сезне туфрактан, соңра мәнидән, аннан соң кан тамчысыннан *(яралгыдан)* яралткан, аннан соң бәби итеп *(дөньяга)* чыгарган, аннан соң сезне көчле-куәтле итеп үстергән, аннан соң картайткан да, кайсыларыгызны иртә вафат иттергән, кайсыларыгызга озын гомер биргән дә—Аллаһтыр. Бәлки, сез акылга килерсез, ә?

*(«Адәмне туфрактан халикъ кылды, соңра нәселегезне үрчетер өчен сезне бер тамчы судан, соңра ул суны оешкан кан кылды, соңра төзеп бетергәч, бала хәлегездә анагыздан тудырадыр».*
Шәех Ногмани тәфсиреннән.)

*(«Ул сезне бер туфрактан, соңра бер мәнидән, соңра бер оешкан каннан, соңра бәби буларак чыгарган».*
Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

*(«Тормыш башлангычы бирә торган кеп-кечкенә тамчыдан».*
Мәүлана Али тәфсиреннән.)

*(«Создал вас из праха, потом из семени, потом из кровяного сгустка, потом младенцем вывел вас».*
Валерия Порохова тәфсиреннән.)

*(«Сезне туфрактан, соңра мәнидән, соңра кушылган-аралашкан күкәйдән яраткан».*
Али Тургут тәфсиреннән.)

*(Соңгысы мәсьәләне яхшырак ачыклый кебек. Чыннан да, хатын күкәйчеге белән ирнең күкәйчеге бергә кушылып, ана карынында яралгы барлыкка килә.)*

**68.** Ул—терелтүче дә, үтерүче дә. Ул берәр эш булуын теләсә, бары тик бер сүз әйтә:
—Бул!—ди. Һәм Ул теләгән нәрсә барлыкка килә.

**69.** Син Аллаһның аятьләре турында гаугалы рәвештә бәхәсләшкәннәрнең хәлен күрдеңме? Ничек итеп алар Хакыйкатьтән читләштерелде. **(70)** Алар Пәйгамбәребезгә иңдерелгән Китапны һәм андагы дәлилләрне ялганга чыгарырга маташты. Озакламый алар *(гөнаһлары өчен җәзаланачакларын)* аңлаячак. **(71, 72)** Муеннары тимер богаулар һәм чылбырлар белән уралган хәлдә, алар кап-кайнар суга кертеләчәк. Аннан соң аларны утка атачаклар. **(73, 74)** Аннан соң алардан:
—Аллаһны инкарь итеп, сез табынган нәрсәләрегез кайда?—дип сорарлар. Алар исә:
—Бездән качтылар. Чынлыкта, без әүвәл һичбер нәрсәгә дә табынмый идек,—дип әйтәчәк. Аллаһ кяферләрне әнә шулай саташтырыр.

**75.** Хакыгыз булмаган көенчә, чамасын белмәстән *(байлыгыгыз белән)* мактана идегез. Хәттин ашып, тәкәбберләнеп, күкрәк киереп, рәхәт яши идегез. Бу җәзалар сезгә шуның өчен. **(76)** Сез мәңге шунда калачак җәһәннәмнең капкасыннан керегез. Хәттин ашкан тәкәбберләр керә торган ул җир бик тә хәтәрдер.

**77.** Бәс, *(Рәсүлем)* син сабыр ит. Шик юктыр ки, Аллаһның вәгъдәсе тормышка ашачак. Аларга вәгъдә иткән җәзаларыбызның бер өлешен сиңа күрсәтербез яки сине алданрак вафат иттерербез. Һәрхәлдә алар Безнең хозурыбызга түнәчәк.

**78.** Хактыр ки, синнән алда да пәйгамбәрләр күндердек. Кайберләре турында сиңа сөйләгәнем дә бар, кайберләре турында берни дә сөйләмәдем. Һичбер пәйгамбәр Аллаһның рөхсәтеннән башка бер генә аять тә үзеннән китерә алмас. Аллаһның әмере килгәч, дөреслек урнашыр. Яман саналганнар җәзага тартылыр.

**79.** Аллаһ сезнең кулланышыгыз өчен хайваннар яратты. Кайсысына атланып йөрегез. Кайсыларын чалып ашагыз. **(80)** Ул мал-туарларда сезнең өчен күп файдалар бар. Теләгәнегезне майтарыр өчен, сез аларга атланып дөнья гизегез. Алар ярдәмендә һәм дә көймәләргә утырып, йөкләр төяп, гамәл кылырсыз.

**81.** Аллаһ сезгә үзенең аятьләрен күрсәтә. Хәзер инде шул аятьләрнең кайсысын сез инкарь итәрсез икән?

**82.** Алар *(кяферләр вә мөшрикләр)* Җир йөзендә сәяхәт итеп тә, үзләреннән әүвәл яшәп киткән гөнаһлы токымнарның ничек итеп һәлак булганнарын күрмәделәрмени? Әүвәлгеләре боларыннан күпкә ишле иде. Дөньядагы корылмакальгалары мәсьәләсендә дә алар күпкә өстен һәм куәтле иде. Ләкин аларның бу җыйган маллары *(җәза килгәч)* чынлыкта аларга файда китермәде.

**83.** *(Үз араларыннан чыккан)* пәйгамбәрләре аларга ап-ачык дәлилләр китергәч, алар үзләренең белемле булуы белән масайдылар һәм аятьләрне мыскыл итеп көлделәр. Алар мыскыл иткән нәрсәләр *(җәза булып)* үз башларына төште. **(84)** Минем тарафтан үзләренә бик тә хәтәр җәза килгәч:
—Аллаһка инандык вә Ана тиңләштергәннәребезне инкарь иттек,—диделәр. **(85)** Газабыбызны күргәч кенә иман китерүләре аларга файда бирмәде. Аллаһның колларына карата куллана торган *(җәза)* ысулы шулдыр. Кяферләр югалтуга дучар иде.

# *Әхмәт Фәйзинең тууына 100 ел*

*XX гасыр татар әдәбиятының иң күренекле вәкилләреннән берсе булган Әхмәт Фәйзи сугышка кадәрге чорда ук үзен матур әдәбиятның төрле жанрларында актив эшләүче купкырлы талант иясе итеп таныта. Ә. Фәйзинең иҗат уңышлары беренче нәүбәттә шигърият белән бәйле. Аның поэзиясе башта ук заман сулышын тирән тойган, социаль яңгырашлы иҗат булып формалаша. Күп санлы шигырьләрдә һәм «Өермәләр» (1925), «Флейталар» (1933), «Дала һәм кеше» (1933), «Туу сулышы» (1943) кебек поэмаларда бу бигрәк тә ачык күренә.*

*Әхмәт Фәйзи—байтак сәхнә әсәрләре авторы да. 1939 елны татар дәүләт опера һәм балет театры үзенең беренче сезонын Н. Җиһановның Ә. Фәйзи либреттосына язылган «Качкын» операсы белән башлап җибәрә. Шагыйрьнең тагын бүтән уңышлы либреттолары да бар.*

*Ә. Фәйзинең сугыштан соңгы иҗатында «Тукай» романы үзенә аерым урын били. Халкыбызның сөекле шагыйре образын милләт тормышы белән тыгыз бәйләп, олы тарихи вакыйгалар фонында тасвирлаган бу романы өчен Ә. Фәйзи 1958 елда, язучылардан беренче буларак, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән бүләкләнде.*

*Ә. Фәйзи—әдәбият белеме, әдәби тәнкыйть һәм публицистика өлкәсендә дә бай мирас калдырган әдип. Аның иҗатында шулай ук юмор-сатира да зур урын били. Ә. Фәйзи рус авторларының күп кенә проза һәм поэзия әсәрләрен татарчага тәрҗемә дә итте.*

*Түбәндә без бу күпкырлы талант иясенең шигъри әсәрләреннән берничә үрнәк тәкъдим итәбез.*

## Əxmət Fəyzi

**TƏRLE YILLARDAN ŞİĞERLƏR**

### Umırzaya

*Qız cırı*

Boz qatlawı eregəç, cir østenə
Umırzaya çığa, qarağız:
    Umırzaya çığa,
    Umırzaya qalqa,
    Umırzaya suza sabağın.

Boz qatlawı kebek kənküreştən
Çığasım la kilə tizrək,
    Umırzaya kebek,
    Umırzaya kebek,
    Umırzaya kebek tiz ürləp...

Umırzaya bik tiz üsep çığa,
Bik az ğına yəşi turayıp,
    Umırzaya bik tiz
    Başın asqa iə,
    Umırzaya sula moŋayıp...

Yuq, min yəşər idem ozaq, ozaq.
Minem kilmi alay bulasım:
Umırzaya kebek,
Umırzaya kebek,
Umırzaya kebek sulasım...

Yuq, min yəşər idem cəy yasawçı
Zur çəçəklər belən cıyılıp,
Yuq, min ülməs idem
Umırzaya kebek,
Umırzaya kebek boyığıp...

*1933*

*

Almağaçlarnın yaqtı qızıllığı
Yəzlərendə sinen çağıla tesle,
Əllə alma sinen yəzen tesle,
Əllə yəzen sinen alma tesle.

Ber qarasan, küzen qara tesle,
Ber qarasan, üze qonğırt tesle,
Əllə şomırt sinen küzen tesle,
Əllə küzen sinen şomırt tesle.

Tiər-timəs açıq irennəren,
Alar bersen-berse səyə tesle,
Əllə çiə sinen irenen tesle,
Əllə irenen sinen çiə tesle.

Sin torasın qarap küzlərəmə,
«Min bit sinen cırın!» digən tesle,
Belmim, belmim, qızıy, axrısı min,
Axrısı min sine səyəm tesle.

*1937*

## Aç tərəzən

*F. Kərim istəlegenə*

Aç tərəzən yazğı kükrəwlərgə,
Yanğır tamsın, gəllər çılansın.
Min qaytırmın yazğı kükrəw belən,
Sin sağınıp qarşı çığarsın.

Yazğı kükrəw ütər tərəzənnən,
Min qaytalmam bəlki... Şulay da
Yəş arqılı, irkəm, yılmayırsın
Həm yurarsın monı unayğa.

Bəlki yıraq Karpat itəgendə
Min yığılırmın sulışım kiselep,
Tik şulay da sinen yanına qaytır
Dan qazanğan minem isemem.

Minem isemem qaytır sinen yanına
Cinü kəne belən berkənne—
Qabınıp süngən yıraq yəşennən son
Sonğa qalğan kükrəw şikelle.

*1945*

## Ğabdulla Tuqayğa

Belmim, qaysı tawlar
kükrəgennən
Həykəlennen taşı, timere,—
Tik sin üzen xalıq
yərəgennən,
Xalıq məxəbbəte—sinen
isemen,
Xalıq ğəmere—sinen
ğəmeren!

*1958*

Yubileylar
Юбилейлар

# ОСТАЛАРНЫҢ ОСТАЗЫ

## МӨХӘРРИР-ГАЛИМ һӘМ ТӘРЖЕМӘЧЕ РӘИС ДАУТОВКА 75 ЯШЬ

Рәис Нәүширван улы Даутов кырык ел гомерен Татарстан китап нәшриятына - татар телендәге язма мирасыбызны барлау һәм дөньяга чыгаруга багышлаган олуг шәхесләребезнең берсе. Әгәр ул елына ун-унбиш китапка «җан өреп», басмага әзерләгәндер дип уйласак та, аның каләме аша татар укучысы кулына җәмгысы биш йөзләп рухи хәзинә барып ирешкән, дип әйтә алабыз. Ә инде аның гадәти мөхәррир генә түгеллеген, әдәбият фәне өлкәсендә рәсми дәрәҗә алган галимнәргә дә тиң мөхәррир-текстолог булуын да истә тотсак—бүгенге көндә аның дәрәҗәсендәге башка белгечләрнең калмавын танырга мәҗбүр булачакбыз. Борынгы әдәби ядкярләрдән Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ын, Утыз Имәни, Габделҗәббар Кандалый, Заһир Бигиев, Акмулла, Дәрдмәнд әсәрләре җыелмаларын, Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал, Галимҗан Ибраһимов һ. б. классикларыбызның күптомлыкларын басмага әзерләү Р. Даутовның турыдан-туры катнашы һәм практик ярдәмендә башкарылды.

Татарстан китап нәшриятында алтмышынчы еллар урталарыннан бирле борынгы әдәби мирасны белүче һәм аны заман укучысы аңларлык дәрәҗәдә редакцияләүче белгеч Рәис Даутов кына иде дисәк, һич тә хата булмастыр, мөгаен. Әйтик, хәзерге заман әдип-классиклары әсәрләрен китап рәвешенә китереп бастыру мөхәррирдән әлләни зур әзерлек таләп тә итми кебек. Аны бераз «каләм тоткан» һәркем башкара ала. Ә менә төрле чор, төрле гасырларда иҗат иткән шәхесләребезнең мирасын бүгенге көн югарылыгыннан торып бастырып чыгару өчен мөхәррирдән зур osталык һәм югары гыйльми җитлеккәнлек сорала. Әйе, андый китапларның кульязмасын әзерләгәндә, нәшрият мөхәррире әдәбият галиме дә булырга тиеш. Егерменче гасырның икенче яртысында Татарстан китап нәшриятында Рәис Даутов шундый осталыкка ирешкән мөхәррир иде. Хәзерге көндә ана тиң әзерлекле мөхәррирләргә барлык нәшриятлар да зур мохтаҗлык кичерә, минемчә.

Соңгы алтмыш-җитмеш еллык дәвердә татар халкының милли йөзен, телен саклап калуда Татарстан китап нәшриятының тоткан урыны бәяләп бетермәслек дәрәҗәдә зур булды. Чөнки ул татарның бердәнбер үз, дәүләти нәшрияты иде. Анда әлифбадан башлап, барлык төр милли дәреслекләр, борынгы һәм бүгенге әдәби җәүһәрләр, ара-тирә генә булса да иҗтимагый-сәяси яки тарихи эчтәлекле китаплар нәшер ителде. Ул елларда китапларның тиражлары да унар-йөзәр мең данә исәпләнер иде. (Хәзерге көндә иң үтемле дип саналган китапның да тиражы өч-дүрт мең данәдән артмый.) Халыкның рухи тормышын тулаем канәгатьләндереп бетермәсә дә (дини эчтәлекле хезмәтләрне басарга рөхсәт ителмәгән заман иде), зур күләмдә басылулары сәбәпле, ул китаплар һәр йортка барып җитәр, туган телебезне онытмаунын бер чарасы булып торыр иде.

Рәис Даутовның мөхәррирлек эшчәнлеге нәкъ менә шушы милли үзаң үсеше елларына туры килде. Татарстан китап нәшриятында ул 1953 елның февраленнән эшли башлый. Шәхес культына бәйле рәвештә барлыкка китерелгән сәяси торгынлыкның әкренләп чигенә башлаган чоры. Совет чынбарлыгын

танымаган кайбер «буржуаз» яки репрессияләр корбаны булган әдип вә зыялы җәмәгать эшлеклеләреннән Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Дәрдмәнд, Шакир Мөхәммәдев, Шамил Усманов, Газиз Гобәйдуллин кебек шәхесләрнең иҗатлары туган халкына кабат кайтарыла башлаган дәвер иде ул. Илленче-алтмышынчы елларда аларның бер-бер артлы сайланма әсәрләре, аерым томнары нәшер ителә башлады. Шул эшкә югары белемле яшь мөхәррирләр тартылды.

Рәис Даутов та шул беренче карлыгачларны чыгаруга җиң сызганып керешә. Хәтта берара, редакция мөдире буларак, дистә еллар дәвамында онытылыбрак торган олуг мирасны кабат халкына кайтару эшендә аңа башлап йөрү бурычы да йөкләнә.

Шул ук елларда аның тәүге үз хезмәтләре—әдәби тәрҗемәләре күренә башлый. Дөнья һәм рус классик әдипләре әсәрләреннән М. Твен, Ф. Купер, Ф. Достоевский романнары, Э. Хемингуэй, О. Генри, А. Куприн һ. б. хикәя, повестьлары татар укучысына аның тәрҗемәсендә барып ирештеләр. Шәхес культы чоры корбаны булган Мәхмүт Галәү-Мәрҗанинең «Мөһаҗирләр» романына яңа сулыш өрүче дә Рәис Даутов булды. Патша Россиясе хакимиятенең сәяси кысу-ызәрләкләүләренә түзмичә чит илгә чыгып китәргә мәҗбүр ителгән татар гаиләләре язмышын тасвирлаучы бу житди әсәрнең татарча варианты да авторы белән бергә «кулга алынган», юкка чыккан иде. Аның сакланып калган русча нөсхәсеннән Рәис «яңа роман» язарга тиеш була. Шул хезмәткә тотынып алдыннан аңа М. Галәүнең барлык иҗатын барларга, үз күңеле аша уздырырга туры килә.



*Рәис Даутов гаилә әгъзалары арасында. Беренче рәттә, уртада—хатыны Диләрә ханым кызы Фәридә белән, сулда—Сәлимә ханым, уңда—Әнәс Камал; икенче рәттә, уңда—Рәис Даутов, сулда—Диләрә ханымның энесе Фидакарь. 1959 ел.*

Тәржемә өлкәсендә Рәис Даутов бик күп каләмдәшләренә үрнәк һәм остаз була алды. Татар теле һәм әдәбияты тарихын тирәнтен белү, яшьли татарның зыялы катламы белән якыннан аралашу аның оста тәржемәче булып танылуының төп нигезләредер, мөгаен. Форсаттан файдаланып кына булса да әйтеп үтик—ул мәшһүр драматург һәм танылган артистлар династиясе саналган Камаллар гаиләсе даирәсенә кергән бәхетле затларның берсе. Шул татар зыялыларының ишле гаилә вәкиле булган драматург Әнәс Галиәсгар улы Камалның кияве. Хәер, Рәиснең үз нәселен дә зыясызлардан дип булмый. Атасы Нәүширванның гарәп язуындагы әдәбиятны яхшы үзләштергән булуы мәгълүм.

Әйе, Рәис Даутовның тәржемә өлкәсендәге эшчәнлеге, чыннан да үрнәк булырлык. Әдәби тәнкыйтьтә тәржемәченең хезмәтләре уңай бәяләнде. Аның тәржемәсендә дөнья күргән китаплардан аеруча Достоевскийның «Җинаять һәм җәза», Купринның «Атышу», «Гранат кашлы беләзек», Куперның «Соңгы могикан»ы турында Афзал Шамов, Кыям Миңлебаев, Таһир Нурмөхәммәтев, Равил Фәйзуллин, Наис Гамбәров һ. б. тарафыннан байтак җылы сүзләр язылды.

Рәис каләмдәшнең тагын бер эшчәнлеген аерым билгеләп үтү кирәктер. Татар әдәбиятын пропагандалауга ул мөһим бурыч дип карый. Көндәлек татар матбугатында, еллык календарьлар битләрендә төрки-татар әдипләренә, аларның аерым әсәрләренә багышланган күпсанлы мәкаләләре басыла. 1986 елда аның Совет чоры татар язучыларының тормыш-көнкүрешенә һәм иҗатларын барлауга багышланган зур күләмле биобиблиографик хезмәте дөнья күргән иде. Ул хәзер язучыларның, гомумән, әдәбият белән кызыксынучы голяменең өстәл китабына әверелде. Былтыр гына «Мәгариф» нәшрияты Р. Даутовның «Балачак әдипләре»

исемле җыентыгын бастырып чыгарды. Китап эчтәлеге, сурәтләү теле җәһәтеннән дә, техник эшләнеше ягыннан да бик зәвыклы, затлы кимәлдә башкарылган. Җыентыкка бүгенге көндә актив иҗат итүче утызлап күренекле язучыга караган биобиблиографик белешмә кергән.

Рәис Даутовның иҗади эзләнүләренең тагын бер юнәлеше—төрки-татар дөньясына караган борынгы язмаларны һәм белешмәлекләрне туплау, өйрәнү. Тикмәгә генә шәкертләре аны «рәсми дәрәҗә алмаган академигыбыз» дип атап йөртмиләрдер. Татар шигърияте антологиясен төзүгә керешелгән илленче еллардан бирле ул элекке гасырларда иҗат иткән шагыйрь, әдипләребез мирасын туплауга җитди игътибар бирә. Антологияләргә кермәгән яисә ул тупламаларда иҗатлары тулаем чагылыш тапмаган (антология булгач, анда сайланма әсәрләр генә урын ала ич) күп кенә авторларның мирас хәзинәсе Рәис Даутовның китап киштәләрендә нәшер ителү чиратын көтеп яталар. Аның тарафыннан кат-кат эшкәртелеп, нәшер ителгән хәзинәләр исәбенә мәшһүр әдип Заһир Бигиевнең «Зур гөнаһлар» исеме белән чыккан җыентыгын атарга кирәктер. Ул китапка ике роман һәм бер юлъязманың бүгенге укучыга авыр аңлаешлы төп нөсхәләре дә, авторына багышлы күләмле биографик очерк һәм төзүче-тәрҗемәченең бай мәгълүматлы искәрмәләре дә урнаштырылган. Мәгълүм ки, Заһир Бигиев татар дөньясында беренче романнар иҗат иткән шәхес. «Мавәраэннәһердә сәяхәт» исемле күләмле юлъязмасы да бай, тирән эчтәлекле җитди әсәр. Ана Фатих Әмирхан да үз вакытында «хәзергә кадәр татар әдәбиятында тиңе булмаган әсәр» дип бәя бирә. Китапка кергән әсәрләрнең барысы да XIX гасырның икенче яртысында иҗат ителгән.

Язучы, журналист һәм матбугат тарихы белгече Исмәгыйль Рәмиев мәдәният өлкәсендә зур эз калдырган вакыйгаларга һәм шәхесләргә багышлап кайчандыр кулъязма сүзлек төзегән иде. Рәис Даутов «Мәдәниятебез фидакяре» дип исемләнгән күләмле очеркында бу хакта түбәндәге сүзләрне яза: «1961 елда И. Рәми (сөргеннән)... Казанга күчеп кайта. Нәкъ шул вакытларда өлкән әдипләрдән бер төркем дуслары (Н. Исәнбәт, А. Шамов, Ә. Еники һ. б.) ана... Октябрьгә кадәрге татар әдәбияты буенча кыскача белешмәлек төзергә киңәш итәләр. Әдип илһамланып эшкә тотына һәм алтмышынчы еллар ахырларына «Әдәби сүзлек» дип аталган хезмәтен төгәлли.» Шул ук елларда И. Рәми аны китап итеп бастыру хәстәренә дә керешә, ләкин бу ниятен гамәлгә ашыра алмыйча үлеп китә. Ул кульязма хезмәт җирлегендә 2001 елда ике автор исеменнән (И. Рәми, Р. Даутов) «Әдәби сүзлек» китабы басылып чыкты. Рәис Даутов энциклопедик әһәмияткә ия ул китапны Исмәгыйль аганың башка төр кулъязмалары һәм үзенең авторлык өстәмәләре исәбенә шактый тулыландырган. Бүгенге көндә ул сүзлек-китап татар әдәбияты вә мәдәнияте тарихы белән шөгыльләнүче һәркемнең эш өстәлен бизәрлек бер зур хезмәт буларак кабул ителде.



*Язучыларның Кырымдагы Куктүбә иҗат йортында очрашу хатирәсе. Сулдан уңга: кырымтатар шагыйре Риза Халид, Равил Фәйзуллин, Рәис Даутов, кырымтатар шагыйре Сәитгомәр Әмин. 1984 ел.*

Рәис Даутовның тагын бер җитди эшчәнлеген күрсәтеп китәсе килә. 1992 елда Татар энциклопедиясе институты оештырылды. Галимҗан Ибраһимовның сигез томлык иҗат мирасын нәшер итүгә әзерләгәндә бергә эшләүләрен истә тотып, институт директоры, Татарстан Республика фәннәр академиясе президенты академик Мансур Хәсәнов, Рәис

Даутовның энциклопедик белеме һәм тәҗрибәсеннән файдалану ниятеннән чыгып, аны үзенә эшкә чакырып ала. Булачак зур күләмле энциклопедия томының беренчел нигезен тәшкил итәсе лөгатьлекне төзү бурычын йөкли. Шул рәвешле, саф татар телендә төзелгән беренче энциклопедик белешмәлек 1996 елда басылып чыга. Әлбәттә, ана кергән мәгълүматны туплашуда, элек татар телендә кулланышта булмаган йөзләгән термин-атамаларга үз телебездә тәңгәл килердәй исемнәр барлашуда байтак кына галимнәр җәлеп ителә. Мәгәр ул эшне оештырып, тәртипкә салып һәм туплап чыгаручы—шул эшкә тәгаенләнгән өлкән фәнни хезмәткәр һәм әдип-мөхәррир Рәис Даутов булуы безнең өчен мәртәбә, билгеле.

Рәис Даутовның язучылык хезмәтенә бәйле өлкәдә дә, мөхәррир буларак та шәкертләре бик күп. Аны бүген зур-зур дәрәҗәле исемнәр алган, иҗатлары бөтен халыкка билгеле булган абруйлы сүз осталары да, матбугат өлкәсендә эшләп килүче байтак кына мөхәррирләр дә остазлары дип таныйлар. Икеләнмичә әйтә алабыз—бүгенге заман татар әдәбиятының күренекле осталарының бик тә абруйлы остазы ул. Шигырь һәм хикәя осталарына тукталмастан, татар мәдәниятендә күптән үз уңышлары булган кайбер мөхәррирләрне генә атап үтәсем килә. Шул бүгенге осталарның остазы булган Рәис Даутов янәшәсендә эшләп, аннан күп нәрсәгә өйрәнгән шәхесләр. Татарстан китап нәшрияты җитәкчелеге, аеруча Гарәф Низаметдин улы Шәрәфетдинов эшләгән дәвердә алмаш әзерләүгә аеруча зур әһәмият бирде. Шул елларда Рәис ярдәмендә оста мөхәррир булып җитешкән, яхшы тәҗрибә туплап, үз сукмагына баскан кешеләрдән мәрхүм Фәез Зөлкарнәевне (соныннан ул «Татар әдәбияты тарихы» томнарын редакцияләде), Харрас Әюповны (хәзер Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире), Наис Гамбәровны («Казан утлары» журналында бүлек мөдире), Рәфикъ Юнысовны («Идел» журналының баш мөхәррир урынбасары), Равил Рахманны (хәзерге вакытта Мәскәүдә Татарстан Республикасы вәкиллегендә эшли) атап була.

Рәис Даутов белән беренче танышуым алтмышынчы елларга туры килә. Ул дәвердә яшь язучылар иҗатына багышлап ел саен бер җыентык әзерләнә иде. Шундый китапларның берсенә минем «Дәгъва» исемле озын хикәям дә тәкъдим ителде. Ул тупламаның проза өлешен Рәис Даутов редакцияләде. Якыннан танышу-аралашуларыбыз шул көннәрдән башланып китте. Хәзергәчә иҗади дустанә мөнәсәбәттә яшибез. Бернична ел дәвамында Татарстан китап нәшриятында бергә эшләдек. Бүгенге көндә дә бер арбаны бергәләшеп тартабыз: татар дөньясында беренче мәртәбә буларак, туган телебездә җирле-милли энциклопедик сүзлекне нәшер итәргә әзерләнәбез. Ул «арба»ны төпкә җигелеп тартучы, төп юнәлеш бирүчебез Рәис Даутов булса, тәртә ягаларыннан ярдәмләшеп баручылар—аның күптәнге каләмдәшләре һәм хезмәттәшләредер. Зур күләмле (йөз утыз җиде табаклы), бай мәгълүматлы татарча энциклопедия сүзлеген туплау 2002 елның декабрендә тәмамланды һәм редакцион советта расланды. Рәис Даутовның җитмеш биш яше тулган көннәрдә шундый зур күмәк хезмәтне басмаханәгә тапшыру—үзенә күрә бер юбилей бүләге булып кабул ителәчәк, әлбәттә.

**Лирон ХӘМИДУЛЛИН.**

# АЧЫЛГАН ЧӘЧӘК КЕБЕК

ЯЗУЧЫ, ТӘРҖЕМӘЧЕ САИМӘ ИБРАҺИМОВАГА 75 ЯШЬ

Саимә ханым турында язарга уйлап каләм алу белән, яшь чаклар искә төште әле. Институтта укып йөргәндә, җәйге ялга кайткач, күрше удмурт авылына концерт куярга бардык. Сәхнәсез иске клубны селкетеп, ду китереп биедек, минем гармунга кушылып, рәхәтләнеп җырладык, күңел ачтык. Мондый хәлне күрмәгән күршеләребез шаккатканнар. Без киткәч, сөйлиләр икән: «Бер тамчы көмешкә дә эчмәделәр, ә үзләре, аек килеш, җырлыйлар, бииләр!»

Моннан биш ел элек Саимә ханым безне юбилей мәҗлесенә чакырды. Киттек без кулга бокаллар тотып тостлар әйтергә әзерләнеп... Карасак: өстәлдә минераль судан гайре берни дә юк. Үзен мәй белән майларга күнеккән ашказан һаман кетә... һәм, тәмам алданганын белеп, соңыннан ризалашырга мәҗбүр була. Чәй эчәбез дә җырлыйбыз, су кабабыз да биибез. Удмуртлар кебек үзебезгә шаккатабыз: әлегә бик авыр булса да, мәй капмыйча да мәҗлестә бик күңелле икән ич!



*Сулдан уңга: С. Ибраһимова, Ф. Латыйфи, төрек драматургы, «Казан мәликәсе Сөембикә» драмасы авторы Музаффер Кайа.*

Саимә ханым әнә шулай безне чын татарча, мөселманча яшәргә өйрәтә. Бу юбилеена чакырырмы юкмы, әйтә алмыйм: мөгаен, ачы тәҗрибә алган табындашларыннан, үзләре эчемлек алып килмәгәйләре дип, шикләнер...

Дачадагы күршем буларак, тәрәзәдән күреп торам: иртән тора да урманга китеп югала, аннан әби-бабаларыбыз кулланган әллә нинди серле-могҗизалы үләннәр җыеп кайта, шулардан чәй кайната, аш пешерә, ит кулланудан тыела. Кайчандыр башын түбән иеп, кан басымыннан зарланып, авырып йөргән Саимә апабыз китте бит ачылган чәчәк кебек балкып, яшәреп... Пенсиясен картлыкта калдырып, китте үзенең яраткан эшенә -газета-журнал редакцияләренә, яңадан-яңа тәрҗемәләр иҗат итәргә! Әйе, Саимә ханым бу өлкәдә асыл профессионал, чыннан да, ул әсәрләрне тәрҗемә генә итми, иҗат итә. Аның йөрәге аша узган тәгъбирләр татарчага әверелеп, күңелгә май булып, җай булып урнаша. Антон Чехов та, Марк Твен да, Ги де Мопассан да, Агата Кристи да нәкъ безнеңчә милли сөйләшә. Татарга тылмач кирәкми диләр дә бит, кирәк шул, Рәис Даутов, Кыям Миңлебаев, Саимә Ибраһимова кебек тылмачлар бик тә кирәк татарга!

Мәгълүм бер мәзәк искә төште. Урысча белмәгән бер абзый суга бата башлый. Ул «Тону!» дип кычкырасы урынга «Ныряю!» дип кычкыра да су төбенә китә. Ә Саимә ханым Төркиянең үзенә барып Мәрмәр диңгезендә коенса да, батмаган. Бата димени!..

«Сөембикә» журналында эшли башлагач, аңа Сөембикә ханбикә темасы белән шөгыльләнергә туры килә. Эзләнә торгач, ул кызыклы табышка юлыга. Төркиядә 1968 елда төрек драматургы Музаффер ханым Кайа тарафыннан язылып, шул ук елда үзләренең милли мәгариф министрлыгы үткәргән конкурста җиңүче бүләге алган «Казан мәликәсе Сөембикә» драмасының авторы белән элемтәгә кереп, әсәрне татарчага тәрҗемә итә.

Ә Сөембикәгә шул кадәр тугрылыклы шәхесләр күп түгел. Фаҗигале язмышлы ханбикәбез турында язылган әсәрләрне җыеп-туплап китап чыгаруы - үзе генә дә олы мактауга лаеклы хезмәт! Сөембикә ханбикә хакындагы мәкаләләрне, язмаларны, аның хакында татарның олы шәхесләре әйткән фикерләрне, әдәби әсәрләрдән өзекләрне, шигъри багышламаларны, рәсем сәнгате үрнәкләрен туплаган әлеге «Сөембикә ханбикә» дигән китапны Сөембикә турындагы антология дип бәяләргә мөмкин. Саимә ханымның язган һәрбер материалында тирән фикер-хис, әллә нихәтле мәгълүмат...

Саимә ханым кебек үзең дә яшәреп, башкаларны да яшәртеп яшисе иде!..

**Илдар ЮЗЕЕВ**

# КӨНДЕЗГЕ ЙОЛДЫЗЛАР

## РӘФИКЪ ЮНЫС ШИГЫРЬЛӘРЕН УКЫГАННАН СОҢ БЕР УЙЛАНУ

Берзаман Аллаһы Тәгаләдән: «Халыклар белән идарә итә алырдай иң гадел, иң сәләтле, иң акыллы колың кайда яши?»–дип сораганнар, имеш. Бу сорауга дөнья хуҗасы, җир читендәге кыя-таулар ягына күрсәтеп, әнә шунда–кыргый таш-үлән арасында бер байның куйларын көтеп йөрүче ач-ялангач көтүче булыр ул, дигән.

Әлеге кыйссадан хисса: без һәрвакыт өстә ятканны, күз алдында ялтыраганны гына күрергә күнеккән, якында, колак төбендә яңгыраганны гына ишетергә гадәтләнгән. Күңел күзенә күзлек кидереп булмый. Анысы, бәлкем, ул кадәр үк гаеп эш тә түгелдер. Ләкин без сәнгать кешеләренә бигрәк тә язучыларыбызга килгәндә, аларның әсәрләрен укып, күреп, ишетеп мәшәкатьләнмичә генә, кемдер кайдадыр әйткән сүзләргә нигезләнеп, иҗатлары турында фикер йөртергә бәхәсләшергә, хәтта шул хезмәткә бәя куярга остардык бугай.

Ләкин... Ләкин кеше дигәнең көннәрдән бер көнне уйламаганда-көтмәгәндә җиде төн уртасында бер сәбәпсезгә сискәнеп уяна. Барысы да тәртиптә, һәр нәрсә үз урынында кебек югыйсә, кайгы-борчулары да юк сыман. Тышта да тынычлык: яңа ай калыккан, аяз күктә йолдызлар җемелдәшә... Тик нидер үзгәргән, нәрсәдер җитми, әнә шул хәл эчне пошыра, күңелне газаплый. Аһ, сәгать туктаган икән бит, ләбаса. Моңа кадәр бер өзлексез тек тә тек килеп безнең гомернең һәр секундын искәртеп барган, колак тәмам ияләшеп, аны ишетмәс булган тавыш тынып калган. Кеше шулчак сәгать чылбырына үрелә, ләкин ниндидер көч аны бер мизгелгә, фәкать бер мизгелгә туктатып кала. Әлеге көч дигәнең–Вакыт Галиҗанәбләреннең үзедер! Аның тылсымы белән күңелгә яктылык иңә, моңа кадәр башына да килмәгән уйлар уяна, гомернең–мизгел, дан-шөһрәтнең–сабын куыгы, яшәешнең–шартлы булуын тоясың. Кеше әнә шул мәлендә азга гына булса да, мәңгелек белән очрашып ала. Эх, бер янгыр яусын иде дә тәрәз төбендәге гөлләрне шул шифалы явымга куеп, үзең дә алар белән бергә айлы яңгырда коенсаң иде, еллар буе күңелдә җыелган вак уйлар, вак хыяллар юшкынынннан арынып, күңелең чистарып, рухың яңарып калса иде. Һич югы башкачарак, дөресрәк яши башласаң иде, ди. Тик... Тик сәгать тагын үз көенә текелди башлый, кешене янә дөнья мәшәкате, ваклыклар баса, гомер ияләшкән тынчу ярларына кайтып юлын дәвам итә. Әйе, барысы да үз урынына кайта, ләкин кеше күңелендә мәңгелек белән очрашу эзе бөтенләй үк юылмый, хәтердә кала. Һәркемгә килә ул мизгел, төн уртасындамы, көпә-көндезме, бер ялгызың чагындамы, шау-шулы мәҗлестәме, карап тормый, барыбер килә. Әгәр моңа кадәр килмәгән икән, димәк, кешенең ул мизгел белән очрашасы көне алда әле...

Рәфикъ Юнысның, ачык форточкадан җил белән шаярып кына кергән шаян яфрак кебек, кош теледәй календарь битендә кулга килеп эләккән исемсез шигыре дә нәкъ әнә шул мизгелне кабат яңартып, балачак, яшьлек хисләрен уятып җибәрде, күңелгә сафлык кайткандай булды.

* * *

Күпме таңны юлда каршыладым,
Күпме йөзләр үтте каршымнан.
Мин эзләдем сине еллар буе,
Син юк ахры безнең гасырда.

Киләчәктә димәк, туырсың син,
Бүтән җилләр бәрелер кыяга.
Минем кебек ялгыз булырсың син
Кеше белән тулы дөньяда.

Күзге җилләр кебек ачы сагыш
Ерак йолдызлардан эзләтер.
Очратмассың мине. Акылың инде
«Ул–галәмдә юк шул!» дип әйтер.

Син эзләрсең. Минем сурәт чагылыр
Болытлардан, зәңгәр көртләрдән.
Күрәсеңме, сиңа еллар аша
Кулларымны сузам үткәннән.

Үзем җитә алмасам да, сине
Шигырьләрем, бәлки, табар бер.
Сине сагыну тулы бу юлларга
Кайнар яшең, бәлки, тамар бер.

...Күп шигырьләр үтте минем кулдан. Болай, үзем өчен генә дә укылган, эш буенча да. Бу шигырьне укыдым да, уйга калдым: гомумән, нәрсә соң ул шигърият? Моңа мин дә, сез дә беркем дә төгәл генә җавап бирә алмастыр. Ләкин иң беренче нәүбәттә ул яшьлектер, яшьлекнең сафсадә хисләре белән бәрелгән керсез мәхәббәттер. Тикмәгә генә бер билгесез шагыйрь беренче үбешүне тасвирлап: «Мәхәббәтнең бу башыдыр, ахыры да шушыдыр»,–дип язып

калдырмагандыр. Була шундый мизгел: төн инде төн түгел, ә көн әле көн булып җитмәгән. Ул таң дип атала. Мәхәббәттә шушы мизгелнең–таңның билен тоткан шагыйрь.

Таң дигәннән, Тукай шигыренең бер җөмләсен генә алыйк: «Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата...» Галибанә!... Шәрехләп тору кирәк тә түгелдер: бу сүзләрне ишеткәндә күз алдына ниләр генә килми. Яки халык җырын искә алыйк:

Су өстендә дулкын ничек,
Безнең шундый чагыбыз...

Яшьлекнең гайрәте дә, дәрте дә, кыюлыгы да, гүзәллеге дә, шул ук вакытта су өстендә берара гына кабарып алган кыска гомерле булуы да–барысы да бар монда.

Дәрдмәнд, Такташ, Туфаннарның классик үрнәкләренә кагылып тормыйк, озакка китәр, искә беренче килгән «Кистеләр талларымны...» гына алыйк. Күпме фаҗига ишетәм мин бу сүзләрдә Мәгънә тирәнлеге, хисси куәте ягыннан урысның: «Ямщик, не гони лошадей, нам некуда спешить...» дигәннән нәрсәсе белән ким?! «Кистеләр талларымны...» Тәрҗемә итеп кара син аны башка телләргә! Булмый, чөнки анда милли хиссият, милли фикер, дөньяны татарча күрү, аңлау. Бу сүзләр бары тик татар кешесенең генә күңелен тетрәндерә ала. Әйе, «Кистеләр талларымны...»–гади генә сүзләр, югыйсә. Ләкин әйтеп кара син аны, язып кара, бер ишетүдә халыкның күңеленә кера аны уйлата, елата, яисә хыялын шаштыра торган шундый бер юл. Мондый сүзне әйтү өчен син үз халкыңның бөтен барлыгын, җанын-тәнен белергә, кайгы-шатлыгын бүлешеп, күңелендәге һәр кылын тибрәтү ешлыгын төгәл тоеп яшәргә шушы халыкның моңлы улы булырга тиешсең. Рәфикъ шигырьләрен укыганда инде күп тапкырлар баштан кичкән шушы уй кабат искә төшә Минемчә, аның һәр шигыреннән миллилек бөркелә Без, җырларлар, шигырьне ниндидер бер калып, килешле рифма, төзек ритм дип кенә кабул итәргә күнеккән. Ләкин шигырьне, нәкъ музыка кебек үк, тулаем тоярга, ми күзәнәкләренә йөрәк-багырь аша үткәреп кабул итәргә кирәк. Огинскийның «Полонез»ы, әйтик, нәрсә турында? Сүзләре юк бит югыйсә, ләкин аны тыңлаганда башка Ватан, халык, туган тел язмыш хакындагы уйлар килә.



Гәрчә аны башка милләт вәкиле иҗат иткән булса да. Р. Юныс шигыренең дә әнә шулай эчке моңын, сүзләр ярашуы, авазлар җайлашуы ярдәмендә туган көй-музыкасын тоеп уку кирәк.

Шагыйрьнең иҗаты күләме ягыннан җыйнак. Хикмәт күләмдәме? Хикмәт тирәнлектә! Сабый елмаюы, күңел байлыгы, талант дәрәҗәсе күләм белән дә, тонналар, хәтта томнар белән дә үлчәнми ул.

...Рәфикъ Юныс дигәндә минем күз алдына ярсу дәрьяның текә ярында, җилләр оясында читтәрәк үскән горур каен килә Ул башка агачлардан әллә ни аерылмый да кебек. Ләкин ул күзләребезне назлый, карашларыбызны иркәли, аның яфраклары да башкачарак, моңлырак шаулый. Хәер, аның иң зур үзенчәлеге–тамырларында. Без өстә ятканны, күзгә ташланганны гына күрергә күнеккән, дидек. Әлеге каенга әнә шул күзгә күренмәс тамырлары белән ярны ишүҗимерүдән саклап, янындагы башка агачларны яклап яшәү язган.

Әйе, яклап! Рәфикъ Юнысның әле чагыштырмача яңа гына дөнья күргән «Татарстан референдумы» дигән китабы безнең рухи тамырларыбызның берсе түгелмени?! Милләт гөленең бер уч бәрәкәтле туфрагы түгелмени?! Кызганыч, халык әлеге бу китапка тиешле бәясен бирел бетермәде кебек. Ә бит ул татар халкының асыл дәүләтчелеге–Казан ханлыгы басып алынуга 450 ел тулганда көрәшнең әле дә дәвам итүен, халык алдында тагын да катлаулырак, мәкерлерәк сынаулар торганын искәртеп дөньяга килде. Без заман биргән мөмкинлекләрдән тулысынча файдалана белдекме, җиңүләр нәрсә бирде да чигенүләргә ни сәбәп булды? Шанлы дәүләт хәрабәләрендә шытып чыккан Татарстан дигән гөлне ничек сакларга?–автор әнә шулар хакында уйлана. Документаль нигездә язылган әлеге әсәрне кат-кат уку өстәгерәкләргә дә, астагыракларга да беркайчан да артык булмас. Р. Юнысның фәнни дәрәҗәләргә торырлык төпле-нигезле шушы хезмәтне бастырып чыгаруы, «Идел» журналында төпкә җигелеп тартуы, анда татар халкы алдында торган иң мөһим мәсьәләләр буенча «түгәрәк өстәл»ләр, әңгәмәчыгышлар оештыруы, халкы язмышы өчен җан атып йөрүе аңлашыла булса кирәк. Милләт язмышы тагын кыл өстендә торган шушы катлаулы-катмарлы чорда–«илдә көрәш барган чакта өйдә ятып буламы?!» Синең ул шигырьне укысыннар дисәң, әле ул шигырьне укучыларны да саклап калырга кирәк...

Җир әйләнә тора. Җир белән бергә без дә әйләнәбез. Төннәрен асылташлардай җемелдәшкән йолдызларны кояш яктысы каплап китә. Ләкин йолдызлар югалмый. Аның нуры безгә күренмәсә җирнең башка тарафларына төшә. Шулай. Шулай булмаса, Рәфикъ мондый шигырь язмас та иде (бусы—алда искә алган шигырьдән 25 ел соң туган икән...):

Хыял түмен татып ымсынам мин,
Татлы төшләр күреп ургаләм.
Гөл-чәчәкле, нурлы бу дөньядан
Шуып үтте бары күләгәм.
Шуып үтте салкын күләгәм.

Бүләк гомер, бирдәнбер бу гомер
Башланмаган килеш—азакта.
Канда тып-тын купме гайрәт ята.
Җанда купме кайнар наз ята.
Җанда әле купме наз ята!

Тоям төптә тоныкк гөрелтеләр.
Олы язмыш мине көткәндер.
Бөредәге «мин»не уятырга
Баштан сыйпау, бәлки, җиткәндер?
Чәчтән сыйпау, бәлки, җиткәндер?

Өлгермәдем, ахры, табылып мин,
Өлгермәмен, ахры, кабынып.
Дөньягыздан, ахры, китәрмен мин
Уянмаган янар тау булып.
Янмый калган янар тау булып...

**Рөстәм АКЪЕГЕТ**

**РЕДАКЦИЯДӘН:** Каләмдәшебез Рәфикъ Юныс Арча районының Кәче авылында туа. Университетның журналистика бүлеген тәмамлый, озак еллар «Татарстан яшьләре» газетасында бүлек мөхәррире, Татарстан китап нәшриятында—редактор һәм баш мөхәррир урынбасары булып эшли. Соңгы ун елдан артык дәвердә ул—«Идел» журналында баш мөхәррирнең беренче урынбасары.

Басылып чыккан китаплары: «Вакыт чылбыры» (1982), «Җирдә яшим» (1986), «Учтагы песнәк» (1989), «Сүнгән яшен» (1991) һәм «Син һәм мин» (1993) исемендәге шигырь җыентыклары. 2000 елда аның «Татарстан референдумы» исемле публицистик-документаль чәчмә әсәре китап булып дөнья күрде.

Журнал редакциясе һәм редколлегия, шулай ук укучыларыбыз исеменнән каләмдәшебезне 60 яшьлек юбилее белән котлыйбыз, аңа яңа иҗат уңышлары теләп калабыз.

---

## ҮТКӘННЕ КИЛӘЧӘККӘ ЯЛГАУЧЫ



Язучылар арасында төрлесе бар. Хәтта тыйнак, әйтер идем, үтә тыйнаклары бар. Шундыйларның берсе Таһир Нәбиулла улы Нәбиуллин. Быел аңа 70 яшь тулды. Таһир Нәбиуллин 1933 елда Татарстанның Апас районында туган. «Тау ягы—яу ягы» дигәнне ишеткән бар. Бу төбәкнең үзенчәлекле тарихлы, катлаулы язмышлы җирләр икәнлегенә ишарә бу. Риваятьләр, тарихи хикәяләр белән сугарылган як. Таһир кечкенәдән халыкның күңел тарихын күңеленә сеңдереп үсә. Бәлки шул сәбәпледер, әдәбиятка тартыла, туып-үскән Болынбалыкчы авылы тирәсендә ул белмәгән, айкап чыкмаган урман, чокыр, сазлык, чишмәләр булдымы икән?

1957 елда Казан финанс-экономика институтын тәмамлый. Озак еллар Башкортстанда, Чиләбе өлкәсендә үз белгечлеге буенча эшли. 1969 елдан лаеклы ялга чыкканчы Түбән Кама шәһәрендә яши, «Нефтехим» берләшмәсендә эшли.

Балачактан әдәби әсәрләр иҗат итәргә омтылыш ясаган Таһир ин әлек балалар

шагыйре буларак танылa. Түбән Камада оешкан «Кама таңнары» әдәби берләшмәсенең әйдәүче көчләреннән санала.

Татар халкының тарихы бай, гыйбрәтле. Ныклабрак фикер йөртеп, хыялны, фантазияне эшкә жигеп күптән булып үткән вакыйгаларны жанландырырга, күзалларга омтыла автор. Шушы юнәлештә эзләнүләре ана уңыш китерә. «Мәржән убасы» дигән әсәре 1992 елда «Аргамак» журналында басыла. Шушы ук елны Татарстан китап нәшриятында «Урман заты» исемле фантастик повесте басылып чыга. «Кешелек һәм аның тарихы мохит белән тыгыз бәйләнештә тора. Кеше үзе тирәсендәге жан ияләренә мәрхәмәтлерәк караштa яшәсә, аның тормышы, көнкүреше һәм мохите башкачарак, яшәр өчен уңайлырак булыр иде...» ди автор. Бу инде бөек гуманист Карл Линнейлар чорыннан ук килгән гүзәл фикер. Соңгы елларда Таһир Нәбиуллин хәзерге болгавыр заманда гаилә, тормыш, бала тәрбиясе, мәхәббәт мәсьәләләренә багышланган «Гаилә» китабы (1999), чорларны колачлаган «Качкын» һәм «Гасырлар охшашлыгы» повестьларын язып, аерым китап итеп бастырып чыгарды (2001). Әсәрләрне укучылар яратып кабул иттеләр.

Таһир ага Нәбиуллин безне әле яңадан-яңа әсәрләре белән сөендерер дип ышанып калабыз.

**Факил САФИН**

## *Безнең календарь*

# Шаһиморат Зәйнинең тууына 90 ел

Шаһиморат Зәйни ( Зәйни Әхмәт улы Шаһиморатов) 1913 елның 7 мартында элекке Оренбург губернасының Бозаулык өязе (хәзерге Оренбург өлкәсе Тоцк районы) Кондызлытамак авылында мулла гаиләсендә туа. 1933 елда Ташкентта икееллык педагогия институтын һәм 1936 елда Казан театр техникумын тәмамлагач, Республика халык иҗаты йортында методист-режиссер булып эшли. Бөек Ватан сугышы башлану белән Ш. Зәйни фронтка китә. Мәскәүне, Сталинградны саклауда катнаша, совет гаскәрләренең алгы сафларында Польша, Чехословакия, Румыния, Венгрия, Австрия һәм Германия җирләренә кадәр барып җитә. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен Ш. Зәйни Кызыл Йолдыз ордены, “Батырлык өчен” медале белән бүләкләнә.

Армиядән кайткач, Ш. Зәйни җиде елга якын Халык иҗаты йортында эшли, 1956 елда инвалидлык буенча пенсиягә чыгып, гомеренең соңгы көннәренә кадәр (Ш. Зәйни 1980 елның 25 августында вафат була) фәкать иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

Шаһиморат Зәйни әдәби иҗат эшен курчак театры өчен пьесалар язудан башлый. Аның бу жанрдагы беренче әсәре–“Шүрәле” исемле өч пәрдәле драма-балладасы 1938 елда язылa һәм шул ук елда Казан дәүләт курчак театрында куела. Шуннан соң иҗат ителгән “Мәч-Мәчин” (1939), “Айтуган” (1941), “Кечкенә партизаннар” (1947), “Таң–Чулпан улы” (1956), “Бәхет кошы” (1956) пьесалары да курчак театры сәхнәләрендә күп еллар буе уңыш белән бара.

Илленче еллар ахырыннан башлап Ш. Зәйни иҗат сәләтен үзешчән сәнгать коллективлары, халык театрлары һәм профессиональ театрлар өчен әсәрләр яза башлый. “Энҗе бөртекләре” (1948), “Хәзрәт үгетләргә килә” (1955), “Тугыз гашыйк” (1957), “Хәят” (1958), “Таң җыры” (1960), “Дәһшәтле минутлар” (1961), “Йөрәк давыллары” (1962), “Уеннан уймак” (1963), “Гөмбәз асты серләре”, “Әй әшнәләр, әшнәләр” (җитмешенче еллар) Минзәлә драма театры, Татар дәүләт күчмә театры (К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма театры) сәхнәләрендә уйнала яки драматургның китапларында, күмәк җыентыкларда басылып чыга.

Ш.Зәйни татар сәхнәсе өчен башка милләт драматургларының пьесаларын тәрҗемә итүгә дә үзеннән зур өлеш керткән язучы. Ул татар теленә ике дистәдән артык сәхнә әсәре тәрҗемә итә.

Ш.Зәйни 1963 елдан Язучылар берлеге әгъзасы.

## *«Казан утлары» архивыннан*



*1969 елда Казанга мәшһүр балалар язучысы, итальянлы Джанни Родари (1920 - 1980) килгән иде. Язучылар союзында (берлегендә) ул татар язучылары белән очрашты. Бу рәсем әнә шул әңгәмә вакытында төшерелгән. Уңнан өченче, кара костюмда Джанни Родари. Биредә, хөрмәтле кунактан тыш, язучыларыбыздан Гази Кашшаф, Гариф Ахунов, Гариф Гобәй, Илдар Юзеев, Җәвад Тәрҗеманов һ. б. да күрергә мөмкин.*



*Бер төркем язучылар «Казан утлары» журналы редакциясендә (Ул вакытта редакция Бауман урамындагы Матбугат йортының икенче катында урнашкан иде). Уңнан сулга: Яхья Халитов, Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Вакыйф Нуруллин, Рабит Батулла. 1968 ел.*



*Бу фоторәсем Татарстан язучыларының VI съезды (1965 ел, январь) көннәре истәлеге. Уңнан сулга: Леонид Соболев, Сергей Михалков, Мирсәй Әмир, Сәҗидә Сөләйманова, Әхмәт Исхак.*



*Казансу буендагы «Парус» рестораны. Үткән гасырның 60-80 елларында бу йөзмә аш-су йортына казанлылар, шул исәптән журналист-язучы халкы да бик теләп йөри иде. Заманында җыйнак палубалары, дүртәр кешелек каюта сыман бүлемнәре булган бу пароход-ресторанның аскорма өлеше хәзер Казансуның Подлужное дип йөртелә торган яр буенда ташландык хәлдә ята.*

# *Берлекнең яңа әгъзалары*

## Дамир Гыйсметдин



*Дамир Минсәгыйрь улы Гыйсметдин 1949 елны Чувашстандагы Батыр районының Татар Тимәше авылында туа. 1966 елны Тойси урта мәктәбен тәмамлап, бер ел туган авылында эшли, шул ук вакытта читтән торып Чуваш авыл хуҗалыгы институтына укырга керә. Аннары язмыш аны Мәскәү якларына ташлый. Анда ул төрле төзелешләрдә эшли. Соңрак, Совет Армиясе сафларында хезмәттән соң, рухи мәркәзебез Казанга килә. Татар җиренә мәхәббәт, әдәбиятка тартылу әнә шул чорда үзен аеруча сиздерә. Дамирның беренче мәкаләләре, шигырьләре «Авангард» район газетасында, «Яшь ленинчы»да басылып чыга.*

*Казан Дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамлауга Дамир Гыйсметдинне «Чаян» журналына эшкә алалар. Шунда эшләгән ун елдан артык дәвердә Дамир үзенең сатирик каләмен чарлый, матбугатта аның татар һәм рус телендә язылган әсәрләре еш басыла. Советлар берлегенең яшь фельетончылары арасында ул иң осталар рәтенә керә. 1980 елларда Мәскәүдә чыккан җыентыкларда аның усал фельетоннары дөнья күрә, Үзәк һәм Татарстан радиолары аша юмористик хикәяләре яңгырый.*

*1986 - 1990 елларда Д. Гыйсметдин - КПССның Татарстан өлкә комитеты инструкторы, халыкара мәсьәләләр буенча консультант.*

*1990 елда Татарстан китап нәшрияты Дамир Гыйсметдиннең «Өметсез шайтан» дигән сатирик хикәяләрен туплаган беренче китабын бастырып чыгара.*

*1999 елны Дамир Гыйсметдиннең тагын бер китабы дөнья күрде. Ул «Әйтсәм әйтим» дип атала. Биредә укучы хозурына сатирик әсәрләр дә, шигырьләр дә, публицистик әсәрләр дә тәкъдим ителә.*

*Соңгы елларда Д. Гыйсметдин, хикәяләр белән бергәләттән, матур-матур җырлар иҗат итә башлый. «Гомер уза», «Күңелең сынмасын» кебек җырлары шундыйлардан.*

*Дамир язучы шөгылен, зур җәмәгатьчелек гамәлләре белән бәйләп алып бара. Ул 1990 елларда «Ватан» җәмгыятен җитәкләде, соңгы вакытта Бөтендөнья татар конгрессының ерак һәм якын чит илләрдәге милләттәшләребез белән эшләү юнәлешен әйдәп бара. Ул - «Азатлык» радиосының үз хәбәрчесе дә әле.*

*Берничә ел элек Минсәгыйрь улы Дамир Гыйсметдиновка Татарстан Президенты фәрманы белән «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.*

*2002 ел ахырында Дамир Гыйсметдин бертавыштан Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителде.*

## Рамил Чурагулов



*Рамил Мотаһар улы Чурагулов—Башкортстан Республикасының Кырмыскалы районында Иске Акташ авылында 1962 елның 16 августында туган. Иске Шәрәй мәктәбен тәмамлаганнан соң Уфа автотранспорт техникумында укый. Аннары «Башавторемонт», «Главбашавтотранс» берләшмәләрендә, Уфа торак хуҗалыгы трестында җаваплы вазифалар (инженер, өлкән инженер) башкара.*

*Башкорт дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген читтән торып тәмамлаганнан соң, Рамил Чурагулов «Амәнәт» (элекке «Пионер») журналында баш мөхәррир урынбасары, аннары татар телендә чыгучы «Тулпар» журналында әдәби хезмәткәр булып эшли. Берара «Азатлык нуры» газетасында баш мөхәррир булып эшләп ала. Бүгенге көндә «Атна» газетасында реклама бүлеге мөхәррире. Шул ук вакытта ул җырчы Идрис Кәлимуллин җитәкчелегендәге «Сәяр» эстрада театрының әдәбият бүлеге җитәкчесе.*

*Р. Чурагулов - дүрт шигырь китабы авторы. Аның беренче китабына язган кереш сүзендә халык шагыйре Әнгам Атнабаев болай яза: «Рамил холкы белән тынгысыз җанлы кеше, ә шагыйрь буларак, ярсу хисләр җырчысы. Шуның өчен ул шигырьләрен нокта куясы урынга да өндәү билгесе куеп яза. Аның бөтен нәрсәдә дә эше бар, бернәрсәгә дә битараф түгел».*

*Рамил Чурагулов киң җәмәгатьчелеккә җыр текстлары авторы буларак танылды. Аның сүзләренә композиторлар тарафыннан йөздән артык җыр язылган. Алар арасында «Әйтмә син авыр сүз!», «Моңнар кайтсын авылга», «Әй, Ходай, исәнлек бир!», «Кайгы җиле какмасын», «Туганнарның кадерен бел» кебек популяр җырлар бар.*

*Р. Чурагулов иҗаты «Шигърият остаханәсе» утырышында каралганнан соң, 2002 елның 28 ноябрендә кабул итү коллегиясе утырышында тикшерелде (Рекомендация бирүчеләр: Гөлшат Зәйнашева, Мәдәррис Әгъләмов, Зиннур Мансуров).*

*27 декабрьдә Язучылар берлеге идарәсе утырышында Р. Чурагулов Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителде.*

Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ЖУРНАЛИСТКА ҺӘР ЕЛ ХӘЛИТКЕЧ

13 гыйнварда Россия матбугатына 300 ел тулды. Татарстан Журналистлар берлегендә кабул итү булды. Анда гаммәви мәгълүмат чараларының баш мөхәррирләре, үз хәбәрчеләре чакырылган иде.

—Бүгенге тормышны газитләрдән, телевидение һәм интернеттан башка күз алдына китерергә мөмкин түгел,—диде Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, кабул итүдә чыгыш ясап.

Дәүләт Советы Рәисе Татарстан журналистларына Президент М. Шәймиев исеменнән рәхмәт сүзләрен тапшырды.

—Бүген житди эшнең яңа этабына старт бирелә,— диде үзенең чыгышында Премьер-министр урынбасары З. Вәлиева. Быел безнең республикала гаммәви мәгълүмат чараларына реформа ясауда хәлиткеч ел булачак, һәм аны гаммәви мәгълүмат чаралары елы дип тә әйтергә була.

## РОАЛЬД СӘГЪДИЕВ ЮБИЛЕЕ

16 гыйнвар көнне Кремльдә Президент Минтимер Шәймиев дөньякүләм мәшһүр физик, Татарстан Фәннәр академиясе һәм Россия Фәннәр академиясе академигы Роальд Сәгъдиев белән очрашты. Әңгәмә башында М. Шәймиев дөньядагы бик күп әйдәүче илләр академияләренең абруйлы әгъзасы һәм мәртәбәле университетларның мактаулы докторы Р. Сәгъдиевкә «Татарстанның атказанган фән эшлеклесе» исеме бирелү турындагы документны һәм күкрәк билгесен тапшырды. Очрашуда академикның хатыны, АКШның 34 нче Президенты оныгы Сьюзен Эйзенхауэр һәм башка рәсми кешеләр катнашты.

Шул ук көнне Фәннәр академиясендә Роальд Сәгъдиевкә 70 яшь тулуга багышланган фәнни сессия булды. Сессияне Татарстан Фәннәр академиясе Президенты Мансур Хәсәнов ачты һәм олуг галим турында кереш сүз сөйләде. «Академикның фәнни казанышларына Россия Президенты В. Путин һәм Татарстан Президенты М. Шәймиев котлауларында югары бәя бирелде»,—диде ул.

—Р. Сәгъдиев—илебез физика фәненең данын һәм горурлыгын тәшкил итүче галимнәрнең гүзәл плеядасы вәкиле,—диде үзенең чыгышында Премьер-министр урынбасары Зилә Вәлиева. Шактый еракта яшәвенә карамастан, ул безнең белән тыгыз элемтәдә, җаны белән Татарстанга бирелгән, барлык вакыйгаларны белеп тора.

Тантаналы сессиядә шулай ук атаклы галимнәр—Г. Месяц, В. Балебанов, А. Коновалов һ. б. катнашты һәм чыгыш ясады.

## ХАЛЫК ШАГЫЙРЕН ЗУРЛАУ

* * *

18 гыйнварда Президент Минтимер Шәймиев Кремльдәге резиденциясендә Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеевны кабул итте. Бирегә шагыйрь белән бергә Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин һәм Татарстанның халык шагыйре Шәүкәт Галиев тә килгән иде. Очрашуда шулай ук Президент аппараты җитәкчесе Әгъзам Гобәйдуллин, Премьер-министр урынбасары Зилә Вәлиева, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Роберт Миннуллин, мәдәният министры Илдус Тарханов, вакытлы матбугат һәм радио-телевидение журналистлары да чакырылган иде.

* * *

20 гыйнвар кичендә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеевка 70 яшь тулуга багышланган «Булыйк гел гашыйклар тавында» исемле әдәби-музыкаль тантана булды. Юбилей кичәсендә тәбрикләү сүзе алган Премьер-министр урынбасары Зилә Вәлиева, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Роберт Миннуллин, Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин әдипнең иҗатына сокылануларын белдерделәр, аның чын мәгънәсендә халкыбыз горурлыгы булуын искәртеп үттеләр. Шагыйрьгә бик күп иҗатташ дуслары исеменнән тәбрикләү сүзен драматург Туфан Миннуллин әйтте. Иҗади хезмәттәшлектә халкыбыз мәхәббәтен казанган җырлар язган композиторлар Мирсәет Яруллин, Ренат Еникеев, Мәсгут Имашевлар да сәхнәгә күтәрелде. Башкортстанның Янавыл районыннан да якташлары шагыйрьне күркәм бәйрәме белән котларга килгән иде.

## ХАЛЫК ЯЗУЧЫСЫН ИСКӘ АЛУ

* * *

Татарстанның халык язучысы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге һәм Россиянең М. Горький исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Аяз Гыйләҗевнең тууына 75 ел тулу уңаеннан Шәриф Камалның музей-фатирында «Йөгез, бер дога» дип аталган хатирәләр кичәсе узды.

* * *

Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының Г. Тукай музее каршында эшләп килүче «Туган тел» клубы да үзенең чираттагы утырышын әлеге истәлекле датага багышлады. А. Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән» повесте һәм әлеге әсәр буенча куелган спектакль турында сөйләшүдә драматургның сәхнә образларын иҗат иткән күренекле артистлар Ф. Хәйруллина, Р. Мотыйгуллина, Р. Шәрәфи катнашты. Әдип Аяз Гыйләҗев һәм татар әдәбиятының күренекле вәкилләре турындагы истәлекләре белән язучының уллары драматург Мансур Гыйләҗев, тарихчы Искәндәр Гыйләҗев, әдипнең җәмәгате, татар теле һәм әдәбияты укытучысы Нәкыя ханым уртаклашты.

* * *

3 февральдә Камал театрында үткән әдәби-музыкаль кичә дә халык язучысы Аяз Гыйләҗевнең якты истәлегенә багышланган иде. Кичәдә сәнгать осталары тарафыннан язучының әсәрләре яңгырады, хат-истәлекләре укылды, документаль кадрлар күрсәтелде, вокаль әсәрләр башкарылды. Камал, Тинчурин, Әлмәт, Туймазы театрлары артистлары А. Гыйләҗев пьесалары буенча куелган спектакльләрдән өзекләр күрсәттеләр. Кичәдә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, драматург Туфан Миңнуллин чыгыш ясадылар.

## ФОАТ МАНСУРОВНЫ АЛКЫШЛАУ

Мәскәүнең дәүләт Зур академия театрында танылган педагог һәм дирижер, Россия, Казакъстан һәм Татарстанның халык артисты, Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты профессор Фоат Мансуровка 75 яшь, иҗат эшчәнлегенә 55 ел тулу уңаеннан хөрмәтләү кичәсе булып узды. Иҗат гомеренең 35 елын багышлаган Зур театр сәхнәсендә «Евгений Онегин» операсы куелды, ана юбиляр үзе дирижерлык итте. Танылган шәхесне зурлауда Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев җитәкчелегендәге делегация дә катнашты.

* * *

Шулай ук Казанның Зур концерт залында Фоат Мансуровка багышланган тантаналы кичә узды. Мәгълүм булганча, атаклы дирижер Мәскәүнең Зур театрында эшләү белән бергә, Татарстанның дәүләт симфоник оркестрын да җитәкли.

Бу юбилей кичәсе аның талантына баш июче күпләрне, коллегаларын һәм дусларын, шулай ук Мәскәү, Санкт-Петербург, Алма-Ата шәһәрләреннән килгән күп санлы кунакларны җыйган иде. Юбилярны Татарстан хөкүмәте исеменнән Премьер-министр урынбасары Зилә Вәлиева котлады.

## «ҖИДЕГӘН ЧИШМӘ»ДӘ—«КАЗАН УТЛАРЫ»

Соңгы дистә елларда Түбән Камадагы милли мәдәни хәрәкәтне «Җидегән чишмә» кичәләреннән тыш күз алдына китерү кыен. Бик күп кичәләр, гадәттә, татар халкының мәшһүр шәхесләре иҗатларына багышланып үтә. Ә бу юлы «Җидегән чишмә»нең кунагы «Казан утлары» журналы булды. 25 гыйнвар көнне Түбән Каманың Техника йорты дип аталган үзәк тамаша залында шәһәр халкы журналның редколлегия әгъзалары һәм хезмәткәрләре белән очрашты. Кичәнең башында журналның баш мөхәррире, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин «Казан утлары»ның тарихы һәм бүгенгесе турында чыгыш ясады. Бәйрәм төсен алган бу кичә язучыларның һәм сәнгать осталарының чыгышлары белән үрелеп барды. Кичәдә журналда эшләүче язучылар Флүс Латыйфи, Марат Закир, Алмаз Гыймадиев, «Мәгариф» нәшрияты директоры, язучы Мөдәррис Вәлиев, Татарстан радиосының баш мөхәррире Җәүдәт Дәрзаман, Татарстанның халык рәссамы Әхсән Фәтхетдинов һ.б. чыгыш ясады.

Бу кичә-очрашуның төп оештыручылары—«Нефтехим» берләшмәсе җитәкчеләренең берсе, «Җидегән чишмә» иҗат берләшмәсе җитәкчесе Мөнәвир Галимуллин, Түбән Кама татар дәүләт театрының баш режиссеры Рөстәм Галиев.

## ТАТАР ПЕН-ҮЗӘГЕ—«МӘГАРИФ» КУНАГЫ

Татар ПЕН-үзәгенең гыйнвар аендагы утырышы былтыргы эш нәтиҗәләренә йомгак ясауга һәм быелгы бурычларны билгеләүгә багышланды. Бу юлы халыкара язучылар оешмасы әгъзалары «Мәгариф» нәшриятында очрашты—аларны татар әдәбияты үрнәкләрен инглиз телендә чыгару буенча алып барыла торган уртак эшләр дә бәйләп тора. Әлеге нәшриятта дөнья күргән «Татар әдәбияты бүген» һәм «Татар халык әкиятләре» дигән китаплар инде язучыларның Хельсинки һәм Мәскәүдә узган Бөтендөнья когрессларында таратылды, дөньяның күренекле китапханәләренә һәм университетларына җибәрелде, инглиз теле тирәнтен өйрәнелә торган вуз һәм гимназияләрнең укыту-әдәби базаларын тулыландырды.

Узган ел ахырында «Мәгариф» нәшрияты, Татар ПЕН-үзәге белән берлектә, инглиз телендә тагын бер мәҗмуга—Татарстанның халык шагыйре Шәүкәт Галиевнең «Көләч көзге» дигән китабын (рәссамы Фәридә

Хәсьянова) бастырып чыгарды.

Хәзерге көндә тагын өч басма—Р. Фәхретдиновның «Татарлар тарихы» фундаменталь фәнни-популяр хезмәте, «Татар акылы» исемле афоризмнар, әйтемнәр, әдәби миниатюралар җыентыгы һәм күренекле язучылар, галимнәр, җәмәгать эшлеклеләренең мәкаләләре тупланган «Татар юлы: халык хокукы һәм сәяси корректлылык» дигән китап нәшер ителә. Соңгы китапның исеме белән быел Казанда узачак халыкара конференциягә атау да күздә тотыла.

Утырышта Татар ПЕН-үзәге президенты Туфан Миңнуллин искәртеп узганча, безнең язучылар делегациясе Македониядә булып узган Бөтендөнья язучылар конгрессы эшендә дә актив катнашты. Мәгълүм булганча, әлеге конгресс Россия халыклары язуын унификацияләүгә каршы резолюция дә кабул иткән иде. Һәм, әйтергә кирәк, язучыларның халыкара ПЕН-клубы бу өлкәдә Татарстанны яклап чыккан бердәнбер күренекле халыкара оешма булды.

## ГАЛИМНӘРНЕҢ ЕЛ ЙОМГАГЫ

Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында 2002 елда башкарылган фәнни эшләрнең нәтиҗәләрен тикшерүгә багышланган конференция узды.

Анда татар филологиясе һәм сәнгать белеменең актуаль мәсьәләләрен эченә алган 80 доклад тыңланды. Дүрт көн буе дәвам иткән конференция өлкән галимнәрнең дә, яшьләрнең дә бүгенге авыр шартларда фәнни эшчәнлеген киметмәүләрен, ин мөһим мәсьәләләрне үзәккә куеп тикшерүләрен күрсәтте.

Пленар утырышта Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Зилә Вәлиева катнашты һәм чыгыш ясады.

## ИСКӘ АЛУ

15 гыйнварда Казан дәүләт консерваториясенә нигез салган күренекле композитор, Социалистик Хезмәт Герое Нәҗип Җиһановның туган көнендә туганнары, якыннары, иҗатын сөючеләр мәрхүмнең якты истәлегенә догалар багышлап, каберенә чәчәкләр куйдылар. Мон иясенең музей-фатирында «Җиһанов рояле янгырый» дигән музыкаль кичә үтте.

## ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ—ЯКТАШЫБЫЗ

Чуваш халык шагыйре Порфирий Афанасьев—безнең якташыбыз, Чирмешән районында туып-үскән шәхес. Күптән түгел ул 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Атаклы шагыйрьнең юбилей тантаналары, бүген үзе яши, иҗат итә торган Чабаксардан күчеп, Чирмешән җирендә дәвам итте. Шагыйрьне якташлары, авылдашлары (Порфирий Афанасьев—Яна Ильмово авылыннан) һәм Чирмешән районы хакимияте башлыгы М. Шакиров, Казаннан килгән каләмдәшләре Татарстан Язучылар берлеге рәисе, тәнкыйтьче Ф. Галимуллин, шагыйрь Р. Харис, «Сувар» чуваш газетасы баш мөхәррире А. Иванов һ. б. котладылар.

Бүгенге көндә П. Афанасьев—Чуваш республикасының Матбугат һәм Мәгълүмат министры урынбасары булып эшли.

## «ХӘТЕР ЯКТЫСЫ»

31 гыйнварда Татарстан язучыларының Габдулла Тукай исемендәге клубында күренекле балалар шагыйре А. Алиш премиясе лауреаты Хәкимҗан Халиковның туууына 70 ел тулуга багышланган «Хәтер яктысы» исемле кичә булды. Кичәдә әдипнең якыннары, каләмдәш дуслары, А. Алиш исемендәге премия лауреатлары, әдәбият, сәнгать осталары һәм аның якташлары катнашты.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Фәнни эшчәнлектәге хезмәтләре өчен филология фәннәре докторы, профессор, ТР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты баш фәнни хезмәткәре **Гарипова Фирдәвес Гариф кызы**на Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Гуманитар фәннәрне үстерүдәге казанышлары һәм матбугат өлкәсендәге нәтиҗәле хезмәте өчен «Мирас» журналы баш мөхәррире, филология фәннәре докторы **Сәхапов Миңнәхмәт Җәмил улына** «Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Казан шәһәре Урта гасырларда.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** шагыйрә Халисә Мөдәррисова.

# ЯҢА КИТАПЛАР

**Татар халык уеннары**. Төзүчесе—Рәшит Ягъфәров.—Казан: «Раннур» нәшр., 2002.—480 бит. Тиражы 5000 данә.




Фольклорчы галим һәм җәмәгать эшлеклесе Рәшит Ягъфәровның дистә елларга сузылган тикшерү-эзләнүләренең бер күркәм нәтиҗәсе бу китап. Рәшит Ягъфәров—Н. Исәнбәт, Х. Ярми, И. Надиров, Х. Гатина, Р. Исхакова-Вамба кебек фольклорчыларның эшләрен лаеклы дәвам итүче галим.

Китапка балалар һәм өлкәннәр репертуарында булган 500 дән артык уен текстлары туплап бирелгән. Алар «Хәрәкәтле уеннар», «Драма уеннары», «Зиһен сынаш уеннары», «Йола уеннары», «Күңел ачу тамашалары» кебек төркемнәргә бүлеп урнаштырылган. Кушымта рәвешендә бирелгән бүлектә «Уен җырлары. Такмаклар» ноталар белән бирелгән.

«Татар халык уеннары» китабы тәрбия, мәдәни-агарту, халык сәнгате өлкәсендә эшләүчеләр өчен файдалы әсбап булачак.

Китапның җаваплы редакторы Ранис Газизов.

**У милосердия древние корни** (Благотворительность и милосердие в Казани XVIII—нач. XX вв.) Сборник документов и материалов.—Казань: «Гасыр», 2002.—208 бит. Тиражы 500 данә.




«Гасырлар авазы» журналына кушымта рәвешендә бирелгән һәм Казанның 1000 еллыгына багышланган әлеге басма «Полиграфия-нәшрият комбинаты» дәүләт унитар предприятиесендә нәшер ителгән. Җыентыкта аерым дәүләт, иҗтимагый учреждениеләр, хосусый иганәчеләр Апанаевлар, Алафузов, Александров, Казаков, Крестовников, Юнысовлар үрнәгендә Казанда хәйриячелек тарихының төп этапларын күзаллау мөмкинлеген бирүче документлар бар. Басмага 84 архив документы кертелгән, аларның күбесе әле беренче тапкыр басыла.

Китапта кыскача исем күрсәткече, иганәчеләр акчасына төзелгән Казан мәчетләре, монастырь һәм чиркәүләр исемлекләре дә бар. Анда иганәчеләрнең фотосурәтләре, Казан шәһәренең хәйрия учреждениеләре биналары, Милли архив фондлары документлары бирелгән.

Китапны төзүчеләр—А. Дмитриева, Р. Исмәгыйлев, Н. Шарангина. Фәнни редактор—проф. Д. Шәрәфетдинов.

Индекс 73210



Х а л и с ә   М ө д ә р р и с о в а

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)